ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.1995



# Равил Фәйзуллин

## Хәтер

*Ветеран җыры*

Гомер узган саен тынмый күңел —
Үткәннәргә хәтер еш кайта.
Тыныч көндә авыр тойгы булып,
Сугыш яраларын кузгата.

Әй син, Хәтер, гомер язларыннан
Безнең яшьлекләрне чакырып ал!
Җырлыйк әле!
Безнең бу көйләрдә
Кайтмый калганнарның хакы бар!

Көрәшләргә чыктык ил чакыргач,—
Газиз башлар ниләр күрмәде!
Нинди генә суны кичмәдек тә,
Нинди генә утка кермәдек!

Әй син, Хәтер, гомер язларыннан
Безнең яшьлекләрне чакырып ал!
Җырлыйк әле!
Безнең бу көйләрдә
Кайтмый калганнарның хакы бар!

Еллар арты еллар агалар...
Тормыш үзегендә — яңалар.
Сорый Хәтер безнең үткәннәргә
Тугрылыкны саклыймы алар!

Әй син, Хәтер, гомер язларыннан
Безнең яшьлекләрне чакырып ал!
Җырлыйк әле!
Безнең бу көйләрдә
Кайтмый калганнарның хакы бар!



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**5**

**(871)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР һӘМ ШИГЪРИЯТ

Ш. ГАЛИЕВ. Минем беренче гомерем. *«Хистәлек»ләр* . . . 3
З. МАНСУРОВ. Дүнү. *Шигырьләр* . . . 69
Р. СИБАТ. Ике гашыйк һәм жыр тыңлаучы ат. *Повесть* . . . 76
К. ЛАТЫЙП. Карт солдат уйлары. *Шигырьләр* . . . 104
Әсрар ГАЛИ. Нәни хикәяләр . . . 111

ХӘТЕР

Фронтовик шагыйрьләр иҗатыннан . . 13—63
Ш. МОСТАФИН. Байракчы Гази Заһитов 115
Ә. ЕНИКИ. Фронт дәфтәреннән . . . 117
Ф. СОЛТАНБӘКОВ. Үлем сәгатен көткәндә *(М. Җәлил һәм җәлилчеләр турында истәлекләр)* . . . 131
Шагыйрьләр, фронт һәм хатлар . . . 150

СӘНГАТЬ

Р. ӘХМӘТ. Фасилнең тормыш фасыллары *(Композитор Фасил Әхмәткә — 60 яшь)* . . . 156

МӘДӘНИ МИРАС

Г. БАТТАЛ. Казан төркиләре . . . 162

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ӘХМӘТҖАН. Әдәбият — әхлак тоткасы . . . 180

Котлыйбыз! . . . 184
Безнең календарь . . . 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 188

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнен адрес 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр*

шигърият, фән, хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повесть-воспоминание Ш. Галиева «Моя первая жизнь», повесть Р. СИБАТА «Два влюбленных и лошадь, которая слушала песню»; рассказы Асрара ГАЛИЕВА; стихи З. МАНСУРОВА, К. ЛАТЫЙПА.
«Память»: стихотворение из творчества поэтов-фронтовиков; статья Ш. МУСТАФИНА «Знаменоносец Г. Загитов»; записи из фронтового дневника А. ЕНИКИ; статья Ф. СУЛТАНБЕКОВА «В ожидании смертного часа»; «Поэты, фронт и письма».
«Искусство»: статья Р. АХМЕТА посвящена к 60-летию композитора Ф. Ахмета.
«Культурное наследие»: статья Г. БАТТАЛА «Казанские тюрки».
«Книжное обозрение»: М. АХМЕТЗЯНОВ рецензирует сборник «Серебряный браслет».
В номере отмечается 60-летие В. Нуруллина.
«Наш календарь».
«На наших обложках»: «Клятва хана» — картина художника К. Нафикова; писатель-фронтовик С. Сабиров.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: Sh. Galiev's narrative and recollection «My first life»; R. Sibat's narrative «Two lovers and the horse who listened to the song»; Asrar Galiev's stories; the verses of Z. Mansurov, K. Latipov.
«Memory»: the verses of poets. Front-line soldiers. Sh. Mustaphin's article «Standard-bearer G. Zagitov», A. Eniki's recod's from the front diary; Ph. Sultanbekov's article «Pending the death-hour»; poets, front, and the letters.
«Art»: R. Akhmet's article devoted to the 60 anniversary of composer Ph. Akhmet.
«Literary Heritage»: G. Battal's article «Kazan turki».
«Book Review»: M. Akhmetzyanov reviews the collection «Silver bracelet».
The 60 anniversary of V. Nurullin is celebrated.
«Our calendar»
In our corvers: K. Naphikov's picture «Khan's Oath», the writer, front-line soldier S. Sabirov.

---

- Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
- Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
- Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»нннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

---

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 28.03.95 ел. Басарга кул куелды 11.05.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 945. Заказ Д-173.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.



## Шәүкәт Галиев

# МИНЕМ БЕРЕНЧЕ ГОМЕРЕМ

«ХИСТӘЛЕК»ЛӘР

### АВТОРДАН

Ел саен, сугыш башланган төндә һәм Җиңү таңында борчылып уянам: кем алдындадыр, ни өчендер җаваплы, бурычлы сыман...

Һәлак булганнар алдында, алар турында әйтелмәгән сүзләр өчендер. Сугышка — үлемгә барганда уй-тойгыларын күз яше итеп йотканнарга сүз бирелсә, үзләре ни әйтер иде? Юк шул андый могҗиза. Ә исәннәрдә бар ул! Күргән елларым, белгән кешеләрем хәтерс йоклатмый мине. Киселгән тыннары, бүленгән уйлары йоклатмый, әйтелмәгән васыятьләре йоклатмый...

Бу дөньяда ике гомер яшәдем кебек. Беренчесе — сугыш алды еллары. Ул гомердә дөньям тигез-имин, туганнарым сау, авылдашлар гөрләшеп яши. Тик ул көннәрнең якты тасмасы кинәт өзелгән кинодай өнсез-авазсыз караңгыда калган, бик күп гомерләрне сугыш сүндергән. Ул тормыш кинотасмасын терелтүне мәрхүмнәр миннән көтәдер кебек. Ярты гасыр буе яратуым, өзелеп сагынуым, юксыну-үкенү әфсене белән күңелдә җанландыра торам — мин барында алар да бар. Үзем белән китәсе шул кадерле җаннар турында уйлыйм. Иң соңгы, иң хәтәр үлемнән — онытылудан коткарасы иде аларны. Үлү — онытылу түгел, онытылу — үлү...

Әбиләрнең: «Сурәт ясама, үлгәч җан сорар»,— дигәнен хәтерлим. Хәлемнән килсә, сүздән сурәт ясап, җан өрер идем сугыш шәһитләренә... Сугыштан соңгы — иҗаттагы икенче гомерем өчен бурычлы мин аларга. Барыбыз да бурычлы.

Бу әсәрдә — сугыш чоры михнәт-газапларын кичергән буын язмышы да бар... Әдәбиятта канатлы гыйбарә йөри: Гоголь «шинеле»ннән чык-

---

Шәүкәт ГАЛИЕВ (1928) — *олылар һәм балалар өчен күпсанлы лирик, юмористик шигырь һәм проза китаплары авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Г.-Х. Андерсен исемендәге халыкара диплом иясе. Казанда яши.*

Журнал варианты.

канбыз, диләр. Безнең буын Бөек Ватан сугышының утта көйгән, пулялар тишкән шинеленнән чыкты. Әтисез кайткан шинельләрдән...

...Ел саен сугыш башланган төндә, Җиңү таңында йокым кача: беренче гомеремнән әле генә уяндым кебек. Әмма ул төш түгел — илле ел буе сагышны уяу иткән өн...

Һәркемнең үз гомере, үз кичерешләре: заманнар уртак булса да, кичерешләре аерым, һәркайсыбызның үз хатирәсе кадерле. Тәүгеләре бигрәк тә: шулардан хәтерең башлана... Күңелгә сыенып калган, сине ташламаган тугрылыклы тойгылар ул: саф чишмә төбендәге якты ташлар сыман... Эчтән йоткан яшьләр — «күңел яшьләре» белән юылган ихлас кичерешләр. Истән бигрәк, хисеңдә укмашып калган узган гомерең ул — «хистәлекләр».

## Алтын яфрак

Танылган рәссам, көмешче ювелир үз остаханәсенә чакырып йөри иде, ниһаять, җае чыкты. Күрер, сокланыр нәрсәләр хәйран күп икән. Музей сыман — үз әсәрләре белән бергә, чын-чынлап «хан заманы»ннан калган көнкүреш җиһазлары — сәнгать үрнәкләре: беләзек, чулпы, хәситә, күкрәкчәләрдән алып, төрле килбәтле комган, самавырлар киштәләргә тезелеп, бауда асылынып, чөйләрдә эленеп тора. Шәмаилнең дә төрлесе, Тукайның «Туган тел» шигыре язылганы да бар...

Сәндерәләр түшәмгә чаклы тулган. Балачагым хатирәләрен таныйм — Питербурдан бабай алып кайткан сәгать, җиз кыңгыраулар күңелдә чыңлап ала... Йотылып карап йөрим, хуҗа мавыгып китүемне күрә — әле бер, әле икенче зиннәтле табышка ишарәли. Рәссамның үз эшләрен, сызма-эскизларын җентекләп карыйм: талпынып та оча алмый калган рәссам илһамы уяна... Алтынчы дистәне тутырганда ис китәр нәрсәләр сирәк очраучан. Остаханәдә мин җан рәхәте кичердем. Гади вә гали затлы ядкарьләр, милләтнең рухи байлыгы иде монда — көмешченең әтисе, бабасы кулыннан үткәннәре дә бар. Татар баласына сабый чактан газиз нәрсәләр...

Онытылып тамаша кылуым — соклану дигән бәһа рәссам күңеленә хуш килде. «Иң кызыгы — бусы!» — дигәндәй, хәйләкәр елмаеп, һавага нидер чөйде дә «өф» итеп өреп җибәрде. Җиңел, юка иде әлеге хикмәт — саргылт нурдай һавада тирбәлә... Кулымны суздым — көзге яфрактай учка кунды, тын алганда мена-менә очып китәр шикелле...

— Беләсеңме бу нәрсә? — ди оста. Мәгънәле генә тынып тора да:

— Сусальное золото! — дип куя.

— Алтын яфрак, — дим мин дә юри, гадәти нәрсәдәй. — Сабый чакта мин моны шактый йоттым. Тәтәй Питербурдан алып кайта иде...

— И-и, бик файдалы ул! — дип сөйли көмешче һәм хасиятләрен санап китә.

— Файдасы тигәндер инде безгә дә... — дигән булам тыйнак кына. Остаханәдә иң зур тәэсир алганым шул иде. Тәтәй алтын яфрак биргән кояшлы иртәләрне хәтерлим. Күңеле булсын дип кенә йота идем, алтынның бер тәме дә юк — исегез китмәсен! Гомергә кызыкмадым, «сары шайтан» коткысына бирелмәдем. Әмма бу яфрак бала чагым агачыннан — Латифа тәтәй хатирәсе бит! Якыннарымның миһербанлы карашы, мәрхәмәтле куллары алтын яфрактай йомшак, җиңел иде. Алар «йоттырган» — йотылып тыңлаган әкият, бәет, җыр-мөнәҗәт, кыйссалар икән иң файдалысы. Рәссам иҗатында ул алтын яфрак күзгә күренеп, балкып торса, без язганнарны эчтән яктыртадыр...

Алтын яфрак... Татар өстеннән узган зилзиләләрдә шәҗәрәләр урманыннан коелмыйча чак эләгеп калган алтын яфраклар... Көмешче

картның улы — мәшһүр рәссам, инде янәшәдә үз баласы эшли — нәсел дәвам итә, һөнәр-тәҗрибә өзелми.

Күзләрендә табигать тә, алтыннарын җилфердәтеп, сабыйларда иҗат дәрте кузгата, мине алар илһам бөреләнгән чагыма чакырып кул изи. Туган телемнең алтын яфраклары, туган авылымның алтын кешеләре... Кала башмакларын салып, такыр сукмаклардан кайтам. Яланаяк йөрү файдалы, ди галимнәр, чыклы үләннәр чыныктыра, ди. Иллә дә гыйлем булганбыз нарасыйлар — гел яланаяк сыпырта идек! Чык агарткан тыкрыкта яшел эз калдырып чабар идек — бар ашкыну, бар омтылу — киләчәккә! Гомерләр үткәч, төшендем: иң кызыгы үткәннәрдә — бала чакта икән... Алга барыр юлы кыскарган саен борылып карыймы адәм баласы, гомер юлларын озайту әмәлен эзлиме? Алтын яфраклы балачакның иртәнге чыклары — асыл ташлар ул, аякларга чеби чыгып елатканчы, татлы әрнүләрне кабат кичергәнче барыйк әле...

## Балачак әтәчләре чакыра

Күнелгә хуш килгән, җанны тынычлыкка көйләгән авазларның берсе — әтәч тавышы. Балачакның кояшлы, имин иртәсендә, тавыклар коенган нигез туфрагына, чирәмле ишегалдына кайтара ул.

Яңа чабылган печәнле арбага утыртып, әткәй мине дә Кайбыч ярминкәсенә алып барды. Ниләр генә истә калган соң? Аллы-гөлле бизәкле курай! Ат кыяфәтендәге буяулы сыбызгы да алдык. Бик арыдым, иртә кузгалдык бит, кайтканда йокыга оеп киткәнмен. Әтәч тавышына уяндым. Күземне ачканда ук беләм: нинди дер шатлыгым бар — шулай уяныргга яратам мин... Бүгенге сөенечем, менә ул — әтәч! Голландски әтәч тә алды бит әткәй:

— Сиңа бу, син карап кайт, күз-колак бул, — диде. Ә мин йоклап киткәнмен... Ярый әле әтәч үзе колакка әйтте! Безнең авылда мондый әтәчнең булганы юк. Малайларның исе китәр инде! Үзем дә хәйраннар калып торам, гел күз иялешә алмый: салават күпередәй ялык-йолык кояшта уйнап торган, чит-ят илдән килгән әкияти-хикмәти төсләр бу! Тәтәйнең әфтияккә кыстырган тутый кош каурые сыман. Киртләч-киртләч кәпәч-кикриге, гайрәтле тавышы, ул горур, тәкәббер карап торышлары! Аягыннан бәйләп куйганнар иде, әрҗә эчендә кайтты. Авызын бәйләмәгән лә... Ә ул миңа тимәде, мин дә курыкмадым. Тиз ияләште — әллә кайчан безнеке сыман. Әткәй әйтә, насыйп мал шундый була, ди.

Балачагымнан шул әтәч аваз бирен, гомер ярминкәсе юлында черем иткән күңелне уята: тормыш арбасында мин, дилбегә күптән үз кулыма күчкән... Исәпләсәң, исең китәр — күпне күргәнбез икән, сөенечләренкөенечләрен хәтер катламнарына түшәлеп калган, видеомагнитофонга тоташтырып булмый ул тасмаларны, әмма күңелдән кат-кат кичереп, гомер буе «карыйсың»: җан азыгы булып, җир куенындагы саф чыганактай уй-тойгыларыңны туендырып торалар.

Әтәч ул могҗизалы кош: ерак Африкадан килсә дә, әүвәлге туган ягы көйләгән вакыт белән яши, таңда кычкыруы да, көндез аваз салуы да шундагыча. Безнең татар да бар дөньяга шул әтәчләр сыман таралган... Инде милләттәшләр Австралиядән ук кайтып, Иделне сагынуларын сөйли. Күңелдәге-җандагы җирсүне сагыну әтәчләре уята, буыннан — буынга, каннан — канга күчеп туган туфракка тарта: әтисе кайталмаса — баласы, оныгы кайта ,васыятен үтәргә кайта...

Әтәч тавышын калада ишетсәм, күңелдә сала терелә. Балачакка дәшә ул тавыш, барлап тора: ерак китмәденме, онытмадыңмы? Әле дә авыл гадәтенчә таңнан торып, шушы язмага керешкән идем. Сәгатькә карыйм — туктаган, борып куярга оныткანмын... Эх, әтәч булса, вакыт-

ны чамалар идең... Бик күп дәверләр авыл әтәч сәгате белән яшәгән. Төнге тавышы тирән тынлыкны тойдырса, таңда кычкыруында офык яктылыгы яңгырый! Билләһи дим, магнитофон тасмасында искәртми тыңлатсалар да аера алырмын шикелле: җәйге челләдәге тавышы — өченче төрле, эсседән оеган һаваны уятып килә...

Әтәч койрыгы сыман елкылдап торган бик сәер исемле уенчык алып кайткан иде әткәй — калейдоскоп. Бусы инде соңрак, миңа сигез яшьләр булгандыр. Гаҗәп тә соң, ничәмә-ничә әйләндерсәң дә яңа төсләр оеша, яңа күренешләр укмаша — гел менә кабатланмый! Кызыгып карый идем. Инде күңел күзем балачагыма төбәлгән: хәтер калейдоскобында төсләр, сурәтләр яңара, онытканың да ялт итеп килеп чыга. Шул якка таба кайтыймчы әле хатирәләр арбасында... Әтәчләре дә сагынган — әнә ничекләр өзелеп-өзгәләнеп аваз бирәләр...

## ...Дөнья бу!

Үзең дөньяга килгәнче үк, сиңа кагылышлы хәлләр булган...

Әнкәй сөйли иде:

— Иртә таңда суга барганда теләдем: сөйгәнемә барсам иде, дидем. Кабул булды теләгем... Ябышып чыкканда, елга буйлап, таллар арасыннан житәкләшеп кайттык. Таң сызылган иде... Бакча артыннан кердек. Каралтыдан үткәндә кыекка күрсәтте Галиулла:

— Әнә, безнең...

— Нәрсә? — дип өскә карадым.

— ...күгәрчен оясы!

Әнкәй шул көннәрне күңелдән кичереп тәэсирләнә:

— Күгәрчен ике генә бала үстерә. Ырымы бар икән, атаң шуңа ишарәләгән. Ике балабыз булыр дидем, рас килде...

Тыңлыйм да, күз алдыма китерәм: күгәрчен оясыннан сузылып, күзләремне елтыратып карап ятам: әнә ул — егет әткәй белән сылу кыз әнкәй... Ул чакта алар әткәй-әнкәй дә түгел, ул чакта әле минем җаным ике якта — сөешеп кушыласы ике кайнар йөрәктә мин... Уртак мәхәббәтебез табыштырды, кавыштырды, дип сөенәләр, бәхетлеләр. Ә бит мин ашыктырам, ике йөрәк кыйтгасындагы «мин» — булачак ярымшарлар магниттай тартыла... Дөньяга мин яралырга тиеш!

Әнкәй сөйли иде:

— Почмак якта йоклыйбыз. Бер көнне, төнлә уянгач, әйтә атаң:

— Сиңайтәм, яхшы түгел, ишетеләдер, ул хәтле шытырдатып ашама. Шикәрне кибеттән алып бирермен...

Шкафтан алып кимерә дип белгән. Аны-моны дәшмәдем:

— Мә, сиңа да — ач авызыңны! — дидем. Сикереп торып ут кабызды, нишләргә белми:

— Тоз ич бу?! — ди.

— Тоз шул, дим. — Төрләнеп йөргән чагым... Улым, синең белән йөкле идем. Тоз теләде күңелем, түзәр әмәл юк...

Менә шулай, җәмәгать, «тозсыз» дияргә ашыкмагыз, без аны әнкәй белән дә аз ашамаган... Ник төчене сорамаганмын? Канны җылытырга, йөгертергә тоз кирәккән. Кытлык булмагае дип, маяга да тоз җыялар. Күп кирәк ул — күз яшьләрең булып та күпмесе агылыр... Ә бит сөенеч яшьләре дә тозлы. Аларның барысы да көткән мине. Яратасы, әрнисеачынасы дөньям көткән. Мохиткә тагын бер җан иясе — тагын бер язмыш өстәлә...

...Ә ник кычкырып җылап җибәрдем икән? Еламаган балага ими бирмиләр дигәнне сизенептер. Елый белеп туганбыз, елмаерга, көләргә өйрәнәсе бар. Якыннарың өйрәтер, тормыш өйрәтер...

Кеше үзенең беренче елларын хәтерләми. Ни өчен тәэсирләрне баш миенә язмый табигать? Ул өч елда адәм баласы әти-әни, әби-бабалардан — гасырлар төбеннән күчкән кан хәтере белән яши, шуларны «имеп» — сеңдереп ята. Баш миенең нигезендә ул мирас: холкын-гадәтен, иманын, моңын...

Ә берзаман кинәт аң-зиһенең ачыла, күзең ачыла — инде ул күңел күзең белән тәңгәл килгән. Шул көннән башлап син барын да хәтерләп үс, берсен да онытма. Истәлекле уй сукмакларыңны урап әйләнә тор, яңарта тор хәтер буразналарын. Яңарта тор мәхәббәтеңне, яңарта тор иманыңны, нәселеңне... Мәңгелектән шул вазыйфалар белән килдең син, тәкъдирең шул.

Әнкәй бишектә тирбәткәнне, юатканны ишетәм:

— Чү, чү, елама... Әлли-бәлли бәү, йокла, балам, йом күзең, үсәрсең...

Әткәй уятканны ишетәм:

— Тор, улым, уян! Йә гомереңне йоклап уздырырсың!

Бабам көлемсерәп тора:

— Ач күзеңне, дөнья бу!

## Гомерең бар икән...

Көзнең соңгы аенда, кышка күчәр алдыннан туганмын. Төп йортның тәрәзәләре, аскы өлгеләрен томалап, кар-бураннарга карарга җыенган. Балага өрмәсен дип, рам араларына кәгазь ябыштырганнар. Түрдә бишек, сиртмә түгел — пружина, әткәй дә шунда тирбәлеп үскән, Һидият бабам мәркәздән алып кайткан аны. Кала сиртмәсе мине кая сикертер микән?..

Мин туган елда әткәйгә егерме дүрт, әнкәйгә — 22 яшь булган. Латифа тәтәй — илле алтыда. Һидият бабам өч ел элек вафат, 58 дә булыр иде. Әткәйнең ике абыйсы: Сафиулла — «дәү абый», Насыйбулла — «кечкенә абый» — Питербурда. Сеңлесе Бибигайшә, ике энесе: Сафа — «тәти абый», Хатип — «шәкерт абый» өйдә. Алты җан янына җиденче булып кушылганмын. Өйне утын гына җылытмаган, җиде җанның тере тыны да җылыткан. Бусы югарочта булса, түбәночта сау-имин Зиннәт бабам (68 яшьтә), Миңсылу тәтәй (63 тә) көтеп торганнар. Бу якыннарым, пьесадагыча әйтсәк, минем тормыш сәхнәсендә катнашучылар булыр.

Кыштан чак кына алдарак килеп, тышны күрмәгән өй кошы булганмын, өйдә «сайрагаймын». Тау астындагы мунчага мамык юрганга төреп йөрткәннәр. Бер ягы ачыла — борының сузып үс, биләүдән арынып кеше арасына чыгу ихтималың бар. Кызамык, чәчәк, тагын әллә нинди, сабыйны сагалаган җәбраил илчеләреннән исән-имин калсаң, әлеге «конвертта» киләчәккә китәрсең... Кыш — нарасыйга зур сынау — сират күперенең беренчесе, җирдә яшәүгә алып чыга торганы. Кыш — хәлне алган, хәвефхәтәр баш очында гына йөргән. Әнкәй сөйли иде:

— Мич яккач, иртәрәк япканмын — ис чыккан. Котларым алынды — зәңгәрләнеп киттең... Үлесең дип торам... Юрганга төреп ишегалдына алып чыктым, нишләргә белмим... Тирбәтәм, селкетәм... Күзләреңне ачтың! «Гомерең бар икән, балам!» дип еладым. Ә бервакыт, кагына торгач, бишектән егылып төшкән идең. Елый алмыйча тынсыз калдың. Күтәреп тау астына йөгердем — өйдәгеләргә сиздерәсем килми... Гомерең бар икән.

Кояшны язын гына күргәнмен дә, күзем чагылып борын җыерганмын. Ә борын сизгән нурлы һаваны, тал бөресенең баллы исен... Бәлкем, яз шуңа да тансыктыр: кышның тынчу өненнән чыгып, ирек-иркенлек сулышына сөенгәнмен, шул хәтерсез чактагы сиземләү канымда яңарадыр...

Борынгы бабайлар Яңа елны нәүрүз бәйрәме дип, яздан башлап санаганнар. Яз — яңарыш, терелү. Мин дә бит өй карынышнан дөньяга язын «туганмын»... Бар нәрсәгә күз тутырып карамак булам да, карый алмыйм, яктыдан күз алларым караңгыланып китә... Ашыкма, дидер Кояш, әз-әзләп карасаң күп итеп күрерсең — син күрәсен кем күрсен: «Гомерең бар икән»,— диде бит әнкәң — сине тудырган Кояш...

Әнкәйнең бу сүзендә тагын бер мәгънә бар икән. Үзгенә уткәнгә күрәдер, ул аны ничәнче кат искә төшерә... Син дөньяга килгән көнне кар яуган иде, ди. Ә котылуы бик авыр булган. Шуңа да, гореф-гадәт буенча, ахыр чиктә әткәй мәчет ишеген күгәненнән алып торган... Рәхмәт инде, ярдәме тигән, көмеш айлы, хәер-догалы мәчеткә дә бурычлы икән мин. Тары боткасы пешергәннәр иде, туйганчы ашый алмаган идем, шул истә, дия иде әнкәй. Өч көн капмый торган яшь килен: хәле хәл булгандыр... Әйтәм аны, бик теләп, тәмле итеп шул ботканы пешерә торган иде — уртасына оя ясап, сары май салыр иде...

Безнең кайбер сүзләр, кыланмышлар да сары май булып ятмагандыр инде, йөрәген сызландырган чаклар булгандыр. Бала күңеле соңга калып төшенә. Җанда, бәгырьдә сагыну, үкенү тулгаклары... Әнкәй сөйләгән гыйбрәт искә төшә: учыңда тәбә пешереп ашатсаң да, әнкәңнең бер тулгагына тормас, ди...

## Мылтык тавышы

Бу дөньяга хәтерем ачылып, үземне белә башлагач сискәндереп истә калган тәүге тойгылар: шомлану, кызганудыр... Кинәт дөпел-дөпел шартлау, тәтәйнең хәвефләнеп тәрәзәгә каплануы:

— Киләләр, киләләр... Безгә дә җитәләр!

Бәрелеп-сугылып капка астыннан Полкан килеп керде, куркып келәт астына ыргылды. Качты, котылды дип торганда, кара киемле икәү мылтыкларын сузып артыннан бастырып керде дә келәт астына үрмәләде... Өйдәгеләр куркынып сөйләшә:

— Эт җыючылар килгән!

— Күргән бер этне атып йөриләр!

Әткәй дә, Сафа абыйлар да өйдә юк, алар кертмәс иде... Ишегалдында гөрес-гөрес мылтык шартлады! Полкан әрнеп-рәнҗеп елый. Тагын гөрес... Полкан тынды. Качтымы дисәм, теге ике карачкы маэмаемны аягыннан өстерәп алды... Ник өрми, ник ырылдамый шуларга? Башы карда өстерәлеп, әрле-бирле чайкалып килә, авызыннан алсу эз саркый. Өзелгән өннәре шулдыр: коткарыгыз, дип ялваргандыр...

Эт атучы явызлар капканы ачык калдырып китеп барды: тавышлары усал иде. Ачык капкадан шом салкыны үрмәләп җанны өшетеп алды: шундый хаксызлык була икән, куркыныч икән бу дөнья — беркем яклый алмый кала: кеңәләр дә аталар!...

Бик ярата идем Полканымны, күзләрен тутырып, елмайган сыман карый иде... Гаҗиз калдым бу кансызлыктан — ничек шулай мөмкин?! Ул чакта миңа дүрт яшь булган. Әткәй кайткач та, каршысына йөгереп, йөрәк өзгеч хәл турында сөйлим:

— Полканны атып бәрделәр!

Әткәй мине юатты, тегеләргә бик ачуы килде. Нишләсәң дә соң иде шул... Бу хаксызлыкны, бу фаҗигане оныта алмадым. «Атып бәрделәр» ... дигәннән абыйлар көләргә тора, «мылтык ату» белән «атып бәрү»не аермаганмын. Мылтыктан курку шул чактан калган. Күземне ачканда дәвере шундый булган: мылтыклы карачкы, үзе күренмәсә дә кайдадыр барлыгы, аңардан шикләнү чикләп-сагалап күләгәдәй ияреп йөргән, һәр сүзеңә колак салган...

Сугыш алдыннан әткәй да ау мылтыгы алган иде, йортны эт сакламаса, мылтык ярар, дигәндер. Әнкәй чормадан шикләнүен беллергәч, бер кичтә түшәмдәге төннектән гөрселдәтте:

— Качты җен-пәриләр, курыкма! — диде.

Малайлар мылтыкка кызыга, ә мин читләшәм — җаным өркеп, тәнем ытыргып калган... Әткәй сугышка киткәч, ул мылтыкны күрше Хәбибрахман абый алып торды да кайтармады. Сорамадым. Әткәйнең шахтер лапмасын саклыйм, ул аның яшьлек хатирәсе. Ә мылтыкка аныкы дип ияләшә алмадым...

Күземне ачканнан бирле илдә мылтык тавышы тынмаган. Сискәнеп уянган, сәбәпсез елаган сабыйлар шуны тойгандыр. Әткәй гомере дә сугышта өзелде, кара тәреле карачкылар кулындагы мылтыктан...

Әткәй җырларын, әнкәй бәетләрен хәтеремдә яңартам. Өзекләре генә истә шул, аларны да мылтык шартлавы өркеткәндер:

> «Атмачы мылтыгың,
> Куркадыр җаннарым,
> Шул наган тавышына...» —

дигән сүзләр бар иде берсендә. Үткән фаҗига-бәетләрнең киләчәккә төбәләсен, безнең язмышка да туры килерен кем белсен...

## Беренче чәчәкләр...

Миһырбансыз дөньяның баланы каршылаган беренче чәчәкләре — «чәчәк авыруы» иде. Чәчәк сүзен иң әүвәл сырхау мәгънәсендә — кайгырып сөйләшкәндә ишеткәнмен. «Чәчәк» корбаннарын санасаң, безнең авылда шактыйдыр. «Чәчәк салмаганга үлгән», — диләр иде. Миңа салдылар, сул кулымда кутырлап, әчетеп, соңыннан төчетеп торган чагын беләм, гомерлеккә эзе калды. Исән котылганлыкка тамга икән...

Чәчәк, чәчәк... Хәзер генә ул кабергә чәчәк кую гадәте бар. Утызынчы еллар башында Тау ягында, калын урманнар артында табиб та, шәфкать туташы да булмаган. Сабыйлар табигатьтән генә шәфкать көтеп, ут эчендә бәргәләнеп яткан. Кыр чәчәген дә күреп өлгермәгән нарасый күзләрен еш кына кайгылы «чәчәк» томалаган. Кара чәчәкләрне яратмыйм, куркам мин алардан, шомлы булалар. Өй борынча йөргән «чәчәк» авыруы да куркытып үткән, ярый әле үземне аяган.

Кызамык белән кызышып, иреннәрем, тәнем янып, авыр сулап ятуымны, упкынга чумгандай онытылып-югалып калуымны хәтерлим — ничә көннәр белештерми ятканмын. Озак йоклап уянгандай, күптән күрмәгән өй эченә тансыклап карадым. Корама юрган бизәкләре, чаршаудагы зур-зур алсу-кызыл чәчәкләр — кызамык белән авырганда кызыл төс файдалы дип әнкәй элгән.

— Иншалла, күзен ачты! — дип елаганы, әткәйнең кызыл билле прәник биргәне исемдә. Кызамык кызганган — алып китмәгән, әткәй, әнкәй баш очымда — алар бирмәгән, алла саклаган.

Яшьли дөнья куйган нарасыйлар үсеп, кем булыр иде дип фараз кылам. Күзен ачып өлгермәгән энем Ислам... Табигать миңа абый бирмәгән, энем дә була алмады. Гөлсем сеңелемне хәтерлим, почмак баганасына тотынып, теле яңа ачылып килгән чакта:

— Әделдәти-үтәти! — дип такмаклап биеп торуы күз алдыма килә. Ике яшьләр чамасы булгандыр, тамагы шешкәч, әнкәйнең иненә башын салып, нәни бармаклары белән тамагына күрсәтә: әйтер сүзен әйтә алмаган... Сулар сулышы беткән, диделәр. Чиксез мәңгелек ана бер гомерлек сулышны кызганган. Ә бит — һава күп ул... Куркып-куркып

кайгырдым, әнкәй жылый, әткәй сулкылдый... Бигрәк мөлаем, туганнар килсә, кара чәчләрен җилфердәтеп кочагына атыла торган сөйкемле сөяк иде, яратып муеннан кочаклап алыр иде... Чәчәк кебек иде, чәчәкле күлмәген ярата иде — ак җирлектә бөртек-бөртек алсу чәчәкләр күнелгә якын рәсем булып калган... Чыбылдыктагы аллы-гөлле чәчәкләргә бармагын төртеп, яратуын белдерер иде. Ул да кыр чәчәкләрен күрми китте, өйдәге тамчылы гөлләр елап озатты. Шуңадыр, алар һаман моңсу күренә. Тәкъдир кем маңгаена нинди «чәчәкле» мөһер салган... Үсеп җимешләнә алмыйча, яшәү кояшын тоймыйча югалган гөнаһсыз җаннар... Алар да йоклагандай онытылып киткәндер, аермабыз шунда — мин дөньяны яңадан тойдым, алар уянмыйча сүзсез мәңгелеккә кушылды...

Яз саен беренче чәчәкләрне көтәм. Әнкәй юрый:

— Сары чәчәк күрсәң — сагышка...— ди. Кайсы очрый бит, чәчәкнең ни гаебе булсын инде? Беренче күбәләкләр дә язның канатлы җаны сыман, чәчәктән — чәчәккә кунып очулары үзе куаныч! Әнкәй тагын көрсенеп куя:

— Кара күбәләк күрсәң — кайгыга...

Кызыл балчыклы инеш ярындагы сап-сары үги ана чәчәкләрен күргәч тә, уйга калам: үги ана тирәсендә ятимнәр сагышыдыр...

Кышлыкка гәҗит тасма ябыштырылган тәрәзәләр ачыла, ызба иркен сулап җибәрә, агылып-ашыгып тал бөреләре исе тула... Тәмле һавага ияреп кызыллы-каралы күбәләк тә кергән, ишекле-түрле салмак кына әйләнеп йөри.

— Тия күрмә! Күбәләк булып әрвахлар җаны кайтыр ди... Сеңелең Гөлсем, йә энең Исламдыр!

Гөлсем күлмәгенә охшаган шул. Ә Исламны мин хәтерләмим. Аның беренче һәм соңгы күлмәге кәфен булган шул, дөньяга исемен генә калдырып киткән — үз исемен үзе ишетмичә... Күбәләккә кызганып карыйм, тиямме соң, пыялага бәргәләнеп азапланса, сак кына учыма алып урамга очырам. Әнкәй дәшми, моңсу гына карап кала. Күбәләк гомере чәчәк гомереннән дә кыскарак икән шул...

## Әлпиеңне укыдыңмы?

Мамык түшәккә чумып, Мәсгут белән икәү тәтәйгә сыенабыз. Йоклыйсы килми, күзләр шар ачык, әкият көтәбез. Тәтәй сөйли, йомшак тавышы иркәләп бишектәй тирбәтә... Күз кабаклары авырая, йом... йомыла. Тәтәй моны сизә:

— Әлпиегезне укыдыгызмы? Йә әле, бергәләп! — ди дә, таслап тезә башлый:

— Әлиф-би, пи-ти...

Без дә кушылабыз:

— Җим, чи... дәл, зәл...

Йокы алдыннан укый торган дога бу, балалар догасы:

— Гаен, гайн, фи, кап...

Телгә ятышлы тылсымлы авазлар белән оеп ук киткәнбез... Бу доганы укысаң саваплы, бәхетле буласың. Әнкәй белән дә көн саен яңартабыз, яттан үзебез генә дә укый алабыз. Күңел хушланып, бик канәгать булып йокыга таласың. Шундый тәмле була йокы — башны мендәрдән аерып булмый. Ә берсендә курка калдым — баш мендәргә ябышкан! Мәсгут тә уянган, катырак тартылган иде, кычкырып җибәрде:

— Мендәр чәчне тарта!

Тәтәй кайчы белән кисеп, чак аерып алды. Баксаң, үзебез гаепле: авызда тупыл мамыгы кушып ясаган балавызлы сагыз иде, йоклагач төшеп ябыштырган...

Әлпинең гап-гади алфавит икәнен соңыннан белдек. Дога дип күнелгә битләткәннәр, дога булган да ул — Туган тел догасы. Бишек җырына ялганып безнең көйләгән, бәхетле иткән. Әткәң-әнкәң телен белмәсәң, бәхетле булыр идең мени?! Әлпи белән бергә:

— Әппәр ит! — дип, бит сыпырырга өйрәткәннәр. Аннары гына әлхәм-колһуаллага күчелгән. Өйгә ишек ачып кергән картлар:

— Әссәләмәгаләйкем! — дип сәлам бирә. Хатын-кыз сәлам кайтара алмый, әткәй юкта ир заты — син:

— Вәгаләйкемәссәлам! — дисәң дә, зур вазыйфа башкаргандай буласың. Мактап та җибәрсәләр, башың күккә тия инде, үсеп китәсең. Безнең «гыйлемлек» шуннан узмады бугай. Тәтәйләрне сөендерергә яраган, «замана сабагы»на хәтле сеңеп калсын, дигәннәр.

«Ана теле» дип тикмәгә әйтмиләр — карында чакта ук шул аһәңгә көйләнә бала. Әмма «садик» карынына күчкәч, онытучылар күп хәзер, анда бүтән әлпине ятлаталар. Ә нарасый чагында сеңгәне гомерлек. Әнә, Мәсгут Ленинградта яшәде, җәйләрен тәтәй янында, бергә уйныйбыз. Тәтәй телен онытмады. Читтәгеләр югалтудан куркып, тырышыбрак саклый. Казан-башкалабыз уртасында күбрәк югала туган тел... Казан карынында бүтән телне күбрәк ишетә шул нарасый. Ә Мәсгут немец телен дә белә, Ленинградта шәрекъ университетын тәмамлап, Коръәнне тәрҗемә кылган атаклы Крачковскийда укып гарәп теле укытучысы булды, 2 нче гимназиядә эшли. Әлпи догасының файдасы!

Икенче бер очрак искә төшә. Русча сөйләшкән, русча шигырьләр язып танылган шагыйребез Мәскәү янындагы иҗат йортында яңа поэмасын укырга бирде. Исем китте — татарча язган! Теле дә элеккерәк, өлкәнрәкләр сөйләшә торган тел әле:

— Бала чакта дәүәни янында үстең мәллә?

Шулай икән. Әнә бит, баш миенә «ак нур белән...» сызылып калган әлпи аһәңнәре. Борынгы рәсемнәрне яңартучылар өсте-өстенә түшәлгән буяу катламнары астыннан иң әүвәлге кыйммәтле сурәтләрне шулай ача...

Рәхмәт инде әлпине — туган тел догасын ятлаткан әнкәй, дәүәнкәйләргә, йокы алдыннан укытулары җанга сеңдерү булган. Иренгән, киреләнгән чакларда ярый әле мәҗбүр иткәннәр. Бу уңайдан, әле шушы арада күргән рәсем искә төште. Намазлыкка тезләнгән әби, янына чүгәләгән оныкның башын аска идереп намаз «зарядкасы»н төшендерә. Өйрәнерме замана баласы, гамәленә керерме, әмма әбисенең «картаеп каткач буыннар — эш белү уңайсыз ул» дип кабатлавы хикмәтле. Талчыбыкны яшьләй бөгәләр. Әлиф-би көенә тел биетергә дә шул яшьтә көйләнеп калсаң гына... Әлпиеңне укыдыңмы? Йәле, әйдә әле, бергәләп кабатлыйк:

— Әлиф-би, пи-ти...

## «Без — Шәһри Болгардан!»

Сак-Сок бәетен ишеткән чакта ук, җае чыкканда әнкәй:

— Без — Шәһри Болгардан! — дия иде. Борынгы бабайлар җире икән ул.

— Шәһри Болгар — изге җир! — дип җөпли әткәй дә. — Мин — татар дию генә җитми, татарның төрлесе булыр, мин — мөселман, диергә кирәк!

Әлпи-тисине ятлаталар, «Шәһри Болгар — изге җир» дип, бисмилла сыман кабатлыйлар. Үсә-үсә, балалыкта ишеткәннәр дәрәҗәсенә үсеп җитәсең икән. Китаплардан эзләп таптым, барып та күрдек Бөек Болгарны. Әллә кай, әүвәл заманнарда — борынгыда калса да, якында икән. Изге җиргә сәҗдә кылырга безнең Тау ягыннан әби-бабайлар йөргән,

шуңа багышланган, халык теленә кергән бәет бар. Дингә каршы лекцияләрдә хорафәтләр, юк-барга ышану дип бәяләнә иде изге чишмәләр. Әмма халык хәтере чишмә башын югалтмаган — кан тарткан, ул чишмәләр тамырларда аккан...

Болгар хәрәбәләре дә «искелек» калдыклары саналган. Анда без тарих төбенә карагандай булдык. Татарның үз җирендәге кәгъбәсе ул. Шәһәреннән җимерек манаралар калса да, исеме аумаган, изге чишмәләр корымаган. Кабер ташлары чиркәү нигезендә «сакланып» калган... Бусы — нигезендә, ә гөмбәзендә — җиңелеп чалкан төшкән, аста калган Ай өстенә тәкәббер Хач баскан. Чиркәү үзе дә нигезендәге Ай-ташларга кара хач булып баскан. Әмма тарихка кайту дошманлыкны түгел, иманыбызны яңартсын. Үч-ачу ташларын кузгатып мәчетләр нигезенә салып калдыруны күз алдына да китереп булмый лабаса!

Әткәй-әнкәйнең: «Без — Шәһри Болгардан!» — дип тәкърарлавы турыдан-туры безнең төбәккә кагылган — изге җирдән кагылган-куылган өммәт килеп урнашкан Тау ягына, безнең борынгы Чучак бабай нәселе дә шуннандыр...

Бала күңеленә, хәтернең нигез ташлары итеп нәсел-ыру, туган туфрак турында мәгълүмат салып калдыру фарыз шул. Рухыбызны иман кыйбласына көйләгән әткәй, әнкәйгә, тәтәй, бабайларга рәхмәт. Кабатларга кирәк хак сүзне: үсә-үсә төшенер бөекләрне, уе-буе җитә башлагач аңлар бала — җаны гына уяу булсын...

... Тормышта туры килеп торулар була бит ул. Әле Ш. Сайкинның «Борынгылар мирасы» дигән язмасын күрдем («Шәһри Казан», 1991 ел, 30 октябрь). Танылган педагог Шәриф ага безнең авылга күрше Аюкөйдергәндә туган, бер үк тарихларны ишетеп үскәнбез. Ул яза:

«Элек-электән килә торган йола буенча һәр җәй саен Тау ягы авылларында карт-карчыклар, төркем-төркем булып, Шәһри Болгарга, борыңгы әби-бабайларның нигез туфрагына зиярәткә бара торган булганнар...

...Шәмсекамәр әби әйтә: «Безнең борынгы бабайлар, шул җулбасарлардан качып, безнең җакларга урнашканнар», — ди.»

Мәкаләгә «Шәһри Болгар бәете»нең XX гасыр башында Аюкөйдергәндә теркәлгән варианты да өстәлгән:

«Манарасы биек икән, санап мендем баскычын.
Мәсҗетенә керә алмадым, кафер бирми ачкычын....
...Манарасы биек икән, күргәч аны калдым хәйран,
Каферләрнең арасында сәхабиләр ята вәйран.»

Ишетә идем, безнең авылдан да изге туфракны сәҗдә кылучылар бар, савабы хаҗга баруга тиң, диләр иде. Әлбәттә инде яшерен эшләнә, кайткач та шауламыйлар. Менә берсе, Пиркәч Фәрхиҗамалы диләр иде ул карчыкны. Әнкәй белән сөйләшеп утыра иде, күңелен бушатып, белгәнен укып. Шәһри Болгарга баруын сөйли. Сәеррәк күренә, дәрвишрәк, авылдан-авылга йөри. Бар булганы өстендә, төенчегендә. Фәкыйрьне бала-чага да кимсетә, үртәп балчык атып калучылар да була. Түзә карчык, ахыр чиктә әйтә торган рәнҗү сүзе шул:

— Ходай сине солдатка алырга кушсын! — ди...

Әлеге бәеттә тагын шундый юллар бар:

«Габдрахман кыя ташында дәва корбан чалалар,
Габдрахман кое суын дәвам өчен алалар».

Изге су алып кайтканнарын беләм, тирә-юнь төбәкләрдән сукмаклар өзелми, диләр. Шуңа күрә дә, «изге чишмә» — уйдырма, дини хорафәт дип мәкаләләр чыга иде.

Табигатьнең мәңгелек могҗиза, серләре бар. Кошларны да туган туфрак тартып, җиде диңгез артларыннан кайтара — нәрсә адаштырмый, нинди хикмәтле кыйбланамә? Кан тарта, җан тарта, кешене — аң да

тарта. Бабайлар васыяте әткәй-әнкәйләр сүзе белән буыннан-буынга күчә килгән, милләтебезнең төп йорты, нигезе шунда. Без — Шәһри Болгардан!

«Яраплан»

Безнекеләрне гел аңлап булмый: искитәрлек нәрсәдән дә көләләр... Ә ул көнне хәйран калмаслык идеме? Каршы урман өстеннән килеп чыкты ул: дүрт канатлы, шундый зур яраплан! Авылга житкәч, таллар очына чак кына орынмыйча, яман шытырдап очты! Күреп алдык та, бер-беребезгә күрсәтешеп, шаккатып артыннан йөгерәбез, күләгәсенә басмакчы булабыз. Олы урам өсләп оча тимер тилгән, без дә калышмыйбыз. Югары очта төп йорт, анда тәтәй, абыйлар. Аларга да әйтим, күрми калмасыннар тагы! Шаккатсыннар әле! Бергәләп йөгерербез, каян күреп алдың, диярләр. Шәп йөгерәм дидем бит, әле дә ярарланга әлләни уздырмыйм, сулышым кабып, сөенче алгандай күккә күрсәтәм:

## ХӘТЕР



**Муса Җәлил**
(1906—1944)

### Җырларым

Җырларым, сез, шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм халык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю —
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

*1943*

— Яраплан! Яраплан, карагыз! Гомеремдә мондый зур яраплан күргәнем юк иде!

Бер дә исләре китмәде, эш ташлап йөгерүче булмады, күтәрелеп бер генә бактылар. Ярапланга түгел, миңа карап көләләр... Ничек күреп алганымны, бик иләмсез зур икәнен колач җәеп күрсәтүемне, аларга әйтергә дип йөгерүемне ашыга-ашыга сөйли башласам, тагын авыз ералар:

— Гомеремдә дә, ди бит!

Тәтәй булып тәтәй дә:

— И-и бәбкәм, синең гомер әле...— дип куя. Үзе җиз ләгәндә үрдәкләргә салган кузгалаклы кычытканны көрпә белән бутый бирә, балта белән турап тагын өсти... Үзләре гел «гомеремдә дә» ди, аларга ярый, мин әйткәч нәрсәсе көлкедер?

Бар гомерем биш-алты яшь кенә булган шул... Ул җәйдә ярапланга бәйле, авыл шаулаган тагын бер вакыйга булды: арттагы урамга лүтчик кайткан! Парашут белән әллә ничә сикергән, йөздән артык. Сикергән саен акча бирәләр, ди. Ник микән? Без аны күрергә йөгердек, капка төбенә чыгып баскан. Зәңгәр киемнәре бигрәк матур! Менә нинди була икән самолет йөртүче. Иң гаҗәбе шул: читтә укыган, эше тыгыз булган, авылга... ун ел кайтмый торган ди! Ун ел! Башка сыймаслык күп ич, бик озак ич! Ул чакта минем «ике гомерлек» булган шул... Күп еллар үтте, үзем дә авылга унар ел кайтмый торганмын... Олыгайгач үткән ун ел бер дә егылып китәрлек озын-озак түгел икән. Сабый гомерендә вакыт бүтәнчәрәк үлчәнә...

Балачак йолдызларга карап хыяллана, күккә омтыла: серле киләчәккә илткән юллар шундадыр. Хикмәт-могҗизалар шунда инде, тизрәк үсәсе иде! Әле кайткан лүтчик Гарифҗан абый шул киләчәктән сикереп төшкәндер... Авыл өстеннән очсаң иде аны: «Вагыйз! Нурхуҗа!» — дип кычкырсаң иде! Күреп хәйран калсыннар иде!

Шактый гомердән соң летчик абыйны Казанда күрдем, авылдаш дип ишетеп, үзе эзләп тапты, өйгә килде. Өлкәнәйгән, калыная төшкән абзый — балачагымның канатлы егете шушымы? Ул инде киләчәктән түгел, үткәннәрдән кайткан шул, күк төсен, сокландырган зәңгәр киемнәрен шунда калдырган. Хыялыңда йөргән кешенең җирдә — янәшәңдә басып торуы сәеррәк икән. Сабый чактагыдай үткен түгел шул күзең: авылдашыңда канат күрмисең — хыялыңның төсе уңган... Аннары, шунысы да бардыр: хәзер ул инде үзе миңа гаҗәпсенеп карый.

Гомеремдә төрле самолетларга утырып ерак сәфәрләргә очканым бар, бу хәзер кем өчен дә гадәти хәл. Тик тавыш тизлеген узып очкан самолет та теге ярапланга җитми инде. Анысы беренче гомеремдә шул — кайтавазлар кайтмый торган яланаяклы гомеремдә...

## Эчеңдәге кара мәче...

Эссе көннәрдә ызбада һава сүлпәнрәк — бераз тын алырга була. Ишек ачык — мин кергәндә бусагада ят бер кара мәче утыра иде.

Башын боргалап ялт та йолт күзәтә, ни тапкандыр шул хәтле? Перес! Күзләре ут яна, усаллык кына түгел, ерткычлык уянган үткен караш иде ул. Бер дә чыгып атылмады, теләр-теләмәс кенә кузгалды. Курыкмый, йорт хуҗасына буйсынып кына юл бирде. Бусаганы атлагач та, пырылдап очкан тавыш ишеттем: чыпчыклар кергән, шуларны күзәткән икән! Ботарлап ташлыйсы булган, ярый әле кереп өлгердем. Кудым явызны!

Түргә узып, ишек катына куам, түшәмгә тияр-тимәс әрле-бирле чәбәләнеп оча чыпчыклар: шыр ачык ишекне күрмиләр! Көш, дим, көш, савыт-сабаны кыралар инде... Әллә мәчедән өреккәнгә ул якка карамый-

лар? Менә аңгыралар, юк бит иде ул! Чыпчыклар тәрәзәгә ябырыла, бәргәләнә — ватмагайлары... Бу нинди каты һава дип мыңгериләр, ах-рысы, ябышып яталар. Шуны да белмиләр — пыяла бит ул, пыяла. Әлсерәп томшык ачканнар, түшләре инеп-инеп авыр сулыйлар... Тәрәзәдән куам, янә түшәм аслап очалар, ишек өстендәге аятьәлкерсигә тәртеләләр — түшегез инде чак кына аскарак! Ачудан кәпәчне ыргытым — шул хәтле мәнсез булырга соң! Мич арасына, сәке астына керәләр, әмма ишеккә бармыйлар. Тавык мие эчкән чыпчык башлар! Яхшылыкны белмәгән нәрсәләр, син аларны иреккә чыгармак буласың! Өйдә калдырсаң, пычратып бетерерләр: ак мендәргә эзләре тамган, әнкәй чигешләренә үз «нәкышләрен» өстәгәннәр инде... Көш, көш, юньсезләр!

Куа-куа тирләп беттем, ачу килә, минем дә кан кызды. Ну, әләктерәм, бирәм инде! Кая әле... Тоттым берсен, йөрәге дөп-дөп итә. Курыкма. Һавага чыгарам, миннән булсын яхшылык. Очканыңны күреп калырмын. Учны язып карамакчы идем, ычкынды, ишеккә җиткерә алмадым... Ә-ә, сез әле шулаймы! Ни әләкте шуны тондырам, тидерә генә алмыйм — болар бит мине мыскыллап йөри — алар чаярак, имеш! Тотсаммы бу юлы, миннән яхшылык көтмәгез! Ачу-ярсу көч өстәде, шул кайнарлык үземә дә ошый: аучы дәрте керде! Минем кулда сез, әләктерәм, бетерәм!

Шулчак куркыныч төштән уянгандай булдым, үземне читтән күрдем: ниндидер ят, куркыныч малай иде бу... Эчемдә шундый явыз бар мени? Теге кара нәрсә җен булдымы әллә, зәхмәтле кагылдымы, мине җен алмаштырдымы? Күзләре һаман бораулап-яндырып карый сыман... Мәчене куып, аның урынында үзем калдыммы?! Салкын тиргә батып шул хакта уйладым, урамга чыксам да кыяфәтем карачкыдыр — явыздыр сыман, күргән кеше ни дияр...

Чыктым, икеләнеп кенә барам, юк, малайлар сизенмәде, әлеккечә дип беләләр... Чынлап та булдымы соң бу хәл? Өйләнеп ызбага кердем. Бусагадан карыйм — чыпчыклар күренми. Алар бит миннән дә курыккан — зуррак ерткыч дип... Әнкәй кайтып керде:

— Ничә әйттем, бусагага басма, үсми калырсың, дип!

Беләм дә, онытып җибәрәм шул. Үсмәгәнмен шул әле... Күтәрелеп карарга базмадым, урамга сыйдым. Таллар арасыннан йөгерәм — эчемдәге кара мәчене адаштырыйм! Калсын ул миннән!

Арына алдыммы ул көнне? Шигем бар — поскан тынадыр... Гомер буе уяу булдым, ерткыч тырнакларын күрсәтергә ирек бирмәдем мин аңа. Бар иде, бик булды ыргылып чыгарга теләгән чаклары... Адәм баласы үзеннән дә саклансын икән, уяу булсын — эчендәге явызлыкка юл бирмәсен. Күкрәк читлегеннән чыккан яманлык гыйфрите кешене тимер читлеккә кертә...

Бала чактан бирле эчтән тынган, оялган серләрең була. Шуларның берсе иде бу, укырга кергәнче үк алган сабагым.

## «Бармак малай» сызгыра...

Гарифулла абыйның «Ак бүре» әкиятен кичләрен бүрәнә өстендә агайлар янында тыңладым. Әкиятче үзе дә елгыр, хәйран калып тыңлаучылар күбрәк булган саен дәртләнебрәк сөйли — аңа тамашачы кирәк.

Миннулла абый — орынып торган күршесе, йорты тыкрык буенда — чатта, күпер төбендә. Бакча койрыгы безнең тәрәзәсез — «глухой» яякка килеп терәлә. Әкиятче дип тә белмиләр аны. Аз сүзле, шыпырт кеше. Кичләрен әткәй янына кереп утыргалый. Мин дә шунда кысылам, әкият вакыты җиткәнне көтәм. Әкерен генә сөйли, аңа менә, янында утырып, сенеп-сеңдереп тыңлаган бала кирәк булгандыр, ялгыз тамашачы алдында күңеле ачылган. Үзенең баласы да юк — әллә шуңа дамы?

Миңнулла абыйдан ишеткән әкиятнең берсе — «Бармак малай». Бигрәк кечкенә — күрмиләр дә аны. Ат колагына кереп посарлык булгач, ничек күренсен? Үзе иллә дә ачы сызгыра икән — буена күрә түгел, тавышы үзеннән зур! Бармак малай минем күңелгә дә кереп урнашты. Кабартма янына килеп басса, кабартма нинди зур булыр иде аңа! Ә кабак, менә бу кабак таудай булып, ул аның өстеннән шуып уйный алыр иде!

Урамда без олылардан ишеткәнне кабатларга яратабыз. Тотынышып басабыз да, җырлаган итәбез:

Без авылдан чыгып китек,
Чабатага төялеп;
Сөйгән ярлар озатып калды
Әрекмәнгә сөялеп...

Көлке җыр инде, кызык итеп әйткәннәр генә. Тик шуны торыпторып искә төшерәм. Әллә әрекмәннәре талдай биек, әллә кызлары кәтәнә...

И яшь чаклар, яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар;
Саламнан тәртә каерып
Чикерткә җиккән чаклар!

Тәртәсе салам булгач, арбасы нинди? Ат урынында чикерткәне күз алдына китер... Кәтәнәләр дөньясы бар мәллә? Әнә бит, чирәмлеккә ятып карасаң, кырмыскалар мәйханә кылә, кызыл тараканнар кайнаша: үлән арасы аларга карурман ич! Әллә «Бармак малай» шунда яшиме? Аңа барысы да зур булып күренә ич! Бусын да ул җырлыйдыр:

Тау башына тары чәчтем,
Тартар чүпләп бетергән;
Кечкенә генә хатын алдым,
Чыпчык сөзеп үтергән...

Шаяру икәнен беләм мин ул җырларның, көлеп әйтә абыйлар, «чыпчык сөзеп үтермәгәнне» беләм. Ә шулай да бәләкәйләр дөньясын чын итеп күргәндәй булам.

Без үстек. Бармак малай бер көе, ул һаман да ат колагына кереп чая сызгыра, яңадан-яңа малайлар ишетә, ышана, аңа иярә. Сызгыра-сызгыра үстерә ул аларны! Минем Шәвәли дә хыялымда шул Бармак малай токымыннан тумадымы? Ашыгыбрак үсеп кенә киткәндер? Ни булса да, колагында Бармак малай сызгырган сакаллы сабыйлар әле дә бар. Билләһигазыйм бар, чынлап әгәр, чәчрәп китмим менә, кайчакта шуларның берсен үзем дә сакал кырганда көзгедә күргәлим...

## Әткәйдән ишеткән гыйбрәтләр

Кичләрен әткәй укый торган китапларның тагын берсе — «Кыйсаселәнбия». Пәйгамбәрләр тарихы ул. Иң кызыгып тыңлаганым — Йосыф кыйссасы. Аның тәтәй көйләп укый торганын да ишетәм. Борынгы заман хәлләре түгел, бүгенге кешеләр сыман, шуңа җәллим дә... Гыйбрәтле хикәятләрне әткәй кат-кат укый, тыны тузып беткән.

— Тыңларга ярата малай, — ди дусларына. Мактавымы, әзрәк мактанып алуымы. Мөгаен, кыбырсынмыйча, колак салып, сеңдереп утырсын, дигәндер. Ә мин, әткәй укый башласа, ишеткәнемне күрәм сыман.

Әнә, безнең инеш күперен чыгып, тузанлы юлдан аталы-уллы икәү атлый. Коллар ягыннан киләләр... Әтисе юлда яткан даганы күрде:

«Ал, улым, кирәге чыгар!»

Иелергә иренде малай. Әтисе шул даганы тимерчегә сатып, чия алды, сиздерми генә берәм-берәм юлга төшерә... Малай шунда ук иелде, капты: тәмле! Мимылдап-каралып пешкән чияләрне чүпли-чүпли әллә ничә иелде... Әтисе әйтте:

«Менә, улым, бер иелергә иренсәң — йөз иелерсең!»

Мин үзем дага күрсәм алам, дага тапкан кеше бәхетле була. Күп чапкан ат — әнә ничек ялтырый дагасы, көмештер әле...

Ике ташчы турындагы кыйссаны тыңлый башласам, давыл чыккандай була, җирдәге саламнарны очыртып, ызба башындагын йолыккалый, талларны әрле-бирле кыйный... Биектә эшләүчеләр басып торган такта кубып, ике ташчы чакябышып кала... Такта икесен дә күтәрмәс... Яшь ташчы:

— Син яшә, абзый, синең балаларың бар...— ди дә, кулларын ычкындыра...

Иптәше хакына үзен корбан иткән егет искә төшеп, уйлана идем. Әлеге кыйссаны соңрак үзем дә укыдым. Әткәй тавышы белән сеңгәнс гыйбрәт булып гомергә калган. Чыңгыз Айтматовның «Диңгез яныннан йөгерүче ала эт» повестында да шундый тетрәндергеч хәл: балалар исән калсын өчен өлкәннәр диңгезгә сикерә... Чыңгыз — яшьтәш, әнисе Нәгыймә — мөгаллимә, теге кыйссаны улына укыгандыр. Балачак тәэсир-

## ХӘТЕР



**Фатих Кәрим**
(1909—1945)

### Сибәли дә сибәли

Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми.

Уема да кертмәдем мин
Аның бу төн үләсен.
Разведкадан кайткан чакта
Тиде немец пулясы.

Өс-баш юеш. Керәкләргә
Үзле балчык сылаша;
Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.

Кайгыдан каралып торган
Яшь-яшь нарат төбенә
Яшь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.

Яшь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми,
Көзге төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

*1942*

ләре иҗатына этәргеч була бит ул... Чордаш әткәйләр, фаҗига диңгезенә төшеп, безне коткарган...

## Илһамым — канатым

Әнкәсенә ияреп, сап-сары бәпкә-йомгаклар тәгәри-тәгәри кагынганны яратып-көлемсерәп күзәтәсең. Кая әле бәләкәчләргә очу — каурыйлары томшык төртеп кенә килә ләбаса. Канат юк, ә төбендә-тамырларында очу дәрте, биеклеккә омтылу үсә! Каян беләсең, дисәләр, үзем кичердем, дия алам.

... Иртән уянып урамга чыктым. Күзләрне чагылдырып-йомдырып кояш шаяра, ачуланмыйм, көләсем генә килә. Тәндә шундый рәхәт җиңеллек! Чирәмнән яланаяк йөгереп китәм, йөгерәм-йөгерәм: кызурак! Тагын да тизрәк! Кулларымны селкеп кагынам, алар канат — мине җирдән күтәреп алыр! Менә хәзер очып китәм! Үрдән йөгереп төштем, күтәрелә алмадым... Ник әле болай дип гаҗәпләнеп, нәүмизләнеп калдым: оча алам ич, ничек җиңел очкан идем! Бүген, бүген... төшемдә булган икән шул. Өнемдә дә очармын сыман, сикереп-сикереп йөгереп карыйм — юк, булмый...

Оча алмадым, ә менә күңелдә илаһи ашкыну — биеклеккә ашу рәхәте хозурлыгы ымсындырып калды, мин аны татлы серем итеп күңелдән кичерәм. Төшемне әнкәйгә сөйләдем.

— Үсәсең, улым, үсәсең! Үскәндә шулай була! — диде, куанып. Шуннан соң мин төшемдә кайчан очармын икән дип көтә торган булдым. Очу дәрте — илһам булган, нарасый-бәпкә күңелендә, ана карынындагы яралгыдай җан кереп үзен сиздергән... Шигырь яза башлагач кына төшендем.

Илһам — күңелнең канаты. Адәми зат та кайчандыр очкандыр, очу теләге өннән төшенә күчеп калгандыр... Җәяү йөрергә калгач, иңдәге канатлары җанына сеңгәндер. Сеңгән дә — илһамга әверелгән, шул канатлар күңелне биеккә дәшәдер...

Адәм баласы әле һаман да очмакчы... Әнә, сабыйлар йөгерә дә йөгерә — очып китәрмен дип ышана. Мин үзем дә йөгерергә яратам, мөгаен, очу ләззәтен тойдырган өчендер. Кошлар да җирдән күтәрелер алдыннан кагынып-йөгереп ала. Бездә очуның шул беренче өлеше генә сакланган... Күккә, биеккә күтәрелү кадәресе илһамында — күңел канатларында.

Нарасый чактан бирле төшемдә очам. «Үсәсең, улым», — дип үсендерергә инде әнкәй дә юк. Ул әйтсә дә, шаярту булыр иде: үсәсен үстек, өндә йөгереп, төштә очып инде оныклар үсә. Ә мин һаман очарга яратам — төшемдә әле дә очам. Белеп торам, илһам уята, бәхетле көнем бу, каләм канатланган! «Үсәсең» дию өлкәнәйгәч тә дөрестер: күңел үсә! Әллә сабыйлыктан аерылмауммы? Шулайдыр, әнә бит соңгы елларда төштә очуым — ниләр кичерүемне, аерыласы килмичә, кәгазьгә күчереп барам: сакаллы сабый түгел диген... Канатлар салынмасын, өмет сынмасын: яшәү — үсү әле ул, очу!

## Диңгез күзе

Чогырчакта, Габдуллалар бакча башында серле бер чыганак бар. Тирә-юнe сазламык, кое авызы чаклы мөлдерәмә тулып, ташып тора. Таяк батырабыз — буйламый, колга төшерәбез — төпкә җитми, пылт итеп кире сикереп чыга!

— Төпсез бу!

— Диңгез күзе диләр аны...

— Астан дингезгә тоташкан ди!

Дингезнең үзен күргән булмаса да, галәмәт зур икәнен, очсыз-кырыйсыз дигәнен ишеткән бар. Карап ярлары күренми ди! Тирәнлеккә дә тегермән тобасы гына түгел инде ул Каф тавы артындагы дингез. Шунда ук барып тоташты микәнни? Чогырчакта тирбәлеп торган ул тирә куркыта — үлән тамырлары өзелеп, төшәрсең дә китәрсең, суырып алыр да йотар... Ә бит тып-тын тора үзе. Эңгер-меңгердә, дию пәриенең сыңар күзе сыман, шомлы карап озата... Бусы мин ялгызым чакта. Малайлар белән килгәндә төрле сүз була:

— Дингез күзе түгелдер...

— Ә ник суы кара? Кара дингез кебек булганга!

«Дингез күзе» хыялны кузгаткан, әкиятне чын дип таныганбыз. Суы кара күренүгә торфлы җир сәбәпчедер. Ә бит әүвәл-әүвәлдән ышанганнар, «дингез күзе» дип йөрткәннәр, без уйлап чыгармадык. Хыялый җаннар элек тә булган ла, шулардан калган гыйбарә. Дингез күреп кайткан авылдаш атады микән? Әллә бик күрергә теләүчеме? Бәлкем, борын-борында дингез якларыннан күченгән кавемдә сагыну-юксыну булып яшидер? Ни булса да, гадәти күзләр белән карамаган борынгы авылдаш: дингез күзе белән — тирән вә зур итеп күргән...

...Шактый кайтмый торганнан соң авылны сораштырам, «дингез күзе»н дә искә алам. Кордашым аны... белми! Онытхан!

— Хәсән тегермәненә барганда, сукмак буенда гына! — дип тә карыйм. — Габдуллалар бакча башында!

Юк, искә төшерә алмады! Чирмешәндә тегермән буалары беткәч, болыннар корыды, «дингез күзе» дә йомылгандыр... Хәтергә дә кагыла икән сулар саегу!

«Дингез күзе»нә мин шигъри күзләр белән караганмын. Кара дингез буена барган саен искә алдым. Чын дингезнең исеме «кара» булса да, суы зәп-зәңгәр иде. Зәңгәр иде дингез күзе. Төннәрен кара була — бусы инде күзен йомган чагыдыр...

## Патефон җырлары

Кинода утызынчы еллар сурәтләнгәндә, патефон күренми калмый. Кара тәлинкәләр чайкала-чайкала әйләнә, җыр бөртекләрен сөреп йөгергән энә шытырдый, карлыккан, тыенкы-басынкы тавыш яңгырый. Узган гомер, сагынычлы елларның үкенечле авазы ул, җанга якын, кадерле. Безнең өчен генә шулайдыр — күңел «тәлинкәсе»нә ядкарь булып сызылган...

Балачакның шул могҗизасын бер көнне әткәй күтәреп кайтты, пате-фун дигән яңа сүз белдек. Мохтаҗ әйберләр дә бар, ә менә күңеле тылсымлы тартмага төшкән. Үзе уйный, үзе җырлый, искитмәле! Җырчысы шундадыр дип үрелеп-үрелеп караган бер мин генә түгел идем...

Тыңларга тирә-күрше керә, суга баручылар туктала. Каракучкыл елтыр тәлинкәне әткәй әйләндереп-әйләндереп алыштырып тора. Таныш җырлар да бар, без ишетмәгәннәре дә: татар, башкорт җырлары, урысчасы — бигрәк тә Русланова истә...

Патефон белән эш итәргә әткәй мине дә өйрәтте. Борып җиткермәсәң, мәзәк кенә, сүрелеп-сузылып кала җыр, ә тоткасын әйләндерсәң кызулап, дәртләнеп-сөенеп китә. Артыгы да ярамый, пружинасы шартласа — бетте, — диген. Шуңа күрә ачкычы буй җитмәслек урында — почмак ишеге өстендә. Буй җитмәсә, таяк җитәр иде дә, ярамый — таяк ул ике башлы...

Җырга ияләшкән апалар әткәй югында да килә, кайтканын көтеп ачкычка текәләләр. Менә берсе көрсенеп куя:

— Тавык мие әчкәннәр инде без, и наданнар — шушы машинаның рәтен белмибез...

— Без булдырырдай түгел шул,— ди өметсезләнеп ахирәте.— Без инде шул калдырча өйләндерсәк кенә.

— Ә мин беләм...— дим тыйнак кына.

— Кит аннан, булмас ла!

Урындыкка бастым да, алдым хикмәтле ачкычны, аллага тапшырып.

— Бер булганнан була инде — Галинең малае да башлы! Карасана, тәки җырлата! — дип мактадылар. Бер мактадылар, ике... Өч дигәндә көч килде, үсенеп киттемме — шарт пружина!.. Җыр өзелде, тыңлаучылар шуен-шуен таралды, патефон белән икәү генә калдык. Нишләргә? «Башлы малай»ның башына уй төште. Соң ул пружинаны алып кына карыйсы ла! Берәр җире ычкынгандыр, кая әле... Менә шунда, икенче... «шарт», икенче хатам... Сикереп кулдан атылып, сүтелә-сүтелә зуп-зур булды, калае борынга чиртте... Инде оясына сыймас — очын яшереплек түгел. Язын ишегалдында әрле-бирле чабып, шатлыгыннан шашкан бозау сыман бирешми — кертеп кара син аны киртәсенә...

Әткәй дә тыярлык булмады ул пружинаны. Тынды патефон, үпкәләде җырчылар. Алай да, күңелдә калган лабаса! Тәлинкәләр тузан җыеп ятса да, күңелдәгесе әйләнә: җырның әле берсе, әле икенчесе яңгырый — кушылып үзем дә көйләгән булам.

Төзәттереп тә карады әткәй, тик инде кызыгы бетте бугай, сатып ук җибәрде. Бәлкем, лисапит алырга акча җитмәгәндер. Анысы да әкәмәт — авыл аркылы берәрсе үтсә, артыннан йөгерәбез, калай койрыгына орына алсаң, бер дә харап инде!

Велосипедын да күрдек, тик ул, тиз йөрсә дә, әкерен әйләнгән патефонны уздыра алмады. Киресенчә, җилдә җилеп барганда таныш җырлар искә төшә:

Дәртле җырлар агыла киң күкрәктән,
Ташып чыга дулкын шикелле.
Уянсыннар кырлар,
Җырласын батырлар,
Хезмәт тавышы җирдә
Яңрасын!

Тәлинкәләр ватылып, югалып беткән, заманнар авышкан, әмма шушы «Уянсыннар кырлар»... бик кирәк чакта күңелдә яңарып әйләнә, дәртләндереп куя. Сәйдәш, Әхмәт Фәйзи... Патефон тәлинкәседәй Җир әйләнгән, җырлар алмашынган, әмма югалу-ватылудан калган беренче көйләр тансык. Юкса җырларны бик тиз алыштырып оча заман тәлинкәләре. Истәлек «тәлинкәсе» озак уйный торганнардан икән...

Мәшһүр Сәйдәшне илленче елларда күреп, атаклы көйләрен нотага төшергән, илаһи таягы белән дирижерлык иткән нәфис кулларын тотып күрешермен дип кем уйлаган... Язмыш тәлинкәсе әйләнеп, Әхмәт Фәйзи беренче шигырь китабыма фатиха бирер, дип беркем әйтә алмас иде. Кош теледәй җыентыгымны «Яңа көйләр» дип исемләргә җөрьәт итүем дә яшьлек шаукымы. Аларның очы газиз моң чыганакларына тоташкан: «Уянсыннар... җырлар!» — дип дәртләндереп торган, яңа Илһамнарны тудырган. Салих Сәйдәшевнең 90 еллык юбилеендә бу җырны моңдаш чордашыбыз Илһам Шакиров башкарды. Теге, патефонлы елларда ул да бишектә тыңлап тирбәлгән...

## «...Иман юлы тап-такыр»

Ир затлары мәчеткә җомга намазына җыела. Ишектән кергәч тә кызыл эчле галуш, киез каталар тезелгән булыр. Картлар изге йортта оекчан йөри, йә тула оекчан. Малайларга ияреп мин дә бер-ике тапкыр тәвәрих тыңларга бардым. Мактансаң, савaплы эшнең

әжере бетә, җае килгәндә генә әйтүем... Тантаналы тынлыкта ярым пышылдап, сабыр гына гәпләшәләр:

— Кычкырып сөйләшмә, фәрештәләрне куркытырсың, иман качар!

Тәвәрихта картлар нишли, шуны кыланасың! — иярүе читен түгел, чос кына бул: иртәрәк калыкма да, сузаеп калма. Догасына ук ияреп булмый, эчтән колһуалла белән әлхәмне тәкърарлыйсын. Ирен кыймылдау хак булсын — күңелең изгелектә булгач, ярый. «Ят та тор, ят та тор, иман юлы — тап-такыр», — дигән сүзләр — безләргә төбәлгәндер. Кайчан бетә инде бу, дигән түземсез уйлар белән шайтан ялгыштырмак булса да, яту-тору кадәресен җиренә җиткерәбез, анысы: тезләнсәк тә, картларныкы ише буыннар шыртламый. Бүтәненнән сакласын... шыртлап тәһарәт сынмасын... Хуҗа Насретдин сыман. Чү, шайтан тагын шул мәзәкне искә төшереп көлдермәкче...

Әткәй, Сафа абый, Хатип абый төрле китаплар укый, әкият сөйли. Дога өйрәтү тәтәйләр, әнкәй һәм апа вазыйфасы дип беләбез. Ятлаталар, кабатлаталар, аптыраталар, тәмам йоклаталар. Күңелгә сеңгәнме дип сынап-сорап карыйлар. Үзләренә мәчеткә керергә Коръән кушмый.

## ХӘТЕР



**Гадел Кутуй**
(1903—1945)

### Туган ил

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәр чакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың.
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар.
Бүген дә әле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

*1944*

Коръән Хафиз кушмаганны совет кушты, мөнбәрдән хәзрәт төште, манара киселде — шау-шулы мәктәпкә әверелде мәчет. Кыска-кырыкмыш чәчле, кызыл яулыклы укытучылар тык-тык басып керде, чәрелдек кызлар тулды. Андагы чыр-чу, әвәрә килү, әрле-бирле йөгерешкә түзәрлекме — фәрештәләр беренче тәнәфестә үк кул селтәгәндер. Иман да качкандыр — Имамнар, Исламнар, Инсафлар, Тәүфикъләр шаулап-дөбердәшеп йөргәндә чыдарлыкмы! Анда, зиһендә пышылдап яткан иске әлхәмнәрне кысырыклап яңа җырлар шаулый:

Без туганбыз Октябрьдә,
Без — Окбярь баласы;
Октябрьдә туганнарның
Ленин була бабасы!

«Ә Зиннәт бабам? Һидият бабам?» — дигән уемда тукталып торган идем дә:

— Һидиятуллин! Ник җырламыйсың! — дип, тиз айныттылар. Кешедән калышма, күмәк җыр бу! Бу җыр турыдан-туры миңа кагыла, мин ул Октябрьдә туган, бәйрәмендә. Әткәй:

— Октябрят кушам! — дип йөргән. Октябрьнең үзенә дә унбер генә яшь булган ул чакта...

— Малаең гомер буе үпкәләр, бүтән исем тап,— дигән дуслары. Ә Югары Балтайдан килеп эшләүче читават Фазыл абый:

— «Шәүкәт» куш,— дип киңәш иткән. Мин белгәндә дә эшли иде әле, Фазыл абыйга рәхмәтлемен. Үз исеме дә матур, фамилиясе бигрәк тә: «Сәйдәшев»! Мин үземне бер дә бүтән исем белән күз алдыма китерә алмыйм — аннары мин булмыйм бит инде ул?! Кешенең иманы да шулай аерылмас булырга тиеш икән.

## Мәхәббәт догасы

Хатын-кызга мәчет бусагасын атлап керергә ярамый. Җыелыйк дисәләр, берәр иркенрәк ызба гына кала. Апа-абыстайлар аерым, кыз-кыркын үзләренә. Болары аулак өйдә дога укырга җыелмый, уенда-гамендә вә гамәлендә мәхәббәт догасы: җыр, бию, гармун, егетләр. Савап кадәресе ничектер, гөнаһлары сизелми сыман...

Апа-абыстайлар да аулак өйгә җыела: ирзат, кайнатай сәфәргә, йә базарга киткән көн була ул. Алдан киңәшеп-килешеп шул көнне тәгаенлиләр, кемнәр буласы, кем китап сүзе тыңларга маһир. Өйнең дә тын почмагына сыярлык — күбәү булмыйлар. Тугани аптый гыйлем иясе, укымышлы — көйләп торып, моңланып укып җибәрә... Яулык чите белән күзләрен сөртеп көрсенеп куйсалар, искә килергә җай биреп, көтебрәк тора.

Иң кызганыч — Йосыф кыйссасы. Кайта-кайта уйлаткан, җәлләткәне шул. Аның көйлесе дә бар әле. Зиннәт бабайларда ишеттем, тугани аптый кулында шул китап: бик кадерләп, дога кылгандай теркәлгән кушучына салган иде. Кат-кат укылган битләре саргайган, төбеннән кубып, тегәрҗептә чак эләгеп тора. Сатира апты сулышы-тыны белән өреп кенә ача аны... Коръән — әфтияктәй изге китаплар рәтеннән икәнен күрәм дә, мәчеттәге сыман тынып калам. Мондый китапны тәһарәтең булса гына кулга алу фарыз икән. «Бүз егет», «Кисекбаш» дигәнне дә шунда ишеттем.

Ничә җыелдылар микән, озак көйләде аптыебыз Йосыф кыйссасын — бүленеп-бүленеп тыңларлык икән ул. Күргәнем бар, дога укыганда, мөнәҗәт әйткәндә ахирәтне уйлап әбиләрнең йөзенә күләгә төшә, сабырланып, фани дөнья мәшәкатеннән ваз кичеп утыралар: үлем-жите-

мне искәрткән, ходай каршына барасы бар ла... Ә менә Йосыф кыйссасын тыңлаганда бүтәнчәрәк, мин моны сизеп алдым. Чаршауны тартыбрак, уртак серләре бар сыман, яшеребрәк... Тугани аптыйның атлап йөрүләре дә җәһәтрәк, елмаюы тыенкы булса да куанычлы. Кызлар җыелып өлгергәч, менә-менә ишек ачылыр да, егетләр керер дип көткән чак дулкынлануы иде... Инде китап битләрен ябып, матур сүздән яктырган битләрен сыпырдылар — дога кылдылар. Күтәренке иде күңелләре, дәртле иде сүзләре. Бер әби кайтырга кузгалганда, тәртип өчен әйтә торган «һай, билем оеган»ны онытты, хушлашып бусагагы атлагач, мич арасына сөялгән тәсбихтай шомарган таягын искә төшерде...

Әлеге кыйсса да дога дип белә идем. Дога икән, мәхәббәт догасы, хатын-кыз күңелен хуш кылә торганы. Үкенечле, сагышлы, яшь гомеркәйләрне сагындырганы... Гасырлар буе телдән-телгә, күңелдән-күңелгә, буыннан-буынга амәнәт итеп әбиләр, әниләр саклаган аны. Ах, шунда утырган булсам — күпме тыңлый алган булыр идем. Ахирәтләре янына — әлеге «мәчет»кә бу юлы ир затлары сыймый иде шул. Без малайлар да андый чакта ир кәмәше бит. Кулга бирәр тәмле нәрсә тоттырып, юмалап-җайлап урамга озату ягын карыйлар. Шулай да, бер иргә яраган анда катнашу, тик соңлап белдем аның исемен, язган кешесе ул — Кол Гали. Адаш бабай. Моңыбыз, мәхәббәтебез адаш булган бабай. Татар моңын адаштырмыйча җитәкләгән бабай. Безнең шәҗәрәләр, өммәтебезнең тамыры аңа тоташа, аның аһәңнәренә, аның илһамына, мәхәббәтенә...

## «Тешкараны чыгарганнар...»

Ак тешләр белән мактанабыз, таза тешләр — матур! Кап-кара негрның ак тешләре балкып тора. Ә менә безнең әбиләр тешне... каралта иде. Үзем белгәннән бирле шулай булгач, гаҗәпләнмим: кара йөгерткән көмештәй килешле. Баштарак мин әбиләр кара тешле була дип уйладым... Теш порошогы, щеткасы дигән нәрсәләр юк, намазга аруланып бисмилласын әйтеп кизләү суы белән авызын чайкаган да — вәссәлам. Ул хакта артыгын сөйләп «авыз чайкап» тормаган. Тешкара ягу — тешне чистарту булган, нык-таза саклаган. Шәрекътән килгән, әлмисактан булган гадәт икән. «Искелек» дип, белер-белмәс күләргә — «теш агартырга» яратабыз. Баксаң, ак-таза тешләрең өчен үзең дә әбиеннәр тешкарасына бурычлыдыр әле.

Аулак өйләрдә кыз чакта алар тешләрен елтыратып утырмаган. Тартынып елмайган уймак авызны яулык чите белән томалаган. Алай да тиешле кешесенә күренгән дә, гыйшык утында яндырган. Бу җырны ерак бабамнарның берсе егет чакта әйткәндер:

Тешкараны чыгарганнар,
Тешне каралтыр өчен;
Яр сөюне чыгарганнар
Йөзне саргайтыр өчен...

Бизәнү-ясану, киенү-чишенүгә мода үзгәрә килә, җәйге-кышкы көннәр сыман инде: озая да кыскара — әшхәрәдән тәшхәрә... Хәзер әнә кызлар яңак алсулатып буяу сөртә — оялчанлык билгесе имеш, үзләре кызара да белми... Модалар үзгәрә, әхлак тәртипләре дә бүтәнчәрәк. Җырлар да яңара, әнә бит, «Каш карасын чыгарганнар кашны каралтыр өчен» дип җырлыйлар. «Йөзне саргайту» чаклысы үзгәрми: әле дә гамәлдә, әбиләр яшьлегеннән килгән ярату хисе һаман да бер... Һай, шулай микән, дип шикләнә дә калдым: ул чакта тешкарасы астында ак тешләр булса, хәзер тыйнаклык ялангач бугай...

Аның эштән кайтканын көн дә күрәм. Җәйге челләнең куырган чагы, мин күләгәдә капка төбендәге эскәмиядә утырам. Көтүдән качып кайткан бозау да шунда сыенган. Усал этләр юашланган, гайрәтле әтәчнең дә томшыгы ачык, күзен ак элпә каплаган... Әнкәй нәүрәптән катык алып чыгарга кушса икән! Салкын карга басып, үкчәне салкын пешергәнче рәхәтләнеп торыр идем... Елга каршыда — аякны суга төшереп утырасы иде дә, ирендерә. Әнкәй дә, якын барма, дип кисәтте. Бөтен авыл күләгәгә поскан шул вакытта күренә ул, төшке ашка кайтуы:

— Нихәл, Ситдыйк абый!

— Бигәйбәт әле, наным. Утырабызмы?

Каш сикертеп көлемсери — берәр мәзәк әйтер сыман. Кайчакта дәшми дә уза, арыган буладыр. Аркасы тирләп, тузанланган күлмәгенә, дегет шомарткан чалбарына карап калам. Кояшта пешкән җилкәсенә, чәчләренә башак кылчыгы сарган. Өйләре тау башында, безнең яннан үткәч әкрен генә шунда күтәрелә. Артка куйган кулларында чыбыркысы. Калдырып йөрдем юк — сигезләп үргән, еландай елкылдап торган юрмәсалават диләр аны. Безнең хыял инде, буе җитсә кем үрелмәс... Ситдыйк абыйны тауга менеп күздән күмелгәнче карап озатам. Әткәй аны гел тырыш кеше дип телгә ала. Ул арып-талып кайтып бара, мин тик утырам... Оят, нәрсәдер эшләп акланасы килә, оеп утыра димәсен. Тагын күзенә чалындым, кузгалырга өлгерә алмый калдым — төшке аштан китеп бара...

— Утырабызмы? Чеби чыкмыймы әле?

Беләм инде, имеш, ояда утырган тавык сыман мин... Шушы кайнар көндә ялан кырда, кояш астында эшли Ситдыйк абый. Кич кайтканда да абайлап калам, ә менә иртән киткәнен күргәнем юк, уянмаган булам. Бөтен авыл йоклаганда, әнкәйләр көтү куганчы ук торып китә ди...

Җир эшендә Ситдыйк абыйлар кирәк, җаны тарткан, кулы яткан эше, яшәү рәвеше ул аның. Шуның өчен туган, шуңа сәләтле, дәртле, аңардан уздыручы юк. Тырышып-тырмашып җиргә ябышкан нәсел. Әтисе дә, бабалары да шундый булгандыр. Шулайдыр, әнә малае да үзе сыман, тикмәгә Ситдыйк Рифкате, димиләр — ата баласы. «Атказанган авыл хуҗалыгы работнигы» дигән кәгазьдән мактаулырак ул исем.

Кечкенәрәк буйлы Рифкать тау башыннан йөгән тотып тәгәрәпйөгереп төшә. Тере малай, тиз эшләр, җайлы эшләр — печеп эшләр, диләр безнең авылда. Бер тирәдә җир сөргән чаклар булды. Атлары да әйбәт, дирбиясе ипле, шома кистереп салган буразналары җайлы аның — тере сыман ялтырап ята... Сабаны да көйле, эше көйле, аның кулында барысы да көйле. Без дә кыймылдаган булабыз, безнең атлар да тик тормый, ә ул әйләндереп кенә сала гектарны! Үзе сукалап караган белә — шактый ул гектар, ә Рифкать арттырып та куя. Без эленке-салынкы күренәбездер, мыштырдауга эче пошадыр. Җирне дә илһамланып, тәм табып, яратып сөрәләр! Аталы-уллы алар минем күңелдә эшчәнлек үрнәге булып калды. Тау башы — яшәгән урамны гына түгел, аларга лаеклы биеклекне дә күрсәтәдер...

## «Югарочтан түбәночка...»

Бу җырны безнең авылныкы дип беләм, минем турыдадыр:

Югарочтан түбәночка
Агып төшә йомычка;
Юк йомышларын бар итеп,
Нишләп йөри бу очта?

Язгы, җәйге яңгыр суларында йомычка агызып уйныйбыз. Йомычкадан узып мин йөгерәм. Йомышка да йөгерәм, йомышсыз да. Югарочта — әткәй нигезе, анда Латифа тәтәй. Түбәночта — әнкәй нигезе, анда Зиннәт бабам, Миңсылу тәтәй. Ике очта да үзем сайлаган, иләшкән бизәкле агач кашыкларым бар...

Латифа тәтәй Питербурны күргән, Миңсылу тәтәйнең Ялчек базарына да чыкканы юк. «Өй кошы» булган — бабай ат җигеп, куна-төнә еракларга сәфәр йөргәндә, балаларны канат астына җыеп торган. Әнә ул түрдәге сәке өстендә шыпырт кына тәсбих тарта. Тамырлы, ябык беләгендә, кызыл, яшел ташлы беләзек шуып йөри, толымында көмеш чулпы, хәситәсендә әби патша, сакаллы патшалар төшкән көмеш тәңкәләр. Карап бетерерлек түгел, елларын карыйм — борынгылар. Тәтәйне кем Миңсылу ди, кем — Нәүбаһар...

— Мулла кушканы — Нәүбаһар,— ди тәтәй, мин сорагач.

— Ә ник Миңсылу диләр?

## ХӘТЕР



**Абдулла Алиш**

(1908—1944)

### Үзем турында җыр

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.

Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип.
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем иректә булсын, дип.

Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә,
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

*1943*

— Миң чыкканга... Каты авыргач, исемен күтәрә алмады, дип алыштырганнар, авыру-сырхауны адаштырырга...

— Авыру адашамы?

— Нәүбаһарны эзләп килсә — Миңсылу икән дип, китеп бара. Шулай исән калганмын...

Шул ук хәл әнкәй язмышында кабатлана. Мулла кушкан исеме Хәлимә, Миңлебикә дип үзгәрткәннәр. Бикә диләр иде кыскартып. Соңыннан паспортта Хәлимә булды, тик ул әнкәй исеме түгел сыман, күнегә алмадым. Мулла абзый Әсгате әле әнисе исемен бөтенләй белми икән... Ничек белсен — «абыстай» дип дәшә бит барысы да! Кереп тиз генә сорап чыкты — «Мәсрура» икән...

Миңсылу тәтәйнең тавыш күтәреп сүз әйткәнен хәтерләмим. Ахрысы, гайрәтле бабай авазы өстенлек иткәндер. Холыксыз түгел, әмма кайчакта кызыбрак китүчән гусар... Капка төбенә кайтып җитә, кайнар атлар тапталып тора, бабай да юл дәртеннән суынмаган. Тәтәй тәрәзәдән күреп капканы ачып өлгерергә тиеш! Читкә тайпылып кал — үрәчә кагып китүе бар! Ашкынып кайткандыр, сагыну, ярату, көнләшү бергә... Әбиең-бабаң кайчандыр егет-кыз булган лабаса! Кыркулыгы да — ярату галәмәте. Миңсылуы бакчадагы мунчага алданрак китсә:

— Кем янына ашыгасың! — дип, әллә шаярта, әллә битәрли. Тәртип — бергә барырга тиешле!

Миңсылу тәтәй — изге җаннардан булгандыр. Ил анасы буларак, бал кортыдай ишекле-түрле өйне барлап, кайгыртып киләп сарган, көне — гомер тәүлеге шулай узган. Йорт үзе дә умарта оясыдай гөжләп тора, без, оныклар, көннәр буе чыр-чу килсәк тә, чытык чырай күрмәдек. Тәтәйдән җанга тынычлык-иминлек иңдергән сабырлыкка сыенсаң, бабайның бер мәлгә елмаеп, күз карашы белән иркәләвен тоясың. Эштә мавыкканда:

— Ипле тот! — дип, кырыс кына кырт кисеп куяр — җебек булма, егет бул! — дип өйрәтүе. — Капчык бавын чиеләп бәйләмә — чишүчегә читен булыр. Элмәкләп куй! — дияр. Шөкер, тормышлары тигез, имин булды. Бизмәннең бер башында тәтәйнең күркәм сабырлыгы, икенче якта — бабам тынгысызлыгы булган, бәрәкәтле нигез иде.

Ата гайрәтле булса — бала гыйбрәтле була, ди иде әнкәй. Оясында шуны күргән, үзендә дә шулай булсын дигән. Ярату — һәрчак баштан сыйпау гына түгел. Ярату, эшкә-тәртипкә, димәк, бәхеткә өйрәтү дә! Әти-әнисе канат астында үскән кеше бәхетле. Әби-бабасының, ягъни, дәү әтисе-дәү әнисенең җан җылысын, шәфкать-миһырбанын тоеп үскәннәр — икеләтә бәхетле. Тормышның түбәночыннан шулар күтәрә, гомернең югарочына чаклы шулар озата...

## Бабай-гусар

Гаскәри чакларын искә алырга ярата ул. Какча гәүдәле, хәрәкәтчән бабай тагын да төзәеп, дәртләнеп китә:

— Гусарски полкта хезмәт иттем! Палкауникны йөрттем — күчер идем! — дип, кузлага утыргандай, дилбегәсен һа-ай дип тартып, аргамакларына чөңгереп җиффәрә дә, кагынып-калкынып тыгыз җилгә каршы оча башлый... Ат — татарның язмышы ,бар дөньясы инде, ир канаты — ат булыр! Тройка җигеп йөргән елларын ул эшен очлап куйган кәефле чакларда сагынып ала. Ә нигә, мактанырлык та бит, полковниктан да алда — биектәрәк утырган! — дип күз алдыма китерәм мин. Тагын шунысы кызык тоела — гусар атлары дилбегәне бушаткан саен катырак чаба икән... Дуламасын дисәң, һәрвакыт нык тоту кирәк!

Туганнар, дус-ишләр җыелган мәҗлестә ул аргамакта очып кына калмый, «җиргә төшеп», сугыш уены да күрсәтә, анысын да өйрәткәннәр.

Әлбәттә инде бусы ачы бал әзрәк ирен чылаткач, яшәреп алгачрак. Андый табын уен-көлкесез, мәзәксез буламы? Ычтыкланып алучан холкын белеп, үзара көлемсерәп, көйли башлыйлар:

Айкап жибәр, чайкап жибәр,
Шул казакның камчысын;
Ал, күтәр дә эчеп жибәр,
Калдырмыйча тамчысын! —

дип, Сафа абый «камчыны» гусар кодасына суза. Бабай аңа җырлап җавап кайтара:

Алай түгел, болай ул,
Арпа түгел, бодай ул;
Бар туганнар бергә килгәч,
Менә шулай була ул!

Сафа абый да салпы якка салам кыстырырга оста:

Син алай да әйтәсең,
Син болай да әйтәсең;
Фал китабын ачтың мәллә,
Зиннәт тә генәй кода,
Бигрәк дөрес әйтәсең! —

дип хуплап куя. Бабай уенны күтәреп ала, тамашачы барда күренеп алу ярый. Өлгереп җиткән шул мәлдә Ярхәм җизни, беркатлыга салышып, сорап куя:

— Кода дим, сугыш уеннарын оныткансыңдыр инде?

— Бу арада эше күп — өшәнгәндер... — дигән була, яклагандай, Сафа абый. Шул җитә кала:

— Кая әле! — дип иданнең ачык җиренә атылып чыга бабай, ул арада кемдер мылтык көтеп сузылган кулына табагач тоттырып өлгерә...

Бер генә күрмәгән инде мәҗлес халкы бу уенны, кабат сорыйлар икән — ошатканнар, димәк. Үзләре мыштым гына, терсәк төртешеп көлешә. Мавыккан бабай моны сизмиме, сизеп тә үпкәләмиме — үзе дә тансыклап торган, ахрысы. Берсендә шулай, кыш көне була бу, күрше Сөнгатьләрдә мәҗлестә дә сугыш уенын сорыйлар. Беразрак кыстаткан итә дә ризалаша бабай. Хәрәкәтләре тиз, житез — күз иярми:

— Коротким — коли! — дип, алга омтыла да, җәлт чигенә. Һәм, кинәт бер йодрыкка тупланып, үз-үзенә команда биреп, алга ташлана:

— Длинным — коли!

Штык сугышында хәлиткеч мизгел шушы — йә син өлгерәсең, йә дошман! Күршенең табагачы озынрак булдымы, әллә түрләре таррак, әллә баллары мәкерлерәк... табагач-мылтык ике хат тәрәзәне тишеп, кар көртенә төшеп кадала! Мәҗлес халкы тәгәри инде, икеләтә канәгать:

— Менә чын гусар, ичмасам! Безне дә ектың! — дип мактыйлар. Бабайның чепи күзләре йомыла төшкәнме, бал пәрдәсе каплаганмы, мактаумы — тәрәзәдән җил өргәнне сизмичә кайнарланып басып тора. Җиңүче кыяфәтендә — кабатларга сорасаң, бүтән уеннар күрсәтергә әзер! Тәрәзәләр тагын бар бит әле... Йорт хуҗасы да сер бирми, түрдә өелеп торган җиде мендәрнең берсен бөгәрләп тәрәзәгә тыга... Уеннан уймак — тәрәзәдән табагач чыккан икән, бу эшкә очындырган Сафаның үзенә җыелгач та искә төшерер әле Сөнгать Бугаз: кисәү тоттырмагае гусар кодага!

Хәрәкәтле уен, бабайның аякларын язып алуы булгандыр — кем кемне шаярткан әле: сез оеп утырдыгыз, мин канны кыздырып, буыннарны язып алыйм, дигәндер. Аяк язу дигәннән, Зиннәт бабай сабан туенда да әкәмәт кыланып ташлады. Шулай, кулларын артка куеп, кызыклар тамаша кылып йөри икән. Менә бер якта яшь-җилкенчәк ярыша-ярыша озынлыкка сикерәләр. Күз төшереп ала да:

— Әлләни майтара алмыйсыз икән...— ди. Егетләрнең кытыгы килә:
— Әллә үрнәк күрсәтәмсең, Зиннәт бабай?— диләр, үртәп.
— Хи-хи, болай да ком җитәрлек монда,— ди, майтара алмаган берсе өстен кага-кага. Бабайга шул җитә кала:
— Ә без гусар чакта...
Сүзен әйтеп бетерми, йөгереп килә дә: һо — о — оп!
Авыз ачып кала егетләр — барысын да уздырды!
— Биеклеккә дә сикереп күрсәт инде,— диләр бу юлы шаяртусыз гына. Гусар бабай бусында да сынатмый. Бер җыелынган көе йөгерүгә дә барып килә. Юк, капчык киеп йөгерүгә түгел — еракка! Гусар дәрте капчыкка сыярмы — аңа иркенлек кирәк!
— Ай, рәхмәт! — дип озаталар җиңүчене, сөлгеләр бәйләп:
— Син кайта тор инде, бабай, яшьләргә бүләк калдырмыйсың ич!
Ул көнне бабай гусарски палкауник урынында үзе иде:
— Фәлән аршынга сикердем! — дип сөйләде.— Миннән уздыручы булмады!
Аршын кадәресен мин аңламыйм, әмма шушы сүзләре дөрес:
— «Бабай» дип каршыладылар, «абзый» дип хупладылар, «абый» дип котладылар!
— Тыйнакланма инде, әйтеп бетер,— ди күрше Кашәфетдин абый, кәефләнеп.— «Егет» дип озаттылар!
Авылдашлар шаһит — бер дә арттырмыйм. Холкы шундый, җанындагы егет-гусар сикереп чыкканда яшәреп китә. Әллә тагын, бәлкем, җаны яшь булганга гусар каны уянадыр? Ә бит яше дә җитмешнең өстенә «сикергән» иде ул чакта: аршын белән үлчисеңме, болаймы — ярыйсы инде. Бабай күңелендәге егетлек форсат кына көткәндер. Шунысына өч пошып тора фәлән аршынны озынлыкка сикергәнме, биеклеккәме — өзеп кенә әйтә алмыйм. Бабай хәтере юк, ахрысы, миндә, аныңча чыныгу юк. Гусарски полкта хезмәт итәргә туры килмәде шул...
Дөнья күргән бабай, нужа куган — ул чакта тимер юл мазар юк безнең тирәләрдә, кулда дилбегә булган, йөк тарттырып еракларга йөргән. Ә гусар дигәч тә, түр шкафтагы чәй, шикәр тартмалары артындагы коңгырт көрән чүлмәк шешә күз алдына килә — хәрефләре дә, сурәте дә чит илләрчә. Шактый гомерләр үткәч, Латвиядә очраттым — Рига бәлзәме булган ул. Балтыйк буенда янә бабайны искә алдым. Бакчасында үскән бал янында бальзам дигән ерак кунак та булган.

## Әкият янчыгы

Авыл кешесе эштә тирләп салкын тидерсә, утлы ләүкәдә чабына да, баллап-мәтрүшкәләп чәй эчеп төренеп ята. Эчтән «чабынып» салкынны куа, иртән — аяк өстендә. Бабайның чирләп урында ятканын белмим. Хәер, ничектер хәрәмләшеп, сырхау аны аяк чалып еккан иде бер.
Түрдә, чаршау артында бабай. Тамактан калды, күпләргә шифалы нәрсәләр дә күңелен ача алмады. Тәтәйләр им-томнар кылгандыр, догалар да укылды — авыру дигән «җенне» куып чыгара алмадылар... Бабайның тик ятканын күргән юк: хәрәкәттә — бәрәкәт, дип гел кыймылдар иде. Тавышы да торган саен әкренрәк.
— Аллам сакласын, белмәссен...— дип, әбиләр тәсбих шудыра башлады. Тавышы да зәгыйфь чыга бабайның, нидер әйтмәкче дә, сүзләрен оештырып җиткерә алмый:
— Гарифулланы...— ди.
— Кайсын? Укытырга — Гыйззәт Ґарифынмы?
— Ю — ук...
— Хөсәен Гарифынмы — ветсанитарны?

— Түгел...
— Әллә саташуы. Тагын кайсы булыр?
— Бүре...
— Ә-ә, шулай мени? Хәзер, хәзер!

Берничә йорт аша гына ул, килеп житә дә, сырхау янына үтеп, чаршауны тартып куя. Озак утыра, мыдыр-мыдыр нидер сөйли, дога укыймы? Колакка катырак әбиләр икеләнә:

— Дога дисәң, макәме үзгә...
— Дөньялыкта ни булмас, алла сакласын, бәхилләшәдер...

Ә Гарифулла чыкмый да чыкмый... Менә берзаман пәрдәне киереп торып ачып җибәрә, үзе елмаеп бабайга һаман нидер сөйләвендә... Ә бабай, бабаймы, калгып мендәргә сөялеп утырган да, елмая, күзләрендә гусарски палкауник кучерының дәрте кабынган!

Гарифулла абый — авылның атаклы әкиятчесе. Берәү авырса, төрләнеп тансык ризык сорар, ә бабайга әкият, мәзәк кирәк булган, шул килеште! Бүре Гарифы дип йөрткәнне белә әкиятче, бер дә исе китми. Адашлар арасында адашмас өчен тагалар кушаматны. Ни өчен «Бүре»,

## ХӘТЕР



**Сибгат Хәким**
(1911—1986)

### Фронтовик

Фронтовик кайта шәһәргә,
Кулында ярасы бар.
Яралы япь-яшь егетнең
Сөйгәне — җанашы бар.

Ул сөйләр сугыш турында,
Кызы тыңлаган булыр.
Читләтеп кенә үтәр дә
Сүзне бүтәнгә борыр.

«Бөтенләйме?» — дип сорар кыз,
Фронтовик: «Азга, — дияр. —
Кулларым инде төзәлә,
Соңгы кат назла», — дияр.

Илдә яу йөргән чагында
Ир кеше түзәрмени?
Аерылу җиңел түгел дә,
Кыз өмет өзәрмени?

Савыгып киткән егетнең
Бик чибәр җанашы бар.
Йөрәге читендә аның
Мәхәббәт ярасы бар.

*1942*

анысын әйтә алмыйм. Яратып сөйләгән әкияте «Ак бүре», шуна түгелдер лә? Һәрхәлдә, мин аңарда усаллык күрмәдем, киресенчә, халык күңелен көйләүче сүз остасы — тел бистәсе ул. «Бүре» дигәне дә борынгыдан килгән изгелек кылучы бүредер...

«Ак бүре»не кичләрен бүрәнә өстендә сөйли, эштән кайтып, ашап-эчеп алгач. Әкият әллә ничә төнгә сузыла, кич саен җыелабыз. Районга Гарифулла абый белән барганнар әйтә:

— Юл буе әкият сөйләп барды, сөйләп кайтты. Алай да бетмәгәч, капка төбендә атын туктатып торды. Гайнелбану аптый чыгып алмаса, тәки сөйләр иде әле! Район бездән унсигез чакрымда. Бару-кайтулар белән бергә ничә чакрымлы әкият булып чыга? Дөрес әйтә хатыны:

— Син үзең әкият, билләһи! — дип, бот чабып тора.— Кер инде, калганын үземә сөйләрсең!

Сугыш вакытында ун йортка бер агитатор иде. Килә укытучы кызый гәҗитләр тотып, укый башлый оетып... Егетләрнең күзе чибәрдә, ирләр күзе — гәҗитендә.

— Сораулар бармы, иптәшләр?

— Бар ие шул,— ди Гарифулла.— Әкиятең бик ошады... Шул кызык җирләрен калдырсаң иде. Бергәләп, якыннанрак танышыр идек...

Агитатор игътибарга шат, әлбәттә. Эш шунда ки, тәмәкесен үстерә абзыйлар, дәүләткә дә тапшыралар, калганын төрергә кәгазь юк... Җиткезеп булмый: без янганчы тәмәке янсын дип, гел янчыкка үреләсең... Әбит уйлап баксаң, әле чиләк тотып күкәй җыйган, әле заемга кыстаган агитатор сүзеннән җанга җылы бармы? Әкиятченең файдасы күбрәк — гәҗит әкиятләренә караганда халык аңа күбрәк ышана. Тузга язмаганны сөйләсә дә яшерми — әкиятне әкият ди.

Патшалар әнә тәхет янында шамакай дип йөртелгән зирәк, туры сүзле мәзәкчеләр асраган. Халык-патшаның үз осталары булган — Хуҗа Насретдин, Әбугалисина авыл саендыр. Гарифулла абый шулар токымыннан, имен им иткән — Зиннәт бабамны да терелткән. Чирне куарга тәнгә мунча өстенә «җанга мунча» дигәне шушыдыр...

Үзе шаянга халык та наян, бурычлы калмый, «Әстәгыйфирулла» дип, саваплы булган саен Гарифулланы телгә ала. Әнә, каралтыда икәү: ире астан саламны чөя тора, хатыны өстә — өя тора. Егыла язды да, әдәпле генә әйтеп куйды:

— Чук... Әстәгыйфирулла!

— Өстә — Гайнелбану, аста — Гарифулла! — ди ире, бик канәгать, үзе уйлап чыгарган диярсең. Афзал хәзрәттән башка, әйтмәгән кеше юк моны Олы Бакырчыда. Башка авылларда ничектер, ас-өс кадәресен алмаштырып та әйткәлиләр... Аста кала торганнардан түгел, ни дияр Гарифулла? Әкиятле иреннәрен мөлаем тибрәндереп куя, әмма дәшми. Куеныннан Гайнелбануы чиккән тәмәке янчыгын ала: җырның ертыгы юк, мәзәкнең артыгы юк димәкчедер, күңелләрне күтәрә торсын! Безнең күзләр янчыкта — гадәти түгелдер, әкият янчыгыдыр ул, хәзер чишеп җибәрер...

## Бабай Коръән укый

Корбан гаетеннән кайтышлый бабай безгә керә, бүтән чактагыча түгел — тантаналы, горур кыяфәттә ул, гәүдәсе дә туры-төзрәк. Исәнләшеп, бәйрәмчә җыелган өйгә күз төшереп ала да әнкәй өстәл җәймәсен алыштырганны көтә. Бераз узалдына тынып-көйләнеп тора, күз кабаклары ябылган сыман... Аннары, мәкам белән, серле догаларын көйли башлый. Кат-кат тыңлаган булгач, таныш гыйбарәләр ишетәм, тик мәгънәсен белмим, тиешле дип тә уйламыйм — Корьән ул кешеләр телендә түгелдер — күктән иңгән Алла сүзе... Сүзләре таныш

булмаганга, илаһилыгы тынлаган саен яңара, ул сине буйсындыра: иманыңны яңарт, инсафлы бул, ди. Бу моң Тукайның «Көзге җилләр» шигыренә ялгана. Әткәй аны да Коръән укыгандай көйли. Аятелкөрси урынына тикмәгә шәмаилгә «Туган тел» язылмаган икән... Халыкның иманы ул, җирдә яшәргә, мәңгелектә нәсел-ыруы тереклек итәренә инануы. Безнең шкаф өстендә үрелеп алырдай төштә Тукай иде. Коръән сыман һәр ызбада булырга тиеш дип беләидем. «Әссәләмәгаләйкем», гарәпчә булса да, милли телемнең җан сакчысы икән.

Бабай Коръән укый, озак укый, тавышы көр, тыны үзгәрми, көе-моңы сүрелмичә тигез агыла, бер мәлдә тыныбрак кала, кулларын вәкарь белән йөзенә күтәреп, дога пышылдауга күчә, аннары ашыкмый гына битен сыпыра. Бусына мин дә кушылам, әнкәй әйтеп куйды, авыз эченнән бисмилламны әйтәм. Әнкәй бабайга сәдака бирә, шулай тиеш. Аннары өстәлгә яңа пешкән, әле беребез дә авыз итмәгән, табадан гына төшкән кабартма-юка, тәм-том куела... Бабай мактап ала:

— Камырың унган, кызым,— ди, яратып мина карый, кисәсеннән кабак орлыгы кушылган сап-сары чикләвек алып кушучыма сала, кесәмә тутыра... Белеп, көтеп торасың, ел саен кабатлана, әмма ел саен яңа бу бәйрәм! Тукайның «Бәйрәм бүген» шигыре дә, Октябрь, Май бәйрәмнәрендә җырланса да, «корбан гаете уңае илә» язылган. Татар баласының күңеле, халәте ул шигырьдә, мин туганчы ук каян белеп-тоеп, язып куйган? Коръән көйләгән бабай белән Тукай бергә — уртак милли хис какшамас булып күңелдә калган.

Бәйрәм юкта да, йортка иман иңсен дип, әледән-әле бабай Коръән укый. Әрвахларга багышлаганда ярты авылны санап чыгадыр: туганнар, кардәш-ырулар, тирә-күршеләрне телгә ала, мәрхүм вә мәрхүмә танышбелешләрен онытмый:

— ...шулар рухына багышлыйм, ходай ризалыгы белән, кабул кылсын,— дип тәмамлый. Үзем белгәннәрнең исән чакларын күз алдыма китерәм. Юк инде алар... Күңел нечкәрә, дога кылган кеше үзе дә сафланып каладыр... Дога ул мәрхүмнәр дә ишетә торган сүзләр дим...

Без бала чакта, укырга-язарга өйрәнгәндә «Сугышчан алласызлар» журналы чыга иде, исеме үк имәнгеч... Дингә көн бетте — егылганны тәпәлиләр... Халыкның гореф-гадәтләре, йолалары да мәчет манарасы белән бергә киселде. Үзебез дә, картлар белән сөйләшкәндә булсын, хәтта әниләр белән бәхәскә керешеп, оста телләнә идек. Имеш, «теге дөньяга» ышану юк нәрсә. Шулай да булсын ди. Әмма иманым — халкым иманында, борын-борыннан өзелми килгән, мирас булып күчкән инану-өметләрдә. Бусын беркайчан да онытмадым. Коръән сүзләрендә, Тукай шигырьләрендә ерак бабамнар моңы исән килгән... Пакъ җәймәгә тезләнеп, үз җанына йомылып бабай көйләгән аһәңнәр һаман күңелдә. Шаукымга бирелеп мавыккан, әтәчләнеп киткән чакларда чабудан тартып сабырлыкка өндәгән, юлдан яздырмаган кодрәт ул...

## Зират өстендә җиләкләр...

Бу арада бабайның ахирәт эшләрен кайгыртып йөргәнен күрә идем: картлар җыелып зират тирәсенә рәшәткә тоталар — имән баганалар, җепсәләр илтте. Беркөнне мине дә ияртте. Күпер чыккач та — зират каеннары. Үргәрәк күтәрелдек, уң кулда — Тәүгелде ягында, зират биләмәсе чигендәге үләнле канау янында туктадык:

— Менә бу урынны чамала,— дип, ул чакта зират читендәрәк, яңа имән багана, җепсәләр белән бүленгән кишәрлеккә күрсәтте. Анда — үлән үскән ике калкулык...

— Бусы әти кабере — Гали бабаң, бусы — әни, Гайниҗамал әбиең,— диде бабай күз карашы белән ишарәләп, ияк кагып. Мин беләм, монда

бармак төртеп күрсәтмиләр. Онытылып ялгыш кул сузсаң, бармагыңны тешләп, тфү-тфү дияргә.

— Менә монда — үземә, Миңсылуга урын алып куйдым...

Ни әйтергә белмим... Исән-таза кеше, үзен җирлисе урынны күрсәтә... Бабайга куркынычтыр дип, карасам — йөзе тыныч, тантаналы тыныч иде. Күзләрендә — кирәкле гамәлен башкарган кеше разыйлыгы, ирен читләрендә елмаю... Иплəп утырткан баганаларны сыйпаштырып, кытыршы кулын сайгактан шудырып ала — шырпы тырнарлык түгел. Нык, төз — боларда бабай пөхтәлеге, җиренә җиткереп эшләнгән. Күрдеңме дип, бәясен белеп, эшен дә күрсәтә... Үлем-җитем кирәк-ярагын кайгырту шомлы эш түгел, йоласы — соңгы туйга тыныч әзерләнә картлык. Кәфенлекне алдан хәстәрләсәң — гомерең озын булыр, ди. Бабайның урын алып куюы да шушы борын-борыннан килгән гамәлдер.

Язулы ташлар сирәк, киртәләр череп таралып, ияләре онытылып, йә калку-түмгәк, йә иңкү урыннар калган... Монысы да борынгы гореф-гадәт, билгесез булып югалсын: Җир үзе биргәнне үзе ала, адәм баласы Җиргә китеп, мәңгелеккә кушылып калырга тиешле ди... Ахрысы, нәселнәсәп хәтере таш хәтереннән озаккарак җитәр, чыдамрак булыр дигәннәр. Имән баганалар да гомерлек түгел. Бабам да, үскәч килеп таба алсын дип, «ахирәт йортын»дагы урынын күрсәтергә алып килгән мине...

Авылга кайткан саен әби-бабайлар каберен зиярәт кылабыз, рухлары шат булсын дип сәдака бирәбез. Күчтәнәч тапшыргандай, күңелең хушланып кала: үз жаның тынычлыгы өчен дә кирәк... Аяк астында каен җиләк тә җир җиләк — сак кына атлыйбыз. Монда үскән җиләкне ашарга ярамый — эчең авыртыр, диләр иде, хәзергеләр дә беләдер. Кып-кызыл җиләкләр — өзелеп сибелгән муенса мәрҗән, тәсбих дисбеләре сыман... Тере җиләкләр кояшта сәйләндәй җемелди, чык бөртегендә дымланып сүзсез генә күзгә карый. Бабай, әбиләр тирәнлегеннән — борынгыдан карый...

## Иң зур мирас

Чирмешәннең аръягында колхоз хуҗалыгы: ашлык амбарлары, кәнүшни, ферма, келәт, складлар. Ике арада күпер генә. Бригадир, ни йомышы булса да, бабайга килә:

— Коткарса Зәннәт абый коткара инде. Бөтен ышаныч — аңарда! — дип авызын ерып керә Хәсәнҗан бригадир. Йомшак ягын белә төлке: эшен күреп бәяләсәң, очынып очарга әзер карт. Гаепмени, тәкъдир иткәнгә сөенү ич. Коры «таяк»ка калган «трудден»нән бигрәк, хезмәтеннән, үзен кирәкле санаудан тәм тапкан.

Зәннәт бабай, чыннан да, коткара... Кыш буе баш күтәрми ул. Ике япьле көлтә сәнәкләре ясый, салам өяргә — өч япьлесен. Нәрәтне кәтми, көне-сәгате җиткәч кенә йөгерә башласаң ни майтарып булсын — алдан әзерләп, барлап куйган. Тырнавычлар да кулыннан үтә: какшаганын яңарта, яңаларын әмәлли. Иген җилгәрергә дип, кулга ятып торган агач кирәкләрен күр, тимер кирәкләргә сап, балта саплары, иген соскылары дисеңме — нинди җайлылар! Ни кирәген белеп тора, дистәләп, йөзәрләп әзерли ул аларны. Мәҗлестә тезеп-санап бирердәй җаен таба — эшенә йомгак ясап ала. Бер генә дә кабатламыйдыр. Бу гадәтен белгән агай-эне көлебрәк тыңлый, әмма ихтирам белән — бәһасы зур. Бил турайтмый эшләгәндә, баш күтәрми казынганда көткән бу көнне: матур итим, сокланып сүз әйтерләр, дигән. Ул сүстән ишкән бихисап тәртә баулары, капчык баулары, дилбегә, арканнар... Киндер талкып сүсен дә әзерләгән, ишкән, суга батырып юкә каезлаган, тимерчелеккә күмер яндырган. Куллары төен-төен сөялләнеп, бармаклары бөгелми башлагач, учларына кыстырып ишә иде, шул җаен тапканга да сөенә... Ә тәтәй кулында фарыз энәсе — капчык ямый, төзәтә, рәтли...

Такыр итеп себергән, җыештырган лапасына керергә яратам. Нинди генә эш коралы юк — һәммәсе күз алдында, ипле, үткен — үрелеп кул җитәрлек төшкә кыстырып куелган. Берсенең дә сабы бушап, кылтыймылтый килеп эчне пошырып тормас.

Утынга кайткан агачларны да җентекләп күздән кичерә, сайлап куя: бусы — нигезгә, бусы — тәрәзә яңагына ярар. Бездә бит сайларлык та, ботаксыз-нисез ыспай имәннәр: ипигә май яккандай юка итеп йомшак агачларга сылап кына затлы мебельләр ясыйлар хәзер алардан. Рәтсез күренгән куыш юкәнең дә үз урынын табар бабай — бал ләңгәсе булыр, ындырда көшел тутырырга подаука...

Күргән кеше кызыгырлык итеп, һәр эшне тәмләп, яратып башкара. Көн саен иртән ишегалдын себерә. Мин дә себерке алам, бабай янында тик торып булмый. Кызыктыра! Тик аныңча очып кына йөрми себеркем...

## ХӘТЕР



### Шәрәф Мөдәррис
(1919—1963)

### Ярсый йөрәк

Курай уйный Зөфәр. Борчу вакыт,
Килеп яттык без дә каршына...
Тышта ак ай. Дөнья моңсуланып,
Көмешсыман нурга манчыла.
Көйли Зөфәр моңлы «Минзәлә»сен,
Хәтерләтеп болын хуш исен,
Туган якның тугай, чишмәләрен,
Каләм кашлы кызын, дус-ишен.
Эх! — дисең бер шунда газапланып,
Тешең кысып тынга каласың...
Нәләтлисең немец палачларын,
Китергәнгә сугыш бәласен...
Якташларым җырга кушылдылар,
Курай уйный Зөфәр... Ярты төн.
Землянкада дус-иш, сугышчылар,
Тышта серле, моңсу, якты төн...
Фашист өерен кырып ташламасаң,
Эх, ничек соң иркен суларга?
...Таң аткач та һөҗүм башланачак,
Ярсый йөрәк бүген шуңарга!
Күп тә үтмәс, илнең тугай-кырын
Нурга бизәп таң да яктырыр...
Шул вакыт ул, уйчан курайчыбыз,
Пулеметлар җырын яудырыр.

*1942*

— Мафафалай тот — каты басма! — дип күрсәтеп бирә бабай, кулымнан тотып. Сыгылып-тирбәлеп торган каен себеркесен үзе бәйләгән, маяда тагын күп әле, ел әйләнәсенә житәрлек. Ындыр өчен дип тә хәстәрләгән — кайчан кирәге чыгарын, мохтажлык туарын чамалаган. Хәсәнжан кайчан керсә дә — әзер!

Булышсын, өйрәнсен диптер, миңа да эш табып тора. Эч пошырып калгып торганны, оеп йөргәнне яратмый. Үзең монда, күңелең тегендә булып, мәжбүри теркәлеп торганны, уең уеннан аерылмаганны тиз күрә:

— Йоклама! Мафафалай тарт! — дип кызып та ала түземсез, эш әпипәсенә биетә, әнә, пычкысы да жырлап тора! «Мафафалай» — менә шушылай дигән сүзе, тешләр сирәкләнгәч авыз бөрешәдер, әллә ашыгып әйткәнгә.

Эш тәмене бабайдан, әткәйдән өйрәндем. Нинди шөгыльне дә күңел жирендәгечә башкарсаң гына жан тыныч. Бер эштән куаныч икенчесенә дәрт уята.

Улы Гыйльмулла — тугани абый — шул каралтыда әтисе эшен өзмәде, хәзер йортта Расих оныгы хужа... Эш кораллары үз урынында, бабай куйганча — мин аларны таныйм! Берсенә дә тутык йөгермәгән, ялт итеп тора — оныкка та аларга тузан кундырмый. Тимерчелектә бабай үзе ясатып алган нәрсәләр бар, андыйларны кибеттә күрмисең, бабалар кулыннан күчеп мирас булып калган.

Хәрәкәттә — бәрәкәт дип, эшкә көйләнергә өйрәткән бабай. Ә бит яшәү тәме шул икән. Үзең булдырган эш белән юану, кешеләрне сөендерү. Шул икән бабай калдырган иң кыйммәтле мирас. Нинди һөнәр иясе булсаң да, шул сыйфат кына бәхетле итә. Улларым, кызларымда, оныкларымда бабам тырышлыгын танысам, сөенеп торам...

1943 елның җәендә, урманнан арба белән тартып ташыган корык сайгаклардан үзем корып куйган туры әвеслекне күреп куанган иде бабай! Багана дигәне дә сыек кына инде... Ул якларын «күрмәде», мин үсмерне йортта ир кеше итеп күрде, кулыннан эш килә, дип үсендереп җибәрде. Йөзендә жылылык, күзләре елмая, карашы белән сыйпый. Шуннан да зур бәя бармы: ул ни әйтер дип тырыштым бит үзем дә...

Авыл гадәтләре шәһәрдән читтәге дачада да жирлек таба. Зур йорт дип тә хыялланмыйм, булганы житәр, ә менә Зиннәт бабамныкы ише иплежайлы каралтым булсын иде дә, эш коралларын тезеп урнаштырып, яңгырлы көндә шул лапаста иркенләп эшләсәң иде...

...Инде үзем дә, оныкларым булышканда:

— «Мафафалай тарт!» — дип, бабай сүзе белән шаяртып куйгалыйм, тәртип, пөхтәлеккә өйрәнеп үссеннәр.

— Чисталык ярата иде палкауник, — дип сөйләгәне истә. — Кесәсеннән ап-ак батист кулъяулык алыр да, ат өстеннән сыпырып карар иде!

Йоннары ябышып оеган, төймә-төймә яшел шөлдерләр асылынган колхоз атларын күз алдына китерәм дә, «эләккән икән бабайга...» дип куркып торам. Ә ул тешсез авызын ерып елмая:

— Шалкан мае сөртеп ялтыраткан сачтай елкылдап тора иде аргамакларым! — ди. Әле дә, ат жигеп кайтса, аерым хужалык чактан калган кыргычын кулга алып чистартырга керешә. Мондый гамәлдән бизгән малкай, «бу нинди бимаза тагын» дигәндәй, колакларын шомартып борылып карый, аннары күзләрен йома төшеп, рәхәтлектән аскы иренен салындырып, оеп тора...

## Бал бабайлар

— Әйдә, Казаклар чатына!

— Жиләккәме?

— Хәмит бабай бал аерта!

Малайлар, тузан туздырып, уздырыштан урманга элдертә. Бадамша күперен чыгып, үргә күтәрелгәч, бал кортларын хөрмәтләптер, әкеренәяләр... Кыюраклар алга чыга:

— Әһә, шөр җибәрдегезме? — дигән була Һидиятулла. Имеш, кортлар аны таный, үз биләмәсе бит. Берәрсе чәнчеп алса да сер бирмисең инде — балын яраткач, «балавыз сыгып» елап торалармы — кеше көлдереп!

Умарталыкта таныш гөжелдәү тынлыкка бик ятышып тора. Әнә, Хәмит бабай үзе дә:

— Сәхипҗамал, өндәүле кунаклар килде! — дип кеткелдәп тора.

Үләнгә җәелгән паласта агач кәндиләр, чәчәкле кашыклар. Ипи сыныклары янында сынык кашыклар да бар. Җитмәгәнгә чәшкә, чүлмәк китекләре дә өстәлгән: күпме «кунак» буласын кем белгән. Болар гаеп итә торган түгел, кашыкларын да таныйлар, бер генә килмәгән лә! Кәрәзле балдан һәркемгә өлеш чыга. Кашык-савыт җитмәгәне аптырап калмый — әрекмән яфрагы җиләккә дә, балга да ярый ул! Бисмилланы әйт тә, ялап ялт иттер!

— М-мм, мәмм-ле! — дигән авазларга бал кортлары кушыла:

— Без-з җыйдык! — димәкчеләр.

— Салкын су эчмәгез Бадамша кизләвендә — эчегезгә тияр, — дип озата бабай.

— Кортларыгыз мал булсын, малларыгыз мул булсын! — дип, малайлар бал ябыштырган бармакларын кушырып дога кылалар. Карт белән карчык кулларын каш өстенә куеп карап кала. Яңа балны башлап нарасыйлар авыз итте: кортлар җыясы өлешләре булсын, сабый теләген ходай кабул кылсын...

Бал кортларын эштән аерып борчымыйк дип, саграк атлаган малайлар, юлга чыккач, уйнаклап авылга чаба. Хәмит бабайның Вилдан белән Һидиятулласы да кәләпүшләрен җил очырмасын дип, кулга тотып, узыштан әйттерә: бал куәт биргән! Һидиятулласы әткәйгә әти буласы, миңа бабай... Күреп өлгерә алмадым, мин туарга өч ел кала гүр иясе булган. Ә менә умарталыкны, малайларны күрдем сыман. Бибигайшә апа сөйләгән ие... Казаклар чатында, колхоз умарталыгында, үзем дә сыйланганым бар, малайлар җыелып барган идек. Хәмит бабам заманыннан килгән гадәт безгә дә эләкте әле...

Ерак чатка күчкәнче бабайның умарталыгы төп йортка якын — Бикитау итәгендә, инеш буена сыенган. Тау башы урамында яшәүче Хәким атлы кеше бәрәңге бакчасын ярга чаклы сузгач, умарталык урман буена күчкән. Хәмит бабай Бүәлегә — урыс авылына йөреп, балавыз да җыя торган булган, кәсепнең бусы да азмы-күпме файда китергәндер, койган кәрәзгә алмашу өчен дә кирәк булган.

Инештә галәмәт зур өянке бар иде, әллә ничә колач та җитмәле түгел, ботаклы-чатаклы, бик борынгы. Каерылып, сынып төшкәләгән, үзен-үзе күтәреп тора алмый. Бөргәләнеп аккан, ташыган су өянке төпләрен ашый... Хәмит бабай өянкесе икән, ул утырткан булган. Моны соңрак белдем. Бабайларны уйлый башлаганда шактый ерагайган булалар, сорашырдай чордашларын да Вакыт елгасы агызып киткән.

Хәмит бабай талыннан бер яфрак өзелде дә, инеш суына кунды. Агым аны тибрәндереп, түбәночка — Чирмешәнгә алып китте. Балакларны сызганып, йомры-шома ташларны табаным белән тоеп, үткенендә җыерылып, шомасында шуып кинәнеп, бака түшәгенең йомшак ефәкләрен аралап, яфракка ияреп мин киләм. Дулкыннарда чайкалган — әллә яфрак, әллә үзем... Инешем елгага кушылып, Зиннәт бабайлар каршыннан уза. Чыланган балакларны сыпыргалап, биек күпер астыннан чыгам. Әллә Чирмешән күпере баш өстемдә, әллә дәверләрне тоташтырган күпер... Дөбер-дөбер әллә арбалар үтә, әллә тынгысыз еллар...

Зиннәт бабайның алма бакчасында, борынгы балбаллар сыман, төпумарталар басып тора. Хәмит бабамнар чорында барысы да шундый булган. Имән кискәне куышлап ясаганнар. Балбалда бал да үзгәрәк — кучкылрак, әчкелтемрәк. Кортлары да кыргыйрактыр димме. Балының

шәт, аермасы да юктыр, күбрәк ашаганга әчедер... Ящик марталар кибеттәге конфет әрҗәләре кебек: анда да тәмле, монда да татлы...

— Ящик марталарны әле яңа куйдык,— ди Зиннәт бабай. Умарта күзәтергә кызык: бал кортлары мыжлап ята, ашыгалар, һәрберсе үз эшендә. Балавызлы тотен исе сеңгән битлек киеп, дымарь өрдерептөтәтеп бабай янында торганым бар. Гөмбә язның иң тәмле, тансык исе бал вәгъдә иткәндер... Бал кортлары никтер төтеннән кача, мин — алардан куркам, берәр усалы, танымыйча, угын батырмагае, дип куырылып торасың. Бабайны белә алар, иямәшкәннәр, битлексез дә тимиләр. Минем өчен читтәнрәк карау хәвефсез. Йөгермә — кача алмыйсың, селтәнмә — бал кортын үтерергә ярамый. Тик кенә тор: безелдәп әйләндер дә, китеп барыр. Әкерен генә атла: тыз-быз йөргән ярсыта, тыныч эшләренә матавык булма...

— Эшләре күп — бал җыярга ашыгалар,— ди бабай. Безнең эш шул җыйганны җыештыру инде...

Миңсылу тәтәй бирнәгә өч баш умарта алып килгән. Кулы җинел булган — оялар үрчегән. Элегрәк күмәртә булган — тәтәйнең әнисе Гайнижамалның Мәһди бабайга бирнәсе йөз илле баш умарта булган! Аюкөйдергән авылыннан төшкән ул килен булып. Аю бал ярата дип әкият сөйлиләр, бабайлар аюдан уздырган булса кирәк...

Безнең якта умартачылык әүвәл-әүвәлдән төшемле кәсеп икән. Урманлы як, болынлы-чәчәкле Чирмешән буйлары, күгелҗем карабодай басулары... Кышка умарта өенә кертәләр. Бакчада да кышлый, төп умарталар бигрәк тә. Кар өстеннән чаңгыда үткәндә туктап колак салам: эчендә нәни җилпәзә канатлы тырыш җан ияләре черем итә. Уянмаганмы? Кыш патшалыгы уртасында чәчәк исле тере җәй посып ята, сабыр гына черем итеп язны көтә...

Әнкәй бирнәсендә ничә умарта булгандыр, безнең бакчада да бар алар. Әткәй, әнкәй янында дымарь төтәтеп торам: безнеке кибеттән алган, кызыл күрекле, ятрак. Бабайларныкы ише ысланган балавызлы түгел. Безнең умарталарга бабай да күз-колак булып киткәли. Дерт итеп, әлләни булгандай — давылдай кузгаткан сүзне хәтерлим:

— Корт аера — каенга сарган!

«Ил» ишәйгәч, башка чыгу аларда да бар. Кот алынып торам — атны да чагып үтерә, диләр... Әткәй, әнкәй тотәткеч ала да, каенга сырышкан кортлар тәлгәшен агач тустаган белән тубалга җай гына соса:

— Корт анасы кала күрмәсен! Ансыз ил тарала...

Шөкер, яңа мартага — яңа өйгә яптылар яшь гаиләне. Хәзер алар үзләренә дип, балны тырышып җыяр!

Бибигайшә апа белән Ярхәм жизнидә бал кортлары бик килеште, тәләй булды аларның. Апа — Хәмит бабайның оныгы ла — шәт, таныганнардыр! Җизнинең тирә-якта даны таралган. Казан базарында да беләләр, «бал бабай» исеме алган тырыш, уяу җан, хәйләсез.

Бирнәгә умарта бирү йоласында изге ният-теләк булган. Ишле булыгыз, гөрләп яшәгез — тереклек итегез, корт анасыдай йортны барлап, бер тирәгә туплап яшә, кызым, дигәннәр. Шул уйга килдем дә, төшенүемә сөендем — әлбәттә, шулай! Бүләкнең һәрвакыт ишарә-мәгънәсе булыр. Борынгыларны аңлап, алар киңәшен-акылын тота белсәк, тормышлар көйлерәк булыр иде канә...

Балдай якты гәрәбә эчендә ничәмә мең еллардан сакланып килгән бал корты күргәнем бар. Бусы да ерак бабайлардан ишарә-гыйбрәттер? Бүтән сыйфатлары өстенә, бал кортлары нәселне ясалма үзгәртүгә — «яхшыртуга» бирешмәгән: кеше күзеннән читтә, оча-оча кавыша алар. Адәм баласы кулга ияләштерсә дә, ирекле табигатен идарә итәр дәрәҗәдә баш бирмәгән алар... Бал дигән иң татлы нәрсәнең ачысы-хакыйкате шулдыр — кеше үзенең асыл сыйфатларын югалта бара...

Бал дигәч бер кими, бармак тисә — ике кими, диләр. Балчы осталар да кими бара. Бабайлардан килгән иң борынгы кәсеп ул, җитмеш төрле

сырхаудан дәва, диләр балны. Гамьсезлектән файдасы бар микән? Әллә бусы инде җитмеш беренче чирме?

Гайяр Һидият

Олы урамнан мәчет ягына әкерен генә картлар атлый:
— Хәмит Һидияте кайткан.
— Чапаны затлы — мәркәзчә...
— Түбәтәй урынында — эшләпә, анысы урысча түгелме?
— Безгә дә киертмәгәе — җәдит укуын юллап йөри, хәттин ашып!

Бабама авылдашлар тасвирламасы бу. Заманча алдынгы карашлы булган, ди иде уллары. Өстәвенә, Ленин белән бер елны туган, Ленин кордашы: бу уртаклыкта горурланыр урын бар лабаса. Инде төгәл булсын дисәк, Лениннан калып та бер ел яшәгән әле. Миңа бу туры килү ике «дата»ны истә калдыру өчен унай иде...

Фамилиям булып калган бабам үзе нинди иде микән? Сорыштырам, биш улыннан чалымнарын эзлим...

— Киң бәдәнле, буйлы иде, — диде Ярхәм җизни. Бибигайшә апа җөпләде.

— Питербурда «Гайяр Һидият» дип йөрткәннәр! — дигәнне ишетү күңелле. Анда татарлар бер тирәдә укмашып яшәгән. Алыпсатар — вак сәүдәгәрлек булган һөнәрләре, безнең халыкта моңа маһирлык бар.

## ХӘТЕР



### Мөхәммәт Садри

1913 елда туган.

### Алтын Прага, злата Прага

Алтын Прага, злата Прага!
Килеп яз таңнарыннан
Дошманнарны себереп түктек
Влтава ярларыннан.

Алтын Прага, злата Прага!
Балкый халкың йөзләре;
Невский кылычларыдай —
«Йөзбашня»ң шпильләре.

Алтын Прага, злата Прага!
Җырың җирне гөрләтә,
Азатлык әләмнәреңне
Май җиле җилфердәтә.

Алтын Прага, злата Прага!
Йөрим кылып тамаша;
Мәңгелек дуслык кулын без
Суздык сиңа ут аша.

*Прага, май, 1945*

гайярлеге дә шунда күренгән булса кирәк. 1909—12 елларда Бохара әмире булышлыгы белән мәчет салдырганда казначы да булып торган. Телгә оста кеше турында:

— Сатып җибәрер ул теле белән! — дигәннәр. Сәүдәгәргә бигрәк тә кирәк булган бу сыйфат.

— Әкият сөйләргә оста иде,— ди Бибигайшә апа.— Берсен бала чагымнан хәтерлим. Эзәрлекләүдән мәгарәгә качкан патша балалары турында иде. Исемнәре: Ямлиха, Мөхсәнинә, Мәслинә, Бәрнуш, Дөбернуш, Шатернуш. Әтиләренең кушаматы — Кыйтмир...

Питердә яшәсә дә, бер аягы белән авылда бабай, гаиләсе, балалары авылда — нигезен ташламаган. Тәтәй баргалап, үзе кайткалап йөргән. Сәүдә дигәнең дә тормыш көйләрлек-майтарырлык кына булгандыр инде: саланы калага ялгарлык кына. «Алтыга ал, бишкә сат — атың булсын сәүдәгәр»,— дип остарып үзләре әйткәндер.

Гайяр Һидиятне авылда элеккечә «Шырпы Һидият» дигәннәр. Гомер шырпысы янып, күмерләнә башлагач, тәкъдиредер, бабайны туган туфрак тартып кайтарган — бакый йорты нигез туфрагыннан күз күреме җирдә генә... Карточкага төшәсе итмәгән: мөселманга гөнаһтыр, дигән. Әтәтәйнең бер фотосы бар — бабайдан соң ун ел үткәч, Ленинградка кунакка баргач, үләр елында уллары аны күндергәннәр. Бабайның сурәте ниндирәк икәнне дә әйтә җизни:

— Ак кына йөзле, озынчарак борынлы, чәче юк иде...

— Әти зиһенле булган, шуңа күрә коелып беткән,— дип ялгап куя Бибигайшә апа.— Бер нәрсәне күрсәм, ун елдан соң да хәтерлим, ди торган иде әти.

— Мәчеткә ак чапан киеп йөрде,— ди җизни, хәтерләп.— Аллы-гөлле бизәкле...

— Ашказаны белән авырды — ашау үтмәде... Әни җиңел ризык дип йомырка куырып биргән иде, аны да ашый алмады...— дип соңгы көннәрен искә ала апа.

Бабамнан калган гадәт буенча «Питербур», «Питер» дип сөйләшәләр бездә. Аның гомере узган калада гомеремдә бер генә булдым — 1961 елны. Анда да Мәскәүдә ике ел укыганнан соң шәриктәшләр белән күмәк сәяхәт кылып... Яңгырлы, салкын май иде. Күп нәрсәләр күрдек, Насыйбулла абый атаклы мәчетне дә күрсәтте:

— Сукарно, Җавахарлал Неру булды, зур бүләкләр тапшырды,— дип сөйләде. Ә мин «бу таш диварларда бабам йөргән» дип карадым. Зиннәтле вә кыйммәтле әсбаплар калдырмаган ул, мәркәздә яшәп. Ил күзендә исемен калдырган. Сынатмаган, кеше булган. Питербур татарлары бәһасын шулай аңлыйм. Шөкер әле, лаеклы варис булсыннар дип, дәрт калдырган.

Петербург мәчете мөселман дөньясында атаклы булганлыктан, Һидият бабам күргән, аралашкан даирәне белү ягыннан «Нур» гәҗитендә (Ленинград) чыккан «Хакыннан тормаганнар» дигән мәкалә кызыклы булыр (1991 елның 22 июнендә «Шәһри Казан» күчереп басканча). Менә ул:

«Петербург мәчетенә 1910 елда нигез салына, өч елдан төзелеп тә бетә. Бу изге бинага Россия мөселманнарыннан җыелган 800 мең сум акча тотыла. Бохара әмире генерал-лейтенант Сәйд-Абдул-Әхәт хан җир участогы өчен өч миллион сум түли. Мәчетнең художник-архитекторы Н. В. Васильев. Аны төзүдә академик А. М. Фон Гоген, инженер С. С. Кричинский катнаша.

Конкурста Аксак Тимер чорында Урта Азиядә салынган мәчет һәм төрбәләр стилендә эшләнгән проект җиңеп чыга. Патша аны үзе раслый. Әмма төзелешне башлар алдыннан... Эчке эшләр министрлыгы төзелеш комитеты һәм императорлыкның сәнгать академиясе тарафыннан шундый белдерү ясала: «Мәчетнең мондый да ачык, күренә торган урынга салынуы белән килешү мөмкин түгел. Янәшәдә — Петропавел соборы,

Изге Троица чиркәве, Бөек Петр йорты, бу төзелеш шәһәребезнең борынгылыгын, бөтенлеген бозачак».

Моңа каршы Бохара әмире үзенең ризасызлыгын белдерә. Мөселманнар җыелышып, Министрлар Советы Рәисе П. Столыпинга баралар. Ул инде бер рөхсәт бирелгән төзелешне туктатмаска карар итә.

Мәчеткә беренче нигез салу тантанасына зур шәхесләр катнаша: үзенең яраннары белән Бохара әмире, статский советник Харузин, Новиков, камергенер Сазонов, генерал-лейтенант Кондратьев, генерал Фон-Ажберг, генерал-лейтенант Самсонов, князь Юсупов, градоначальник Драчевский, мөселман дин әһелләре: мөфти Солтанов, Ахун Баязитов, Дәүләт Думасы әгъзалары, полковник Мөфти-задә, Сыртланов, дворяннар: Тәфкилев, Еникеев, Тукаев, «Тәрҗеман» мөхәррире Гаспринский, Төрек, Фарсы илчеләре һ. б.

Бу гаҗәеп затлы һәм сәнгатьле эшләнгән мәчеткә биш мең кеше сыя. 1930 елда большевикларның канлы кулы монда да сузыла — мәчетне яптыралар. Һиндстанның бөек дәүләт эшлеклесе Җавахарлал Неру килгән вакытта мәчет әле ачылмаган була, ул аны тыштан карап китә. 1956 елда кабат эшли башлаган мәчеттә соңрак президент Сукарно, Әбдел Насер гыйбадәт кыла. Һәр елны монда гарәп һәм Африка илләреннән утызлап делегация булып китә.»

Бу соңгыларын инде Һидият бабайның улы Насыйбулла да күрә.

## Һидият бабай васыяте

Төп йорт — туган нигезебез, кендек каныбыз шунда тамган. Бабайдан калган йорт-җир, каралты-кура, җиз самавыр, җиз ләгән, җиз комган... Ат күзе сыман түм-түгәрәк кыйбланамә дә бар. Авылның түрендә йорт: Чирмешән күперен чыгып югарочка күтәрелгәч инешкә терәлгән алты төтенле генә тыкрык. Сул кулда, тирән яр буенда Фәсхетдин абыйлар, бирерәк Һидият бабай утырган. Каршыда — башка чыккан Вилдан абзасы.

Үскән балалар оядан оча торган, нәүбәт буенча әткәй дә башка чыга. Төп йортта төпчек калу фарыз да — Хатип абый сугыштан кайтмады, Сафа абый яшәде. Нәсел-ыруыбыз шәҗәрәсен аңардан белдем. Изге әманәт — бабамның васыятен күрсәтте: соңгы сүзләре нинди серләр саклый микән? Икеләтә кадерле ул миңа — әткәй кулы белән язылган. Гарәп хәрефләрен Сафа абый укып бирде, күчереп алып сакладым. Ахырда, уйлап эш йөртә торган абый, вакыты җиткәнне тойгандыр:

— Илле ел сакладым, инде сиңа тапшырам,— диде. Бу бер бит кәгазь ашыгып кына, унөч яшьлек Сафаның җырлар дәфтәреннән ертып алынган...

«Февраль, 27 нче, 1925 ел. (март, 12)

Тәтеш кантоны Урта Балтай волосте Зур Бакырчы авылы гражданы Һидиятулла Хәмитов вафат булды шогбанның 18 нче көнендә. Янача мартның 12 сендә, кече атна көн, төштән соң сәгать 2 нче яртыда. Күмелде мартның 13 ендә җомга көн төштән соң сәгать 2 дә. Аллаһе тәгалә иман байлыгы бирсен. Ярый, шулай булсын, амин, ярабби.

Моны язучы Галиулла Һидиятуллин (Хәмитов)»

Әткәйнең искәрмәсеннән соң, бабайның сулышы өзелер алдыннан әйтеп яздырган теләкләрен укыйбыз:

«ЗИРАТНЫ МАТУР УРЫНГА КАЗЫГЫЗ. МИН ҮЛГӘЧ КОРЪӘН УКЫГЫЗ... МӘЧЕТКӘ ӘЙТКӘН ДҮРТ ПОТ АРЫШНЫ БИРЕГЕЗ».

Матур урында бабайның бакый йорты — Чиремшәннең сөзәк ярында. Коллар кашына күтәрелгән урдә. Матур урын сайлый кеше, үзе күреп ятмаса да... Күп гомерен читтә үткәреп, соңын сизгәндәй, патшалар яшәгән мәркәздән ата-баба мәркәзенә — Олы Бакырчысына кайткан. Туган яктан да олырак җир юк шул. Балачактан якын, сагындырган,

бәдрә таллы елга буенда ятасы килгән. Шәһәрдә дөнья кусаң, мәңгегә тынычланыр ахирәтең шушында...

«БИБИГАЙШӘ КЫЗЫМА МАШИНА...»

Биш ир баланың бердәнбер кыз туганы, кадерләп, олылап торган Бибигайшә өчесенә сеңел, икесенә апа ул. Егетләр урнашыр, кыз бала кеше катына барасы. Тегү машинасы — байлык, тегүгә маһирлык та тормышка бирнә. Читтән кайткан бабайның хәзинәсе шул булган, тикмәгә васыятькә кермәгән ул. Апаның сакчыл кулларында келтерәп кенә әйләнә.

«ТУННЫ ӘНИЕГЕЗГӘ...»

Латифа тәтәйгә — төлке тун, соңрак — тормыш юнәтергә дип сатып җибәргәннәр, ишле гаиләдә очын-очка ялгарга булышкан.

«...ВӘ ЯНӘ ИКЕ МАЛАЙНЫ ЯТИМ ИТМӘГЕЗ, ЯЗГА АКЧА КИЛСӘ, ИКЕСЕНӘ ДӘ БИШМӘТ ТЕКТЕРЕГЕЗ...»

10—13 яшьлек Хатип белән Сафа. Питербурдагы олы абыйлардан ярдәм көтелгән, алар булышкан. Нинди өстәмә чыганак бар авылда? Игенен җыйгач, кышка кергәч, дәртлесе читкә китеп эшләгән. Анда эшнең иң саллысы көткән — әткәй дә шахтада булган. Бер көнне сәкедә әтисе урынына аяк бөкләп утыргач, көрсенеп әйткән:

— Әткәй керде гүргә,
Мин утырдым түргә...

Әткәйнең бердәнбер шигырь юлларыдыр... Түр җаваплылыгын күргән: табын тирәли ике энесе, сеңлесе, әнисе утыра... Шахтада күпме акча юнәткәндер, шахтер лампасы белән көрәген алып кайткан, бусы да хуҗалыкта ярар, дигәндер. Әле дә истәлек итеп саклыйм.

«МУЛЛАГА ЧАПАН, БЕР САРЫК, СӨНГАТУЛЛА МӨӘЗИНГӘ ТҮТӘРӘМ УҖЫМ».

Мөәзин дигәнебез, булачак укытучыбыз Сөнгать абый лабаса! Хәер, ни гаҗәп, Афзал хәзрәт тә мөгаллим булган. Минем өчен кызыгы шунда — түтәрәм уҗым бик белеп бирелгән: чирек гасырдан соң Сөнгать абыйның беренче кызына әткәйнең бердәнбер егете өйләнәсе:

— Үзебезнең ипине ашатып үстердек! — дисәң дә урынында...

Чапан тарихы да бер әкәмәт. Бибигайшә апаның төпчеге Рәшит тә белеп өйләнгән: Мөнәвәрәсен Һидият бабай чапанына төреп үстергәннәр! Тарихы мондый. Бабай затлы чапанын Афзал хәзрәткә һәдия кыла. Күпмедер кигәч, мулла абзый Чатбаш авылының указлы мулласы, дусты Нургалигә бирә. Анысы мәчеткә киеп йөри, уңа төшкәчтен намазлык тегәләр. Аңардан улы Хәмиткә күчә — Мөнәвәрәнең әтисенә. Әвәрә ул язмышлар, очларын югалтып кына гафил булабыз...

Бабай хәтта васыятендә дә калган дөньяны кайгырта: ничек көн күрерләр, тормыш майтарырлар дигән борчылу, җаваплылык анда. Васыять кәгазендә ни генә әйтеп була? Яшәвең, тормыш рәвешең үзе васыять: башында булган балага әйтмичә дә мәгълүм... Язмыш кайларга ташласа да, туган туфрагыңны онытма. Бик күп йортлар урнашкан Идел-Йортны онытмыйк. Ата-баба рухы, гореф-гадәтләр, туган тел дә — төп йорт, төп нигез. Нинди гаҗәеп яңа йортлар күккә ашып күтәрелсә дә шушы тарихи нигездә булсын. Борынгыларның васыяте шул. Утта янган, дәвер фаҗигаләрендә югалган васыятьләрне дә онытмыйк. «Аллаһе тәгалә иман байлыгы бирсен. Ярый, шулай булсын, амин, ярабби». Әткәйнең бабай васыятьләренә кереш итеп язган шушы сүзләре белән очлыйсым килә.

## Бөтнек исе

— Бәбкәм, ашка бөтнек өзеп кер әле!

Токмач кисәме, чумара саламы — казан кайнаганда тәтәй миңа кушар йомыш бу. Әгәр якында булса, чатыр чабып урамда йөрмәсәм. Аш вакытында өйгә якынаям анысы. Яратам мин

йомыш тыңларга — рәхәт булып китә, бөтнек иседәй рәхәт. Тәтәйгә дә шулайдыр, сөенеп тора:

— Кул арасына керә башлады — үсә инде, бәбкәм, үсә,— ди. Аның кул арасына төшәктә дә керәм — куенына борын төртеп ятарга яратам. Питербурда озаграк торып кайткач, шулчаклы сагындым — кайтып түр сәкегә утырып дога кылганда ук күлмәге астына үрмәләдем. Көлделәр барысы, тәтәй көлмәде, тавышы калтырады. Күлмәге аркылы сыйпый:

— Сагынган, бәбкәм... Мин дә сагындым шул.

Инде яныннан киттем юк — ияреп йөрим, ястыгында йоклыйм. Мәсгут кайткач, икебез ике яктан сырышабыз:

— Тәтәй, әкият сөйлә!

Әкият тыңлый торгач, йокыга талганны сизмибез дә... Ястыкка сылангандай изрәп киткәнбез. Иртән чынлап та башны аерып алып булмый! Ябышкан булып чыктык... Менә, әкият!

— Рәхмәт төшкере... Кайчым кайда соң? — дип, тәтәй чәчләрне аралап, җайлап кына кисеп, йокы патшалыгыннан йолып алды. Ул көнне без, йокы чүлмәкләре, бөтнек өзәргә өлгерә алмый калдык. Сагыз чәйничәйни яткан идек, авыздан төшеп, үзебезне ябыштырган...

Күп еллардан соң, сабый чакны искә төшереп, төп йортның каралтыкурасын карап әйләндем. Күз алдымда яңарганы — такта, шифр япканы, ә күңелемдә салам түбәле — элеккесе... Ат кимергән улаклар юк инде, сыер ышкына торган баскыч та үзгә. Бусына — сөенәм, тегесен — сагынам... Бакча капкасын ачтым. Бөтнек исе! Әллә һаман каралты буенда

## ХӘТЕР



**Зәки Нури**

(1921—1994)

### Күгәрченнәр гөрләп оча җимгә

Чәчәк ата кебек үзе күңел,
Таң шикелле хис саф, уй якты.
Мине бүген бомба шартлап түгел,
Сандугачлар сайрап уятты.

Тәрәзәләрен ачтым бөтенесен,
Күрәм: урман, болын, күл әнә...
Ничек рәхәт! Җәйнең җиле керсен
Блиндажыма түгел, бүлмәмә.

Күгәрченнәр гөрләп оча җимгә,
Мин аларның аңлыйм телләрен:
Алар сөйли, бу иртәне җиргә
Китерде, дип, җиңү көннәре.

Инде томан сирәгәеп килә.
Эшкә ашыга яңа, яшь шәһәр.
Әнә юллар... Беләм, шулар илтте
Мине моннан Одерга кадәр.

Иртә таңнан бүген тордым шулай,
Сызлануын онытып яраның,
Һәм, сокланып тыныч тормышыма,
Ачык тәрәзәдән карадым.

*1946*

үсәме? Үсә икән, сабый чагым бөтнегә үсә! Тамырлары бүтәндер, ияләшкән урынга утырта икән Сафа абый. Каралтыга сөялеп, бөтнек тәме белән бергә татлы яшьләремне йотып, су буендагы таллар бөдрәсенә, ак ташлы, кызыл балчыклы Бикитауга карап тордым... Чумаралар инде имгә дә юк, ясмыкны чәчмиләр дә — токмач ашына бөтнек алып кердем.

— Онытмагансың икән әле! — диләр. Онытаммы соң, безнең төп йорттан бөтнек исе килә, сагындырган, тансык хушис. Якыннарым, газизләрем тезелешеп утырган түгәрәк табынның тәмле исе, истәлекләр исе...

## Нәзер

Насыйбулла абыйлар җәен матур чакта кайта, әткәйләр, үзләре әйтмешли, кунак-кунак уйнап алалар. Нәсел калын, туганнар ишле, берсеннән-берсенә йөреп өлгер генә! Кайчакта көненә ничәшәр җиргә өндәүле. Егетләрчә дәртле атлап, елмаеп килгән көр күңелле ыспай абый ак ефәк шәл ябынган сылу, алтын тешле, монсурак Һаҗәр апаны култыклаган, флотча киенгән иркә уллары Мәсгут әнисенә сыенган. Без күрмәгән ерак шәһәр белән кызыктырып, күңелне иләсләндереп, баш әйләнгеч хушисләр бөркеп, ел саен көтеп алган яңалык булып йөри алар... Адым саен әкияти сарайлар инде анда, патша яшәгән Питербурда. Шундый җирдән дә гел авылны сагынып кайталар. Бусы ничек микән?

Бер көнне Кечкенә абый затлы кәчтүнен салып, Сафа абыйның бәрәңге казыганда кигән чалбарын сорап алды, майкадан калып, көрәк, кәйлә күтәреп урамга чыкты. Кәйләсен — кәйлә, хәйләсен әйтми: нәрсә казырга, кая бара? Уенны куеп, без дә иярдек. Йөрмәгез, димәде. Тар тыкрыктан төшеп, елга күперен чыкты да, сулга — без уйный торган чирәмлеккә борылды. Талларга карап, нидер исәпләп, чамалап алды да ышанып әйтте:

— Шушында булырга тиеш!

— Хәзинәме?

— Хәзинә, дөрес әйтәсез! Табыла калса, барыбызга да җитәр...

Урман-чытырманда түгел, монда гына икән... Чирәмлек тигез түгел, уенты урыны бар, булыр да, ихтимал... Кәсне кистереп, комлы-ташлы кызыл балчыкны актара. Тирләп эшли, ашыга. Чокырдан күзне алмыйбыз —ниләр чыгар микән ялтырап...— Алтынмы, көмешме?

Хәзинә булса, ник көпә-көндез казысын икән? Әкияттә гел төнлә була... Менә бер мәлне көрәк доңк итеп бәрелде... Сандыкмы? Сөенеп куйды абый:

— Әйтәм бит, шушында дип!

Табылган нәрсә бура чите иде.

— Менә, улагы да! — диде Кечкенә абый. Шулхәтле әйтми түзгән диген... Туктап тын алган арада сөйләде:

— Алтынмы, көмешме, дисез... Мин кечкенә чакта монда көмеш сулы кизләү иде, суга йөри идек. Авылны сагынганда Дымбылатны, Каракизләүне, инеш буйлап бар булган чишмәләрне берәм-берәм күз алдыма китерәм. Төшемдә күрәм... Менә шушындагы кизләүне дә күрәм — улагыннан чылтырап су ага... Үрелеп учыма алыйм дисәм, уянам да китәм, буем җитми кала. Бер генә кермәде төшемә. Авылга ел да кайтабыз, шушыннан үтеп йөрим, томаланган кизләү мин ачканны көтәдер сыман. Бабайлар карап, чистартып торган заманында. Яшьрәкләр аның барлыгын да белмидер. Каты авырып, суга сусап, утта янып ятканда нәзер әйттем: исән булсам, кайтып шул кизләүне ачар ием, дидем...

Нәзернең ни икәнен беләм. Латифа тәтәй әйтә:

— Үтәмәсән, нәзер тота ул, бик хәтәр, ди...

Менә шуңа Кечкенә абый кунакка бармыйча жир казый. Төштән соң килеп тә, озак чокыды, актарды, менә саркып су да күренде!

— Суы тәмле иде, ачылып китәр, шәт! — диде абый.— Агып торсын әле шулай, тегәржеп хәтле булса да... Улак куярга кирәк.

Кичтән дә, иртәгесен дә килеп карадык. Юк, һаман беленер-беленмәс кенә саркыган көе...

— Чыганак бүтән юл алган... — диде абый, күңелсезләнеп. Нәзерен үтәде-үтәвен, суы юк... Кизләү ачылып китсә, су алганда авылдашлар: «Насыйбулла ачкан», — дип искә алыр иде...

Читкә китүчеләр үз юлын тапкандай, онытылган кизләү дә, әкренләп таш-балчык ишелеп, юшкын басып күмелгән, суы качкан — бүтән юл алган... Сусыз — агач корый, караусыз чишмә дә кибә. Мәрхәмәтле караш үз вакытында кирәк. Теге иске кизләү урынын яңадан чирәм басып, яшеллеккә кушылып калды. Анда кизләү булганын, мөгаен, инде мин генә беләмдер. Без дә читкә киттек, бүтән юл алдык. Кизләү булган урында, иске кабер сыман калкулык — чишмә кабере... Билгесез чишмә.

## Гыймалетдин абый

Авылда аңардан көчлерәк кеше юк — бер-бер йодрыгы баш хәтле! Юан беләкле, зур гәүдәле — баһадир! Әлбәттә инде, зурлыкта авыз-борын да калышмый. Сөйләгән чакта иреннәре... ни белән чагыштырыйм икән, ә — ә, кышын клубта бияләйле агайлар алкышлаган сыман сүзләрен хуплап тора. Калганнарын шуннан чамала. Көчлеләргә хас булганча сабыр, түземле ул, авызы елмаерга әзер. Куәт-дәрман дигәндә тирә-юньдә аңа тиң чыкмас. Йә, кемнең күпер аратасы сынгач, иңендә тотып, йөк төягән олауларны үткәргәне бар? Бәхәстән ат астына кереп күтәреп ындыр табагын әйләнгән, дип тә сөйлиләр. Аты да «Гыймал айгыры» дип атаклы — зур торыклы, нәселле мал, бар яктан иясенә охшаган. Мәгәр, авызы гына кечкенәрәк бугай... Күренекле булганга нәселгә тоталар, персидәтел районга барса гына жигәләр. Колхоз дилбегәсен ничек толадыр, айгырны тыя алмый — күчердә Гыймал абый. Кушаматы «Тубал» икән.

Сабантуйда көрәшсә, һичшиксез, батыр калыр иде. Чыкмый мәйданга, көченнән тартынган сыман читтә тора. Әллә бәлкем, имгәтермен дип куркадыр? Көрәшнең дә мәл-әмәлләрен белү кирәк, ихтимал, андыйга теләге юктыр. Барыбер авыл белеп тора: безнең көрәшмәгән сабан туе батыры бар әле!

Гадәттә, ул йөк ташулы эшкә йөри: төяргә-бушатырга булышчы кирәкми, һап иттереп ала да җаен китереп сала, капчыкмы, бүрәнәме, ни булса да. Авыр йөк дигәннән, арбага... йомырка «төягәнен» күргәнем бар. Арыш саламы белән аралаштырып, пөхтәләп ничә рәт түшәгәч, өстеннән юкә кабыклар япкач, аркан үткәреп, аяк терәп тартмасынмы! Күкәйләр сытылып жиргә ага ич хәзер... Ә ул дилбегәсен кулга алды да, арба кузгалган уңайга үзе дә сикереп менеп утырды! Сытты — бетерде бөтен авыл йомыркасын дип күзләр йомыла... Атка дигән барыр-кайтырга юллык солысы, үз азык-төлеге, кирәк-яраклары да йөк өстендә. Казанга китте, йөз чакрымлы даңгыр-доңгыр юлдан ничек үтәр?

— Бер генә бармаган инде, әйбәт йөри, әйтмәгәнем булсын!

Әткәй шулай дисә дә, булган шул бусында. Кайткач, Гыймал абый, авыз читләре белән генә елмаеп, уңайсызланып кына үзе әйтте:

— Машинаның килеп чыгуы булды, атым дулап читкә каерып та алды... Йомыркалар бер якка, үзем икенче якка тәгәрәдем...

Кибет янына жыелган агай-энегә житә кала:

— Харап булгансың ич!

— Юк-юк, бер йомырка да сытылмады!
— Берсе дәме? — дип үтә җитди кылана Пажи Фәсхетдине.
— Берсе дә! — дип раслый Гыймал абый. — Тәяүчеләрс кем соң — Гали белән икебез!

Мактанса да җирендә, көч өстенә — эш мәлен белә. Түкми-чәчми, ватмый-чатнатмый илтеп тапшырган. Эш беткән, көлтә җыелган, көлке чәчелгән, дигәндәй бераз «җылынып» алгач — авыз ерылып калгач, абзый Казанда күргән, исе киткән бер хәл турында сөйли.

— Ышанырсыңмы-юкмы, Галиулла, билләһи дим, үзем күрдем — бер кешенең авызын йозаклап куйганнар! Менә шулай, — дип, калын иреннәрен юан бармаклары белән тотып, йозак бөгәҗәсе тишкәндәй күрсәтеп ала. Әткәй дә, чынмы-мәзәкме бусы, дигәндәй тыңлый. Мондый авызга ат тышаулый торган богау йозак яраса гына дип карап торам мин дә. Хәйран калып сөйли торгач, оныткан — урамда плакат итеп куелган рәсемне әйтә икән... Нарасыйлык бар иде баһадирда...

Заманнар үткәч, «Чаян»да эшләгәндә, иске журналлар актарганда әлеге карикатура килеп чыкты. Утыз җиденче елларга хас рәвештә, уяулыкка өндәгән рәсем — сер саклау турында. Ә бит аны халык, хаклык авызындагы хөр фикерне тышаулаган «богау йозак» дип тә була... Тик ул чакта ул авызларны бикләп бетерә алмадылар. Сүз өчен баш китсә дә, «татар теленнән тапса»да, телен тыймаучылар бар иде...

## Җилпуч Габдулла

Кушаматның гадәтиләре күп: Кәҗә, Бүре, Куян, Аккош, Чыпчык ишеләр... Ә Җилпуч — аерылып тора. Хатын-кыз кулындагы нәрсә ник-ничек Габдулла абыйга тагылган әле? Тарихын белүчеләр бар. Ата-бабадан күчкән мирас түгел, бала чакта үзе яулап алган. Кыскасы...

— Һәй, әкәмәт булды ул, — ди, әллә үзе күргән, әллә ишеткән, әллә ишетүчене күргән Пажи Фәсхетдине. — Габдулла өй түбәсенә менә дә, җилпучка утырып очам, дип бәхәсләшә. Һәм дә ки оча! Канат урынына көлтә куеп оча. Суккан арыш көлтәсе.

Моны ишеткәч, Габдулла абыйга текәлебрәк карый торган булдым. Гайрәтле егет, «төшеп калганнардан түгел». «Төшерә» торганнардан да түгел. Әмма дәртләнеп бәхәсләшсә, бугаз төене уйнап тора! Иң каты, усал сүзләрен әле йотып калдыра икән, алар шул төендәдер дип уйлыйм...

Арттагы урамга кайткан теге летчик сыман ул да. Сүз дә юк, парашут белән сикерү куркыныч. Күз алдына китерсәң дә тез буеннары йомшый... Парашутсыз очу тагын да хәтәррәк... Чормага менеп, өй кыегына уелган айдан җиргә караганым бар — ай-һай, биек! Эчләр жу итә — җилдә морҗа гүелдәгән сыман... Күргәндәй булам, әнә Габдулла абый култыгында — көлтәләр, җилфердәп өй кыегыннан очып төшә... Бик очасы килгәндер. Биектән дә курыкмаган тәвәккәл. Теге летчикка акча түләгәннәр, ә бусы — бушлай очкан, летчикка матур кием биргәннәр, ә бусы — терсәге сизрәгән инечле күлмәктән йөри...

Соңрак, чиркәү гөмбәзеннән сикергән кешеләр турында укыгач та әлләни исем китмәде — безнең «Җилпуч Габдулла» да очкан! Борынборын замандагы Икар турында да белдем, булыр-булыр, дидем, безнең авылдаш сыманрак икән, иртәрәк кенә торган да, алданрак кына өлгергән...

Габдулла абый озын буйлы, мин аңа астан карыйм — манарадай тоела. Шул үзен таныткан очуы, батырлыгына күрә горур йөридер, шуңа зур үскәндер! Игътибарлы безнең Олы Бакырчы, онытылмас хәлне мәңгеләштерә белгән — менә дигән кушамат таккан: канат итеп, гомерлеккә — ул синең исемеңне еракларга җиткерер...

Анысы, авылда төрле кеше бар инде. Кайберсе, данын көнләшептер, ычтык-мактанчык, җилъяк-җилаяк дигән була. Ул бит күңелендә канат тойган! Тыелып-җыелып килгән шул омтылыш ташып чыккан. Биектә торганда очып китәрсеңдәй тоелган мизгел кайсыбызда булмый? Тора-тора аңлыйсың авылдашларны: кызык итеп яши белгәннәр. «Җилпуч Габдулла» да мәзәк ясап очкан. Әнә, авылдаш ук булмаса да, Тау ягыннандыр — Хуҗа Насретдин да, коедагы айны тартып чыгарам ди торгач:

— Чыгуын да чыктың, мине генә ектың! — дип, кызык эшләгән. Оеп яшәмә, күрә каравына әйләнмә — күтәрелеп якты айга кара, елмаеп йөзең яктырсын дигән ил зирәге!

Җил ягыннан салам кыстырсаң — мактабрак җибәрсәң, очына инде адәм баласы. Габдулла абыйга карата андый ниятем юк — көлтәсе белән үзе кыстырган да, очкан да. Иннәренә каз канатлары куйган, дип тә сөйлиләр. Атаклы кешеләр тирәсендә аның хәтле генә арттыру-киметүләр, хәтта башка төрле хикәятләр дә булыр инде ул. Хикмәт андамы, хикмәт — күңел канатларында!

Җилпуч — борынгылар уйлап тапкан көнкүреш җиһазы ул. Иген җилпегәндә тиз аера: саллы орлык кала, буш-җиңеле очып китә. Булды инде еллар — хәтәр җилләр саллыларны да иләп-иләп очырды. Җилпучсыз да читкә очтык, чит җирләргә төшеп тамыр җәйдек. Җилпуч Габдулла да тикмәгә җилпенмәгән икән. Әйе, яшьлек хыяллары көчле булган — зәңгәр биеклек, рәшәле офыклар ымсындырган аны да... Туган туфракның тарту көче барыбер көчлерәк икән: картаймыш көндә яңадан авылга кайткан.

## ХӘТЕР



**Нури Арсланов**

(1912—1991)

### Сугышчы төше

Иркәләнәм кочагыңда
Назлы бер төндә,
Мин бәхетле бу чагыңда,
Без икәү бергә.
Уянам, син юк янымда...
Мин ялгыз түгел:
Автомат кулда, аңымда —
Җиңү дә син гел.

*1943*

— Бер дә бирешмәгән, сиксәндә димәссең: яшь-яшь күренә! — диделәр. Очу дәртен югалтмаганнар шулай була.

Ә кушаматын үзе кайткан төшкә югалтмый-онытмый авыл саклап торган: хәтер җилпучыннан гомер буе очмаган, саллы булгандыр, күрәсең...

Очарга ашкынган кеше, әмма туган җирнең тарту көче куәтлерәк. Тарту дигәннән, әле авылдашлар искә төшерде, ызба башыннан очканда Габдулла җилпучка сүс дилбегә бәйләгән булган:

— Тарт, Шәвәли, тагаракны, мин очам! — ди икән энесенә. Ягъни, Гагарин утыз елдан соң аңа охшатып: «Поехали!» дигән булып чыга!..

Тагын шунысын да искәрттеләр, Габдулланың мирастан килгән кушаматы «Көл». Җилпучсыз оча торган көлме ул, әллә «көл» дип кытыклап торган сүзме? Ни булса да яратып, хәтта ки горурланып көлгән авылдашлар. Сеңлесе Хупҗамал белән булган хәл дә бу нәселнең тиктормаслыгын раслап тора. «Хупҗамал тәрәзә ваткан шаси юлында»... дигән такмак кыйпылчыгы хәтердә. Тарихы болай: сугышка хәтле безнең калын урман аша район үзәге Кайбычка таба... агачтан шоссе салганнар иде. Ташка — кытлык, агач — күп, кыска-кыска имән төпләр түшәгәннәр иде. Шунда, артыгын шаярыбрак, Хупҗамал машина тәрәзәсен ваткан, гөнаһ шомлыгы. Яшьләр бәет тә чыгарып өлгергән. Агач «шаси» тузды, такмагы да чак эләгеп калган... Имән кискәле юлдан җәяүләп бик күп үттем. Кайбыч аркылы шигърияткә илткән ул мине. Такмазаның шаянлык уятырга җиле тигәндер әле, бер шигыремнең «Хупҗамал» булып куюы тикмәгә түгелдер. Авылның канатлы сүзләре безне дә күтәргән. Шәвәлиләр бер уңайдан мине дә тарткандыр сүз дилбегәсе белән... Ничек очсак та, шөкер әле, туган җирдән аерылмадык!

## Тимерче салкын буламы?

Түбәночта, аръяктагы тимерчелек — колхозныкы, анда читтән килгән урыс булыр, югарочта салкын тимерче Кәрим абзый үз каралтысында чүки. Мич артындагы чикерткәдәй чык-чык чыкылдап, туктаусыз «сайрап» тора. Үзе колакка каты, гомер буе тимер кыйнап томаланды микән? Кеше сөйләгәнне авызы белән тыңлый, авыз ачып. Бик кирәктә чүкечен куеп, колак тирәсеннән узып китмәсен дип, сүзне зур учлары белән тота. Үзе гел чүкүдә, аның өчен чүкече сөйли, дөнья белән аңлашуы шул.

Йомыш белән дә киләбез, йомышлыга ияреп тә — безгә тамаша булсын. Олы урамда, капкасы һәрвакыт ачык, узган-барганда кагылып китәбез. Комган, табак, самавыр яматырга килмәгәнме дип күтәрелеп кулыңа карый да эшенә иелә, нидер майтара. Без кызыккан, тотып карыйсы килгән тимер-томыр күп монда. Хәстәрле картның байлыгы төрледән-төрле. Сөяк җыйганда безгә тимердәй авыр нәрсә бирде, ул — теш икән! Мамонт теше, диделәр, чормасында яткан, әйләндереп-әйләндереп карадык та, кибеткә илтеп конфет алдык. Мамонт тешенең безнең тешләргә дә файдасы тиде. Тиде... бәлкем, зыяныдыр — сызлап интеккән чаклар аз булмады... Ә мамонтның теше сызлады микән? Ай-һайлар диярсең, мондый зур тешнең сызлавы да зурдандыр!

Кәрим абзыйның йорты урамга караса, бакча койрыгы инешкә төшә, шактый сузылган. Тау астыннан аулак сукмак шуннан үтә. Бакчасында галәмәт дәү ак гөмбәләр була. Кар тәгәрәтеп ясаган өем диярсең! Яңгырдан соң кай арада калкып чыгадыр. Саңгырау гөмбә ул.

Кипкәне хәтәр диләр, төтенләп тузаны оча, колакка керсә, саңгыраулата, ди. Кәрим абзый ике аягы белән дә шуңа баскан мәллә, абайламыйча? Ямь-яшел бәрәңге бакчасында ап-ак кар өемнәре... Кочакка алып күтәреп, күтәрә алмаганын тәгәрәтеп, ваткалап-бәргәләп, инеш буенда кар атышкандай уйныйбыз. Бәрәңге дә тапталгандыр, кем сайлап кына баскан... Без бит колакка каты түгел, чүкегәнне тыңлап эш итәбез. Карчыгы бездән соң шаулаганны ишетмибез, сызган булабыз — бүтән җирдә, бүтән уенда инде.

Гөмбә дөмбәскәләрә ак аюлар сыман ята. Бик-бик соңлап кына белдек, ашарга яраклы икән... Умырып-умырып алып, шундый йомшак, шундый матурны аяк астына ташлап, тибеп йөрдек, туп урынына. Сугыш ачлыгында, ни-нәрсәне ашап була микән дип исәнеп йөргәндә шуны танытучы булмаган... Белмәдек шул, үзебез дә «гөмбә» инде. Әрекмән тамыры да яраклы икән. Чокыр буйлары тулып, күкрәп утыра — яфраклары фил колагыдай... Налог җыярга упалнамоченныйлар күп йөрде, ник берәрсе файдалы үләннәр җыярга өйрәтмәгән? Әрекмән арасында егылып ачтан үлүчеләр булмас иде. Аларга ни, районнан килгән «гөмбәләр» он да яздырып ала, балын да бирәләр. Берсен әле дә искә алалар. Тоташтан яңгыр койган борчулы көннәр. Игеннәр сөрлегә, чери дип эче яна халыкның. Ә ул тәрәзәдән карый да:

— Әйбәт кенә сибәли! Гөмбә булыр! — дип, сөенеп, кулларын уып тора...

Кәрим абзыйның чүкече кайчан тынды микән? Аның кул җегәрен дә мохтаҗ еллар йомшарткан. Тамырын корыта алмый иза чиккән саңгырау гөмбәнең җан асрарга яраклы икәнен белмәгән... Бар маһирлыгы тимер тирәсендә. Салкын тимерче, дияргә тел бармый, тимерченең салкыны буламы?! Кайнарланып, җиренә җиткереп башкарган ла, чүкеч-тукран туктамаган. Шулай инде бездә, бал белән гәрчис янәшәрәк йөри шул, игътибар җитми...

Бу ишарә хәләл җефетенә кагыла, исемен хәтерләмим — «Кәрим абзый карчыгы» дип йөртәләр. Гел ачлык-мохтаҗлык булмаган ла, кунакка да йөрешәләр иде заманында. Ирләр — аерым, хатыннар үзенә җыела. Үзләре бизәкләп суккан, идәнгә җәелгән паласка аяк бөкләп тезеләләр. Абыстайга, хәзрәткә мамык мендәр салынган. Ирләр сүзе бер, хатыннар сүзе үзгә — әдәплелек тә, ачылып-чәчелеп гәпләшергә, ял итәргә форсат та аерым булгач. Берсендә шулай, дога кылып амин тотып китәргә кузгалгач, Кәрим абзый карчыгы арткарак кала да, нәфесе төшеп, ымсындырып торган, нишләптер бераү дә кагылмаган бал тулы җамаякка үрелеп, агач кашык белән батырып берне каба. Бисмилласыз гына булганмы — тыны куырылып, өнсез кала, — әллә ниткән хәерсез нәрсә бу! Йотса — харап, төкерсә — оят, кеше күрә... Кызарынып-бүртенеп чыга, яшерерлек түгел! Бал дигәнең фәрештә кыяфәтенә кереп алдаган гәрчис шайтан, имеш... Шул котырткан, шул ялгыштырган. Күрәчәк — күз йомдыра, ашыккан... гәрчискә пешкән...

Кәрим останы мактау балына бер кашык гәрчисне ник куштыммы? Бал кортлары гәрчис кырыннан да җыя татлы тәмнәрне — тормышта ачысы-төчесе бергә. Аннары, мактанчык икән, авылдашларын гел мактый, димәсеннәр. Гәрчис телләләр бездә болай да аз түгел, анысы. Тел чарлау чаялыгы да тимер чүкүдән калышмый. Олы Бакырчыда андый «көмешчеләр» дә бар... Һәр нәселнең үз һөнәре: осталыгы ылына калды — Кәрим Каюмы дип йөртәләр, бу аның вывескасы, кемлеге дә һөнәрендә күренә... Тимерче-бакырчылар осталыгы авылга исем биргән. Патша тыюы сәбәпче микән — бу кәсептән суына-суына, салкын тимерчеләр генә калган. Хәзер бар микән? Чү, тыңлыйк әле, ишетәсезме чек-чек сәгатьтәй чүкеч йөргәнне? Юкмы? Юктыр шул — авыл исемендә генә яңгырап тора...

Тәбәнәгрәк булса да, киң явырлы Бөдрә Бәдри. Ахрысы, табигать буйга дигәнне дә аркылыга салган. Хәрәкәтчән, тиктормас бәндә — катнашмаган жире, кермәгән ишеге юк. Калын иреннәр ипләп-сипләп, хөкем чыгаргандай сүзен әйтер: карышмагыз, минемчә булыр, дигәндәй, кистереп әйтер. Тәбәнәк буйга әзрәк өстим диптер, табигать аның чәчләрен бөдрә иткән. Җыелышта чәчрәп чыкканда — башы кызганда бөдрәләр сугышчан әтәч кикригедәй күренә. «Актив» дигәнне беләбез — шул куштаннарның берсе ул. Була бит власть өчен яратылган адәмнәр — бусын да табигать җитми калган буйны исәпләп — искә алып бирәдер. «Урындагы» кеше барыбер зуррак күренә. Комач өстәл янына чыгып кунаклагач, биегрәк «тәхеттә», — бигрәк тә. Төрле тармакларда җаваплы эшләрне ышандылар аңа.

Бөдрә Бәдри — җәмәгать тормышы ипле булсын дип ихлас тырышкан иптәшләрнең берсе, моны үзенең вазифасы, гомерлек бурычы дип таныган. Үз хуҗалыгын карый белмәдеме, игътибары җитмәдеме — фәкыйрь яшәде, икенче хатыныннан да уңмады шикелле. Ике ояның балалары шактый иде — сугыш вакытында капчык асып та чыкты бахыркайлар, нишләмәк кирәк... Революция кузгаткан беркатлы фидакарьләр бар иде әле ул чакта — Бәдри шуларның берсе. Аңа абруй-дәрәҗә, ил күзендә өстенлек биргән күренекле кеше булу да җиткән. Хәер, дан дигәнең дә түләүнең бер тере, ул да зыянлы түгел, диләр...

Кайсы кеше кимчелек өчен үзен битәрләп, бетеренеп яши, таләп күзләре гел үзенә төбәлгән. Ә Бөдрә камиллекне бүтәннәрдән, бар дөньядан таләп итә, кыза, төн йокысын шул борчулар качыра. Төп эше, вазифасы — башкалардан тәртип даулау. Ревизия ясарга кем алыныр, бүтәнгә әйтмиләр дә — Бөдрә эше бу! Сыйфат комиссиясен кем җитәкләсен ди ул барында! Теләсә кем йөзен ертып әйтә дә алмый. Бәдригә карата беркем дә:

— Соң, җәмәгать, кеше тикшерердәй адәмме — үз тормышын рәтли алмагач! — дими. Бәдринең тавышы бөердән чыга. Бөердәге — боерулы — кызыл комач артыннан яңгыраган кызыл сүзләр: көн кадагына сугып торган күрсәтмәләр аңа көч бирә. Кадакка булса икән, агайлар башына суккан инде — алар башын авырттырган... Менә нәрсә белән коралланган, менә ни өчен бөдрәләп-гөрләп сөйли, сүзе — корал, партия коралы...

Корал дигәннән, без кечкенә чакта, мондый хәл булды... Мәҗлестә кәефләнеп алган егетләр — некрутларда була мондый әтәчлек — сүзгә килеп, якалаша икән. Таза-таза ирләр арага кереп, җайламакчы булалар, килештермәкче. Тыңламыйлар, кагып-этәреп кенә җибәрәләр — йомшак кына итеп. Менә шунда Бөдрә Бәдри килеп җитте. Өерелеп кайнашкан яшьләргә очып-очып куна, сикереп тә карый, тик аңа илтифат юк, күренми дә шул — буйлылар артында ул...

Буйга өстисе тагын бер дәлиле бар икән, бусын яшерен власть биргән. Кесәсеннән ак марляга уралган нәрсә тартып чыгарды да, яныйяный сүтәргә кереште. Сүтә торгач... наган көпшәсе күренде! Һәм шул җитә калды, сүтеп тә бетермәде — суынды кайнар егетләр. Өркетер өчен генә күрсәткән, атмагае дип курыккан идем. Егетләрне аерасы абзыйлар Бәдрине юмаларга кереште, табынга чакырды... Ник кат-кат уралды микән ул наган, дип баш ваттым. Кирәк чакта, ашыгыч чакта сүтә алмый ич? Балалары шаярмасын диптер, өй тулы бит алар, каян да табарлар ашарга эзләгәндә... Бәлкем... үзеннән саклау өчендер — кызган баштан ашыгып чакмага басмагаем, диптер?

Ул кереп киткәч, агайларның берсе, ялт-йолт каранып:

— «Тайный милиция» — шаярма син аның белән! — дип куйды. Клуб мөнбәрендәге утлы сүзләре өстенә, утлы коралы да бар икән,

таяныр урыны бар. Бер ышанганга инде ышаныч. Менә ни өчен сүзгә куәт эзләп кесәгә кергән, «маузер иптәш»не чакырган... Мәҗлестәгеләр арасында иркенләп утырды, әйтерсең, берни булмаган. Чакырылган кунактай түрдә ул, агайлар өчен бу гадәти хәл: беренчесе дә соңгысы да түгел. Ике як та хикмәт нидә икәнне белеп тора да эчтән тына, сөйләшми торган «тайный» яклары бар дөньяның...

Сугышлардан исән-имин калып, чордаш-кордашларыннан да калып, озак яшәде Бөдрә Бәдри. Тынгысыз кайнарлыгы сүрелмәгән иде. Тагын кайларга язгандыр, район газетасында актив язышты, матбугат та партиянең көчле коралы бит, ул да власть. Некрологны да район газетасында күрдем, эшчәнлегенә югары бәя бирелгән иде. Чәчләре һаман бөдрә иде аның: коелмаган да, агармаган да. Шулхәтле ил-көнне кайгыртып та...

Сугыш вакытында малае белән мәктәптә бергә укыдык, бик башлы иде, мохтаҗлык белән генә укый алмый калды — әлләкем булыр иде!

## ХӘТЕР



### Әнвәр Давыдов
(1919—1968)

* * *

Кулларыма
Туган кырларымнан
Туфрак алып үпсәм, көлмәгез,
Моны күңелем йомшак булуыннан,
Җаным җебегәнлектән күрмәгез.
Ят юлларның әче тузаннарын
Көнбатышка карап йотканда,
Чит җирләрдән алга үрли-үрли
Әрем сабакларын тотканда,
Курыкмадым, дуслар, үлемнән мин,
Әмма һаман шуны уйладым,
Җылы бөркеп яткан бразнаның
Очы күренмәгән буйларын,
Туган җирләремнең
Күгәрчен түшедәй
Күпереп торган симез балчыгын
Уйладым
Һәм дошманыма каршы
Сүрелмәс үч белән ярсыдым.

*1946*

Хәер, андый омтылыш та юк иде, әлләкем булмыйча, бүтәннәрне өйрәтми генә, үзе булып, матур итеп тормыш корганын беләм. Әтисенә охшаган ягы да бар — бөдрә чәчле...

## Хуҗа Насретдин һәм Барон Мюнхаузен

Гарифулла абыйдай әкиятче, Фәсхетдин абый сыман мәзәкчеләрне тыңлап үсәсең. Әткәй дә, Сафа абый да җае чыкканда сүздән кызык табарга тора. Коллар, Балтай, Биябашыннан килгән җор агайларны күрәм. Хуҗа Насретдин да, шулар сыман, мин күрмәгән берәр авылда яшидер. Беләм дә кебек: сакалын селкетеп кеткелдәп тора. Пажи Фәсхетдинен дә, Сәләхетдин җизнине дә Насретдин итеп күрә башлыйм. Үзләре көлмәс, белмәмешкә-көлмәмешкә салышкан булыр. Кичләрен пожарныйга җыелган агайлар арасында да утырадыр Хуҗа, ут сүлпән — үзе күренми, әмма сүзләрен ишетәм! Ә инде базар, ярминкә, кушкапка, сабантуйларда, әлбәттә, ул әйләнеп-тулганып йөрүче! Үзе киткән — сүзе калган, агайлар шуны бер-берсенә кат-кат сөйләп тәм табалар. Кәҗәсе түгел, мәзәге дигәндәй, Насретдин ишәккә атланып түгел, телдән-телгә, өйдән-өйгә, илдән-илгә күчеп йөри, нәкъ менә кирәк чагында килеп җиткән булыр! Бар сөйләгәне безнең авылдашлар турында, исемнәрен әйтеп, кылган гамәлләрен белеп сөйли!

Хуҗа Насретдин — татар бабае. Хозер Ильяслар нәселеннәндер, ә менә Барон Мюнхаузенның исеме үк әллә нинди чит-ят... Сафа абый белән Хатип абый кулында юка гына китап күргәч, рәсемнәрен карагач, аптырап калдым... Ничек инде кармак йоткан үрдәкләр бер-бер артлы тезелешеп очсын ди? Ярты атка... атланган, ә аты су эчә! Ышанмас та идең — сурәте бар, юкны ничек, каян алып ясасыннар? Абыйлар берберенә сөйләп-сөйләп көлешә, элек тә укыганнар. Мин беренче ишеттем. Хәрефләрен белсәм, укыр идем...

— Чынмы, шулай булганмы, Сафа абый?

— Булмый ни, без дә үрдәккә барырбыз, киндерә ишә тор!

Дөресен сөйли торган Хатип абый да раслый:

— Юкны язалармы, юкны сөйлиләр генә... Шәкерт булгач, барын да белерсең!

Көләләр. Әллә бароннан, әллә юеш борыннан. Мин көлмим, мин гаҗәпләнәм: әллә нинди әкәмәт китаплар бар икән! Ә менә Хуҗа Насретдин — китаптан түгел, ул үзе бар!

Нарасый беркатлылыгы, сабый ышануы, балачак хыяллары... Гомергә юлдаш булыр китаплар белән очрашкан тәэсирләр... Әкиятче абыйлар белән бергә, Хуҗа Насретдин, Барон Мюнхаузеннардан сабак алгансың. Хәйләкәр затлар сине дә ияртеп киткән — Насретдин ишәгендә, Мюнхаузенның ярты атында сиңа да урын табылган. Рәхмәт инде, юкса әллә кемнәр арбасына утырыр идең дә, әллә кайчан кәкре каенга терәтеп калдырырлар иде. Кеше ышанмаслык хәлне дөрес булса да сөйләмә, диләр. Ә менә сөйли белсәң, тузга язмаганнар да дөрес тоела икән. Бусын инде Хуҗа да, Барон да түгел, илнең — иксез-чиксез илнең чикләнгән хуҗалары бик озак еллар буе булдыра килде, тәмам барон булганчы...

Илдә күпме фаҗига, кайгы-хәсрәт, үлем-җитем булган. Әмма Насретдиннар исән, алар кирәк, көлеп авырлыкны куяр өчен, рухында көч тояр өчен, кеше булып калыр өчен кирәк. Заманнар алмаша, бабайлар каберстанга күчте. Ә Насретдинне инде оныклар таный, илдән-илгә сәфәр кылып, кайгыларны таратып йөри ул.

— Ишеттегезме әле, Насретдин белән Мюнхаузен очрашкан ди?

— Йә, йә, шуннан? Шуннан?

— Утырган да шуган! Калганын үзләре сөйләр!

Берьюлы шулхәтле матур-матур рәсемле китап күргәнем юк иде! Буяу исләре үк ымсындыра, кайсын алырга белмәссең. Мәктәп көтепханәсенә беренче керүем... Күзем төште: «Г. Тукай. Күңелле сәхифәләр». Менә бусы миңа инде! Бер шигырь — бер китап булган. Рәсемдә аучының тишек эшләпәгә аптырап каравын күргәч, исемә төште: Әткәй укыганда кызганган идем, мин аны... Икеләндем дә: бичара куян балаларын ятим иткән аучы да шул түгел микән? Куян балаларын җәллим, сиздермим генә — елак диярләр йә...

Мәктәпнең кечкенә көтепханәсе михрабта — мәчетнең иң кадерле урынында. Мәккә ягын — кыйбланы күрсәтеп торган урын ул, мулла абзый догаларын шуннан торып укыган. Хәзер анда кызыл яулыклы Сылу апа китап биреп тора. Иң беренче алган китабым — иң кадерлесе. Шигыре дә хикмәтле, тиктомалга искә төшеп, телгә килә дә тора:

Бакчы аучыга,
Кош аулаучыга:
Шактый читен эш —
Арый, талчыга...

Әлеге шигырьнең бер хикмәтен күптән түгел төшендем, хәзергечә әйтсәк, «Әйләнә-тирә мохитне саклауга» багышланган ул. Табигатькә атсаң — үзеңә тидерүең бар дип, әллә кайчан кисәтеп куйган Тукай: эшләпәң эчендә башың булса, беткән идең бит! Хуҗа Насретдин мәзәге искә төшә, төнлә бакчага угры кергән дип, уктан аткан да, үз күлмәгенә тидерүен күргәч: «Ярый әле эчендә үзем булмаганмын!» — дип сөенгән. Бәлкем, аучы да шуны уйлап сискәнгәндер, эшләпәсен кызганып түгел? Без дә табигать эчендә: эшләпәбез, күлмәгебез, үзебез шунда... Менә ничек, беренче сыйныфта күңелгә төшкән шигырь орлыгы тагын бер ачылды — бусы инде хәзерге заманда. Үсә төшкәч тә таман булыр, дип, без бәләкәй чакта зуррак кием алалар иде. «Күңелле сәхифәләр»дә — күңел сәхифәләре, тирәнрәк мәгънәсен әле күрдем... Балаларга яза башлавымның ачкычы да шушы шигырьдә түгел микән? Бер китабымның исеме дә «Күңелле сәфәр». «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр» дип язам, ә эчендә һәркайсының үз гыйбрәте — бусы да Тукай сабагы...

Кыйблага караган михраб-көтепханәдә китаплар күп иде дә, беренчесе, минем бәхеткә — иң кирәклесе булган, гомерем буе күңел михрабында. Тукай — кыйблабыз, илһам кәгъбәсе.

## Беренче сыйныфта беренче мәхәббәт

Дәрес башланмаган әле, алданрак килгән малайлар бик тырышып черкен уйный. Сызыгын кызлар сызган да, сикереп ярышу кемгә дә кызык. Мин килгәндә Әгъзам титаклый иде, кызарынып чыккан, әмма сыңар аяк ялгыш басмый. Малайлар сүзе колакка чалына:

— Әгъзамның хатын тапканнар...
— Мәгъфрүз кесәсеннән!
— Җыры да:

«Мәчет башы кыйгач-кыйгач,
Кыйгач саен сандугач;
Алдым каләм, яздым сәлам,
Син дустымны сагынгач...»

Әгъзам — гармунчы булгач, кич кызлар янында уйнап йөри. Мәгъфрүз дә була анда, чибәр кыз, үз бәясен белә! Без бер сыйныфта

Карыйм, бер дә сер бирми Әгъзам. Әллә оялып кызарганмы? Иң яшерен серең фаш булса, беттем диген... Эсселе-суыклы булып китәм: аның урынында булсаң, нишләр идең... Минем дә серем бар, ярый әле беркем белми. Партада өчәү без: уң ягымда озын торыклы, үткен кыз Тәнзилә, сул ягымда... у л. Ике кыз арасына утыртканга гарьләнеп, үртәгән малайларга рәнҗеп, Гөлсирә апага үпкәләп партага башны салып үксегән идем... Тәнәфестә бергә уйныйбыз үзе а н ы ң белән. Никтер гел карыйсым килеп тора, аның янында миңа рәхәт. Йөгереп-куышып, әбәкләшеп уйныйбыз, бер-беребезне этеп җибәреп көлешәбез — егылган чаклар да була. Берсендә уйнап кына таш аткан идем, чынлап тиеп кашы канап чыкты... Әй, курыктым, әтисенә әйтер, әтисе бит укытучы... Әткәйгә дә җитәр минем усаллык турында яман хәбәр... Әткәйләр дус бит, очраша торалар:

— Синең кыз бар, минем — малай. Кодалар булырбыз әле! — дип шаяртканы бар әткәйнең... Бер көн курыктым, ике көн. Берни булмады тагын. Әйтмәгән! Минем белән бүтән уйнамас диган идем дә, ул хакта искә төшермәде. Кашы өстендә тамга калгандыр әле...

Мин а н ы укырга кергәнче күргән идем. Сеңлесе белән икәүләп Чогырчак чирәмендә бәпкә саклыйлар. Сәләхетдин җизниләр бакчасы янында. Мин кайтып бара идем. Кара күзле шушы кыз әллә нигә якын тоелды, үзенә тартты... Бакча буеннан яланаяк саз сөреп барганда тездән баткан идем, көлде болар чыркылдап. Инде юри кыланам, ләмгә баткан булам: балак пычранса да җәл түгел — көлсеннәр генә! Сеңлесе кечкенәрәк, ул аны җитәкләгән, ата каз тимәсен, дидер...

Ә мин беркайчан кечкенә булмадым сыман. Үзеңне бәләкәй дип уйламыйсың. Әллә мәхәббәт хисе шулай тойдырамы: олыда-кечедә бер бит ул... Бусын мин хәзер шулай уйлыйм. Яшел чирәмдә сары бәпкәләр саклаган кызны яратып калдым. Күңелдә олы хисем бәпкәсе «пи-пи» тавыш биргән... Үсеп, кагынып очканчы озак саклыйсы әле бәпкә-хыялны, бик озак. Иң яшерен серем, татлы тойгым ул. Фаш булса — югалыр, бетәр... Белмәсеннәр, сизмәсеннәр! Ә үзе? Үзенә сиздерү диган нәрсә бөтенләй башка сыймый! Ничек мөмкин?! Минем хатны беркайчан да аның кесәсеннән тапмаслар...

...«Мәчет башы кыйгач-кыйгач...» иде, манарасын кисеп төшерделәр берзаман. «Кыйгач саен сандугач» түгел, чәүкәләр чарылдашты... Әгъзам белән Мәгъфрүз арасындагы «алдым каләм, яздым сәлам» дә бала чактагы сызыклы-кызыклы уены гына булып калды. Кызганычлыдыр... Язмыш та черкен уены — ялгыш сызыкка эләкмә, «җәннәт»кә туры килмәсәң ут диган хәтәр «тәмуг» көтә... Язмышны сикереп үтеп булмый икән.

## Беренче сайлаулар. Үткен очлы карандаш...

Комачлы бәйрәм булып истә калган ул сайлаулар. Клуб өстендә җилфердәгән флаг, теш порошогын суда изеп язылган лозунгендәмәләр... Авыл советында зур самавыр гөжләп утыра, кибет килгән. Сайлауга әзерлек зур булды, избач тирәсендә чуалган малайлар — без моны күреп тордык. СССР Верховный Советына ла! Самавыр да шуңа күрә авыл советында.

Иң мәшәкатьлесе — сайлауның яшерен булуы. Кемнән, ник, ничек яшерәләр — шуны беләсе килә. Эскәмияләр читкә өелде, клубны чаршау белән бүлгәләп, пәрдә бүлемнәр ясалды. Сайлаганны беркем күрмәсен, карарга ярамый! Һәр яшерен нәрсә кызыктыра, күрәсе иде — нишлиләр микән анда? И — и, гап-гади карандаш белән, бюллетеньгә язылган кешене сызу, яисә сызмау икән ул сайлау. Сызарга мөмкин, әмма һич кенә дә ярамый: каршы кеше буласың. Күреп тә торсалар...

Депутатлыкка кандидатлардан иң истә калганы — Отто Юльевич Шмидт. Әй, интеккән идек шуны әйтә алмыйча. Кайсы үз исеме, кайсы әтисенеке дә, кайсы бабасыныкы? Берсендә тел сөрлегә, икенчесендә абына — ерып чыгар хәл юк. Әйттек дигәнең дә: «Атта юллый иш Ишмәт» килеп чыга... Без әле хәреф таныйбыз, латин әлифне таяк дип кенә белә башлаган, наданлыкны бетерү өчен оныкларыннан сабак ала башлаган карт-карчыклар:

— Әнә, тегe, зур сакаллысы! — дип кенә җибәрә. «Челюскин» батырына кем каршы булсын? Кемнең аңа ни ачуы бар? Безнең илдә генә ул батмый торган батырлар!

Авыл советына кешеләр керә-чыга, бүген монда папирос төтәткән налог сораучылар урынында паф-поф самавыр җиз корсак утыра. Чәйне өйдә дә эчеп була да, монда кызык ич — испалнител белән чакыртып эчермәсләр — шушында сайлауның кызыгы. Әллә яшерен булганга, берни күренмәде клубта. Оештырып йөргән ике актив сөйләшкәнне ишеттем, алар әле нидер күргән:

— ... карандашны үткен итеп очладым да бүлмәгә кертеп куйдым... «Тегe абзый» чыккач та карыйм — очы ашалган карандашның — сызган бит, сызган!

## ХӘТЕР



### Салих Баттал

(1905—1995)

### Хуш, Казан!

Күкрәк киереп кайткан идем,
баш иярге дә вакыт;
«Саумы?» — диеп өлгермәдем,
«Хуш» дияргә дә вакыт.

Хуш, Казан! Борылу эзен
салып китәм карыңа.
Иреннәрем тияр-тимәс
кунакчыл тостларыңа.

Борылдым. Күзләрем тагын
вокзалларыңны күрә.
Атлаган саен урамың
табаннарымны үбә.

Адым саен син каласың
тизрәк һәм томанлырак,
күңелемдә яшәр өчен
бик ачык һәм бик озак.

«Хуш» — солдатның ялы тәмам,
алга чакыра зур эшләр,
талап алынган бәхетләр,
һәм алынмаган үчләр.

Хуш, салкын юлым өстендә
җылынып чыккан җирем,
бик күп дуслар арасында,
хуш, минем бердәнберем!

*1944*

Чаялыгы белән мактанып сөйләве — икәүләп көлештеләр. «Теге абзый» дигәне, исемен дә әйттеләр — турысын сөйләргә тайчанмаучы авылдаш... Бот буе малай ни белер дип, мине исәпкә алмаган комиссия кешеләре. Яшерен тавышларын ишеткәнмен икән... Карандаш очлап куюны ярамаган эштер дип кем уйлаган ул чакта? Әмма онытылмаган шул бер авыз сүз. Явыз сүз икән... Очлы карандашлы очлы күз кара пәрдә тирәсен тикмәгә сагаламаган... Аулак бүлмәдә «тавыш биргән» абзый язмышына кадалган карандашның үткене... Шул карандашлар стенага терәп сорау алган, яза-яза, акылдан яздыра-яздыра, кыскара-кыскара чәнти бармак чаклы пуляга әверелгән... «Яшерен тавыш бирү» тирәсендә яшерен эшләр куерган икән. Клубтагы «спектакль»дә күз-колак булучылар да катнашкан.

«Дөньяда иң демократик сайлау системасы»... Комачтагы теш порошогы белән язылган сүзләр дә теш ырҗайту булып җилгә очкан... Беренче сайлаулар. 1937 ел...

## Куркыныч төш

— Әнкәй, төшемдә акбүз атка атландым!

— Мәртәбәгә ирешерсең, бәбкәм! — дип юрый әнкәй, куанып. Атта җилеп йөргәндәй рәхәт булып китә. Әнкәйне шатландыру күңелле — икенче юлы да сөйлим:

— Кабарып пешкән ак күмәч иде кулымда!

— Бөтен күмәчме?

— Түп-түгәрәк.

— Гомерең озын булыр, ашлы-сулы,— ди әнкәй, төш юрарга ярата ул. Радио-фәлән юк, телефон да кермәгән авылга. Иң беренче «хәбәрне» төш житкергән, ахрысы... Рас буласына ышандыра әнкәй. Юраганның юш килүен ахирәтләренә дә әйткәне бар. Бигрәк тә берәр борчулы хәл булса:

— Төшемә кергән ие аны... Сизенгән ие күңелем! — дип өзгәләнә. Күргән төшләрне юрашалар, кайсы сагайта, кайсы сөенеч вәгъдә итә.

— Төрлесе була, җиде көннән, җиде елдан да туры килә,— ди әнкәй.— Иң рас килгәне — җитмеш елдан соң була, диләр. Әткәй көлебрәк карый:

— Җитмеш ел эчендә ни булса да була инде ул!

Ат белән ак күмәч күрүем гаҗәп түгелдер, тавык төшенә тары керә, диләр (Тавык та төш күрә микән?). Сабый чактагы төшләрнең күбесе уянганчы ук онытылган. Ап-ачык булып күңелдә калганы берничә генә. Күңеллесе — очуым иде, әле сөйләргә җыенганым — шомлысы, әнкәйгә дә сөйләмәдем — курыкмасын, дидем...

— Начар төшне дә яхшыга юрарга кирәк,— дип юатканы бар-барын. Киләсе хәвеф-хәтәрне адаштырмакчы ул, үзен тынычландыра... Белмим, әлегесе юрау белән генә үзгәрер микән?

...Төшнең «декорациясе» мондыйрак. Утызынчы елларда күргән плакатлар тәэсиредер, чүкеч күтәргән эшче белән урак тоткан игенче тора, алар артында — нурлар чәчеп чыккан кояш... Еракта завод морҗалары, төтеннәре бөдрә-бөдрә. Рәсемдә күргән дөнья — кызыктырган дөнья. Социализм шул икән. Ул ерак якларны күрсәң иде, әнә бит, тәгәрмәчле тракторлар күпме тезелеп килә!

Эшче белән игенче «кызыл капка» өстендә тора, киләчәккә шуннан чыгасы, бәхет шул якта икән, халык агыла да агыла. Өстендә флаглар лепердәгән капка үзе дә алга бара! Әй лә, болытлар агыла икән... Ленин-Сталин белән Маркс-Энгельс сурәтләре дә болытлар арасында йөзә. Туктап тору юк, арттан килүчеләр үкчәгә баса... Сафлар таралып,

кире кайтканда ничек була? Социализмнан кире кайталармы? Сабый башына нинди уйлар килмәс...

Төшнең мине куркыткан төшенә життек... Кызыл капкада классның кара тактасы икән. Эшче-игенченең берсе акбур белән «Социализм» дип язды да, икенчесе чүпрәк белән сөртеп ташлады!

Куркып уяндым — кара тактадай караңгы төндә ятам... Үзеннән үзе юрала төш: «социализм» юкка чыгамы? Аны эшче-игенче бетерәме?! Андыйларны халык дошманы диләр... Сөйләсән син дә дошман сүзен тараткан буласың... Гәжитләрдә тулы-тоташ шул хакта язалар. Төшне беркемгә сөйләмәдем. «Үсеп баручы социализм», «житлеккән социализм» дигәндә дә хәтер төбендә яткан. Кылт итеп искә төшергән сиксәненче еллар уртасы житте. Күрәзәле төш булган түгелме, теге, житмеш елдан раслана торганы? Социализм дигәнебез үзе дә төш кенә булган, акбур белән генә язылган икән... Киләчәккә бара торгач, кызулык белән узып киткәнбез, ахрысы. Куркыныч төштән шүрләп йөрүем тикмәгә түгел: илнең өнен алган куркыныч өн булган — 1937 еллар...

«Кызыл капкалар» шаукымы бетте, сүтелде алар. Черегән иде шул баганалары. Киләчәккә барыр юллар капкасыз калды. Кай якка барырга хәзер? Коммунизм Ленин бабайның таш кулы төбәлгән якта дип белә идек, һәйкәлләр ава, озак басып торгач, алар да ойый, алар да арый, фикерләре дә... Үзгәрә заманалар, көн саен күпме яңалык беләбез. Яңалык дигәне башка төеп оныттырган хакыйкать икән... Менә, капка дигәннән, гомер буе «урыс капка» дидек. Күчергече «өлкән туганнан» дияр идең, үз авылларында капка да юк, кот та юк — нигезләрен ташлап таралышып беттеләр. Безгә килеп тә чит осталар күтәрмәгән капканы — авылдашлар эше. Бу сорауга да җавап бар, өннен дә житмеш елдан җавап табылганы була икән. «Ырыс капка»! — «бәхет капкасы» дигән сүз риваятьләрдә сакланып калган. Туган нигезеннән дөньяга ачылган капканы бабайлар бәхеткә юраган. «Сандугачлар капкада, канатлары тактада» — сайрашып яшик әле дип, яраткан кошын ясап куйган, тынычлык теләп — күгәрченен. Урыс кышы, урыс каены ди торгач, «ырыс» та — «урыс»ка әйләнгән...

Уяндык, үткәннәр төш булып калды сыман. Ничек юрасаң да төш — төш инде ул, өндә яшисе. Өнне дә юрарга туры килә: киләчәк нинди булыр? Киләчәккә илткән бүгенгебез нинди? «Ырыс капка»дан башлансын юллар — өметле, хәерле булсын! Оныкларыбыз яңа гимназиядә укый. Бабам васыятен әткәй язган имла кайта гамәлгә. Киләчәк үткәннәрдән башлана бүген, төш күреп томаланып яткан чишмә-чыганаклар терелә!

## Саф каенга кара йокмый...

Ул көнне Гөлсирә апабыз, дәрес башлыйсы урында, шыпырт кына дәфтәрләрне жыя башлады. Язылмаганын да алды — шунысы аңлашылмый. Үзе борчулы — ни булды микән? Тәнәфестә чыш-пыш, коридорда сүзнең үз юлы:

— Фашист билгесе бар икән ул рәсемдә...

— Кылычына «Долой СССР» язылган, ди...

Дәфтәр табып, качып кына Олег дружинасы төшкән рәсемне карыйбыз, сырлар бар, ә «СССР» күренми... Зурайткыч пыяла белән тапканнар, ди. Күренмәслек булгач, кем күрә, ник язды микән халык дошманнары? Бардыр инде без белмәгән серләр. Бу хакта шауларга ярамый. Гөлсирә апа каушавын сиздермәскә тырыша, дәресне башлый. Күрәбез инде, яңаклары кызарып чыккан...

Китте аннары эзләнү, нинди рәсем бар — шуннан... Пушкинның үлүенә 100 ел дип куелган плакаттан да карыйбыз. Мыштым гына инде, фашист билгесе белән кызыксыну үзе гаеп...

Пушкинның үлүен гел-гел искә алып, бәйрәм иттеләр. Үлгәнгә шатлану сыман, сәер инде, әйтмим генә. Әнә бит, кеше вафат булгач, кайгыртып үткәрәләр. Пушкин бик күптәнге, әкияттәге кебек еракта...

Мәктәптә кызык, борчулы да. Гел үзең белмәгәнне эшләргә кирәк. Физзарядкада кулны кайчан ничек күтәрергә белми буталасың... Ә җыр дәресләре?

— Класс алдында һәркемне аерым җырлаталар! — дип котны алдылар. Шул хәтле кеше алдында ничек җырламак кирәк?! Сыер саклаганда тәкәрлектә үзалдыңа җырлау түгел лә! Сакаулыгым ишетелә башлый да, тотлыгып калам... Ярый әле, хор белән икән, Гөлсирә апа башлый, без кушылабыз. Тавышым янымнан китми, бүтәннәр гөрләгәндә тавыш көтүенә минем кәҗә бәрәне кушыла, ул да булса — аксак... Ә менә бер җыр бар, ул башланды исә, барысын онытам, кызгану оныттыра. Көйле бәет тә шулай — әллә кайларга алып китә. Җырдагы фаҗигане күрәм...

...Авыл башындагы ак каенга көтүче егет сөялгән. Башында ак киез эшләпә, ак күлмәген билбау белән буган, тула оек өстеннән чабата кигән, иңендә — чыбыркысы, авызында курай, моңлы-моңлы итеп уйный. Каен яфраклары талгын җилдә сөенеп тора, кошлар сайрый. Тыныч, рәхәт бер көн... Көтмәгәндә юлда тузан купты, атлылар күренде, усал мыеклы, ялтыравык погонлы офицер, солдатлар кылычлар ялтыратып егетне чолгап алды... Үз билбавыннан — эзәреннән астылар бит, аһ, урап чыкмаган булса! Аклар китеп тә барды, көтүче генә харап булды... Исән әле, коткарып буладыр! Тизрәк, тизрәк! Беркем дә күренми... Каен кызгана, ул гына сорый:

Авыртмыймы муеның, Хәйбулла?

Хәйбулла әле исән, әнә бит ни ди:

— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла...

Без дә Хәйбулланы коткарырга йөгермибез, җәлләп җырлыйбыз гына... Исән әле ул, исәндер... Җыр беткәч тә класс беравык тын кала, күзләр яшьле. Гөлсирә апаның да тавышында сизелә...

Шуннан соң бу җыр гомер буе күңелдән китмәде, вакыт-вакыт эчтән генә көйләнелә иде. Күмәк җырлау кая — искә алырга дип ярамый. Безне яңалифтән урыс хәрефенә күчерделәр. Хәсән Туфан исеме, шигырьләре белән бергә, күчми калды, күз алдында латин имласы белән тора, күрүең дә чормада — өй кыегына уелган айдан төшкән кояшта гына... «Ак каен» җыры әрнетеп-уйландырып, үткән дөньямда калды...

Шагыйрь исеме тыелган елларда да җыр күңелдә моңланып торды. Бабам, тәтәй җирләнгән зиратның матәм каеннары сыман иде ул. «Каен каера алмадым, кая барсам да үземнән кайгым калдыралмадым...», яки: «Каен ауган, каен ауган, кайтасы юлларыма...» Халык җырларында да ак каен — кара кайгы юлдашы... Аклыгы белән юатыр өчендер. Туфанның кайтыр юлларына кара еллар ауган икән...

Ак каенга кара ягылмый — хак нахактан аралана: мәңгегә дип ябылган зинданнан — теге дөньядан теп-тере Туфан кайтып төште! «Ак каен»ны җырлаганда аны да Тукай, Такташ сыман әллә кай заманда яшәгән дип белә идек. Ул пәйда булу шулар яныннан кайту сыман могҗиза булды! Хәсән абыйны сөендерәсем килеп, без сине онытмадык дип, «Ак каен» турында сөйләдем, ничек җырлавыбызны әйттем. Тыңлап та тормас дисәм, зәңгәр күзләрен тутырып карады — дымлы иде алар... Бер уңайдан тагын шуны да әйттем:

— «Юл буеннан аклар килделәр» дип җырлый идек, ак мундирлы аклар итеп күз алдына китерә идем. Китабыгызда «ятлар» диелгән... Ярлы авылдашны аскан — аклар булган бит, заманы-чоры шул?

— Уйлап карарга кирәк,— диде Хәсән абый, минем күңел булсын өчендер... Әмма яңа басмада алыштырган иде. Кыенсынып куйдым: дөрес эшләдемме? Бигрәк зур җаваплылык алганмын өстемә...

Хәсән абыйга әйтеп өлгермәгән бер күзәтүем калган икән, мин моны үзеннән соң гына күрдем:

Яфраклары яшел ак каенга
Юл буеннан аклар килделәр,
Ак каенның ярлы авылдашын
Билбавыннан асып киттеләр...

«Килделәр — киттеләр» рифма була алмый бит, берәр тәнкыйтьче «килделе-киттеле» дип төрттереп тә куяр. Моңа хәтле берәү дә сизмәгән. Хикмәт шунда: җырдай көйле тормышны дошман боза — ничек җайлы рифма калсын? Егет фиҗигасе яулап алган безнең күңелне — рифма кайгысымы!

Җырдан да ертык таптылар, җырны да төрмәгә яптылар, оныттырдылар... Баланы тетрәндереп, кызгану, шәфкать-миһырбанга өйрәткән сызланулы җырлар да кирәк. Без җырлаган тагын бер «Ак каен» бар, Зыя Ярмәки шигыре. Тыңлыйм да уйланам: нинди сере бар җыр дигән хикмәтнең, ничек заманнар кичә ул? Күңелнең кайсыдыр кылына чиртә, аваздаштыр. Хак шулайдыр «Ак каен»ның бусына кара якмадылар, иснәнеп, ак тузыннан «долой...» эзләп, һәм табып, тузга язмаган гаеп такмадылар, тамырына балта чапмадылар...

## ХӘТЕР



### Рәхим Саттар
(1912—1943)

### Халкым өчен

Көнчыгышта алсуланып
Ата ал таң.
Күккә калкып таулар күренә,
Гүя калкан.

Алга карыйм. Анда ята
Томан һаман.
Ерак Туган илдә яши
Газиз анам.

Коралдашлар яу кырында!
Кайда соң мин?
Кем мин сиңа, ятиммени?
Әйт, Туган ил!

Бар хәсрәтең, бар михнәтең
Миңа уртак.
Син генә сук, син иркәлә,
Син мине как.

Ләкин син бел: һәр сулышым,
Барлык көчем
Синең өчен, Туган илем,
Синең өчен!
*1942*

Хәсән Туфанның әлеге шигыре 1933 елны язылган. Аннан соң күп еллар узган, без җырлаганда дүрт кенә яшьлек булган шигырь... Ул арада ил өстеннән нинди фаҗигаләр кичкән, күпме язмышлар харап булган... «СССР» үзе дә зурайткыч пыяла белән дә күренмәс булды, югалды... Шагыйрь сүзе империя гомереннән озынрак булган дәверләр туар икән: Туфанның «Ак каен»ын бүгенге балалар да җырлый, кайтты җыр — муенына салынган цензура элмәге чишелде... Коткарып өлгердек!

## Башын киссәң... тамыр бар

Ул көнне бөтен авыл шаулады. Йә ходаем, ахырзамандыр, дип шөбһәләнде картлар. Манараны аудара калсалар, зилзилә кубар да җир убылып дөнсезләрне йотар! Мәчет — ходай йорты, аның рәхмәте илә күктән иңгән, мәңгелектер, ничек шуңа кул күтәрмәк кирәк? Көмеш ае нинди биектә, төшерә алмаслар, адәм кулыннан килердәй эш түгелдер. Азан авазлары, дога моңнары авыл тынлыгына ятышып, иминлек, миһырбанлык теле иде... Хөкем көткәндәй, тавышсыз-өнсез калган манара. Куркынып көтәбез. Мәчет тирәсендәге яшел рәшәткәгә тотынып югарыга карыйбыз:

— Монда торсаң — өскә төшәр...

— Читкәрәк китик,— дип, чигенә-чигенә, Нурхуҗалар бакча текмәсенә кунаклыйбыз, аннары мулла абзыйлар коймасына сөяләбез: монда да җитәр сыман... Хәзрәтнең йортында авыл советы, үзләрен подвалга — базга төшерделәр, тәрәзәнең өске өлгесе базмый гына урамга, кешеләр аяк астына карый... Аларны кызганмаган кеше юктыр авылда. Беркөнне шаулап яңгыр ташкыны басты, чиләкләп-чиләкләп суын түгештеләр, тартып алудан калган китаплар суда йөзгән...

Менә озын-озын арканнар китереп ташладылар мәчет алдына. Берберсенә ялгадылар — манара муенына элмәк... Биектә пычкы тоткан кешеләр күренде...

— Кемнәр микән?

— Мөэмин мөселман алынмас. Чуашларны китергәннәр, ди. Аркан тартучы да булмас!

Анысы да уйланылган икән. Арканга авылның активы тотынды, авыл советы председателе Палкин, Шәфигуллин Халла, тагын кемнәр... Безнең күзләр манарада: бик якын тора болар — өсләренә төшәчәк! Айны фәрештәләр күтәреп күккә ашар, дип тора картлар... Тартты, тартты тегеләр — бирешми манара! Сабантуйдай халык җыелган, тик шомлы иде бу мәйдан... Күккә тигән пәһлеванны җыелышып ирләр тарта, хәрәмләшеп, «аяк чалып» — төбенә балта чабып... Көчәнеп-бүртенеп, аяк терәп тарттылар... Чайкалды манара, менә хәзер ходайның каһәре яшен булып сугар. Шыпырт иреннәрдә бәддога... Тик күкләр аяз иде, авылның иң биектәге көмеш ноктасы юаш кына буйсынып җиргә төште, авыл күге бушап-котсызланып калды... Йөгерешеп без дә бардык, такталар чәрдәкләнеп сынган, ә ае — юк! Айны таба алмыйлар!

— Җиргә чумган ул, җиргә качкан! — диделәр, өметләнеп. Бераздан таптылар, көмештән коелган әйбер дәүләткә тапшырылырга тиеш, ди...

— Тәрәзә каршында гына — бу хәлгә хәзрәтнең йөрәге ничек түзә икән...

— Күзем күрмәсен дип, нишләргә белмичә, кырга чыгып киткән. Подвал тәрәзәләре мәчеткә карап тора бит...

Подвалга кусалар да, Афзал хәзрәтнең абруе төшмәде, авылның иң ихтирамлы кешесе, мөгаллиме, үтә дә йомшак күңелле, ихлас, зыялы зат иде. Бала-чагага тиклем олылап сәлам бирә. Уңайсызлангандай, мөлаем елмаеп, җавап кайтара мөхтәрәм карт. Китапта язган муллаларга бер дә охшамаган иде ул!

Авыл советының аяк астында — мулла абзыйның түшәме, аяк дөбердәүләре, шау-гөр, тәмәке төтене, йорт каршындагы баганада радио шаулап тора — азанны хәзер Мәскәү әйтә...

Шул көнне үк яңа бәет чыкты. Ул арада, кем чыгарды микән? Отып алдык, безгә нәрсә, кычкырып такмаклыйбыз, куркып торган юк:

Мулла абзыйның бакчасында
Йодрык-йодрык алмалар;
Мәчет манарасын тарта
Шәфигуллин Халлалар...

«Халла» дигәндә «Алла» сүзе ишетеп, сәерсенеп торам: ничек ул манарага кул сузган... Мулла кушкан исеме Хәлиулла икән, авыз тутырып әйтүче генә юк. Халык ышанып сөйләде:

— Менә, күрерсез, ходай җәзасын бирми калмас — кулы корыр!

Палкин фин сугышыннан качып дезертир булды. Халла, аяк-кулы өшеп, бармаксыз калды. Кызгансалар да, астыртын гына әйткәлиләр:

— Алла тоткан, аңа хөкем чыккан булган...

## ХӘТЕР



### Хәйретдин Мөҗәй
(1901—1944)

### Качкын

Ул каһәрләнгән кешенең
Күп-күмгәк булган төсе.
Барлык бандиттан да бандит
Шул инде качкын кеше.

Ул ватанына төкергән,
Таптаган эчкән антын.
Ул бүген качса, иртәгә
Безнең дошманга якын.

Ул эшләгән җинаятьнең
Чиге дә юк, башы да.
Дөньяда ни шакшылык бар —
Тиң аңар хас барсы да.

Ул сугышта канга батып
Сугышучы иптәшен
Ташлап китеп, түктерүче
Соңгы тамчы күз яшен...

Ул бүген суд каршысында,
Тел сата:
— Мин,— ди,— әле,
Гаебемне бетерерлек
Эшләр эшләрлек хәлле.

Суд аңар тик үк бирә һәм
Туфракка хак бирә.
Ул кабахәт җирдә инде,
Җиргә дә тик тап килә.

Булса булыр, җир белә ул,
Җир аңар бирми чәчәк.
Чәчәк тә юк, хөрмәт тә юк,
Исеме мәңге бетәчәк...

*1941*

Аркан тартмаган авылдашлар үлеп калды, анысын әйтүче юк... Халла избач булып эшләде, спектакль саен сәхнәдә, озын-мәзәк борынын сузып, кыяфәте, беркатлылыгы белән кеше көлдереп йөрде, озак еллар парторг булды, актив. Әмма гонаһсын онытмадылар, кичермәделәр...

Авылда ике мәхәллә. Үзәк чокыры арьягындагы мәчет гадәти кыеклы, каралган такталы булса, бусы күркәм иде. Түбәсе дулкын-дулкын, матур яшелгә буялган, ике катлы бина үзе алсу төстә, җиңелдер, очып китәр төсле иде. Бигрәк тә ае болытлар арасыннан йөзгәндә...

Тагын бер хәл искә төште. Зәйнетдин атлы кеше, акылга җиңеләеп киткән дә, шул илаһи биек мәчеткә су торбасыннан үрмәләп, манара төшерүчеләргә ләгънәт орып түбәсендә йөгереп йөргән. Туктатып кара, чабуыннан тот! Ничек егылып төшмәгәндер, ходаның хикмәте. Акылына зәгыйфьлек килүгә дә мәчет фаҗигасе сәбәпче икән... Төшкәч үк тотып алып, кулларын каерып бәйлиләр дә районга озаталар.

Кайбычка алар кичен килеп житте, бездә куна калдылар. Зәйнетдин абыйны да алып керделәр. Кулындагы бауны чиштеләр: кызарып-шешенгән, бау сырлары батып кергән. Сүзсез генә уып утырды... Төнлә нишләр, дип шүрләгән идем, шымы да чыкмады, тыныч иде — ачу-ярсуын кузгатканнар авылда калган. Казанга илтеп тапшырдылар — «сары йортка»...

Иң биек урын — мәчет манарасы иде. Руханилар рухны кайгырткан. Хәзер авылларда силос башнясы — корсак биектәрәк. Рух җәлладлары фикер манараларын кисеп торган — үткәнне бүгеннән аерганнар.

«Мәчет манаралары, манара аралары...» Замана аралары ярты гасырдан артык булды. Яңа мәчетләр күтәрелә. Элеккесе урынында сугышта һәлак булганнарга һәйкәл тора. Мәчет белән бергә туздырылган рухларга да һәйкәл ул... Яңа манара тәбәнәгрәк, «башын киссәң, тагы үсә» дисәк тә, авыррак үсә шул, әмма тамыр исән, тамыр киселмәгән — яңа Айлар үсеп чыккан. Афзал хәзрәтнең улы Әсгат кордаш әтисе вазыйфасын үти, аның кебек үк сабыр, изге күңелле. Урманда эшләде, үзе язган шигырьләрне укый иде, хәзер мәхәлләгә Коръән моңын җиткерә... Манара кискәндә җанына урын таба алмыйча иген арасында ярсып йөргән әтисе әйләнеп кайткан сыман — рухы тынычтыр инде...

## «Шуңа күрә, уй йомгагын сүтеп...»

Район китапханәсенә кергәч, исләрем китеп торган идем: элекке мәчетнең биек түшәменә чаклы китап та китап! Таган атынганда, йә биек агач башыннан караганда баш әйләнеп, эчләр жу итеп китә бит — монда да шул түшәмгә җиткәнче укыйсым, анда көткән хикмәтләр иләсләндерде. Китапларның тыелгысыз тарту көчен тойдым.

Сусап, йотлыгып укыган чагым. Төн уртасында электр сүнгәч, имеш, Горький язган малайга охшатып, айлы төндә кәстрүл төбе белән яктыртып укыйм... Шул көннәрдә китапка карандаш белән язылган шигырьгә юлыктым:

Шулай инде,
Аны яшереп булмый,
Яшь күңелем Сезне ярата.
Шуңа күрә,
Уй йомгагын сүтеп,
Шигырь язам Сезгә карата...

Каты басып та язмаган карандашы, сак кына, йөгереп кенә узган. 1939 ел бу, латин әлифе белән язылган, без аны дүртенче класска тиклем укыдык. Кемгә багышланган, кем язган — билгесез. Мәхәббәт иясе күреп хисләрен таныр, дигәндер. Шигырь китапларын күп укыганым бар, ә

бусы... Кеше шулай үзе теләгәнне яза ала икән: каләм ала да яза! Җанны тынгысызлап, моңача татылмаган рәхәтлек уянды: илһам ялагысы канатлана башлагандыр. Бәпкә дә шулай кыймылдап ала, аннары ак кабык эченнән ишетелер-ишетелмәс тавыш бирә...

Шигырьне язган билгесез егет, ике йөрәк арасындагы сер дә кызыктырган мине. Кем икән ул? Кайбычта ун ел яшәсәм дә, шигырьгә һәвәсләрне якыннан белсәм дә, очратмадым мин аны. Фин сугышына эләгеп, Маннергейм линиясендә кар өстенә аудымы? Әллә Ватан сугышына китеп, окопта язган дәфтәре бомба чокырында күмелдеме? Сөйгән кызына ирешә микән «Сез» дип килештереп әйткән нәзәкәтле «уй йомгагы»?

Азмы ул яшьлектә кабынып гыйшкын белдергән саф күңелләр... Илһамнары бер шигырьлек булса да, бәхетле алар: йөрәк серен сөйгәненә җыр итеп җиткерердәй илаһилык кичергән. Яшьлек хыяллары шигъри киек казлар булып йолдызларга күтәрелү бәхете һәркемгә тәтеми.

««Шуңа күрә, уй йомгагын сүтеп...»» — ихлас ярату белән кызыгып кабатлыйм әлеге шигырь юлларын. Минем дә шигырь йомгагымның очын тоя башлаган бәхетле чагым булган ул... Илһам да, мәхәббәт тә өзелми-югалмый, күңелдән-күңелгә күчеп яшидер...

## Хыялга бер адым калгач...

Китапханәгә тартылам — хыялымны эзлимдер... Рәсем белән мавыккан чагым. Пушкин, Лермонтов шигырь-поэмалары, рәсемнәре бердәй кызыктыра. Өметләрнең чыңга ашуын күрәсе килә китапта. Әнә бер ятим малай, торыр җире юк, үзе ач, эте белән кышкы урамда калган, өстендә сәләмә кием. Эте минем Сарбайга охшаган... Хыялы җылыта аны, рәссам булмакчы! Минем сыман дип, йотлыгып укыйм. Шәһәрдә күргәзмә-ярыш буласы, шунда катнашмакчы, аннары рәтләнер иде. Ә киндер алырга, майлы буяуга акчасы юк. Такта кисәгенә күмер белән яза... Минем әле акварелем бар. Төнлә килеп, бозланган тәрәзәдән карый — аның эше дә куелган! Таң атар, ачылыр бу зал, күрер кешеләр...

Күргәзмә ачыла, гап-гади күмер белән язылган рәсем күз явын алырдай төсләрдән өстен чыга! Зур талант иясе, дип бәяли осталар. Кем эшләгән, кайда ул рәссам — күренсен! Эзлиләр, белүче юк. Урамда этен кочаклап туңып үлгән малай табыла, әлеге рәсемнең иҗатчысы икәнне белмиләр...

Китапларда төрле фаҗигаләр очраган. Әмма бусы... Хыялыма ирештем, дигәндә бит, нинди кызганыч... Ник шәфкатьсез бу язмыш? Язучы да җәлләми — исән калдырса соң? Художниклыкка укый башласа? Үз өметем өзелгәндәй, шуңа онытылмый ул... Сәнгать корбан сорый шул. Әсәр укучыны «җәлләмәсә» генә күңелендә кала... Хикәя татарчага тәрҗемә иде, язучысын карамыйча укыган чагым, исеме дә онытылган — китаплар океанында күмелеп калды...

Икенче бер очракта язучыны «төзәтми» түзә алмадым... Бусында да ятим малай, портка юнга булып яллана. Олылар белән беррәттән эшли, торыр җире, сыеныр кешесе юк. Боцман аны кыйный, җәберли. Матрослар теш кысып түзәргә мәҗбүр — өйдә ач балалар көтә... Ятимнәрне кызгану күңелгә җыелган: өйгә кереп хәер эстәгән теләнчеләр, Тукай язган мескеннәрне җәлләү... Авылга — бабайга дип, өметләнеп хат язган малай, барып ирешмәс хаты... Юнганы да яклыйсы иде! Җаен таптым, хикәянең азагына үземчә өстәдем:

«Юнганы газаплаган өчен боцманның да кирәген бирде матрослар — яр буена капланган көймә астыннан кыйналган хәлдә табылды...»

Китапны буярга ярамый да, тыела алмадым, ичмасам, миннән соң укыганнар канәгать калыр:

— Шул кирәк кансызга! — диярләр.

Әдәбиятның хаклык яклавын, тормышны төзәтүен күрәсем килгән. Сүзнең илаһи көченә ышану булган... Рәсем дигән хыялымны әдәби сүз алыштырды. Пушкин, Лермонтов рәсемнәре дә шигырьләре, поэмаларына кушылып «эреде»... Шулай да рәсем — ирешмәгән хыялым, татлысагышлы үкенеч булып күңелемдә яши. Ул хыялыма бер генә адым түгел шул инде...

## «Безнең нәсел — күзе яшел...»

Шәкерт абыйга тартылам, аның кебек буласым килә. Энем, абыем юк, шуңамы? Әткәйнең кече энесе ул, кан кардәшлек тартамы? Безнекеләр, кем әйтмешли, берсе дә төшеп калганнардан түгел. Шаянлык, кирәк микъдарда хәйлә, хәтта тыйнаклык та бар бугай... Хатип абый егетлеге белән аерылып тора. Туры сүзле. Кайчакта кискен, әмма һәрвакыт гадел. Хакыйкать, дөреслеккә аеруча сизгер җаннар була, ул — шундый. Дөнья күргән агай-эне ярашмыйча, үзенчә яшәвен күрәләр, яшьрәк дип, елмаебрак карыйлар. «Безнең Хатип шундый!» — дип хуплый үзләре. Аңа охшаган дисәләр, минем башым күккә тия. Тик бервакыт сынаттым, оятка калдым...

Төн җитеп, соң гына арып-талчыгып кырдан кайттык. Өйдә без абый белән икәү генә. Өстәлгә аш куйды: итле бәрәңге исе шундый тәмле! Өстәл әзерләшер урында, мин түземсез, табакка сузылдым...

— Олылардан алда үрелмиләр! — дип өзеп, үткәзеп әйтеп куйды. Шундый итеп карады — ят кеше диярсең... Гаебемне белсәм дә, үпкәлисем килә: ник алай карый, яраткан абыем ич... Гадәтсезлекне ят итеп, ошатмыйча караган, кеше арасында йөз кызарырлык булмасын, дип кисәткән. Гомергә онытасым юк...

— Кемнеке — аныкы, сынатмыйк! Без — Һидиятуллиннар! — ди ул. Гадәти фамилия дә, түгел дә сыман, ул әйткәч. Хатип абыйга кушылып:

— Безнең нәсел — күзе яшел! — дип үк җибәрәм. Ә үзенең күзләре коңгырт әле, минем дә шундый...

Авылда кушаматсыз кеше юктыр. Шуның аркасында малайлар тәпәләшеп тә ала. Безнең кушамат әйбәт — «Шырпы!» Кабыныр да китәр, юаш бу димә, белеп тор, яме! Һидият бабай әле ике кушаматлы — «Гайяр» дигәне дә бар. Хатип абый сыман булгандыр ул да...

Үз дигәнендә тора алуына кызыгам, ул миңа үрнәк. Мәктәп Корчагинны күрсәткәндә изге урын буш түгел иде — Шәкерт абыем бар — мин аның шәкерте. Һәркемгә мәҗбүридәй «яңа үрнәк» итеп тагылганнар — була да үтә, ә менә үзеңнеке үзәктә — үзгәрми торганы, җанга якыны — гомергә кала.

## Зәңгәр тышлы җырлар дәфтәре

Шәкерт абыйның Ленинградта эшләгәндә алып кайткан, мин күз кыздырып йөргән өч әйберсе бар: ике йозаклы шомырт кара портфель, ялтырап торган тимераяк, зәңгәрсу тышлы, шома кәгазьле куен дәфтәре. Иң кызыкканым шушысы — эче тулы җыр, дуслары килгәч, үзләре генә укыйлар. Ул чаклы гына рәт беләм лә — андый чакта тагылмыйм. Ә алар бер-берсенә карашып, көлешеп ала, күзләре наян елтырый. Кызлар турында сөйлиләр... Мәхәббәт җырлары анда, үзе юкта карамакчы булам да, җыештырып йөри. Ерактан күзем төшкән иде:

гарәп әлифе белән язылганы бар, күбрәге безнеңчә — латин. Мин бит инде икенчедә. Гыйшык җырлары гына да түгел анда. Хәер, җырны яшереп була мени...

Утыз җиденче еллар дигәч тә, дер калтырап кына яшәлмәгән, тормыш үзенекен итә. «Телеңне тыя бел», «Ут белән уйнама» дигәнне белә торып, хәтәр шаяртучылар бар. Бер-беренә ышанган халык. Сөт сорап кергән ятимә карчык та чүлмәген сузганда әйтеп куя:

Ләгнәт төшсен Николайга —
Ике сыер саудырды.
Рәхмәт яусын Ысталинга —
Бер кәҗәсез калдырды!

Казан астына ягып чумара пешерергә «карга оясы» төяп кайтканда:
— Тпру, Ысталин айгыры! — дип уфалласын туктатып, алъяпкыч итәге белән битен сөртә:

Уф алла, диярбез ди үлгәч,
Китереп куярлар ди каткан күмәч.
Анысын да алып китәрләр ди,
Калхуз икәнне белгәч...

Безнең дә ишетеп-отып алган такмаклар бар, телгә килә дә тора. «Ярамый»ны беләбез, шунысы кызык та, як-якка карангалап көйлибез:

Кәнүшнинең кыегы —
Ысталинның мыегы!

## ХӘТЕР



## Нур Баян
(1905—1945)

### Сандугачка

Кызык кош син, сандугачым-дустым,
Туп ярыла, ә син сайрыйсың,
Тормыш итәр өчен туган илдә,
Оян өчен куак сайлыйсың.

Матур ил шул безнең илебез,
Ал чәчәкле безнең җиребез.
Их, яшисе килә илемдә,
Һич үләсе килми тигенгә.

*1943*

Кем кемнән ишеткәндер — сүз иясе белән йөрми. Эзләгәннәр «иясен» дә таба икән: төнлә НКВДдан килеп бер абзыйны алып киткәннәр — суга төшкәндәй гаип булды. Кәнсәләр янында кич тәмәке тартканда сөйләгәннәрен кемдер җиткергән. Караңгының кара йөзе... Кармавычлар ерак авылга да житешкән...

Хатип абый да чит күзләрдән саклаган дәфтәрен. «Ярамаган» җырларны җае чыкканда ул да көйләп куя. Тик язу — икенче нәрсә, кәгазьдән саклан син! Армиягә алынгач, хәрби трибунал юлында моңа тагын бер кат инанган. Шомлы еллар, шымчы еллар кәгазьне дә, йөзне дә саргайткан...

Укырга керәсе елымда кояш тотылган көнне хәтерлим. Зур афәтләргә, сугышка ишарә дип шомланды халык. Мондый кояшка карарга ярамый, дип кисәттеләр. Күзне яндыра, сукырайта дип, корымлы пыяла бирделәр... «Кояшыбыз — Сталин» дип җырладык мәктәптә. Ул кояшның да «тотылганын» күрергә ярамаган, күңел күзенә пәрдә корганнар. «Кояшта да таплар була», — дип яклаучы тарафдарларга ни дисең? Кояш дигәннәре Тап кына, кан таплары, сүнгән гомерләр шәфәгы... Күңел карынында — тумый калган җырлар...

## Чегән карчыгы ни юраган?

Шомлы хәбәр гомергә куркытып уятыр: йә пожар, йә кәнсәләргә чакыралар. Тагын ни булды микән — тәрәзә кагалар? Әткәй хәвефләнеп сорады, шәкерт абый үкси... Йокы аралаш гаҗәпләнеп торам: ул да җылый микәнни?

— Абый! Әнкәй... вафат...

Әткәй дә җылый икән... Тәтәйме? Юк, юк, саташамдыр, төшемдер, хәзер уянам... Өнем, өнем. Кайгыны төшенми, түнеп торам — еладым микән әле. Былтыр кояш тотылганда дөнья шулай караңгыланган, шом ябырылган иде...

...Яңа ызба түрендә сузылып ята тәтәй, исән сыман тыныч, мөлаем, ничек инде үлгән булсын? Уяныр да ачар күзен. Мин генә түгел, бүтәннәр дә сагая калды:

— Мәрткә генә киткәндер?

— Көзге куеп карыйк!

Ашыгып, сөлге япкан көзгене алып килделәр, нәрсә күрмәкчеләр? Битенә якын куйдылар, әткәй, Сафа абый, Хатип абый, апа текәлеп көтә:

— Парлана бит! Тын ала! — дип сөенделәр. Өметләнеп кабат тикшерделәр — көзге коры иде. Үзләре сулышы икән... Хикмәте бар көзгенең — исәнне үлгәннән аера белә. Юкса, мәрткә киткән кешене ялгыш җирлиләр, ди. Мин дә сынап карыйм: күзне йомам да көзгене битемә куям: суламый торсам да парлана...

Хатип абый белән Сафа абый ат җигеп, көрәк, кәйлә салып, зиратка кабер казырга бара. Мин дә иярдем. Безнең якта үзле кызыл балчык — кирпеч балчыгы. Шактый казыгач, гүрен уйгач, таманмы дип, шәкерт абый ләхеткә кереп ятып карады. Курыкмый... Абыйлар алдында сынатаммы, төшеп мин дә сузылдым. Өскә карыйм — тар гына зәңгәр һава сызыгы күренә... Тыгыз, дымлы балчык. Бу иләмсез калын, авыр җир гөбердәп ишелер, чыгып өлгерә алмам, кабер кысып алыр сыман... Тизрәк чыгыйм! Алай да сер бирмим... Ниһаять, кулларымнан тартып өскә алдылар. Тар гына күренгән һава нинди иркен! Арбада чалкан ятып, йолдызлы чиксезлеккә хәйран калып кайтам. Кай арада кич булган... Каберлектән ат пошкыра-пошкыра юырта, минем дә тизрәк ерагаясым килә. Тирән базга — балчык астындагы гүргә бүтән төшәсем килми... Тәтәй анда ничек ялгызы ятыр?

— Курыкма, энем, гүргә ятып караган кешенең гомере озын була! — ди шәкерт абый, минем хәлемне аңлап. — Яшибез әле без синең белән!

1937 елның 6 ноябре иде. Илдә — бәйрәм, бездә — кайгы. Илдә дә вәйран көннәр булган, баксаң. Исемсез кабер-чокырларга миллионнар күмелгән. Бу фаҗигаләр соңлап ачылды. Хатип абыйлар 1937 нең чын бәясен белми киттеләр. «Гомере озын буласы» кешенең тулыр-тулмас дүрт елы калган икән. Кабере дә еракта булыр... Кабергә ятып карамаган Сафа абый әлеге зиратка кырык елдан соң кырык имән утыртыр...

— Берсе китмәсә — берсе китәр, имән озын гомерле, тере һәйкәл булсын,— дигән иде ул. Кеше гомере бер саплам гына шул. Сафа абый инде үзе дә шулар ышыгында...

Хатип абый, вокзалда чегән карчыгы очрап, киләчәкне юрады, дигән иде. Үз язмышы, сөйгән кызы турында нидер әйткән чая карчык. Онытканмын, һич кенә хәтерли алмыйм: ни юрады микән? Хәер, багучы алдан күргән «киләчәк» күптән узган, яшь егетнең гомере тәгәлләнгән... Үткән вакыт — иң рас әйткән күрәзәче, аңардан соң барысы да ап-ачык... Ярый әле тереклек шулай көйләнгән — кайчан ни көткәнне беребез дә белми...

## Ярату... Яр... Яра...

Авылга шәфкать туташы килде. Кечкенәрәк буйлы, кара тутлы, шомырт кара толымнары яшел чирәмгә тияр-тимәс тирбәлеп барган, бөтерчектәй җитез, ап-ак тешләрен балкытып елмайган яшь-яшь кыз. Ә үзе... бала тудыру йортында эшләячәк. Әбиләр шөгыле ич, кендек әбисе урынына — кендек кызымы?! Яшьлегең үзсенеп, без малайларны тиле димәдеңме — артыннан ияреп, үртәп-үчекләп барабыз:

— Фәйтүнә апа, бала таптыр әле!

Шамакайлык өчен әле дә оялып куям... Фәйтүнә апа исә, илтифат итмичә җәлт-җәлт атлый да, кинәт борыла! Менә ачуланып, аяк тибеп кычкырыр, дип, без инде качарга әзер. Ә ул бармак янаган итә дә, шундый матур итеп яратып елмая!.. Авылга ак күбәләк булып төшкән ак халатлы «кунак кызы»ның күз чагылырлык чибәрлегенә, мөлаемлегенә сарылып йөрмәдек микән ул чакта? Матурлыктан аерыла алмыйча? Ишеттек, ятимә үскән, япа-ялгыз икән... Ятим бала моңлы була, ә ул шундый сөенеп елмая. Кызлар шулайдыр инде...

Олылар арасында сүз югарыдан йөрсә дә, чос колаклар түбәнтен дә эләктереп ала:

— Фәйтүнә-Хатип... — дип телгә керделәр. Мин моңа сөендем, горурландым: безнең нәсел — күзе яшел, Шәкерт абыйга пар шул Фәйтүнә апа. Үз иттем. Бүтән үртәмәс булдым...

Туганымдай күрәм, очрап исәнләшкәндә үзе дә сизенә бугай. Ак халатлы шәфкать туташы күрсәм, күңелем җилкенеп, сагышлы моң тулыша: үкенечле мәхәббәтләр ромашкадай ак канатлы була микәнни? Шул «ярата» дип юрау никләр генә дөрескә чыкмыйча, «яр... яра...» булып өзелеп кала икән? Чегән карчыгы ни юраса да, ромашкалар ни дисә дә, язмыш үзенчә йөртә шул. Шәфкать туташларына да шәфкатьсез булды сугыш. Ә минем күңелдә кадерле ике исем кавышып җиткән иде... Икесе ике дөньяда булсалар да, яшьлек хыялларымда алар һаман янәшә...

## Колларга сәфәр

Латифа тәтәйнең туган авылы якын гына: рәшә уйнаган офыкка — Коллар кашына күтәрелеп, каршурман буйлап кына барасы... Ул чакта алар — Апас, без — Кайбыч районы булгач, ике арадагы юл артык такырланмый, әмма үлән дә үсми иде: күбрәк безнең туганнарның тарантас эзедер. Бик якын күрешеп йөриләр, дөнья бәясе

кешеләр: Вафа абый, Зариф абый, Сабир абыйлар... Алар килсә — бәйрәм, без барсак — күңелле очрашу сабантуйга әйләнә. Бер-берсен зурлап, хөрмәтләп җырлау дисеңме, тальян да ничек үз итеп сайрый, куана! Табыннан кузгалып, буыннарны язып алганда, шаярышып булса да чынлап торып бил алышалар. Кайсы як җинсә дә, безнеке өскә чыга, безнеке ота.

Колларга иң әүвәл барудан истә калганы шул: кызыл балчыклы текә ярдан «чәй үләне» җыйган идек. Зариф абыйның зәңгәр күзле ике малае — Нәсихы, Шәрифе белән. Чәйгә яраклы үләннең исемен әйтә алмыйм, күрсәм танырмын сыман. Мин дә җыйдым, туган авылымныкы дип, тәтәй куанып, сөтләп, баллап эчәр, дип.

Чәй үләне үскән кызыл тауның үз исеме ничек булгандыр. «Кызылтау»дыр — берничә елдан авыл исемен шулай дип үзгәрттеләр. Юрамалый сыман иде, элеккечә Коллар дип йөрдек. Ирек биргән Октябрьдән соң нинди к о л л а р булырга мөмкин, «кызыл» тиеш, дигәннәр. Рәттән алмаштыру китте шул, ярый әле Кол Галине «Кызыл Гали» диярга фәрман чыкмаган...

Колларга сәфәрне яратам, сыгылмалы тарантаста мамык мендәргә сөялеп-чумып кына тирбәлеп барулар, яратып каршылауны көтеп алам. Кем ничек туган тиешлесен белеп тә бетермим — «безнекеләр»! Коллар белән ике арада юл өзелмәгән: атлар кешни килгән, дуга кыңгыраулары, йөгән шөлдерләре «сөенче, сөенче» дип челтерәп кагына килгән. Латифа тәтәй ике авылдагы ике төп йортны бердәй итеп яшәгән — әнә бит, кар төшкәләп торган бер көнне, октябрь тирәсендә диләр, сүс өмәсе вакытында Коллардан кайткач, өченче малае — Галиулласы туган, әткәй буласы дөньяда бердәнбер кешем...

Колларда зәңгәр күзле яраткан туганнарым бар минем. Һидият бабам күңеле тикмәгә төшмәгәндер — кызларында күңелне җилкетеп торган мөлаем мәхәббәт нуры очкынлана. Латифа тәтәмнең, туганнарымның туган авылы ул!

...Җиңел канатлы тарантасларда очып, Коллар түреннән — үреннән төшәбез. Тәгәрмәчләр йөгерә генә, кайнар атларны чак тыялар. Зират каеннарына җиттек... Ак күлмәкле тәтәй сыман алар... Тамырланган карт ботакларда яшел шәле тирбәлә. Латифа тәтәй белән Һидият бабам кабере янәшә. Коллар белән ике арада: кайтып кына җиткәннәрме, китеп кенә баралармы?.. Мәңгелек сәфәрдә алар. Кыңгыраулы юлларда ашкынган каннары безгә күчкән. Бездән дә калыр... Шул сагындырыр Колларны, Коллар юлларын, чәй үләне үскән кызыл тауны... Коллар дигәндә кимсенмик, коллар инде без мәңге-мәңге — мәхәббәт, сагыну коллары...

## «Истанбул аптый» дияр идемме?

Урамнан йөгереп кергәндә, болдыр басмасында ят кәвешләр күрдем. Чоландагы кисмәктән су чөмереп чыгыйм дисәм, әнкәй самавыр күтәргән:

— Кунак бар!

— Әнкәй, кем килде?

— Кер әле, кер, үзең күрерсең!

Ишек ачтым да каттым... Бусагага басма, үсми калырсың, дигәнне беләм, аптыраудан инде... Түребездә ак ефәк шәлен бөркәнеп Латифа тәтәй утыра! Тәрәлеп калганны күргәч, сәкедән төшеп, колачын җәеп каршыма килә:

— Нихәл, бәбкәм? Оныттың мәллә? — дип сөйкемле карый.

Ничек инде, ни хәл бу — тәтәй терелеп кайтканмы?! Аркамнан сыйпый, йомшак шәленең чуклары битемнән агыла... Көләп җибәргәч, эре

тешләреннән таныдым: Чатбаш аптый ич — тәтәйнең сеңлесе Гайнелгаян! Бик охшашлар шул. Әнкәй дә инде, әйтеп куйса ни була... Нишләр икән дип, кызык ясавы. Мәскәүдә озаграк торгач, ятсына төшкәнмен.

Чатбаш — Коллар кырында гына, бик кечкенә чагымда әткәй бер алып барган иде. Боланың сай суында юшкында йөргән идем. Балык посарлык та таш күрмәдем. Балык та күрмәдем. Бездә булмаган бака казаны — кабырчыклар күп иде. Чирәмле, аулак урамы, яшь таллары истә. Чатбаш аптый дип шуңа әйтәм — кияүгә чыгып шул авылда яшәгән. Тәтәйнең тагын бер сеңлесе Бәдерниса — Казма аптый, Казма авылында... Җеназасына килгәннәр иде, сирәк күренгәч, ияләнеп тә өлгермисең.

Тәтәйләр алты кыз туган, Коллар аптый — Фәхерниса, Кыр Тәүгелдесе аптый — Кәттәюн. Ике ир туганы да бар — сигез бала үскәннәр. Олы туганнары Бибизәйнәп Төркиядә — Истанбулда төпләнеп калган. «Күченеп килгәч, дөя бирделәр. Беркемгә саудырмый, җиленен тоттырмый, ә миңа ияләште», — дигән хатында. Тәтәй сыман җайлы, мөлаем, йомшак куллы булгандыр. Баштарак хатлашып торганнар, кайткалап йөргән. Өченче баладан үлгән... Елмаеп үлгән, нинди тәэсир күңелен хуш итте микән? Балам исән калды, дипме? Җаным туган җиргә кайтыр, дипме? Үлем — соңгы сер... Ике кызы туганлыкны өзмичә хат язган язуын, җавап булмаган, адрес югалган. Чит мәмләкәттәге туганнар белән мактана торган заман түгел иде. Бик белешәсе килсә дә, мин дә эчтән тындым. Орынып торган күрше Төркия безнең өчен ябык, бикле иде. «Личный листок»тагы: «Чит илдә туганнарың бармы?» дигән сорауга «юк» дип җавап бирә идем. Истанбул аптыйны кайда, кем белә...

Кайларга таралмаган кан кардәшләр, шәҗәрәнең чыбык очлары? Хәзер дә Истанбулда безне югалткан, үзләре дә югалган туганнар бардыр. Киткәнче Савиново дигән җирдә яшәгән алар. Казаннан еракта да бар андый урыннар. Динне кысу башлангач, гаиләләре белән киткәннәр.

Чатбаш аптый, куркып торуымны күреп: «И, бала, и бәбкәм, үз тәтәңнән куркалармы?» — диганнәр. Үзем дә оялдым, тик аклана-аңлата алмадым. Тәтәй терелеп кайтса, сөенергә кирәк иде дә бит... Аннары күнектем, төшкә керсә иде, дип сагынып торам. Соңгы юлга китәләр генә — кайту юк... Кояшсыз дөнья, караңгы дөнья... Истанбулдагы Бибизәйнәп аптый да чик артындагы «теге дөнья»да калган. Чатбаш аптый, Казма аптыйдай, анысын «Истанбул аптый» дияр идем микән?

## «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны»

Избачтан кайтуынча, шәкерт абый дуслары — агалы-энеле Әһлиулла белән Галимҗан абыйларга керде. Мин китапларын күтәрештем. Анда тагын кемдер бар иде, хәтерләмим. Истә калганы — кызыклы шигырьләр! Абый укый, тыела алмыйча, рәхәтләнеп көлешеп алалар, яттан да сөйләп ялгап китәләр. Такташ икән! Бергәләп уку өчен кергән абый, бергә күңелле!

Ярату күңелдән-күңелгә күчә, җаның эзләгән рухташыңны шулай табасың. Тукай моңнары хәреф танышанчы ук әткәй-әнкәй мәкаме белән иңсә, Хатип абыйның мәхәббәт тулы күңеле Такташ дәртен тойдырган, гомергә истә калган:

Әй, җырлыйсы килә шушы җырны,
Бу җыр шундый якын күңелгә,
Җырланган җыр кебек яшьлек таңы
Шаулап үтте,
Шаулап үтте инде гомергә!

Хатип абый дәфтәрендәге: «Яшьлек, гомерең кыска синең...» дигәнен дә Такташ язган. Егерме ике яшьлек егетләр яшьлек чәчәген сугыш коясын сизенгәндәй булган...

Такташка күңелем ачылган көн булды бу. «Кара борынның дусты», «Байрак тегәбез», «Пионерлар маршы»н беләм, дәреслектә бар. Абыйлар укыган Такташ бөтенләй бүтән! Шаян шигырьләрен беренче ишетүем. Укып кәефләнә торгач, бер мәлне мине дә шаярттылар.

— Синең хакта да язган,— дип, Хатип абый укып күрсәтте:

Шәүкәт белән таң нурлары арасыннан,
Бәхет эзләп илдән-илгә барган чакта...
...(Үткән көннәр безнең якты түгел,
Ләкин шәүкәт белән алар үтелгән...)

Бәлкем, шушы көндә шагыйрьнең шаян очкыннары күңелемә чәчрәгәндер? Ниндидер ашкыну тоеп, талпынып-сулыгып куйган иде йөрәгем. Әле исемен дә белмәгән-ишетмәгән илаһи тойгы-илһам булгандыр. Заманында Такташ эшләгән «Чаян»га да шул китергәндер?

Мәхәббәте, шаянлыгы яраттырган. Тәнкыйди фикерне оеткан, сатира керпесе кыркылган чорга җан кертеп, Тукай белән икесе укучыларын сәхнә-мәйданга җыйган, туган тел тәэсирендә тоткан. Тукай — моңыбыз, Такташ — мәхәббәтебез. Изге ният, матурлык кына мәхәббәт хәтерендә. Әле бер галимнең, аңа кушылып, яшь шагыйрьнең «мескен Такташ» дип, тәкәббер генә «киләчәктән хат» — хөкем язуларын укып күңелем рәнҗеде. Чор өчен җыр гына гаепләме? Шагыйрь фаҗигасен кем аңлар да кем аңлатыр? Әйбәт фал түгел бу... Ихтимал, тарафдарлары кимегәндер шагыйрьнең, шәкерт абыйлар, бик күп укучылары сугыштан кайтмады. Биштәрдә Такташ китабын йөрткән алар, әлеге галимне дә, шагыйрьне дә дошманга бирмәгәннәр. «Туплар сугышка аркан баралар...» — дигән Твардовский «Теркин теге дөньяда» поэмасында. Хатирәләр гыйбрәте дә, үткәннәргә каратылса да, бүгенгә төбәлгән. Сак булыйк, ялгыш үзебезнекеләргә төшкән тупның ни аяныч икәнен фронтовик баласы белергә тиеш иде...

*Дәвамы бар.*

# ШИГЪРИЯТ



## Зиннур Мансуров

### Дүнү

Дүнә дөнья, дүнә денсез дөнья
дуамаллык тулы бер өйгә.
Әллә кайда җиде баҗа улый:
«Бөрадәрләр идек бүрегә...»

Абыеңны, Йосыф, абайладым
(килеп җиткән ничә ел аша) —
әртилендә һәрбер астыртынга
канлы күлмәк тегеп өләшә.

Дөньялыкны денгә димләгәндә,
хәтта анаң сөте каралыр.
Сукыр тәкә булып хаклык эзли
картлар йортындагы король Лир.

Җантаһире белән Җанзөһрәсе —
әллә ничек бүген ят алар;
сыендырган газиз сандыкларын
урталайга... кисеп яталар.

Үги кызың, дөнья, өйгә кайтмас,
Айдан иңмәс инде без барда.
Искитәрлек: әллә Исусыңмы
кадак сатып тора базарда?!

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) — *шагыйрь, публицист; унга якын китап авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Мәтрүшкә

Малай чагым. Өйдә шау-шу. Гаҗәп хәбәр —
безгә Коръән җибәргәннәр Себердән.
Шушы изге китап белән сабый җанга
гомер буе ачылмаслык сер иңгән.

Кардәшемнең соңгы исән ядкаренә
аулак кичтә ничә тапкыр тартылдым.
«Рәсем»нәрен эзләштереп утырганда,
кәтелмәгән күренешкә тап булдым.

Сәер табыш, сискәндереп, өнсез итте,
уйнак малай әверелде мәэюскә.
...Инде менә ничә еллар истә тора
иске Коръән эчендәге... мәтрүшкә!..

Сулар акты. Җилләр исте. Комнар күчте.
Янгын чыгып, гаип булды Коръән дә.
Мәтрүшкәләр менә тагын миңгерәтте,
печән чабып, яшел чатыр корганда.

Яманатлы сөргенченең әманәте,—
хәзер инде булмый аны аяп та.
Гаҗизләнәм: кыстырылган мәтрүшкәсе
кибеп ятты икән кайсы аятьтә?!

Күзалларга җөрьәт итәм үземчәрәк:
«Тынычланып, Тәңребезгә кайт, кеше!..»
Коръәндәге нинди битне билгеләгән —
«Тәзәккәрү»? «Тәфәккәрү»[1]? Кайсысы?

Инде хәзер малай чакның шушы сере
хәтеремне эзәрлекли һәр төштә.
Абзыкаем үзе генә аңлатмасмы,
күрешергә насыйп итсә гарештә?!

Ирексездән мордар киткән ырудашым
язган булса өч кенә сүз, өч кенә!
...Мәтрүшкәнең учымдагы чәчәкләре
ява төсле ләүхелмәхфүз[2] өстенә...

## Пирамида

*Классташларым Марсель, Таһир,*
*Фәрит, Нургаян, Раиф истәлегенә*

Сабакташлар, без бит, сөбханалла,
шундый дәртле, сылу, төз идек!
Хәтерлимсез: мәктәп сәхнәсендә
тере пирамида төзедек.

[1] Коръәннең «Искә алыгыз!», «Уйлагыз!» дип башланган аятьләре.
[2] Язмыш тактасы.

Жилкенешә идек жилеккәчә
ноябрьнең житкәч жидесе.
Угланнарны бергә укмаштырып,
күккә чөйгән нинди жен көче?!

Кайнаткандыр кайнар каныбызны
бөек корылышлар шаукымы...
Йөрәгемнән һаман ерагаймый
мәктәп елларының шул көне.

Күнелемне ничек күнектерим —
ээәрлекләп тора авыр моң.
Мәчетләре әле манарасыз,
айсыз чагы иде авылның.

Сихерләгеч мәктәп сәхнәсендә
пирамида булып калыктык.
(Балавыздай күндәм балаларын
йөзгә әвәләүче халык юк...)

Империя кемне имгәтмәгән,
тере килеш салып нигезгә.
...Башыгызга менеп басуларым
бәгырь-үзәкләрне ник өзә?

Иңдәшеңнең иң-иң имәндәен
югалтудан тагы ни ачы?
Пирамида төзгән пионерлар —
жиргә иңгән инде ничәсе.

Гамәлләрен комнан әмәлләүче
жаһил чорның, имеш, син колы.
Таралышкан салның тәрәкләрен
йотып торды еллар чоңгылы.

Галстуклы «гөнаһ капчыклары»н
каргадымы бәрәр фиргавен?!
«Яшәсен!»не дәррәү яшьнәткәндә,
кызлар өнсез калды беркавым.

«Вакбаш»ларга, баксаң, бәкыйлыклар
теләгәнбез, узып алланы.
«Яшәсен!»не әйткән яшьтәшләрем,
ничаклыгыз яши алмады.

Нурланышып торган нигргәләрнең
суырмады язмыш күпмесен?!
Күптарылган айлар күтәрелсә,
кулайрактыр, бәлки, Күк өчен...

Парә-парә килде пирамида,
әллә Жире юлдан язганмы?!
...Шәригатькә сыймас шәрикләрем,
кичердегез тәкъдир язганны.

Ерагаймый мәктәп йөрәгемнән,
мине аңа тагы кәз дәште.
...Үкенечле, ай-яй, үкенечле
хәрабәгә тамган күз яше.

«Яшәсен!»нәр белән яшеннәргә
үрелгәндә сылу, төз идек!
...Сүтеләсе мәктәп сәхнәсендә
тере пирамида төзедек...

## Төрмә эчендәге читлек

*Һадига*

Утырабыз икәү өтерменнең
түрәсендә ихлас гәп сатып.
Тоткын кызый кереп чыкты шулчак,
читлектәге кошны ашатып.

Төрмәбашым сөйли тормыштагы
үтә кызык «эшләр» турында.
Җаным тыныч түгел: хуҗа булып
гомер буе ничек тор монда?!

«Күлмәгеңнән чыгып, өйдәгечә
утыр»,— ди ул... шушы чит йортта.
Озак кына сайрап торды кошчык
төрмә эчендәге читлектә.

Аңлый алмый мәхлук, монда яшәп,
икеләтә мәхбүс булуын.
Йөрәк дертләп куйды — әллә инде
ошамады аңа бу уем.

Өтермәндә озак утырмабыз,
без бит кунак кына ич монда.
Хәтта ирек үзе яши әле
ничә катлы читлек эчендә.

Алгысынган рухың алданмасын —
чып-чын хөррияте еракта.
Читенсенеп, кысан читлегеннән
чыга алмый гаярь йөрәк тә...

Сәйрандагы коштай сайраганда,
кенәригә карап, ым кагам:
«Әллә монда чынлап җайлы микән
сакланырга вәхши дөньядан?!»

Иректәге кошны өркетәләр,
ничек кенә аң бул, аң булма.
Нигә әле капыл искә төште
юлда үтерелгән Акмулла?

Чәчәнебез казна читлегеннән
ашыкканмы әллә чыгарга?!
...Утырабыз икәү өтермәндә,
уйларыбыз сыймый чик-ярга.

Ишетелеп тора өшеттергеч
тимер ишекләрнең чың-шавы.

Утырасың хөкем ителмичә —
менә нинди язмыш сынавы.

Күпме черки, кордаш, каның эчте,
үтермәдең — имеш, жәлләтә.
Синдәй затлар кирәк: саксыз булмый
хәтта тәмуг белән җәннәт тә...

Зинахурлар тулы зинданында
өч-дүрт сәгать мин дә утырдым.
Яшергәләп килгән языгыма
җәза булсын — мин дә мут идем.

...Тәрәзәгә терәп тарттырылган
«тимер кояш» аша төн бага.
Чыгыйк әле — Иблис авы белән
челтәрләнеп беткән дөньяга.

Өйдә тагын тимер ишек көтә,
инде моннан, ярый, чыктык та.
Шундый серле карап калды кошчык
төрмә эчендәге читлектә...

## «Гаип»тән хәбәр бирүче

Кеше кайчак, шамакайдай, китә тәмам онтылып:
бүре төсле улап тора, өреп куя эт булып.

Әллә шулай аваз салгач, җанга тансык көч керә?!
Айгыр сыман кешни адәм, ишәк кебек кычкыра.

Карурманда кәккүкләнә, тургайлана басуда...
Аңлыйм, йөрәк авазыннан ерак тора барсы да.

...Инсан булып аваз салса тургай, кәккүк... эт, бүре?!
Хәер, әнә, тутый кошлар кешеләшә отыры:
«Дур-рак!..»

## Түшәм

Тартылганда галәм түрләренә,
башым сиңа ничә бәрелде.
Айга ашкан үги кызга гына
серләр ачар чамам бар иде.

Мине чикли белгән алтын түшәм,
(фәрештәмә, бәлки, идән син?!)
Ике яктан туфрак кысып торгач,
сикереп булмый, нихәл итәсең.

Тарафыңа бер дә төкермәдем —
күңелемдә тотмыйм кер-кинә.
...Сырларыңда серле чиксезлектән
төпсез упкыннары күренә!..

Сабый чакта шундый биек идең,
хәзер инде бераз үзгә без.
(Җирнең асты өскә килгән мәлдә (!)
бишек бөҗраларын эзләрбез...)

Синме әллә күкнең аскы каты —
кичә алган вакыт туфанын?
Туган йорттан читтә нәрсә әйтим:
җиңел булсын авыр туфрагың...

## Диңгездә кызынган авылдашым сөйли

...Абау, әби патшамыни,
утырамын ут йотып.
Башындагы эшләпәсе —
булыр каз да утыртып.

Ука-чуклы күкрәкчәгә
самавырлык су сыяр.
Кулга төшкән ганимәттәй
булса икән шушы яр!..

Акулалар эләгерлек,
сөзсәң, эчке күлмәге.
Шайтанымны шелтәләдем:
«Шунда туктый күр, яме!»

«Сүгенүем сагындыңмы
әллә ничә кат итеп?!»
Әфсенләнгән нәфесемне
тора һаман котыртып.

...Күзләремне кызыктыра
тыелулы сый төсле.
Әгъвалаучы оегына
бер пот суган сыешлы...

## Санау догасы

Малай чакта, йоклап китәр өчен,
саный идем йөзгә, меңгәчә...
Җидегәнгә кадәр җиткәнмендер
Фәрештәдән иңгән моң аша.

Йокы белмәс әби, дисбе тартып,
саный иде туксан тугызга...
Йоклаганда күкләр якынайды,
әфсен укыганны төн безгә?!

Изге җаның, әбекәй, күчте инде
чикләнмәгән саннар ягына.
...Йокы качты. Кулым тисә куркам —
никтер һаман дисбең ят миңа...

## Мәңгелек бусагасы

Шагыйрьлекләр белән шөгыльләнмик
Тукай яшен узып барганда.
Тәңребезнең даһи тамгалысы
була алмый әле бар җан да.

Пәйгамбәрнең изге бусагасы
пычранмасын безнең аркада.
Тормышыңда, баксаң, тормыйсыңдыр
Тукай күзендәге акка да...

## Тартар

Әүлияча әйтүләрдә
ишарәле өн ятар.
Көлешәләр колагыма:
«Бер тартарга дөнья тар...»

Искәртүнең астыртыны —
булам кайчак гарык та.
Кинаяләр кыйнаштыра
шәрык белән гарептә.

Кыйтгаларда — кайтавазы,
җанны талкып моң ага...
Канатыңны канатсалар,
сыярсыңмы дөньяга?!

Болгардагы болыныннан
киткән затмы ден сатар?!
Илаһ ямь бар әйтүләрдә:
«Бер тар-тар-га дөнья тар...»





Рафаэль Сибат

# ИКЕ ГАШЫЙК ҺӘМ ҖЫР ТЫҢЛАУЧЫ АТ

ПОВЕСТЬ

1

Эссе көн. Инеш буендагы әрекмән яфраклары шәлперәеп төшкәннәр. Елганың ташлы сай җирләрендә челтерәп аккан судан башка бер тавыш та ишетелми. Кошлар тынган, тал-тупыллар акрын искән ялгыз җилкәйгә башларын куйганнар. Вакыт-вакыт йокыларыннан саташып уянган яфраклар гына сискәнеп, лепердәшеп алалар. Кояш һәммә җан иясен эссе табага бастырган. Хәтта Ярмәкәй тавы астындагы амбар-амбар зур ташлар да кызган. Юлдагы комлы балчык аяк табаннарын пешерә.

Күлдәге үрдәк-казлар судан чыкмый, көтүдәге сарык-кәҗә, бозаусыерлар агач арасындагы күләгәгә елышканнар. Берничәсе, Нократ суына кереп сыртка кадәр рәхәт мәлҗереклеккә чумган. Көтүченең алабай эте әлсерәп бияләй кадәр телен тышка чыгарып салган. Зур тирәк төбендә дымлы күләгәдә ятса да, үзе эһе-һеhе килеп еш-еш тын ала.

Кайтыр юлга чыгып, күпмедер җир узуга, Канәфинең аты да тирләп чыкты. Үр менүе авыр булды аңа. Югыйсә йөге дә авыр түгел — биш ярка каен утыны. Нократтан агып килгән каен-нарат ларны алар моннан бер генә көн элек иптәше белән яр буена тартып, **ике куллы пычкы белән өч аршынга** кисеп куйганнар иде.

— Бүген миңа, иртәгә сиңа алып кайтыйк,— дигән иде ул аңа, ә Талип иңгә-өнгә тиз генә килә торган егет-малай түгел шул, шуның өстенә комсызлыгы да ташып тора.

— Башта миңа, аннан сиңа!

Әнә шулай өзмәде дә куймады. Нишләрсең! Ризалашты Канәфи. Кичә аңа алып кайттылар, ә бүген Талип, ниндидер эш табып, булышырга да бармады:

— Карун тәре! Алдакчы... Үзенә генә булсын!

Йә, нигә җебеп төшәргә ди? Берүзе булса да, төяде ич әнә утынны. Актай да маладчина — үрне эһ тә итмәде, биеп кенә менде. «Әпипә» көенә.

Канәфетдин канәгать рәвештә тезгә кадәр сызганган чалбарыннан каткан саз валчыгын бәреп төшерде, аяк бармакларын уйнаткалап, арасына кысылган ком-балчыктан котылырга теләде.

Юл тау-түбән киткәч, ул утын өстенә менеп кунаклады. Сырттан әнә авыл һәм аның тирәсе уч төбендәге кебек күренә иде. Әнә Нократ җәелеп ята һәм ашыкмый гына үз көенә ага бирә. Юк, моннан караганда ул акмый да сыман. Тик ята җир өстендә. Зәңгәргә өртелгән урманнар, сары-яшелгә чумган басу-кырлар, бер болытсыз өрфия күк, болында анда-монда зөбәрҗәттәй яткан күлләр Канәфи күңеленә җанлы манзара булып иңделәр. Әйе, ул аларны ике зәңгәр күзе белән күрүдән тыш, җаны белән дә кабул итеп, үзенә — күңел түренә сеңдереп рәсемли иде.

Чиксез хисләнүдән егетнең күзләренә яшь бәрде. Ул утын яркаларын яңа туган сарык бәкәйләре урынына сөйде:

— Сәрби әбигә юк кына бәягә сатам да сезне, акчасына Катифәгә яулык белән хушбуй алам!

Актай егеттән җыр көтте. Менә шулай уңайлы юлга чыгып, бер мизгеллек хис-җанланудан соң, Канәфи өздереп җырлап җибәрә иде. Аның тавышы матур, яңгыравыклы, йөрәк түреннән чыккан бәрхет булу өстенә, күпмедер моңлы да. Һәй, татар булсын да моңсыз булсынмы! Һәр чын татар ярты Илһам Шакир ич!!

— Әйдә, Әпипә, җәтрәк атла, — дип дәште ул яратулы тавыш белән малкайга. Ул Актайга бервакыт та чыбык яисә чыбыркы белән сукмады, ә алар һәрвакытта аның арбасында яттылар югыйсә. Канәфетдиндә, ат белүенчә, ике төрле тавыш: ягымлы һәм усал эндәшү генә бар иде. Тагы җыр. Монысы инде аның күңеленең күктә чагындагы авазы-аһәңе...

Ә бүген Канәфи артык хисле иде. Шуңамы җыр сузарга да онытты.

Иске мәктәп каршындагы Ярмәкәй тавының текә сыртыннан салынган юлдан төшә башлагач, ат котырып чабарга уйлады. Тау-түбән җилдереп алу аның чабышкы булып та арбага җигелергә кушкан язмышы белән тартышып алуы өстенә, кайчандыр Сабантуйда ярышларда беренче урынны алуын искә төшерүе иде булса кирәк.

Актайның тау-түбән кызулый башлавын сизеп алган Канәфи арт тәгәрмәчләргә күсәк кыстырмавын исенә төшерде, әмма хәзер соң иде инде, ат тагы да кызулый төште.

— Актай, трр, ты-рр, чукынчык!

Дилбегәне шытырдатып тартуына карамастан, атның күзләре алгы юлны искез-чиксез дала итеп күрде. Әнә көнбатышта кояш баеп бара. Аның чабасы-очасы һәм кояшны туктатасы килде: «Тукта, Кояш! Китмә, Кояш!!»

Актай бәргәләнде:

— Минем киң күкрәкле, ярсу йөрәкле чабышкы чагым шушы көнгә тукталып каламыни? Бу көн — аның кабере булачакмы? Иртәгә бу көн юк бит. Тукта, Кояш! Китмә, Кояш!

Кинәт атның колагына ифрат матур һәм гаҗәп моңлы, әчке сагышлы бер яңа җыр ишетелде:

Катифәмнең бәгыремнең,
Күлмәге ефәк түгел.
Күңеле ефәк булгачтын,
Башкасы кирәк түгел!

Ат чаба башлаган җиреннән ирексездән тукталып калды һәм, бик бирелеп, җырга күмелде.

Канәфи дә шаккатып калды: могҗиза иде бу — Актай бер котырып чаба башласа, һич туктатам димә. Яңа җыр әсәрендердеме?

Ат аңа, әлбәттә, теле белән әйтә алмады: бу минутта чабышкы үтерелеп, җыр тыңлаучы ат туган иде. Никадәр киң күңелле булып, никадәр аны — бахбаен, «Әпипә»сен яратса да, Канәфинең күңеле Катифәгә бәйләнгән иде. Ул туктаусыз аны уйлады, шуңа атны аңламады.

Кибеттән бүләкләрен — зәңгәр яулык һәм хушбуйны алып очрашуга килүен күзаллады.
Эссе көн. Пешерә дөнья... Эс-се!

## 2

Канәфи Катифә белән кыш көне, үгез җигеп урманга утынга баргач, якынаеп китте. Аңарчы алар, бер авылда торсалар да, күрешкәндә исәнләшүдән башка ым-хәрәкәт кылганнары юк иде. Ә быел кыш...

Ул әле ат җикми иде, аңа үгез бирделәр. Шул киребеткән үгезне ипкә китереп йөргәндә, персидәтел Баттал әйтте. Әйтте генә түгел, әмер бирде:

— Хәернисага бер йөк утынга барасың! Ягарга утыны беткән, ди.

— Кая барырга? Кайдан алып кайтырга? — дип сорады яңа унҗиде тутырып унсигезгә чыккан егет.

— Айдан! — диде Усал Баттал тамак төбендә карлыгып чыккан тавыш белән. — Айга мен дә төяп кайт. Бәлки, Зөһрә кызны да алып кайтырсың, маңка. Шунсыз син өтеккә авылда кызлар карамас. Армиядән дә калдың түгелме?

Усал Баттал махмырдан әче сөйләшә иде.

— Армиягә көз китәм мин. Ә утынны айдан алып төшәсе икән, үзең утырып йөргән Каратайны бир.

— Хы! — Батталның йөзенә комач капладылармыни: — Каратай яныннан читкә тай! Сине беренче салуда ташлап калдыра бит ул, хөрәсән, — диде ул теш арасыннан черт итеп төкереп.

— Алай димә, Баттал абзый. Ат дигәндә аяк идәндә. Җен-албастыны ат дисәгез дә, атланам...

Егет-малайның атка үлүен белепме яисә ике ел элек Сабантуйда ат чабышында Актай белән беренче урынны алуын искә төшерепме, Усал Баттал, гадәтенчә, кинәт кенә йомшарып китте:

— Җә, җарар! Әнә, бик батыр булсаң, Актайны тәртә арасына өйрәтергә кирәк. Гел чабышкы булып кына яши алмас, вакыт аңа тәртә арасына...

— Өйрәтсәм, үземәме Баттал абзый?!

— Ничек үземәме? Калхуз аты ла ул...

— Үзем җигәрменме дим...

— Ә-ә, анысын әйтәсеңме?

Усал Баттал беркавым уйга калды. Шулчак алар сөйләшеп торган камытлар өенә завхоз Мансур килеп керде. Ул соңгы сүзләрне ишетеп өлгергән иде инде:

— Үзең өйрәткәч, димәк ки, үзеңә инде, энем! — диде ул, нәфис кулларын аның җилкәсенә салып. Мансур — аның сугышта үлгән әтисенең энесе.

Авылда Усал Баттал завхоз Мансурдан гына шүрли иде. Йөздә унбиш килолы бу Сабантуй батыры көчле-куәтле, олпат булуы өстенә, утны-суны кичкән, сугыш үткән баһадир һәм туры сүзле, гадел кеше иде. Әле күптән түгел генә Мансурның үпкә чиреннән хатыны дөнья куйды. Калды өч бала белән.

— Кемгә булсын Актай, үзең җигәрсең, — диде Баттал да, башка сүз таба алмыйча.

Шул шатлыктан көлеп җибәргән Канәфи үгезен җигәргә ашыкты. Озакламый ул да ат җигәчәк! Эх! Ат — ат инде ул!! Ат белән ач булмассың. Әле ул гынамы? Авыл урамнарын Актай белән җилләп узу — моннан да зур бәхет, горурлык, сөенеч булырмы? Күп кенә иптәшләренең күзе кызачак, ә кызлары сокланып карап калачак. Бәлки, кыз-кыркынның берәрсен печән салынган чанага утыртып ферма тирәсенә, йә күрше

авылга да утыртып алып барыр. Хәер, алда күз күрер... Аллагысын Алла белә ди...

Шул уйлар белән Канәфи үзенең «Мышлы Мишка»сы белән Хәерниса апалары турына җитүгә, кыегайган җил капка кинәт кенә ачылып, аннан атылып диярлек Катифә килеп чыкты. Үзе шәһәрдәге базар марҗалары кебек кат-кат төренгән. Канәфи аны нигәдер бер дә ошатмады. «Кыз-кыркын белән генә йөрисе калган ди урманга. Моңа нәрсә: балта тота беләме дә, пычкы тота беләме? Хәерниса апа үзе бара, дигән иде бит Баттал абзый...»

— Син кая? — диде ул Катифәгә ачуы килеп. Аннан соң аны үртәүкимсетү өченме «черт!» итеп җиргә төкергән булды. Персидәтел Батталча.

— Урманга, — диде кыз кат-кат чорналган, берничә җиреннән сүтелгән мамык шәле аша гына карап.

— Катып үләргәме?

— Утын тәяшергә!

Көн суык иде. Чатнама салкын. Очып барган хәлсез чыпчыкларның һавада катып үлгәннәре бар. Яталар аннан соң ат тизәге сыман аунап. Ярый әле җиле юк, коры суык. Тик шулай да мондый көнне яхшы кешеләрнең эте дә оясында утыра...

Алар күпмедер бер-берсенә карашып тордылар.

— Син катып үләргә җыенмыйсың ич әле? — диде Катифә, ниһаять, гаять үртәлгәнен сиздерәсе килмичә.

— Мин мин бит ул! Мин — ир кеше!!

— Әнкәем! Ир кеше табылган. Көлеп үләрсең. Ир дигәнең чир булып чыкмасын.

Шунда Катифә гаҗәп матур тавыш белән көлеп җибәрде. Канәфи колакларын торгызды: чыннан да, кыз ифрат матур итеп көлә белә икән ич! Аның әле дөньяда шулкадәр яшәп тә болай итеп көлүчене ишеткәне юк иде. Завхоз Мансур абый да кәефле чакта тәмләп көлә белә анысы. Ул тәмләп шул, ә Катифә матурлап. Аның көлүе — хәйран! Әйтерсең лә, меңнәрчә чәчәкле болын өстендә йөз тавышлы көмеш кыңгырау чылтый. Көлгәндә әнә күзләре үк яшьләнеп китә икән. Егетнең колагы бу көлүгә шундук гашыйк булды.

— Җә, җарар! — диде ул Батталча (персидәтел кискен бер карарга килгәндә шул сүзләрне әйтә иде).

Үгез дә тынычсызлана башлаган иде.

— Утыр! Киттек... — диде Канәфи.

Мышлы Мишка юлдан ялкау гына атлый. Ул гел шулай: урманга йоклап бара, авылга чабып кайта. Ничауа! Барыр, кайтыр. Үлмәс, түзәр... Дөньяга тугач, барысына да түзәргә кирәк. Сине беркем дә чакырып китермәгән ич тормышка. Килгәч, яшә, түз! Әнисе гел шулай ди Канәфинең.

Баралар. Нигәдер икесе дә сүзсез. Егет кин җилкәсе белән Катифәне суыктан, Нократ ягыннан искән аз гына сизелерлек шәпшә җилдән саклый. Тоямы кыз моны? Нигә сөйләшми ул? Әллә инде үпкәләдеме?..

— Әниең барам дигәч ич урманга? — диде Канәфи, сүзсез баруга эче пошып.

— Бара иде, баш әйнәге бүген аңарда...

«Һәй, миңгерәү! Такыр баш!! — дип сүкте егет үзен, янында дөньяларыңны оныттырырлык итеп көлә белгән кыз утырганда, анасы хакында сорашалар димени? Ахмак! Аңгыра!! Дивана!!

Чистый надан...»

Канәфи суыктан бөрешә төште. Бәлки, мәнсезлегеннән бөрешкәндер, кем белә. Юка, иске киемнәр аша үтеп, куырып-куырып ала суык. «Урманга гына керик, урманга гына... Куам мин сине, суык бабай...» — дип уйлый егет эченнән генә, ә үзенең кызга дәшәсе килә, тик нигәдер сөйләшеп китәр өчен бер генә юньле сүз дә таба алмый. Телсез Хәсән кебек утыра шунда.

— Их, кайчан жәйгә чыгарбыз! — диде Канәфи сүз булсынга, шуның өстенә үгез туктап печ итә башлаган иде. Аның Катифәнс (ә ул артка карап утыра) бу эштә шаһит итәсе килмәде. Хәер, белмәгәнме, күрмәгәнме ул моны... Читенсенеп торасы түгел!

— Нигә алай дисең? — дип сорый кыз.

— Суык ич! Тишек фуфайка, өтек бүрек, ямаулы чалбар белән кыш чыгулары рәхәтме әллә?

— Ә җәй? Тузан, яңгыр яуса — пычрак, әле тагы эссе...

— Әйе шул, эссе. Тик шулай да җәй рәхәт!

Шуннан соң алар гел сөйләшкәләп бардылар.

Мышлы Мишка үз җаена гына атлый бирде. Вакыт-вакыт аның тәне дә калтырап-калтырап ала иде. Ул да туңа. Суык шул, суык.

Урманга житкәч, өйгә кергәндәй булды. Канәфи дә, Катифә дә, үгез дә кинәт кенә җылынып киттеләр. Ә инде өч төп коры караманы пычкы белән аударып ташлагач, Катифә мамык шәлен чишеп җибәрде. Моңарчы урманның матурлыгына таң калып, күзәтеп, хәл алып торган Канәфи Катифәнең сүзләренә сискәнеп борылды:

— Канәфи, әнә куян!

— Кайда, кая?

— Әнә теге биек чыршы арасына кереп югалды.

— Һәй! Алдыйсың ич.

— Валлаһи! — Көмеш көлү урманны күмде.

Кинәт кызга күз төшергән егет шаккатты: аның алдында урман кызы, урман гүзәле тора ич. Әллә шайтан, пәри кызымы бу? Карале, ничек матур икән ич Катифә! Эре бөдрә чәчләр, жылы матур күзләр, аз гына калынрак кечкенә иреннәр, килешле ияк, алма битләр... Йә хода!

Егетнең карашыннан өтелеп-читенсенеп киткән кыз шул ара шәлен чолгап бәйләде. Матурлыкны яшереп куйды.

Утынны сүзсез генә диярлек төяделәр. Кайтыр юлда да артык сөйләшмәделәр. Һәм икесе дә бер эш белән мәшгуль иде. Бүген утынга дип урманга баргач, Канәфи дөньяда Катифә дигән кызны ачты, ә Катифә дигән кыз Канәфи дигән егетне очратты. Әнә шулай тормыш океанында һәркем, Колумб кебек, кемнедер үзе өчен ачарга тиеш. Нәкъ менә үзе өчен генә...

Кайтыр юлда Мышлы Мишка ашыкты да ашыкты. Аны хәзер алга баруыннан берни дә туктата алмый иде. Алда җылы абзар һәм фураж көтә үгезне. Идел ярыннан төшкәндә Мышлы Мишка кушаяклап ук чаба башлады.

Ни теләсә дә, Канәфи Мишканы вакытында туктата алмады. Үгездән дә кире кем бар дөньяда! Салуда чананы каплауга, черек бау белән бәйләнгән карама утыннары, начар тормыш кебек, таралып-чәчелеп тә китте. Йөктән котылган үгез тизлекне тагы да арттыра төште. Канәфи аның артыннан. Бар, тиз генә куып җитәрсең! Дүрт аяклы сәмәлүтмени!!

Ул аны теге як ярда башланган куе таллыкта гына тотып алды. Ярый әле үгез төшеп калган бер уч печәнне чемченеп ята иде. Авылга кадәр чапса, камытлар өе янына буш чана белә кайтып керсә? Атна буе көләчәкләр. Теңкәнә тиячәкләр. Усал Баттал авызыннан: «Маңка! Хөрәсән!! Малакасус!!!» — дигән сүзләр пулеметтан сибелгән күк атылып торачак.

Кире килгәндә, Катифә кычкырып елап утыра иде. Канәфинең нигәдер аңа җен ачулары чыкты:

— Нигә күл бакасы кебек сайрап утырасың?

— Сайрамассың! Усал Батталның балтасын югалтсаң, син дә сайрарсың...

— Эзләп кара, тик утырганга шайтан тоттырган...

— Эзләдем, һич таба алмыйм, — диде Катифә тиз генә тынычланып.

— Йөк астындадыр...

— Карадым, күренми.

— Хәзер... Тәягәч чыгар!

Йөкне кабат төягәч тә, Усал Баттал балтасы табылмады. Эзләнә торгач, аны яр өстендә күрделәр. Кояшта көзге кебек ялтырап ята балта йөзе.

— Үз балтагыз юкмыни? — диде Канәфи.

— Каян булсын. Былтыр урманга баргач, кара Мәлик югалтып кайтты.

— Ә Баттал ничек бирде? Ул бит кешедән алмый, үзенекен бирми.

— Бер үптергәнгә...

— Нәрсә-әә? — Канәфи тотлыгып ук калды.

— Шулай инде. Баттал абзый урманга барырга балтаны биреп тор әле, дим. Ә бу шаяра: «Бер үптерсәң, бирәм», — ди. Шаккаткансың иске чикмәнгә, «мә үп», — дидем. Кыз аның үртәлгәненә сөенә иде.

— Шун-нан??? — егетнең тамагы карлыкты.

— Нәрсә шуннан? «Иске чикмән түгел шул, чиккән яулык син!» — дип үбеп тә алды.

Канәфи көнләшүеннән үлә язды:

— Кай төшеңнән?

— Ничек кай төшеңнән? — дип сорады кыз.

— Битеңнең кай төшеннән үпте.

— Битнең битеннән үбәләр инде, — дип көлде кыз. Шәлен каера төшеп ачты да бит уртасына төртеп күрсәтте.

«Һәй, 15 яшьлек маңка!» — дип уйлады Канәфи эчтән генә. Битнең әллә кайсы төшләреннән үбәргә мөмкин: иреннән, күзләрдән, колактан, ияктән...

Канәфетдин абзаның монда тәҗрибәсе бар.

Ат «каплаталар» иде.

Имән исемле айгыр шәһәрдәй гәүдәсе белән авыл чаклы гына биягә атланган. Бия чыдый, чөнки табигать шуны сорый, инстинкт шуңа тарта.

Ат чаптыручылардан телсез Хәсән «гы-гы-гы!» дип көлә. Ат каплату, бия колынлату, мал сую — аның өчен иң зур бәйрәмнәрдән. «Гы-гы-гы»да шатлык һәм сөенеч, гүя, айгыр түгел, биягә ул үзе атланган. Завхоз Мансур бу эшкә бик җитди карый: атлар — тарту көче, колхозны алар алып бара, димәк ки, алар ишәергә тиеш. Завхоз Мансурны «Димәкки Мансур» дип тә йөртәләр. Чөнки ул «димәк ки»не «димәкки» дип кыстырып сөйләшергә ярата. Ат каплатуны Кара Мәлик алып бара, ул, гадәтенчә, эндәшми, аска карап үз эшен генә эшли. Аның негрныкыдай кара йөзе астына ни яшеренгән — бу турыда эт тә белми. Бик астыртын, эчле адәм Кара Мәлик. Персидәтел Батталның күзләре янган. Ул теш арасыннан черт итеп төкерә дә ямьсез итеп сүгенә һәм айгырга көч-куәт, дәрт-дәрман биреп тора.

— Син бит безнең баш пләмәнни! Җәле тырыш! Яхшылап, Имән, яхшылап, — ди. Айгырны котырткан саен, Усал Баттал үзе дә исәрләнә бара. Бу турыда майлы йөзе, фәхеш күзләре һәм чалбарының тырпаеп торган төше нык раслый.

Ат караучы Шамилә Баттал һәм башка ирләрнең хихылдашып торуына түзәлмады:

— Ике аяклы айгырлар! — диде дә атлар абзарына кереп китте. Анда Канәфи Актайны кыргычлап ята иде. Шамилә атларга печән өләшә башлауга күп тә үтмәде, ишектә Баттал күренде. Ул йөгереп диярлек килде дә Шамиләне печәне-ние белән күтәреп алып почмакка китереп салды.

— Нишлисең, Баттал абзый, кеше күрер, — диде хатын өзгәләнеп һәм еш-еш сулап. — Өеңдә хатының була торып...

— Беркем дә юк монда... Ә хатынны сөймим мин. Кочаклау-сөю генә түгел, күрәсем дә килми. Хатыннан бәхетем булмады...

— Шулай да көпә-көндез?..

Бераздан соң коры печән кышкы кар кебек шыгыр-шыгыр килде. Сарай башындагы Каратай пошкырды, ә Канәфинең кулындагы кыргычы төшеп үк китте. Икенче бер караганда, Баттал Шамиләнең иреннәреннән, бит алмаларыннан, күзләреннән, колакларыннан, иягеннән, муеныннан, тагы әллә кайсы төшләреннән шашып үбеп ята иде, ә Шамилә тыныч кына ыңгыраша. Гүя, Баттал аны ашарга тели, ә Шамилә ашатыйммы-юкмы дип саташулы аптырашта калган...

## 4

— Битнең әллә кай төшләрен үбәргә була! — диде Канәфи бик белдекле рәвештә.

— Ай, сөйләп торасың тагын. Үпкән кеше диярсең,— диде Катифә аны тагы да үрти төшеп.

Үгез артыннан атлап барган җиреннән егет туктап ук калды:

— Ә син беләсеңме... беләсеңме Усал Батталның ярты авыл хатыннарын ниткәнен?

— Ниткәнен? — дип сорады кыз кисәк кенә һәм берни аңламыйча. Сорауга ук үзе кинәт кызарып куйды. Ул да атлавыннан туктап калган иде.

— Битен үпкәнен! — диде Канәфи ачуланып һәм үзе дә нигәдер уңайсызланып. Ул, Мышлы Мишкасы кебек, мыш-мыш һәм еш-еш сулый иде.

— Үпмәсә тагы, укасы коелмый ич. Безнең күрше Шамилә апа әйтмешли: «Теге дөньяга киткәч, барысы да юкка чыга». Канәфи аның соңгы сүзләреннән сискәнеп китте:

— Ай-һай, укытучың шәп икән!

— Кем-кем?

— Шамилә укытучың.

— Укытучымыни ул — ат карауччы. Ә укытучы — бездән биш өй генә ары торучы Мәрьям апа!

Аннан кыз күпмедер торгач, сүзне икенчегә борырга теләпме, әйтеп куйды:

— Их, укып булмады шул. Мин дә укытучы булырга хыялланган идем бит.

— Укырга иде,— диде егет үз алдына мыгырданып. Ул әле һаман сүз башын онытмый иде.

— Бик укыр идем дә, әни авырый, энемне укытасы бар...

Канәфи аңа текәлеп карап торды:

— Ничә яшь соң сиңа, Катифә?

— Ай аллам! Көлеп үләрсең, үз авылындагы кызларның яшен дә белми...

— Мин җиденчене бетергәндә, син өченчедәме, дүртенчедәме идең. Йодрык кадәр генә...

— Алдама! — диде Катифә көлемсерәп.— Бишенчедә идем, буем бәләкәй иде шул, ә алтынчы-җиденчеләрдә укыганда минем кадәр гәүдәле-буйлы кыз яисә малай бөтен класста юк иде. Мин бит кинәт кенә үсеп киттем. Шуңа класска да сыя алмадым, андагы малайлар һәм кызлар миңа бала-чага кебек тоела башлады. Укуымны әнә шуңа да ташладым. Ә тууын сугыш чыккан елны тудым. Әти сугышка мине күрми дә киткән.

— Минеке күреп киткән иде дә, кайтып кына күрә алмады...;

— Безнеке дә, ранин булып кайткач, озак тормады. Шул ук сугыш үтерде аны... Ятимнәр без, Канәфи...— диде кыз моң һәм сагыш тулган күзләрен аңа төбәп.

— Ятим булсак та, ким булмыйк, Катифә!

— Менә анысы дөрес.

Алар тагы үгез артыннан тигез генә атлап киттеләр. Сөйләшәсе сүзләре беткән иде булса кирәк. Бары авыл очына керер алдыннан гына егет кызга эндәште:

— Катифә!

— Әү, Канәфи!

— Битеңне Усал Батталга башка үптермә, яме.

— Үптерәмме соң! Тотсын!!

Каяндыр хис бәрде. Шуңамы күзләре дымлана төшкән Канәфетдин бияләен салып Катифәнең кулларын тотты. Чөнки нәкъ шул мизгелдә кыз ни сәбәпледер бер бияләен салып кулын ялангачландырган иде.

Кулга кул тотынышып авылга кергәнче шулай сүзсез генә атладылар. Иң сәере: икесенең дә куллары туңмады, киресенчә кызыша, җылына төште.

## 5

Утынны ишек алдына аударуга, Хәерниса аларны тамак ялгарга чакырды. Өстәлдә бер табак мич бәрәңгесе, берәр олы телеш арыш ипие. Ватык чынаякка тозлы су салынган. Кечкенә чынаякта аз гына каз мае да бар. Монысы — авылда иң күп казлар тотучы Хәернисаның хөрмәтле кунакларга сые.

Әй, урдылар Канәфи белән Катифә шул бәрәңгене! Башта берберсеннән оялыбрак торсалар да, тамак үзенекен итте. Канәфигә бу бәрәңгеләр итле бәлештән дә тәмлерәк тоелды. Аннан соң берәр кружка шикәрсез генә чәй эчтеләр.

— Канәфетдин улым, үпкәләштән булмасын, бары-югы шул,— диде Хәерниса караватыннан күтәрелеп.— Үзем чирлим, терелим генә, алла бирсә, каз шулпасына чакырам әле мин сине. Бәрәңгене дә көч-хәл белән пешердем. Пичне ярый әле Кадыйр якты...— диде ул алгы якта дәрес әзерләп утыручы улына ишарәләп. Малай аларга карап борын тартып куйды.

— Алланың рәхмәте яусын! Туйганчы ашадым, Хәерниса апа. Ипи белән бәрәңгегә тук булгач, ни кирәк тагы?! Яшибез, иншалла!— диде Канәфи картларча сүз корыштырып. Дөресе: камытлар өендәге Ильяс карт сүзләре иде бу.

Катифә ярлы өстәл өстеннән үзе дә оялыбрак торса да, Канәфинең шул сүзләреннән соң җаны эреп, күңеле күтәрелеп китте.

— Кара бу Канәфине, бик акыллы егет күренә. Олылар кебек сөйләшә белә. Утынны да җиңел кисте — пычкыны үзе этте, үзе тартты, төягәндә дә бер ярка да миңа күтәртмәде. Әни, Канәфетдиннең көчен күрсәң! Юан-юан карамаларны берүзе күтәрә дә сала!! — диде ул.

— Бирсен алла! — диде әнисе.— Авыл җирендәге кешенең гомере буе эш. Көч-куәт бик кирәк. Әтисе Шиһап та бик көчле кеше иде. Сугыш харап итте үзен...

Канәфи бу мактаулардан тагы да биегәеп китеп, башы түшәмгә тиде. Күзләрен кая текәргә белми торгач, өйне айкап чыкты. Катифәләрнең йорты ялангач иде: ярты урынны алгач агач сәке, почмакта Хәерниса яткан иске карават, өстәл һәм әтиләре ясап калдырган тупас кына ике урындык.

Тик шулай да күзгә бәрелеп торган ярлылык белән бу йорттан чисталык, тәртип, күзгә күренә торган пөхтәлек бөркелә иде. Ап-ак тәрәзә кашагалары, чигелгән мендәрләр, стенадагы кардай сөлгеләр, түр яктагы палас — барысы да өйгә ямь һәм нур кертәләр иде. Почмактагы шүрлектә китап-журналлар, гәҗитләр дә күренә.

Ни генә димә, Канәфинең бу өйдән чыгасы килми иде. Катифәнең фермага эшкә барасы искә төшкәч, киттеләр тагы үгезгә утырып.

## 6

Шул көнне кич житүгә, Канәфи жанын кая куярга белми, читлектәге бүре кебек бәргәләнә башлады. Моңарчы хатын-кызларга артык исе китмәгән егет күңелендә дәү учак кабынды. Аның тәне кызышты, кулыннан эш төште. Йөрәге, тиктомалдан дөп-дөп килеп, еш-еш тибә башлады. Ишегалдына утынга дип чыккан жиреннән бер култык печән күтәреп керде.

— Син нишлисең, улым, абзарга дип өйгә керәсең түгелме? — диде әнисе аптырый төшеп.

Канәфи печәнен алып кире чыгып китте.

Кич житте. Кар-көрт күмгән өйләрнең тәрәзәләреннән сары якты бөркелде. Абзардагы сыер, сарык, кәжәләр тәмле генә печән кетердәтте. Көндез өреп тамаклары арган этләр жылырак урынга постылар.

Канәфи түзмәде, бар булган яхшы киемнәрен киеп, йөзен-битен тагы бер мәртәбә юып, Катифәләргә юнәлде. Өйләренә кереп килүгә, хәйран калды: көндез урмандагы ыбыр-чыбыр киенгән Катифә урынына йортта аны бөрчек-бөрчек ак эре борчаклар төшкән зәңгәр күлмәкле, нечкә билле, таза, матур аяклы кыз каршы алды. Аның аяк басулары, йомры балтырлары, матур төртелгән күкрәк алмалары, нечкә биле һәм билдән соң кинәт киңәеп киткән түбән ягы — болар барысы, барысы да Канәфине һуштан яздырды. Ярый әле ишек яңагына тотынды, аннан соң сәкегә утырды юкса, билләһи, егылып китәчәк иде.

— Ә-ә, Канәфетдин... — диде ак чалма ураган Хәерниса, караватыннан борылып.

— Хәерниса апа... минем сездә... бияләем калган бугай, — диде егет, ялганлавыннан тотлыгып һәм кызарып китеп.

Ана тиз аңлады:

— Кызым, карагыз. Утын арасында ятмый микән. Кыш көне бияләйсез кая...

Катифә киенде. Ул болай да иннек-кершән сөрткәләп клубка әзерләнә иде. Бүген әйбәт фильм булачак, диделәр. Аннан соң кичә — чуплэм, күмәк жыр, әйләнә. Кызның иннек-кершән сөртүе дә киномеханик Толя өчен. Чукынды бит: «Миңа кияүгә чык инде!» — дип. Киногa гел бушка гына кертә. Чыкты ди ул кыяр башка! Күзе — боз, керфеге — дуңгызныкы. Чыкты ди, әнисе бәреп үтерер. «Урыска чыккан — дуңгызга кызыккан! — ди иде әбисе. Ә шулай да киногa бушка кертүе әйбәт. Акча кайдан төткәрмәк кирәк ди.

Ишек алдына чыгуга ук, эзләнәсе бияләй онытылды. Хәер, аның Канәфи кулында киткәнен кыз үз күзләре белән күрде ич.

— Кино буламы клубта, Канәфи? — дип сорады Катифә.

— Юк!

— Ә кичә?

— Юк!!

— Бәрәч! Ничек юк та юк. Берни дә булмыймыни? Ә нигә безнең очка төштең? Мине клубка алмага дип торам, — диде кыз аңа төрттереп.

— Синең яныңа, Катифә!

— Нишлисең минем белән? — диде кыз, күзләрен зур ачып.

— Минем дә сине үбәсем килә... — диде егет, ифрат та дулкынланып.

— Ха-ха-ха!

Кызның көмеш тавышы ишек алдын күмде:

— Әгәр үптермәсәм?

— Батталга балта өчен үптергәнне, миңа утын алып кайткан өчен дә үптермәссеңмени?

— Ярар алайса! — диде кыз тагы көлеп. — Бер үпкән — читкә киткән, бер кочкан — жилгә очкан. Үп биттән и... өеңә титакла!

— Юк, мин үзем теләгән жирдән үбәм...

Канәфи карны шыгырдатып аңа якынлашты. Катифә дә, әле монарчы ул бер дә тоймаган ниндидер бер нәрсә буласын күңеле белән сизенеп һәм шуннан куркып, җылы зур күзләрен йомды.

Егет, каушап булса да, суырып аның иреннәрен үпте. Кыз башта көлде, әмма бу тыенкы көлү иде. Аннан соң бер урында тора алмыйча киез итеге белән туктаусыз җирне таптады. Кар шыгыр-шыгыр килде. Көлгәндә авыз ачылган Катифәнең энҗе тешләре егетнең иреннәренә төртелде. Икесе дә үбешергә өйрәнәләр генә иде әле.

— Тыныч кына тора аласыңмы? — дип, орышкандай итте егет аны. Нигәдер пышылдап кына әйтте.

— Ә син сузма! — диде Катифә нигәдер кычкырып көлеп.

— Хәзер... Хәзер... Бетерәм... Соңгы тапкыр...

Егет тыны кысылган хәлдә тагы аны бик озак кына суырып үпте. Шунда кинәт кызның да, тын юлына ут кабып, аяклары хәлсезләнде.

— Ка-нә-фи...— диде ул изрәп.

— Ка-ти-фә...— диде егет ләззәтләнеп.

Алар тагы үбештеләр. Тагы үбештеләр. Тагы үбештеләр. Икесенең дә чынлап, кыз һәм егет булып, беренче тапкыр үбешүләре иде. Әле бу яшь, тыйнак, тәҗрибәсез, әмма саф-чиста, эчкерсез һәм кирәкле ноктада тукталып кала торган үбешү иде.

Катифә белән Канәфи бу мизгелдә дөньяда икәү генә калып, лапас тактасының ярыгыннан аларны күктән Ай гына күзәтә иде. Ә егет белән кыз бер-берсеннән генә түгел, Айдан да оялалар иде әле.

## 7

Шуннан китте хәлләр! Сөю мәлләре...

Унбиш яшьлек Катифә белән унсигез яшьлек Канәфи бер-берсеннән башка бер минут яшәүне дә күз алдына китерми башладылар, чөнки бу вакыт алар өчен сагыну булып үтә башлады. Икесен дә тоташ сагыну чолгап алды. Рәхәт тә, михнәт тә иде бу сагыну.

Бу искиткеч шәп мәхәббәт булып, аларның икесенә дә табигать тарафыннан ярата белү таланты бирелгән иде. Әгәр дә йөз баллы мәхәббәт үлчәгеч булса, аларның сөюе нәкъ менә шул санны күрсәтер иде. Кешелектә иң көчле сөю иде бу.

Канәфи, Катифә һәм төнге ай.

Шушы өчесе һәр төнне очрашты соңыннан. Дөрес, вакыт-вакыт айны югалткан төннәре дә булды. Аны юрган-юрган болытлар каплый иде. Әмма ул кайдандыр һәрвакыт килеп чыга да төне буе саф мәхәббәтне саклый. Ярымай — урак килеш, тулы ай — түгәрәк килеш...

Алар сөйләшеп-көлешеп, үбешеп-сөешеп һич туя алмадылар. Катифә йөрәге Канәфигә, Канәфинеке Катифәгә күчте. Катифә Канәфигә, Канәфи Катифәгә әйләнеп, бер-берсен үзләреннән дә артык күреп яшәделәр. Ләкин бу үзеңне дә ярату иде.

## 8

Катифәләргә утын алып кайтуның икенче көнендә үк Канәфи Актайны өйрәтергә булды. Төшсә, ни күрсен: атны чанага Кара Мәлик җигеп маташа.

Егет кантурга чапты. Усал Баттал анда иде.

— Баттал абзый, Актайны миңа өйрәтергә дигән идең ич?!

— Җә, җарар! Шаулама... Мәлик абзаң аждаһаны да өйрәткән кеше, бер-ике көн йөртсен, аннан син...

— Юк, баштан ук мин үзем!

— Чистый кире җегет син, ә?

Камытлар өенә таба баручы председәтел, гадәтенчә, «черт» итеп җиргә төкереп куйды. «Димәкки» Мансур үз складында иде. Канәфи аңа ташланды:

— Мансур абый! Кичә үзең ишеттең ич, Актайны миңа өйрәтергә диде Баттал абзый.

— Димәкки, син өйрәтәсең,— диде тегесе, Батталга коры гына карап.

— Тыкшынма әле, Мансур! — дип, черт итеп төкерде персидәтел.

— Алайса болай,— диде Завхоз Мансур,— икәү көрәшәбез: син егасың икән — атны Мәлик өйрәтә, мин ексам — Канәфи...

— Егарсың сине! — диде Баттал көлеп.— Әнә Мәлик белән көрәш...

Кара Мәликне чакырдылар. Ул Актайны телсез Хәсән белән җигеп бетереп, лапас баганасына дилбегәсеннән бәйләп куйган иде.

— Мәлик, атны Канәфи өйрәтә! — диде Мансур.

— Персидәтел миңа кушты, мин үзем! — дип киреләнде Кара Мәлик күзләрен агартып. Ачуы килгәндә ул күзенең агы белән генә карый.

— Урманнан бушка утын ташыйсың килә синең...

— Ә синең ни эшең бар? Ат өйрәткәндә һәркем ташый!

— Димәкки, болай итәбез. Хәзер көрәшәбез. Син ексаң — Актайны үзең өйрәтерсең, мин ексам — Канәфи энем...

Кара Мәлик Димәкки Мансурдан ун яшькә кече булып, мәйданнарда бер генә тапкыр сөлге тотмаган иде. Ул буйга завхоздан кайтыш булса да, тазалыкка ким түгел. Шуның өстенә, аның куллары Мансурныкы кадәр ике. Бер-бер бармагы да көрәк сабы кадәр. Димәкки Мансур, гәүдәгә баһадир булса да, куллары хатын-кызныкы кебек кечкенә һәм нәфис. Дөрес, бу куллар кечкенә башланып беләге җилкә төбенә җиткәндә бүрәнә юанлыгы мускуллар белән тәмамлана иде.

Тик шулай да Кара Мәлик күп еллар мәйдан тоткан. Димәкки Мансурдан курыкмады, чөнки данлыклы көрәшче соңгы ике-өч елда мәйданга да чыкмый башлаган иде. Ни генә димә, 40 яшьтә көрәшү җиңел эш түгел. «Кырыкта-шырыкта!» — дип юкка әйтмәсләр.

Бил тотышырга Мансур иске дилбегә алып чыкты. Үзе өстендәге кайры тунын салып ташлады. Чикмәнен сала башлаган Кара Мәлик председәтелгә эндәште:

— Нишлик, нәчәлник?

— Җә, җарар! Көрәшегез,— диде Усал Баттал, «черт» итеп җиргә төкереп һәм үзе ит чаба торган зур бүкәнгә барып утырды. Аның Кара Мәликкә Димәкки Мансурны ектырасы килә иде. Алайса, көрәшче булуына масаепмы, аның эшенә тыкшынып йөргән була. Гаделлек эзли, янәсе. Әнә минем урында утырып кара син. Халыкны тотып кара. Берсе дә колхузда батырып эшләргә йөрми. Күбесе шахтага яисә шәһәргә чыгып таю ягында. Ярый әле паспортлары юк, авылы белән Гермәчи яисә Губаха шахталарына Уралга, Пермь ягына чабарлар иде. Ә колхузны кем алып барырга тиеш? Шахтурлар ипи ашамыймы? Ул ипи шахтада үсми шул. Күмерсез яшәп була, әнә иписез яшәп кара!

Димәкки Мансур белән Кара Мәлик лапасның салам түшәлгән җиренә килеп бастылар. Икесе дә әзмәверләр кебек. Берсе ап-ак йөзле, зәңгәр күзле, ә икенчесе кара йөзле, чем-кара күзле. Икесе дә бик матур кешеләр: агы да, карасы да. Кеше ямьсез була димени.

Тотыштылар. Бер биш минут таптанып йөрделәр. Мансур Мәликкә билен бирде, ә тегесе аскарак чүкте. Мансурда үз-үзенә ышаныч һәм тәҗрибә, ә Мәликтә — шик һәм хәйлә. Көч — икесендә дә. Менә Димәкки Мансур тегенең атлаганда адым күчереп, уң аягын күтәреп, сул аягында гына калганын каяндыр сизеп, Кара Мәликне күтәреп тә алды. Әмма черек дилбегә шырт итеп өзелде һәм шуны гына көткән Кара Мәлик, озын Мансурның ике бот арасына кереп, сөзеп суырды һәм центнер да бер пот гәүдәне саламга бәрде.

— Булдымы? — диде сөенеченнән мыш-мыш килгән Кара Мәлик.

— Булдырдың! — дип кычкырды ит бүкәнендә утыручы персидәтел. Ул риза иде. Баш бармагын күтәрде. Рим гладиаторларын сугыштырган диярсең!

— Юк, булмады! — диде Канәфи ачуыннан нишләргә дә белми. Хәтта Батталча черт итеп төкереп куйды.

— Димәкки булмады... — диде завхоз Мансур тыныч кына.

— Ничек булмады? — дип сорады Кара Мәлик.

— Хәрәмләдең... Димәкки!

— Харамга кергәнем юк!

— Мин сине күтәреп алдым, минем сөлге... Кем-ни... дилбегә өзелде. Син шуннан файдаланып... Димәкки булмады!

— Яңадан көрәш! — дип кычкырды Канәфи, алар тирәсендә әйләнгәләп.

— Тыкшынма! — дип кизәнде аңа Кара Мәлик дилбегә белән.

— Әһәһә! Куркасыңмы? Димәкки... — диде Канәфи, Мансур абыйсы сүзен дә кыстырып.

— Көрәш, улым! Үз-үзеңә ышанасың икән, көрәш. Көрәш бер генә булмый, — диде камытлар өеннән чыккан Ильяс карт. Ул монда көн-төн кунып ята. Камыт, ыңгырчак, дилбегә, шлея һәм башка нәрсәләрне төзәтә, рәткә китерә. Алып килгән кешеләрнең итекләренә олтан да салып бирә. Галушка кидерәсе булса, итек артына күн тегә. Барысы да ашау-эчү хакына. Халык ипи алып киләме, бәрәңге яки суганмы, Ильяс карт барысына да риза. Ятимгә ни кирәк тагы. Шулар өстенә, Ильяс картка тәмәке кирәк. Кәгазе — кантурдагы иске гәҗитләр, ә тәмәкесе? Булган чагы бар, булмаганы да юк түгел. Андый чакта ул мүк төреп булса да тарта. Болар өстенә Ильяс карт — авыл философы да. Тормыш турында аннан да акыллы итеп сөйләгән кешене Канәфинең ишеткәне дә булмады:

— Кешене нинди булырга тиеш итеп түгел, ә ничек бар — шулай кабул итегез... — диде бервакыт Ильяс карт. — Юкса бездә «шулай бул, болай бул» дип интектерәләр. Бәлки минем алай буласым килмидер, ә? Бәхет — үзең булу һәм үзеңчә яшәү ул.

Әле бу гынамы? Аның сөйләгәннәрен язып барсаң, бер китап булыр иде. Күбесе китапка язарга ярамый торган сүзләр шул... Ул, 1937 нче елда китеп, ун ел утырып кайткан ич.

Аксакал карт әйткәч, яңадан көрәшергә булдылар.

Бу юлы Димәкки Мансур артык азапланмый гына Кара Мәликне аркасына салды.

— Тот атыңны, өйрәт үзең димәкки! — диде завхоз Мансур Канәфигә, өстендәге салам бөртекләрен каккалап. — Бу ат бәхет китерсен, энем... Димәкки, тамагыңны туйдырсын!

Канәфинең Актайның дилбегәсен баганадан чишеп алып үрәчәле чанага утыруы булды, Кара Мәлик арттан килеп каеш чыбыркы белән атка бер сыдырды. Беренче тапкыр каеш еланның ачы агуы сыртында татыган Актай күккә сикерде, аннан соң, күзенә ак-кара күренмичә, юләрләнеп чабып китте. Берничә секунд узуга, ул Канәфине кантур йортының почмагына бәреп башын ярган иде инде. Ирләр йөгереп шунда бардылар.

Аның ярылган маңгаен Шамилә бәйләде, атын соңыннан Мансур абый тотып алып килде. Кара Мәлик белән Усал Баттал каядыр юкка чыктылар.

— Барыбер үзем өйрәтәм! — диде Канәфи канлы маңгаен тотып.

— Өйрәтерсең, өйрәтерсең димәкки... Камытлар өе янынан мин моңа өч авыр гына түмрән салам... Онытма: атны тәртә арасына йөк кенә өйрәтә... — дип юатты аны завхоз Мансур абыйсы. — Эх, энекәш, энекәш. Абый сугышта калмаса, бәлки үгез, ат та җигеп йөрмәс идең, башкалар кебек йә шәһәргә укырга китәр идең, йә шахтага...

— Ә авылда кем калыр, абый?

— Авыл җәфаланганны сорый ул, Канәфи энем...
— Җиңел тормыш кайда да юктыр инде ул.
— Юктыр да... Әнә мин сугышып узган Җаурупа илләрендә авыл җирләрендә бик матур торалар. Анда аларны хутор дип атыйлар... Чиста, тәртип, таза тормыш анда. Җиңүдән соң поездда илгә кайтып барыш иде. Бер иптәшем кычкыра: «СССРга кердек! Туган ил...» «Каян беләсең? — мәйтәм, — чик баганалары юк ич, димәкки.» «Әнә безнең чик баганалары, — ди. — Әнә безнең без икәнне, СССРны күрсәтүче тамгалар...» дип бу салам түбәле иске йортларга, ауган капкаларга, пычрак юлларга төртеп күрсәтә. Юк, бу — сугыштан гына туган хәерчелек түгел иде, сугыш бит Җаурупа илләреннән дә узды...
— Онытма, улым, — диде аның колагына иелеп Ильяс карт. — Дөньяда яшәгән кешеләр өчен матур көннәр барыбер күбрәк. Бары үзең теләгәнчә генә яшәргә кирәк.

## 9

Канәфи атка чат ябышты. Актайны җигеп йөрергә өйрәтү — егет өчен үлем белән бер иде. Тагын... ат бит тамак туйдыра иде. Атың бар — кеше арасында хакың бар!

Баштарак азапланды ул аның белән. Иң беренчесе — атның муенына камыт кидерү авыр булды. Актайның камыт киясе килмәде. Башына салдыңмы-күккә сикерә, котырып бии башлый. Акрынлап өйрәнде тагы. Аннан соң ыңгырчакны бер дә яратмады. Кеше атланып йөргәндә карышмаган иде, ыңгырчак атлангач — сыртын сикертә, арт аяклары белән тибә. Ильяс карт әйтмешли, «Вакыт — дару», ул Актайны да тәртә арасына кертте.

Бүген — базар.

Егермеләп авылдан, кемдә нәрсә бар, шуны алып килгәннәр. Әнә Ивановка урыслары тозлы кәбестә, кыяр һәм балык сата. Монда итек кирәкме, читекме, конфет-прәннекме — ни генә юк. Көянтә, чабата, мичкә, кашык, уклау, гөбе сатучылар бер читкә өелгән. Болар — Урманбаш кешеләре. Күпер янында чүлмәк, каз чуманы, чабагаш сатучылар да алар. Бал, каклаган каз, карлыган кагын мәчет тирәсеннән алырга була. Иннек-кершән, ислемай, хушбуй, йөзек, алканы да мәчет яныннан ерак салынмаган кибет каршында саталар. Зират ягына таба китсәң, терлек сәүдәгәрләре җыелган: сарык, кәҗә, сыер, бозаулар...

Канәфи базарның бер очыннан икенче очына кадәр йөреп чыкты. Моның өчен мәчет янындагы күпердән зиратка кадәр барырга кирәк иде. Һәркайда халык. Гөрли базар! Кайный базар!

Әнә, авыл сәвите рәисе Усал Баттал Мансур абыйларына кайтып бара. Кайвакыт әйткәләшеп алсалар да, абыйсы Баттал персидәтел белән дус яшәргә тырыша. Болар хәзер «кабып» чыгачаклар.

Егет кабат мәчет янына кайтты. Караңгы йөзле, кара күзле, яңгыравыклы тавышлы ападан Катифә өчен көмеш алкалар сатып алды. Матур иде алар. Елык-елык килеп торалар. Ә йөзек сатып алырга акча эшләү өчен Канәфи дүрт каз чуманы үргән иде. Базарда ул шуларны сатты.

Базарда Талипны күрде. Аның кулында беләзек иде.

— Кемгә бу? — дип сорады Канәфи.
— Катифәгә...
— Ә?..
— Катифә кызыккан иде шушы беләзеккә, менә мин аңа алдым...

Канәфи базардан башын иеп кайтып китте: «Әле картлач Баттал үпкән иде, хәзер Талип аңа беләзек сатып алган...»

## 10

Катифә жаны-тәне белән Канәфине сөйсә дә, кызларга хас мутлык-шуклык белән егетне котыртырга ярата. Ә инде матурлыгына күпләрнең күзе төшүе, аның эчкә яшеренгән горурлыгын, хәтта нәселләрендә әтисе ягыннан килгән мин-минлеген гел үк шәбәйтеп җибәрә иде. «Менә мин кем!» — дип куя иде ул.

Әнә бүген дә, базардан соң мунча керенгәндә, ике иптәш кызы мактау сүзләрен аңа су урынына сиптеләр:

— Катифә, синең чәчләрең нинди куе һәм матур!

— Сез дә чәчсез түгел бит! Пеләшме әллә? — диде ул матур тавышы белән мунчаны яңгыратып.

— Гәүдәң нинди сылу!

— Ә ботларым шәпме? — дип сорады кыз, ялканып.

— Үзләре төз, юан, шалкан күк!

— Билем?

— Нечкә, учка сыя!

— Нишләрсең, Ходай биргән... — дигән булды ул үз-үзеннән бик канәгать рәвештә.

— Теге кинодагы кызга охшагансың син, Катифә!

— Эх! Минем дә аныкы кебек киемнәрем, аныкыдай йорт-җирем, байлыгым булсын иде...

— Син болай матурлыкка аннан ким түгел, Катифә!

Кызлар сукмак буйлап кыр казларыдай тезелешеп кайтыр юлга чыктылар.

— Катифә, бүген Толя кино алып килде!

— Булган! Чыгабыз, кызлар. Үзем сезне бушка алып керәм...

— Ә Канәфи?

— Канәфи — йөргән егетем.

— Синең арттан Талип та йөри!

— Әй, кызлар, — диде Катифә кинәт уйчанланып, йөрү-шаярулар күп булыр, яраткан — бер генә.

Кичен Катифәне ике егет көтә иде: Канәфи белән Талип. Иң беренче аңа Талип сүз катты:

— Катифә, сиңа сүзем бар иде...

— Әйт! — диде кыз.

— Кеше барында әйтә торган түгел.

Алар клуб артында үскән карт тирәк астына киттеләр. Талип кесәсеннән беләзек чыгарды:

— Менә сиңа бүләк!

— Ай нинди матур!!

— Ал инде...

— Юк, юк, Талип, синнән миңа бүләк тиеш түгел.

— Базарда кызыктың ич, шуңа алдым.

— Ә бүләк артында ни теләк?

Талип аның әле мунчадан гына чыккан чиста-гүзәл йөзенә карап борынын тартты, эченнән генә: «Әй бер кочаклап аласы иде үзен!» — дип хыялланды.

— Дуслар булыйк, Катифә!

— Дуслар булыйк, мин риза.

Кыз белән егетнең шунда сүзләре өзелде. Кызлар клуб эченә кереп китүгә, Талип Канәфи янына килде, кесәсеннән чыгарып сигарет тартты. Бертуктаусыз сызгырынып торды да эчке бер көлемсерәү һәм үтергеч елмаю белән:

— Беләсеңме, Катифәне бүген мин озатам, — диде.

Канәфигә тукмак белән суксалар да, болай авыр тоелмас иде, ул чайкалып куйды һәм көч-хәл белән телен әйләндереп:

— Үзе ризамыни? — дип сорый алды.

— Күрдең ич, тирәк төбендә шул хакта сөйләштек. Бүләк беләзекне дә алды.

Беләзекне, гүя, Канәфи үз кулына кигән дә менә хәзер ул, утлы бөжрага әйләнеп, кулын пешерә. Кинәт ул ниндидер уйга килде дә Талипның җилкәсеннән умырып алды:

— Әйдә киттек!

— Кая?

— Катифә янына!

— Ник?

— Сорыйбыз!

— Нәрсәне?

— Кәбестәне...

Ул өстерәп диярлек Талипны клубның текә баскычыннан икенче катка урнашкан тамашачылар залына алып менде. Башын тыгып эчтәге Катифәне чакырды:

— Бер минутка гына кил әле?

— Ни булды? — диде Катифә.

— Сине беләзеккә сатып алган, имеш, бүген мин озатам, ди. Шул дөресме? — диде Канәфи ярсып.

Катифә аптырау катыш күзләрен Талипка текәде:

— Андый сүз булмады ич!

— Юк, булмады, — дип бөрешә төште Талип.

Икенче секундта Канәфи аны баскычтан очырып төшерде дә үзе киногa кереп китте. Әмма кинoны унбиш минут та карый алмадылар. Ачуыннан шартлар дәрәҗәгә җиткән Талип кинодвижокның иң нечкә җиренә бер уч ком салган икән. Урыс егете Толя аңа бу эше өчен алагаемга берне орды. Әле кулында монтировка да бар иде, ярый аның белән кундырмады. Хәер, Талип шул хәлдән соң бер атна клуб тирәсендә йөрмәде. Күз төбенә эленгән «фонарь»ны күрсәтәсе килмәгәндер.

## 11

Канәфи белән Катифәнең мәхәббәте үз агымында дәвам итте. Хәзер ул төгәл сәгать механизмын хәтерләтә иде. Элеккеге кебек ашыгу-каударланулар юк, шашып үбүләр, бер көн бербереңне күрмәсәң, сагынып үлә язулар урынына иплелек, җай, ашыкмыйча гына яратышу, көтә белүләр килде.

Кинәт кенә алар беркөнне күктәге айны да югалттылар. Ай беренче көннәр өчен, мәхәббәтнең тәүге мизгелләре өчен генә кирәк икән ләбаса. Әнә шул иң саф, иң яңа минутларны уздырганнан соң, ай аларны ташлап китте. Кая? Ул хәзер беренче тапкыр кавышкан парларны эзли. Аңа алар белән кызык.

Дөньяга яз килде. Язга ияреп наз килде. Беркөн кичтән авыл малайлары аваз салдылар:

> — Дәр-дәр-дәрәрәгә!
> Иртә торып берсекөнгә сәрәнгә...

Икенче көнне әче таңнан бер төркем 10-13 яшьлек малайлар алар ишегалдына килеп керделәр:

> — Ай, диләр, вай, диләр.
> Маһруй апаны бай, диләр.

Болар — дәрәче малайлар. Әнисе аларга ике чи йомырка, ярма, бер кисәк май һәм тәңкә акча бирде. Малайлар рәхмәт әйтеп чыгып киттеләр. Алардан биш өй генә ары торган Талипның әнисе капкасын бикләп куйган икән, малайларның андыйларга үз җыры бар:

— Иске-москы кәзәки!
Кәзәкинен бавы юк.
Әйбер бирер хәле юк!

Кичтән әнисе суган кабыклары салып күкәйләр кызартты. Кызартты дигәч тә, саргайтты, чөнки суган кабыгында салып пешерелгән йомыркага сары төс инә.

Ә иртән алардан бала-чага өзелмәде. Маһруй аларның берәүләренә төш, икенчеләренә печенье яисә прәннек, ә иң якыннарына күкәй бирде. Менә өйгә Катифәнең энесе килеп керде. Сугыштан соң туган малай әле бу. Мәхшәрдән исән-сау кайткан солдатның дөньяга җанлы бүләге.

Кадыйр керде дә, борынын лышк итеп тартып, ишек яңагына сөялде.

— Йә? — диде Маһруй.

Малайдан җавап «лышк!»

— Нигә исәнләшмисең?

Лышк!

— Телең юкмы әллә?

Канәфинең арага керәсе килә, ни генә димә, Катифәнең энесе — «кайнеш» бит, әмма әнисеннән узып сүз әйтәсе дә килми. Кадыйр чыгып китәргә дә белми, басып торырга да әмәле юк.

— Телең юкмы әллә? — дип кабат сорый Маһруй.

— Бар! — ди малай.

— Булгач, исәнләш!

— Исәнмесез һәм сау булыгыз! — ди малай чатнатып. Кадыйр ишекне ача, әмма Канәфетдиннның әнисе аны тотып ала. Кулындагы киндер капчыгы-ние белән өстерәп алып килеп өстәл янына утырта.

— Кая чаптың, син бит безнең яшь кода! — ди ул шаяртып. Кадыйрга чәй ясый, тәм-том этә:

— Башта чәй эч, аннан күкәй җыярга чыгарсың, — ди. Малай борынны тартып куя. Канәфи килеп аның җилкәсенә кулын сала:

— Әйдә, бергәләп чәйлик әле, мин дә яңа гына тордым.

Кадыйр тәлинкәдән коймак ала һәм «Бисмиллаһир рахманир рахим!» — дип каба. Моны күргән Маһруйның күңеле күккә оча.

— Менә рәхмәт! Бисмилласыз бер эш тә ярамый. Кем өйрәтте?

— Әни...

— Исәнләшеп тә йөр кеше белән. Исәнләшү үзе савап ул.

— Ярый, апа!

Кадыйр бер прәннек тә ашый, ә өстәлгә коелган кечкенә-нәни генә валчыкларын учына сыпырып авызына салгач, Маһруйның күңеле бик була. Тагы сорый:

— Кайдан болай өйрәндең?

— Әни: «Ипинең валчыгын да идәнгә төшермәгез, киялеген күрерсез», — ди...

— Алланың рәхмәте төшсен! Шулай тәүфикълы булып үс. Зур кеше бул! — дип күз яшьләрен сөртә Маһруй. Кадыйр башта ошамаган иде аңа, хәзер Канәфетдиннең әнисе бу малайга мөкиббән китте.

Кадыйр ашап туйгач, «Аллаһәббәр!» — дип ике кулы белән битен сыпыра һәм Маһруйга:

— Рәхмәт яусын, апа! — диде.

Күңеле бик булган Канәфетдиннең әнисе аның капчыгына берьюлы биш күкәй сала. Малайның авызы колагына җитә.

## 12

Төштән соң егетләр «чирмә»гә чыктылар. «Чирмә» дип биш-ун яшьлек балаларның түгел, ә җиткән егетләрнең күкәй, акча җыюлары атала иде.

Югары очта торса да, Канәфи чирмәгә түбән оч егетләре белән чыкты. Сәбәп: Катифәләр очында йөрү иде. Шуның өстенә бу очта

гармунчы Талип бар, ә түбән очта юк. Шуңа ул, әтисенен вараксинын алып, шул якка юнәлде.

Башта Хисмәтләр өенә кереп бирәр кружка әче бал кабып алдылар. Монысы тел чишәргә, жыр жырларга, доньяда үзеңне аз гына булса да иркен, рәхәт, битараф тотар өчен.

Канәфи урам уртасына басып вараксинын сызып жибәрде. И-и-их!

Телгәләнде күңел, җан елады, рух күккә ашты. Ә күктән яңгыр урынына моң яуды. Моң коелды. Булса да булыр икән Канәфидә моң, йә алла! Катифәнең әнисе яулык очларын яшькә манып елады. Яшьли үлгән иренең кайгысы, авыр тормыш газаплары, вакытсыз килгән, кабергә илтәчәк чир бер минутта яулык очына сыгылдылар.

Каршы өйдә идәннәрдә ауный-ауный Шамилә үкседе. Аның җаны бәргәләнә, күңеле теткәләнә иде. Килеп бер ай торуга ук аны Кара Мәлик өеннән куып чыгарды. Ник? Шамилә таза, матур, эшчән, булдыклы кыз иде ич! Сәбәп бер генә: бар ягы да төзек-камил булган кызның бер җире «тотылган» иде. Аңа Усал Баттал «кулы» тигән булган. Шул сәбәптән аны «кара тәре» куып җибәрде. Ә ничек матур яши башлаганнар иде. Мәлик яратып алды ич, ул да аңа сөеп чыкты.

И-и-и-их! Ничек дөньяларны көйләргә? Ничек яхшы һәм матур яшәргә? Ничек яратырга һәм сөелергә?

Апрель кояшы кыздыра.

Урам халык белән тулган.

Тыкрыклардан аккан язгы гөрләвекләр һәм иңкел җирләрдә төшкән «күч суы» үзе үк җәйге инеш кадәр бар иде.

Алларына тәрәзә өленгеләре элгән егетләр урам буйлап җырлап киләләр. Ап-ак өленгеләргә кап-кара саз чәчри. Күнитекләр пычрак ера. Әмма бернигә дә карамастан күңелле! Бәйрәм бүген — ике көн бара торган язгы Сабантуй. Беренче көнне дәрә, дәрә боткасы пешерү, икенче көнне — күкәй җыю.

Кызлар корырак урыннарга басканнар иде. Араларында Катифә дә бар. Катифә — гөлләр арасында аткан чәчәк! Һәрхәлдә, Канәфигә шулай тоелды.

Катифәне күрүгә Канәфинең йөрәге сикереп куйды: Катифә матурым! Катифә сандугачым! Катифә карлыгачым! Катифә бердәнберем! Катифә алтыным! Катифә йөрәк парәм! Катифә чибәрем! Катифә гүзәлем! Катифә җаным! Катифә бәгы...

— Тарт әле, Канәфи бәгырем, гармуныңны! — диде аңа Шамилә. Ул да кызлар арасына кергән икән. Күзләрендә ут. Битләре ялкын-ялкын.

Әйе, шулай диде: Канәфи, бәгърем! Егет күрде, бу сүзләрдән соң Катифәнең битенә дә ут капты. Көнләшә Шамиләдән, димәк, ярата. Мансур абыйсы әйтмешли, димәкки, ярата!

Кызлар-егетләр тиз генә түгәрәк ясап алдылар да бии башладылар. Эх-ма! Күпмедер биеп алгач, егетләр күкәй җыюны дәвам иттеләр. Һәр капка төбенә туктап җыр суздылар:

Телеграм баганасын  
Саныйсым калган икән.  
Күз керфекләрем талганчы  
Карыйсым калган икән...

## 13

Егетләрдән соң, алар артыннан ук диярлек, урамга исакайлар чыкты. Болары — бәйрәм өчен оештырылган бер көнлек театр артистлары. Ике-өч кешедән торган әлеге төркемнең төп максаты — кәмит күрсәтү һәм халыкны көлдерү. Аларга да йомырка, акча яисә бер стакан әче бал бирәләр. Әлбәттә, алар турыдан-туры әйбер

жыю өчен дип чыкмый. Хикмәт — оста уйнап, көлдереп халыкның күңелен ачуда.

«Чирмә» тәмамланып, өенә кайтып баручы Канәфи исакайларны үз турларында агучы күч суында мунча керенеп яткан чакларында күрде. Алар очыннан Әлмөхәммәт абзый белән Котдус абзый кулларындагы мунча себеркесе белән бер-берсен «ләүкәгә салып» чабалар. Чиратлашып. Халык егылып көлә. Янда гына ләгәннәре. Болар «Мунча» дигән тамаша күрсәтәләр икән. Яннарында мөгезенә иске бүрек кигән кәҗә дә бар. Аны да чабындырган булдылар. Берзаман кәҗә, икесен дә күч суына сөзеп егып, урам буйлап чапты. Монысына инде халык чыдый алмады: күбесе эчләрен тотып тәгәри иде. Күзләренә җиләк-җиләк эре яшьләр чыккан. Менә бу тамаша! Кәҗә хәл итте барысын.

Кычкыра халык, көлә, күңеленә яктылык иңә, ак көчләр иңә, ишелеп дәрман керә. Канәфи көлүдән яшьле күзләрен сөртеп тора иде, янына Талип килеп басты. Үзе лыкма исерек.

— Кайда шул кадәр эчтең? — диде Канәфи, аңа өнәмичәрәк карап.

— Бушка бит малай, бушны ник эчмәскә! Сыйладылар...

— Буш дип! Балчык та буш әнә, ашап бетереп булмый.

— Канәфи, сездә бер-ике сәгать ятып чыгыйм әле. Өйдәгеләр...

— Минем әни эчкән кешене яратмый!

— Юк... мин келәтегездә генә...

— Җә, жарый киттек!

Талип белән кайтып, ул аны келәткә алып кереп яткырды. Анда салкынча булса да, бер-ике сәгать кенә йоклаганда түзәрлек иде. Талип кәчтүмен салып аңа бирде дә үзе иске караваттагы урынга барып ятты.

Кәчтүмен элгәндә, Канәфинең кулы аның итәгендәге каты нәрсәгә тиде. Тотып караса — күкәй! Бер генә түгел, бөтен итәге кызартылган күкәйләр белән тулган. Иптәшләреннән яшереп җыйган бу моны:

— И карун тәре! Карун һарун!!

Ул аның якасыннан тартып уятып арт ягына тибеп чыгарырга уйлаган иде дә, бу уеннан шундук кире кайтты, чөнки Канәфи Талипны бер тапкыр баскычтан сугып төшерде ич инде. Аннан соң Талипны канга батканчы изсәң дә, белә торган кеше түгел. Бүген кыйна, иртәгә йөгереп килеп керәчәк. Шундый җан ул Талип.

Шулар өстенә, Канәфи күңеле белән йомшак кеше иде, адәм баласына кул күтәрү аның өчен дөньяда иң авыр нәрсә. Кешегә сукканчы Канәфи үз-үзенә сугарга әзер иде. Үз-үзеңә суксаң, тәнең авырта, ә жаның юк, кешегә суксаң — тәнең авыртмаса да, жаның сызлый.

## 14

Катифәне барлык яклары белән яратты. Ул кызның килешмәгән урыннарын да үз күрә иде. Егет аны үзенә каршы килсә дә, үпкәле сүзләр әйтсә дә, хәтта сүзгә керсәләр дә, сөя иде. Канәфи яшь кенә килеш тулысынча аңлады: Катифә Аллаһы тарафыннан аның өчен яратылган. «Аның үлеме — минем үлем, аның яшәве — минем яшәү!» — дип уйлады ул беркөн кинәт исәнгерәп. Бу уй аңа күктән иңде. Моның шулай икәненә аның иманы камил, күңеле нык иде. Бәлки сөю-мәхәббәт тә күктән иңдереләдер!?

Аларның сөюе кышын — бөре, язын яфрак булса, җәйгә чыккач тәмам чәчәк атты.

Кыр эшләре тәмамланып, җыеннар башлангач, мәйданга алар гел бергә йөрделәр. Авыл халкы өчен алар бер-берләрен тапкан парлар, ике ана өчен якты өмет: булачак килен һәм кияү иделәр.

Күрше авылларга мәйданга барганда, Канәфи Усал Батталдан кайвакыт Актайны сорый иде. Юк, үзләре өчен түгел, олырак яшьтәгеләр һәм көрәш, ат чабышын күрергә теләүче карт-корылар өчен. Канәфи

андый вакытта вараксинын да ала. Гармунын сызып җибәрүгә, арбадагылар җыр башлый:

Сандугачлар җыелганнар,
Без алай җыелмыйбыз.
Дуска түгел, дошманга да
Без кара коелмыйбыз...

Бу вакытта Актай, юыртудан туктап, кинәнеп җыр тыңлап бара.
Менә шулай Канәфи, Катифә һәм җыр тыңлаучы ат җәйне үткәрделәр. Уен-көлеш һәм... эш белән. Урман-болын, басу-кыр һәм җыр белән.

## 15

Ул елны Канәфи белән Катифә мәхәббәте иң матур сөю-сөешү булса, авылда иң гүзәл, иң тиз, иң акыллы, иң хисле ат — Актай иде. Җыр тыңлаучы ат. Ат — тамашачы. Ат — хис. Әнә бервакыт Карун Талиплар турыннан узып баралар иде, анда патефоннан чит бер һәйбәт көй һәм җыр ишетелде. Ат шып туктады һәм бер мәл, каккан казыктай катып, көйне тыңлады. Тик Канәфинең бу ят көйне тыңлап торасы килмәде, чөнки патефон — трофей, немец ягыннан алып кайтылган. Талипның әтисе Карун Һарун сугышта бер яра да алмаса да, бер велосипед, бер тегү машинасы, бер патефон һәм бер... медаль алып кайтты. Әтисе сугыш кырында калган Канәфигә бу патефон тавышын ишетү әҗәл белән бер булды. Гүя, аннан җырламыйлар, ә мыскыл итеп көләләр:

— Атаңны үтердек! Атаңны үтердек!! Атаңны үтердек!!! — дип кыргыйларча шашып сөенәләр. Көйләре дә, сүзләре дә кисәк-кисәк мылтыктан аткан кебек:

— Шарт! Шарт! Шарт!!!

Яисә эт өргән кебек:

— Һау! Һау!! Һау!!!

Әнә шул бер «шарт!» әтисенең йөрәгенә килеп тигән һәм солдат егылган. Аның әтисен Немец дигән кеше үтергән.

Әтисенең ничек үлгәнен быел гына ишетте Канәфи. Гаеттән соң печән өсте башланган иде. Беркөнне печәнгә чыкканда, аның атына Котдус тә утырды. Теге исакай Котдус. Күч суында мунча чабынган артист. Кәҗә аны сөзеп еккан иде.

Иделне кичеп, паромнан чыктылар да киттеләр болын буйлап куышлар янына. Котдус абый, гадәттәгечә, әзрәк «төшергән» иде. Ул шулай инде, «төшермичә» йөри алмый. «Төшермәсә» кәефе юк, күңеле сүрән була.

— Син, Канәфетдин энекәш, әтиеннең ничек үлгәнен белмисең инде. Бәлки белергә дә теләмисеңдер инде. Мин инде күпме әйтәм дидем инде. Һаман суздым инде.

— Ничек үлде соң ул? — диде егет, бу соравыннан үзе үк бик куркып. Чөнки үз күзе белән күрмәгәч, әтисе аңа һаман исәндер кебек тоела иде. Менә-менә кайтып керер. Бүген булмаса, иртәгә...

— Без инде штраф батальонында идек...

— Штраф батальонында?

— Батальонмы шунда, инде ротамы... Аның батальон дигәне ротадан әзрәк, рота дигәне батальон кадәр инде. Кем белсен инде. Без бит инде штрафниклар.

— Дезертирлармы?

— Юк инде!

— Алайса нигә штраф батальоны?

— Сугышта инде, Канәфетдин энекәш, нинди генә хәлләр булмый. әнә синең инде әтиең артеллирист булган. Дошман танкларын берүзе

кырган. Ә туп командиры сержант качкан. Снаряд ташучы үлгән. Үзе ташый, үзе төзи бу, үзе ата инде. Ә инде соңыннан? Теге сержантка зур орден, моңа кукиш. Шуңа бу инде сержантны тотып тукмаклый. Татарны кем якласын инде? Татар үзен-үзе генә яклаcа инде. Карга карганың күзен чукымый. Шул сержант өчен моны штраф батальонына китереп тыгалар. Ә танкларны кырган өчен Герой бирерлек була аңа. «Геройга — ай, юашка — кояш!» — ди әнә Зиннәт мөәзин. Ул инде дөрес әйтә.

— Шуннан?

— Шуннан инде башлар китте бетле туннан! Китереп тыктылар безне җәһәннәм авызына. Вәт инде котырып яңгыр ява. Алда калкулык, аны «Фәлән-фәлән биеклек» кенә диләр инде. Безгә әнә шуны алырга. Атака алдыннан спирт бирделәр инде. Ә ашарга песи дә туймаслык. Әллә юк инде, әллә инде юри исерсеннәр дип ашарга бирмәделәр. «Эх! — ди әтиең,— Котдус туган, авылга кайтып бер таба пич бәрәңгесе ашар идем. Иписез генә. Тоз суына манчып». Бәрәңгене ярата да иде инде мәрхүм. Ачуың килмәсен инде, аның кушаматы да «Бәрәңге корсак» иде бит...

— Мин дә яратам бәрәңгене, Котдус абый!

— Үтергән дә куйган атаң инде. Кем бәрәңгене яратмасын инде. Авыл ашы — бәрәңге.

— Әти ничек...

— Шулай инде. Атака алдыннан кружка белән спирт бирделәр. Рәчиядә башкасы булмаганда да спирт, аракы табыла инде. Безнең белән тагы авылдан Гайфетдин абый да бар иде. Карт солдат, ундүртенче елда ук инде ярманга каршы сугышкан, гражданнар сугышында булган. Ул инде әйтте, еландай телләрен чыгарып әйтте: «Җегетләр,— диде,— бу шайтан суын аз гына, җылыныр өчен генә кабыгыз. Моны,— диде,— инде юри бирәләр. Безне инде хәзер,— диде,— ит урынына тураячаклар. Без монда көзге казлар,— диде.— Әйе, көзгә суелачак казлар,— диде.— Ха-на!— диде.— Чамалап кына эчегез,— диде. Ә әтиең дуамалрак кеше иде. Йөрәгендә һаман теге сержантка һәм аны яклаучыларга ачу. Үч немецларга да, үзебезнекеләргә дә... Андый үч юньлелеккә илтми. Күтәрде дә салып куйды бу үзенекен. Аннан минем калганны да эчте, ә Гайфетдин абый үзенекен азрак йотты да калганын җиргә түкте. Менә берзаман: «Атакага!» — дип акырдылар. Күтәрелә башладык. Гайфетдин абый ым кага: «Ашыкмагыз! Аз гына көтегез... Ашка пешәрсез»,— ди. Ну инде әтиең ике уйлап тормады, окоптан сикереп чыкты да: «Һитлерыңның алласын-мулласын!..» — ди. Нәрсә инде? Без арттан барабыз. Коя нимес, яңгыр коя. Нимес пуля коя. Әтиең озак бармады. Пулемет аждаһасы башын нәкъ маңгаеннан кисеп атты. Кәбестә кискән күк инде...

Котдус абыйсы тынды, аннан кыенсынып кына:

— Син инде, Канәфетдин энекәш, ачуланма,— диде.

— Ә сез ничек котылдыгыз? — дип сорады егет.

— Без инде барабыз... барабыз инде. Шулчак Гайфетдин абый дәшә, юк, ым кага. Миңа кара, янәсе. Карыйм инде, ул снаряд чокырына ава. Сиздем хәйләсен, мин дә, үлгәнгә сабышып, әлеге чокырга авам инде. Чокырның эче тулы су, тирәсендә куаклар үсеп утыра. Батальон инде шул көнне юкка чыкты. Безне нимескә тураттылар, юри тураттылар инде. Нимеснең пуләсе кимесен дип тураттылар. Бер ун кеше исән калды микән? Син инде, Канәфетдин энекәш, безгә үпкәләргә мөмкин. Нишлисең инде, үзебезне саклап кала алсак та, атаңны саклап кала алмадык шул...

## 16

Канәфи, Катифә һәм җыр тыңлаучы атның камил берлеккә, өч йөрәкле мәхәббәткә әйләнеп барган көннәрдә, бу тән-җан-рух матурлыгына Усал Баттал үзенең таза һәм тупас борынын тыкты. Гүя, кешеләр бер-берсенә зыян салу, комачау итү өчен генә яшиләр.

Актайның авылда бер чабышкы булуы, житмәсә аккош кебек ерактан балкып торуы шулай ук ат жене кагылган персидәтел Батталның беркөнне төн йокысын качырды. Иртә белән кантурга төшкәч, ул Канәфигә әйтте:

— Жә жарар! Актай белән ат чабышында өч ел беренче урынны алдың. Аннан соң башка малай белән дә беренче килде ул. Тәртә арасына да син өйрәттең. Монысына рәхмәт! Хәзер Актайны мин үземә жигә башлыйм. Андый атны эшкә жигеп харап итәсе түгел!

— Мин аңа артык йөк төягәнем юк,— диде Канәфи.— Йомышлыга жигеп тә атны бетерергә була. Әнә син, Баттал абзый, район юлында исерек килеш йөреп, Каратайны яндырдың ич.

— Нәрсә?— Батталның чәйнек кадәр борыны самавырдай үсте, кызарып чыкты.— Син, малакасус, кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме? Маңка хөрәсән!

Усал Баттал чикерткәдәй «че-ерт!» иттереп жирәнеп төкереп жибәрде. Ни хикмәттер, аның бер тамчысы адашып Канәфинең йөзенә чәчрәде. Менә моңа егет түзә алмый инде. Канәфи чиста һәм пакь егет, үлсә үләр, әмма дөньяда беркемгә дә йөзенә төкертмәс!

— Бирмим мин сиңа Актайны!— диде ул ярсып.

— Ха-ха! Менә мә!!— диде Усал Баттал кукишлап.— Атаң малы мәллә ул?

Усал Баттал, рәис кеше буларак, эшне коры тотты:

— Жә, жарар! Иртәгә ат жигәргә төшмисең!

Мондый кабәхәтлеккә егетнең жаны суырылды, болай да зур күзләре зур булып ачылды.

— Тиеп кенә кара минем Ак Күбәләккә, өеңә кызыл әтәч жибәрәчәкмен!

Бу сүзләрдән Усал Баттал тастымалдай агарынды. Хәтта кызыл борыны күгәреп китте. Аның дөньяда бар курыкканы янгын иде. Бигрәк тә үз өендә, каралты-курасында ут чыгудан курыкты ул. Ни генә димә, йорты — авылда бер, амбар-амбар ашлык, абзар тулы мал-туар, кошкорт. Баттал утызынчы елларның ач председателе түгел, сугышта йөреп Европа күреп кайткан һәм тук-бай яшәргә омтылган рәис иде. Теге көн тужуркалы хәерчеләр заманы узды. Аларның ни: тужурка да наган. Башкасы юк...

— Нәрсә сөйлисең?— диде ул кинәт йомшарып. Гомумән, аны Усал Баттал дисәләр дә, чынында ул ике котыпта иде: йомшак һәм каты. Баттал күңелендә кешесенә карап кыш була, жәй була, судан бозга яисә боздан суга әйләнә. Әнә шундый сәер адәм иде Усал Баттал.

* * *

Актай һаман Сабантуйда ат чабышында беренче килүен хәтерләде: Киттеләр такыр басу буйлап. Колактан жил сызгыра. Каратайга Талип утырган, Актайга — Канәфи, Разгромга — Нуретдин дигән малай. Калганнарын ул хәтерләми. Актай белә: шушы өч ат кына беренчелек өчен тырышачак.

Актай ук сыман сузылып, борын тишекләрен бәрәңге сыярдай киңәйтеп бара. Ул әле юри генә ярсый. Ул әле чынлап чапмый. Ә менә Каратай белән Разгром чабалар, ашкыналар, ашыгалар...

Юл кайтыр якка. Канәфи аны һаман тыя төшә. Юк инде. Тыярсың, бар! Менә Актай кузгала. Гүя, ул жирдән бармый, ә күктән аккош булып оча. Бәлкем әнә теге ак болыт булыптыр. Шундый жиңел, жил генә уйный. Жил генә сызгыра.

Башкаларны шактый артка калдырып килде ул. Аны соңыннан мәйдан уртасына алып керделәр, муенына кызыл сөлге салдылар. Яшь кызлар ялына чигелгән кулъяулыклар бәйләделәр. Атаклы гармунчы

Кашаф бер читтә «Әпипә»не сибә иде. Беренче тапкыр әнә шунда музыкага исе китте Актайның һәм ул... шушы көйгә мәйдан уртасында бии башлады. «Әпипә»гә...

Егылып көлде халык. Күбесе шаккатты:

— Кара, кара, көйне аңлый бит бу!

— Адәм акылы бар икән!!

— Сөбханалла, машалла!!!

Аның муенына тагы бер сөлге салдылар. Ялына тагы ике кыз ике кулъяулык такты.

Шул көнне «Әпипә» дигән кушамат тагылды инде Актайга. Шулай итеп, исемле генә түгел, кушаматлы ат та ул! Әле ул гынамы? Әнә быел Катифә аңа «Ак күбәләк» дигән исем дә бирде. «Чөнки,— диде ул Канәфигә,— аның ак тай икәнлеге болай да билгеле һәм күренеп тора. Без аңа «Күбәләк» исеме бирик. Менә шулай итеп, көннәрдән беркөнне җыр яратучы Актай «Әпипә» һәм «Күбәләк»тә булды. Канәфи, Катифә һәм Актай. Канәфи, Катифә һәм Әпипә. Канәфи, Катифә һәм Күбәләк. Канәфи, Катифә һәм җыр тыңлаучы ат.

## 17

Эссе көн. Пешерә дөнья. Эс-се! Шырпы сызсаң да, дөньялары кабынып китәр сыман.

Утынны Сәрби әбигә аударып, тиярен алганнан соң, Канәфи Актайны туарып, абзарга кертте. Яшереп куелган җирдән кечкенә чалгысын алды да инеш аръягындагы таллыктан бер кочак яшел сусыл печән чабып, шуны иске капчыкка тутырып, Актае янына кайтып килә иде, инешнең атлар йөздерә торган тирән чоңгыллы урынынннан су анасы килеп чыкты. Егет тораташ катты. Билгә кадәр калын чәчләр, йомры җилкә һәм беләкләр, таза ботлар, киң-киң артлар. Йә хода! Ни хикмәт бу?

Канәфинең теле киселде. Менә су анасы көлеп җибәрде:

— Канәфи, карама, чукынчык!

— ?

— Нәрсә күзеңне тасрайттың, күргәнең юкмы әллә?

— ???

— Карап каткан!

Су анасы чәчләрен сыга-сыга таллыкка кереп китә. Канәфинең тезләре калтыраса да, аяклары нигәдер таллыкка тартты. Су анасы юк иде инде, әллә тагы суга чумганмы? Канәфи, Шүрәле күргән Былтыр сымак, беркавым торганнан соң үз-үзенә: «Аңа миннән ни кирәк?» — дип эндәште. Тукай Шүрәлесен белә иде, әнә абыйсы Димәкки Мансур һәрвакыт аның шигырен кабатлап йөри:

> И сабыйлар, эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә эш,
> Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.

Моңа каршы Зиннәт мөәзин:

— Рәхмәт, Мансур! Тукаен белгән халык югалмаячак. Без — бөек болгарлар нәселеннән. Бу һич тә милләтчелек түгел! — ди.

Дөрес, Канәфи Зиннәт мөәзинне аңлап ук бетерми. Аны шул милләтчелек өчен 37 дә утыртканнар бугай инде.

Канәфи уйларыннан арына. «Су анасы кая югалды соң?» — дип тагы уйлый. Аннан акрын гына ат абзарына юнәлә. Капчыгындагы печәнен Актай алдына салып ишек янына килсә, почмактагы сәндерә күк урында ул — су анасы утыра.

Су анасы тиз генә Шамиләгә әйләнеп аңа елмая:

— Кил әле, утыр яныма! Бая котымны алдың.

Егет дәшми. Аны авыр халәт чолгап алган. Өстенә киенгән булса да, ул Шамиләне һаман анадан тума, шәрә су анасы итеп күз алдына китерә. Киемле килеш тә ул аны шәрә күрә, чөнки таллык буендагы теге сурәт һич кенә дә күз алдыннан китми, шайтан алгыры!

— Йә, нигә боектың? — ди Шамилә аңа терсәге белән төртеп.

— Нишлим соң? — дип сорый ул Шамиләгә аптырап. Аның бу су анасын ташлап та китәсе килә, шул ук вакытта нидер аны тота, һич җибәрми.

— Туңдым, кочакла! — ди су анасы.

Канәфетдин кочаклый. Туңарлыкмы, эссе. Пешеп үләрсең!

— Ныграк, катырак кочакла!

Канәфетдин тагы кочаклый.

— Терәл яхшылап! Ник миннән куркасың? Ә хәзер үп!

Канәфетдин теләр-теләмәс кенә үпкәндәй итә. Ә үзе уйлый: «Ник кочаклата ул? Ник үптерә ул?»

Канәфетдин бераздан шакката: аның алдында шәрә Шамилә, су анасы югалды, Шамилә генә калды.

— Йә, кыюрак! Күрсәт егетлегеңне!!

Инстинкт Канәфетдинне шәрә тән өстенә тарта. Инстинктка Шамилә дә булыша. Дөресе, Шамилә-инстинкт.

Шамилә аңа елмая һәм шулвакыт... Дөньяны яңгыратып матур итеп көлеп җибәрә кемдер! Канәфи колакларын торгыза: «Катифә! Катифә-матурым!! Катифәм, бердәнберем!!!»

Ул Шамилә өстеннән төшә.

— Син нәрсә! — ди Шамилә, Усал Баттал кебек «черт» итеп төкереп. — Куркасыңмыни, булдыксыз?!

— Кирәкми, Шамилә апа, минем...

— Катифәң бар!

— Киттем...

Утыз яшьлек таза хатын Шамилә асылынырга житеп сәке сымак нәрсәдә аунап кала, ә Канәфи, аждаһадан качкан шикелле, өенә чаба.

Кибеттән Катифәгә яулык һәм хушбуй алып кайтып килгәндә, алардан ашыгып чыгып килүче Талипны күрә.

— Катифәгәме? — дип төртеп күрсәтә ул Канәфинең кулындагы әйберләргә.

— Әйе! — ди егет горур рәвештә.

— Соңга калдың!

— Ничек соңга? — Ул «соңга» сүзе егетне тетрәндерә.

— Ишетмәдеңмени, авыл бетереп Катифәне эзлиләр бит. Иделгә батып үлгән, диләр...

— Нишләгән? Ни булган аңа??

Канәфи Талипның кулларын шулкадәр каты кысты, теге «ай» дип кычкырып җибәрде.

— Мин сине ишеткәнсеңдер дигән идем, персидәтел Баттал фермада көчләгән ич аны. Ферма янындагы таллыкта...

Канәфетдингә җир убылды. Кулындагы хушбуе төшеп китеп ташка бәрелде дә чәлпәрәмә килде. Яулыгын җил очыртты. Ефәк, бик җинел яулык иде ул. Үтә күренмәле. Күкнең зәп-зәңгәр икәнен аның аркылы карасаң, күренә. Әмма Канәфи өчен дөнья караңгыланды. Кояш батты...

* * *

Шул ук көнне авылда янгын чыкты. Усал Батталның калай түбәле клуб кадәр йорты бер сулышта янып бетте. Никадәр байлык көлгә әйләнде.

Ярый әле үзе, хатыны, балалары исән калдылар. Ярый әле малтуарын алып чыгарга өлгерделәр. Ярый әле янгынчылар утның күрше өйләргә сикерүенә ирек бирмәде. Кызыл әтәч канатлы ул!

Ярый әле төнлә коеп янгыр яуды. Картлар моңа эчтән генә сөенеп: «Алла саклады»,— диделәр. Шунын өстенә, ходайның рәхмәте, җиле дә юк иде. Шулар өстенә, Усал Батталның иң якындагы күршесе дә, мәчедән курыккан тычкандай, үз өйләрен анықыннан читтәрәк салганнар иде. Әнә шул да коткарды аларны. Алайса янып бетәселәр иде. Бер елны җитмеш йорт янган авыл бит инде бу.

## 18

— Канәфи асылынган!

Бер көн, бер төн эчендә ике яман эштән соң ишетелгән бу хәлне авыл халкы шашып каршы алды:

— Катифә өчен!

— Усал Батталны кичә утка атасы булган!!

— Батталга утны ул салган, диләр...

Әмма Канәфи үлмәгән иде. Улының юклыгына эче пошкан ана аны эзләп чыкса, Канәфине печәнлеккә асылынган килеш тапты. Аның җир акырып елавына күршеләре гармунчы Кашаф кереп, египне баудан кисеп төшерде. Рәхмәт төшкере, егет, бу эштә тәҗрибәсез булгангамы, бауның юанын алган икән. Янәсе, нык булсын! Өзелеп төшәрлек булмасын. Ә андый вакытта нечкә һәм сабынлаган кебек шома бау кирәк ич!

— Ашыкма, энем! Гармун уйныйсы бар әле,— диде аңа Кашаф абзасы, баудан кисеп төшергәч. Егет аңына тиз килде. Бары муены гына тоташ кысылып һәм кытыкланып торды. Аннан тавышы, телсез Хәсәннеке кебек, гы-гы-гы булмаса да, гыжылдабрак чыкты. Хәер, телсез Хәсән теллегә әйләнде ич. Төнлә каршыларында тәрәзә аркылы ут күргәч, уяныл киткән Хәсәннең башта күзләре чәшкә кадәр булып акая да аннан соң ул изрәп яткан хатынын урыныннан куптарып кычкыра:

— Пу-жар! Пу-жар!! Тор! Торр!

Аллаһының бирмеше белән Катифә дә бер дә суга ташланмады. Дөрес, ул күзләре яшьле килеш Идел буенда йөргән, әмма балыкчы Мәгъсүм абзый аны өенә кайтарып җибәргән. Ул өендә, әнисе күзенә күренергә куркып, ике көн печәнлектә кунып яткан икән. Хәерниса, тавык күкәйләре белән бергә кызын да эзләп менгәч, Катифәне табып, тавык күкәйләрен бер атнага оныткан. Ана-бала кочаклашып елашканнар. Аңлашканнар...

Шул көннән соң Канәфи белән Катифә арасына боз тавы өелде. Егет аның ягына борылып та карамады. Катифә ни чакырса да, килмәде. Актай янына да төшмәде. Ә инде иртәгә районга алып китәчәкләр дигәч, ул Актаен җигеп, чикләвек куаклары тезелгән тау-кырлардан әйләнеп төшәргә уйлады. Аны ут төртүдә гаепләп төрмәгә ябачаклар иде.

* * *

Кыр юлыннан Актай килә. Эссе көн. Кояш һәммә җирне эссе табага бастырган. Сырттан авыл һәм аның тирәсе уч төбендәге кебек күренә. Әнә Усал Батталның кара күмергә әйләнгән өе. Әнә аларның йорты. Әнә Катифәләрнеке.

Шулчак аның йөрәген озын энә чәнчеп узды. Узмады, кадалды да калды. Мәңгелеккә... «Катифә! Катифә матурым!! Минеке һәм бердәнберем идең... Син миңа бозык килеш кирәкмисең!!!»

Менә егет җырлый башлады. Ат колакларын сагайтты: яңа көй, яңа моң, яңа аһәң, гомумән, яңа җыр иде бу:

Катифәмнең, бәгыремнең ефәк икән чәчләре.
Катифәкәй, аерылдык, җанда әрнү яшьләре...

Канәфинең җан әрнеткеч моңлы тавышы хәтта күктәге тургайларга кадәр ишетелә. Алар да бу сагыштан зәңгәр күктә катып калганнар кебек. Дөньяны тутырып иңрәгән моң Нократны, елга-чишмәләрне агуыннан туктаткандай итә. Искән җил дә бер мизгелгә ташка әйләнә. Тирә-юньне моң, сагыш чолгый. Мәхәббәт моңы. Мәхәббәт сагышы...

Нәрсәдә аның көче? Кайда сере-сихере? Ник бу моң атны да тыңларга мәҗбүр итә? Атны да елата.

Хикмәт фаҗигадә. Әгәр ул бәхетле мәхәббәт булып, Канәфи һәм Катифә матур гына кавышсалар, сөю турындагы бу моңлы җыр тумас иде.

Галәмдәй киң басуда егет җырлый, ат тыңлый. Моң күккә оча, йолдызларга таба юл ала...

* * *

Иртәгесен Канәфине районга алып китәргә милиция килгәч, Катифә аны озатырга булды. Сүз кыска иде. Егет хәтта аңа ныклап карамады да, күзен читкә төбәде.

— Безнең арада берни дә калмады! — диде Канәфи.

— Ялгышасың, Канәфи...

— Бетте! Хуш мәңгегә!!

— Һич югы бу хатны укы...

Кыз аның уч төбенә кәгазь кисәге төртә дә елый-елый янынннан йөгерә. Егет кәгазьне җиргә ата, соңгы вакытта елап шешенгән Мәһруй аны алып алъяпкыч кесәсенә салып куя. Аннан тагы елый башлый...

* * *

Шуннан соңмы?

Канәфине төрмәгә ябалар. Бер елдан артык Катифә аңа хатлар салып тора, ләкин егет эреми — җавап бирми. Бер елдан соң аны төрмәдән чыгаралар, чөнки утны кем төрткәнлеге билгеле була. Кара Мәлик! Усал Батталның Шамиләсен мыскыл итүенә үчлек белән. Моны Кара Мәлик, бик каты эчеп алгач, Батталга үзе әйткән. «Мин төрттем! — дигән. — Канәфи юкка төрмәдә чери, — дигән. — Тагы Шамиләгә кагылсаң, мин сине үтерәм!» — дигән.

Егет котылып кайтуга, әнисе аңа теге вакытта Катифә биргән язулы кәгазьне тоттыра. Ничек бер ел буе саклагандыр. Анда кыска гына җөмлә:

**«Канәфи, мин дөрес. Элеккечә чиста, саф кыз. Баттал мине, чыннан да, көчләргә маташты, әмма мин аңа бирелмәдем. Киемнәремне ертып бетерсә дә. Кешеләр күзенә күренергә оялуым шуннан иде, ул минем битемне-тәнемне тырнап бетерде. Мин элеккечә сине генә яратам».**

Мәһруй елады да елады. Ул болай да еларга ярата инде.

— Катифә кайда хәзер? — дип сорады Канәфи.

— Әй улым, улым! Агачның җимешен дуңгыз ашар ди, теге кина күрсәтә торган кыяр башлы урыска кияүгә чыкты ич ул... Тапмыйлар микәнни үзебезнең татардан кина күрсәтүчене?

— Ивановка Толясынамы?

— Әйе, шул Ибануфкадагы Түләгә...

— Кайчан?

— Бүген туйлары...

Катифәләргә кергәндә, Хәерниса карчык яшьле күзләрен сөртә-сөртә өстәл җыештырып йөри иде. Кадыйр энекәш аңа усал гына карап, борынын лышк итеп тартып куйды.

— Әй балакаем! Кайларда йөрисең син? Бердәнбер кызымны, Казаннардан Мәскәүгә киткән Сөембикә кебек, чит кешеләргә биреп җибәрдем бит. Ни никах, ни кияү мунчасы, дигәндәй. Ни туе, ни уе, дигәндәй. Аннан-моннан капкаладылар да кияү дигәннәре:

— Майт, майт, без үзебездә пасбаему, ди. Нәрсә соң ул, Канәфетдин, «пасбаему?» Майте — әни инде...

— Үзебезчә дигән сүз...

— Мөселманча, татарча түгел икән, димәк...

— Димәкки, шулай. Катифә үз теләге белән чыктымы соң?

— Нинди үз теләкләре белән булсын! Сиңа атна саен хат яза, җавап юк. Авылда атын чыгардылар, Баттал себеркесе, дия башладылар. «Канәфине көт»,— дим. «Бер генә сүз язса да, йөз ел көтәр идем, ул да йөз чөергәч, мин кемгә генә карыйм соң, әнкәем?» — дип елады. Кем каргышлары төшкән балам өстенә? Кыз бирү түгел, каз бирү күк кенә булды... Кыз бирмәк, каз бирмәкмени?

Хәерниса баш өянәге белән тагы урынга егылды. Ә Канәфи, кинәт бер карарга килеп, атылып чыгып китте.

— Канәфи! Син, бәлки...

Әмма ул Хәернисаны тыңламый иде инде. Йөгереп камытлар өенә төште. Ильяс карт сәкесенә яткан да күзләрен түшәмгә төбәгән. Ак чәч, ак сакал.

— Нихәл бабай? Нишләп ятыш??— диде ул аңарга.

— Рухымны көтеп ятам. Күккә менеп киткән иде. Ни хәбәр белән төшәр, белмим әле...

— Авырмыйсыңдыр бит?

— Карт кеше авырыр да. Тән чире нәрсә ул, җан авырмасын.

— Бабай, миңа киңәш бир!

— Әле соң түгел. Катифәне барып алып кайт!! Хатынын биргән — халкын биргән...

— Шулаймы, бабай?

— Шулай икәне көн кебек ачык! Ашык, улым, ашык!! Дирбия — чөйдә, Актай — утарда, үзең — монда, Катифә — тегендә.

Атны күз ачып йомганчы җикте Канәфи. Икенче минутта ул юлга кузгалды.

— Онытма, улым,— дип кычкырып калды ишек төбенә чыккан Ильяс карт.— Кояш чыгышы — җан өчен, кояш батышы — тән өчен.

Нәрсә әйтергә теләде ул? Канәфи авыл философын аңлап бетермәде. Аңлар әле алга таба. Бары картның: «Кирәгеңне эзләп табасың. Кирәк үзе килми»,— дигән сүзләре генә колак төбендә. Монысын тиз аңлады ул. Ә теге сүзләр?

Актай сабантуй чабышындагы кебек очты гына. Инде үзен чабышкы булудан туктаган дип уйласа да, монда елдам аякларын исенә төшерде. Канәфи аңа сугып карау түгел, дилбегә очы белән дә чиртмәде. Теле белән генә әйтте. Ат аңлады. Кешеләр аңламаганны аңлады.

Ивановкага янгынга баргандай килеп кергәндә, көн кичкә авыша башлаган иде инде. Канәфи картның: «Кояш батышы — тән өчен...» дигәнен тагы бер исенә төшерде. «Тән өчен, тән өчен»,— дип кабатлады үзе. Ул Толяларның өен белә иде, чөнки берничә мәртәбә кино йөртте Актай белән. Ат та белә иде, шуңа туры Толялар өенә чапты.

— Толя кайда?— дип сорады ул эчеп-исереп беткән йорт хуҗаларыннан. Өстәлдә — кыяр, кәбестә, дуңгыз салосы...

— Башта исәнләш, аннары яшь өйләнешүчеләргә бәхет телә син,— диде йорт хуҗасы, туп күк түгәрәк таза сары урыс. Канәфи аны да белә иде. Ул да Канәфине таный.

— Миңа Толя кирәк.

— Ул кәләше белән мунчага китте.

Канәфи өстеннән бер чиләк бозлы су койдыларммыни! Ул ишекне ябып чыгып китте. Капкадан чыгып барганда кемдер аңа:

— Канәфи! — дип дәште. Борылып караса — Катифә! Ни әйтергә белмәде Канәфи. Телсез Хәсән булды. Хәер, Хәсән хәзер теллегә, ә ул телсезгә әйләнде.

— Канәфи, мин сине көттем!

Кыз аңа сарылды. Канәфи нигәдер аны чын күңелдән кочагына ала алмады. Нидерме, кемдерме тота.

— Сезне мун... мунчада диделәр.

— Мин Толяга «мунча кермим», — дидем... Ул исерек. Өч көн инде айныганы юк. Эчә дә йоклый. Өйләнү шатлыгыннан, ди.

— Сез бергә... ни...

— Мин аның белән... булмадым әле. Гел соңыннан дип артка кайтарып килдем. Ул эчсә, йокыны гына белә. Мин һаман сине көттем, Канәфи!

— Катифә!

— Канәфи!

— Мин сине алып китәм!!

— «Күбәләк» белән килдеңме?

— Әйе, «Әпипә» белән.

— Киттек, Канәфи!

— Боларга әйтеп чыгыйк...

— Юк, мин үзем Толяга әйтеп киләм. Мин бит аңа: «Канәфидән башка беркемне дә яратмыйм, әгәр ул кайта икән, мине алам дисә, синнән аерылып китәм», — дидем...

— Рәхмәт, Катифә! Ә нигә кияүгә чыктың соң син?

— Синең миңа ышанмавыңа ачу итеп. Хәзер ышанмый икән, гомер буе ышанмаячак, дидем.

— Кичер, мин гаепле! Яшьлек... Дуамаллык...

Катифә Толяга әйтеп килде. Аптыраган егет күлмәк-ыштаннан гына озата чыккан:

— Бәлки, Катя, сүтелерсең? — ди.

— Юк, Толя, мин — Катифә һәм минем Канәфием бар!

Егет мунчага кереп китә. Бераздан киенеп чыга.

— Китик, Канәфи! — ди Катифә.

— Юк, көтик! Нәрсә дияр!

— Өйдәгеләре исерек, сугыша башларлар. Имгәтеп ташламасыннар үзеңне. Урыс эчсә, үгездәй ул, күзенә ак-кара күренми.

— Безнең кебек үк халык! Ким дә, артык та түгел.

— Дөрес, алар да кеше. Әйбәт, ачык, гади кешеләр.

Өелеп өйдән чыктылар. Толяның әтисе күзләрен алартып аларга карады.

— Әй, ристан татар, кәләшне урларга килдеңме? — Үзенең күзләре көлә. Үзе ачулы.

— Ул — минем сөйгәнем.

— Булгандыр. Хәзер безнеке.

— Ул һәрвакыт минеке.

— Әллә ул синең төрмәдән котылуыңны көтеп торырмы?

— Мин чыктым инде.

— Ничек?

— Гаебем табылмагач, чыгардылар.

— Кызың үзе риза булгач, без дә гаепле түгел ич.

— Ә мин берәүне дә гаепләмим.

— Шулай икән, алла хакына үтенәм: бер чәркә күтәр дә, киленебезне калдырып, юлыңда бул.

Шулвакыт капка төбенә атлар килеп туктады. Канәфи күрде: арбадан абыйсы Димәкки Мансур, Кара Мәлик, иптәше Карун Талип, Усал Баттал һәм тагы әллә кемнәр атларга төялеп килгәннәр. Кадыйр да бар араларында. Ул, килүгә үк, арбадан төшеп, апасына сыенды.

Урыслар калдылар, татарлар киттеләр.

Юлда Мансур абыйсы әйтте:
— Ильяс карт куды безне. «Барыгыз, берүзе китте Катифә артыннан,— ди.— Кыйнап ташламасыннар,— ди, димәкки... Бүген үк туй уздырабыз.

* * *

Күбәләк жил...
Юл буйлап өчәү килә. Канәфи, Катифә һәм Актай — жыр тыңлаучы ат.
Теге моңлы көй сузыла. Әмма анда күбрәк шатлык яңгырый:

Күнеле ефәк булгачтын, башкасы кирәк түгел.
Катифәмнең, бәгыремнең, күлмәге ефәк түгел.

Мансур абыйсы әйткәнчә, туй уздыралар, никах, кияү мунчасын да күрә Канәфи белән Катифә. Хәернисаның баш өянәге бетеп китә. Маһруй елаудан туктый. Канәфи су анасын оныта. Аның урынына сафлыгын аңа саклаган гүзәл кыз — фәрештәне күрә ул. Бары бер генә нәрсә ана көенеч китерә, Ильяс карт камытлар өеннән юкка чыга. Эзлиләр-эзлиләр, таба алмыйлар. Менә монысы хик-мә-әт. Әкәмәт бу!
Кая киткән ул карт? Кайсы дөньяларга? «Кояш чыгышы — жан өчен, кояш батышы — тән өчен»,— дигән иде бит. Тагын: «Кеше ямьсезлеге белән дә матур!» — диде. Моны ничек аңларга? Нәрсә әйтергә теләде ул бу сүзләр белән? Канәфи әнә шуны сорарга теләгән иде һәм аннан соң Катифәгә сөйләргә. Башкаларга сөйләргә. Булмады. Их! Тагын нидер комачау итте...

# ШИГЪРИЯТ



## Кави Латыйп

### КАРТ СОЛДАТ УЙЛАРЫ

* * *

Ярты гасырдан соң,
сугыш кырында билгесез югалган
солдат әтиемне төшемдә күрдем.
Үзем һәм әнием хакында
сөйләп бирдем:
«Әни вафат, оҗмахтадыр...
Ә мин исәнмен,
яшәвем тормыш дигән тәмугта»,— дидем.

Әтием әйтте: «Син шунда яшәгәнгә,
билгесезлектән үзеңә ярдәмгә килдем,
синең өчен бик тә хафаланам,
син бит минем иң яраткан балам,
теләсәң, бергә,
син тормыш дигән тәмугта калам,
йә — үзеңне яныма,
билгесезлеккә алам...»

* * *

Җәлилчеләр, үләр алдыннан,
үпкәннәр Коръән.

Башларын палач чапканда,
Тәңре, бәлки, сискәнеп киткән:
эшафотта дип үзен хис иткән.

---

Кави ЛАТЫЙП (1927)—*фронтовик-шагыйрь, күпсанлы шигырь, проза китаплары авторы; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Чувашстанның И. Яковлев исемендәге бүләк лауреаты.*

Уникесеннән дә:
«Без — Иделдән,
без — татарлар — бер җан, бер тән», —
дигәнне ишеткән.

Шаһит — изге Коръән.

* * *

Көн-төн исә Вакыт җиле,
«ташлар җыяр чак» килде...
Таш саныйм берәм-берәм,
кемлегемне күрәм, беләм.
Үз алдымда җавап бирәм.
Ташлар саныйм бармак бөгә-бөгә,
күз яшьләре түгә-түгә.

Сугышта башлар санадым,
ә яшьләр коелмады.

Анда ташлар елады...

## Бер сәдака...

Бер сәдака —
дүрт солдатка...
Дүртесе дә мөселман,
дүртесе дә кардәш-туган.

Дүртәүләшеп бер рота дошманга
каршы торган, —
пулеметтан атып, «кырган».

Дүртесе дә минем полкташ.
Баш түрләрендә таш.

Бер сәдака
дүрт солдатка —
корбан алар Карпатта.

Син дә сәдака бир:
бер сәдака —
йөз игелеклелек белән
үзеңә кире әйләнеп кайта.

Җиңү көне —
бир сәдака!

## Таш солдат турында баллада

...Сөйли каен, көйли каен
батыр егет турында:

Чиктә тора таш бер һәйкәл
автоматы кулында...
Каен жырын тирә-якка
таң җилләрс тарата.
Таш булса да солдат егет
җыр тыңларга ярата.
Батыр егет — авылдашым,
онытылмас полкташым.
Таш солдатның күкрәгенә
ак каен куя башын...

* * *

Яшьлегемне эзләп килдем,
Карпат тауларына мендем.
Биеклектә калучы яудашларның
каберләрен күрдем.

Алар тапкан — яшьлек биеклеген,
яшьлек бөеклеген
канлы көрәштә...

Яшьлектән картлыгым көнләшә!

* * *

Утырамын күлгә карап
яшел чирәм өстендә.
Мондый хәлне
күргән идем төшемдә...
Бусы инде өнемдә:
Җиңү көне. Тирә-як тын.
Туган җиремә кайттым.
Күңелемне юаттым.

Туган җирне бер күрү —
мең алтын!..

## Үлеп тә...

Яши ул күңелемдә,
сөйлимен үлүен үзенә:
кышкы буранда фронтта аны
бер үзем күмгәнне,
ул төнне йолдызлар сүнгәнне.

Аны мин күмдем,
ул мине күммәде,
аны мин күрдем,
ул мине күрмәде.
Үлеп тә,
үлүен белмәде...

* * *

Гел әйтәсең: «Борчылма!»
Юк, борчылам.
Борчыла-борчыла,
теләгемә ирешәм —
аның очына чыгам.

Борчылмый гына яшәү
килешми мин-картка.

Бүтән идем яшь чакта...

* * *

Күптән таныш бер торнаны юксынуым булды,
ул кинәттән кайдандыр килеп чыкты да,
канатларын җилпи-җилпи,
минем баш өстендә әйләнә башлады.
Әллә ул үзен исән дип әйтте,
әйләнде, әйләнде дә,
күздән югалды.
Кайларга юл алды?..

Инанам, ул тагын килеп чыгачак.
Мин аны юксынган шикелле
ул да мине юксыначак...

## Күзләремне бәйләп

Күңел кыйблам белән
дөрес юнәлеш табам.
Нинди генә хәлдә калсам да,
карыйм туган якка табан:
анда минем үз кояшым,
үз әнкәм.
Анда минем үз оҗмахым,
үз Мәккәм.

Күзләремне бәйләп, сорасыннар:
кыйбла якны —
туган якны күрсәтәм.

Гомер итсәм дә еракта,
күңелем шыткан — туган туфракта.



# Салават Рәхмәтулла

## Бураннар

Кыш — бураннар чагы...
Бүген тагы
Дворниклар таңнан торганнар:
Кала урамнарын көртләр баскан —
Төне буе шашкан бураннар...

Каладагы буран — буранмыни?
Авылдагы буран — бурандыр.
...Мин яшәгән йортка салган карны
Хәзер кемнәр көри торгандыр...

Шунда — тудым.
Тордым.
Оя кордым.
Чәчтем-урдым.
Ауса — тердәдем.
Бишмәтемне читәннәргә элеп,
Таңнар саен карлар көрәдем.

...Ничә еллар мин калада хәзер
(Кабул булды хатын теләгән!..):
Җәй үтеп — бер чалгы селтәгән юк,
Кыш үтеп — юк карлар көрәгән...

Кала урамнарын көртләр баскан —
Дворниклар таңнан торганнар.
Калаларда буран — буранмыни?
Авылда ул иң чын бураннар...

Авылым да таңнан уянгандыр
(Авылда бит һаман йөрәгем...)
Затлы шәһәр тунын салып ташлап,
Тротуардан карлар көрәдем...

* * *

*«Мин үзем дә мәңгә фатирсыз...»*
Ә. Атнабаев.

Әллә кемнәр кулы белән
Дөнья

Әллә ничек ясап куелган.—
Мин дигәнчә түгел!..
Иртәрәкме?
Соңга калып микән туылган?..

Һәм булмас та хәзер «мин дигәнчә» —
Ник кубарга зурдан... ерактан?!.
Фатирларда кемнәр яши икән?! —
Бүлмәм дә юк... тулай торактан.

Берчак миңа өч аршын җир җитәр
(Нигә ул чак мәрмәр пьедестал?!):
Кирәкләрдән кирәкләре бүген —
Бер утыргыч белән бер өстәл.

Ут-шигырьләр язасылар килә
(Язганнарны килә ертасы!):
Шагыйрьләргә дөнья кайда да — бер,
Кайда да — бер: утның уртасы!..

Шагыйрь булып, шагыйрь күңелләре
Ирешалмый торган хәл илдә...
«Тик шагыйрьгә... каләм бирегез!» — дип,
Алман,
Синең концлагерьларда
Тилмергәндер Муса Җәлил дә...

Җаннарымны кыеп-кыеп уза
Явызлыклар кылган бар эшләр...
Йөрәгемне тотып,
Кагыла-сугыла,
Бу дөньядан узып барышлар.

...Әллә кемнәр кулы белән
Дөнья
Әллә ничек ясап куелган:
Иртәрәкме?
Вакытында микән?
Соңга калып микән туылган?!.

Җырлый-җырлый узып барышларым,
Ярылса да йөрәк,— белдермәм:
Кояшым һәм аем — янар шәмнәр,
Күк гөмбәзем — түбәм,
Җир — бүлмәм...

## Кошлар

Канатлылар — биекләрдә,
Күкләрдә, болытларда...
Тилмереп карыйм кошларга
Тилмергән минутларда.

Алар — кошлар шул! —
Карамый

Бураннар-карларына,
Теләгән чакта очалар
Теләгән якларына...

Эх...
Ярты гына көнгә синең
Янында булып кына,
Килер идем...
Ниләр итим,
Ниләр соң кылып кына...

«Кошларым,— дип,
Берчә — авыр,
Берчә җиңел суладым,—
Гомер буе сез — канатлы
Дусларым!» — дип уйладым.

Һавалар ярып кычкырдым:
«Ичмасам, берегез,— дип,—
Ярты гына көнгә миңа
Канатлар бирегез!» — дип.

«Ярты гына көнгә...» — дидем,
Мең тапкыр кабатладым...
Ярты минутка да кошлар
Бирмәде канатларын...

* * *

«Язмышлардан узмышлар бар!» — диеп
Кемнәр (нигә?) башлар бутаган? —
Атлап киләм гомерем юлларыннан:
Берәү дә юк — сиңа охшаган...

Язмышлардан узмышлар — юк, булмый:
Язган — булган, югы — тимәгән.
«Табыштырам» гына дигән язмыш
«Кавыштырам сезне» димәгән...





## Әсрар Гали

# НӘНИ ХИКӘЯЛӘР

### Таныды

Гөлфия әти-әнисенең олы кызы иде. Хәер, алай бүлеп тормасаң да була. Нибары ике кыз бала иде алар гаиләдә. Гөлфия үтә чибәр. Шомырт кара бөдрә чәчле. Шул чәч толгәшләре учлам-учлам аерылып тора. Нәкъ чәчәк бәйләме. Озын керфекләр, диңгез кеби чем-кара зур күзләр тирәнтен карый. Түгәрәк каратут йөз. Ак матур — чак матур, кара матур — бик матур, диюләре шулдыр инде. «Бишле» билгеләренә генә укыды кыз. Инглиз телендә саф инглизчә сөйләшә иде. Татар, урыс телләрен әйтәсе дә юк! Уфа университетын тәмамлады. Кияүгә чыкты. Ике бала биләде. Икесе дә малайлар. Кияве дә үзенә охшаган, университетта бергә укыдылар. Бик бәхетле буласылар иде...

Тик... икенче баладан соң Гөлфия аяксыз калды. Өй эчендә дә стенага тотынып кына йөри иде. Ике ел шулай азапланды ул. Күренмәгән табиб, йөрмәгән им-томчы калмады. Файдасы тимәде. Чаллыда япон аппараты белән карадылар аны. Баш миендә «трамбоз», имеш. Ягъни, кан юлы бикләнгән. Бер дә теләмәсә дә, операциягә риза булды Гөлфия. Аның бит әле кечкенә улларын бер туйганчы сөя алганы да юк. Олысы алтынчы сыйныфта укыса, бусына ни бары ике яшь кенә. Үлеп китсәң?! Ятим калсалар?! Бу ятим кош балаларын кем карар...

Операцияне Казан шифаханәсендә ясадылар. Реанимациядән соң палатага күчергәч, бер тапкыр күзен ачты Гөлфия. Янында әнкәсе иде.

— Әти килмәдеме?.. — диде Гөлфия. — Әлфия килдеме?

Бу аның соңлесен соравы иде.

— Балаларымны алып килделәрме?! Ирем...

Бу аның якты дөньяга соңгы карашы иде.

Гөлфияне Лениногорскига алып кайтып жирләделәр. Утыз өч яшь туларга бер көн калган иде. Бөтен дөнья караңгыга күмелде...

Яшь малай бик кечкенә, анасын тиз онытыр, дип уйладылар. Бала бик күңелсез яшәде...

Елы житте Гөлфиянең. Бу көнне кече малай бик иртә йокысыннан уянды. Йөгереп почмакка кереп китте. Түр тәрәзәсенә йөгереп килде. Диван, карават асларын карады. Үзе дәшмәде. Үз юрганын кат-кат ачып карагач, ирексездән илереп, өзгәләнеп елап жибәрде.

— Әнием кая?.. Китерегез әниемне... Әле бергә идек... Кая иттегез әнине?..

Төшендә күргән имеш, бичара. Үз әнкәсен таныган. Менә син аны өч яшьлек кенә кечкенә малай диген...

---

Әсрар Гали (1938) — *язучы. «Төнге жыр», «Асыл кошым минем», «Көн яктысы» һ. б. китаплар авторы. Лениногорскида яши.*

Әсләмнең хәтере яшьләй әйбәт иде. Әдәби китапларны су урынына эчә. Таныш булмаган шигырь текстын көйләп, җырлый-җырлый укыр иде. Чәчмә әсәрләрне битен-биткә күз йөгертеп кенә барыр иде. Университетта укыганда исә, имтихан барышында тәүлегенә өч йөз иллешәр бит укырга өлгерер иде. Ничек тиз укыса, шундый ук тизлектә сөйләп тә бирер. Башка кешеләрне дә ул үзе кебек укыйлар дип уйлый, шуңа ышанып яши иде. Үзе сукырайгач кына белде: күпләр берни укымый икән. «Күрмим бит, күзлегем юк»,— дип кенә җавап кайтаралар.

Аның матур коңгырт күзләре карап торышка хәзер дә матур. Алар тере. Күрәләр шикелле. Ул элек, күрше-күлән, таныш-белешне биш йөз метрдан күреп, елмаеп-көлеп бара, исәнләшә, кул биреп күрешә иде. Сукырайгач, урамга чыккан саен, аның белән исәнләшүчеләр бермә-бер кимеде. Кая соң, әллә үлеп беттеләрме аның дуслары?! Аннары гына төшенде: үзләренә Әсләм кирәк чакта гына дус булып йөргән икән алар...

Әсләмнең исәнләшми китүенә хатын-кыз халкы үпкәләп үк йөри башлады. Нишләсен күрмәгәч! Шәһәр урамында узган бер кешегә: «Исәнмесез!»— дип йөреп булмый ич. Тиле бу диярләр.

— Алла, Әсләм абый исәнләшмәде дә,— дигән әнә Әсләмнең хатынына бүген дә бер кыз үпкәләп,— тәкәббер атлап, башын өскә чөеп, узды да китте. Эреләнгән. Эре бәрәңге ашаган, ахры...

— Күрми бит ул! — дигән Әсләм хатыны.

— Күзләре бик матур. Күрә...

Бу кызны кайчандыр Әсләм мәктәптә үзе укыткан иде. «Исәнмесез!» — дип ул чибәр үзе исәнләшсә, аның теленә төер чыгар иде микәнни?

Шифаханәдән кайткач, урамга чыгып йөрергә өйрәнгәндә, Әсләм еш кына кешеләрдән вакытны сорый иде.

— Сәгатем юк. Белмим...

Сәгате булмаган кешене гаепләмибез, әлбәттә.

Әсләм кул сәгатен тагып чыга торган булды.

Бераз йөргәч, узучыны туктата да сорый:

— Минем сәгатьне кара әле, вакыт күпме икән?

Ашыгып узучы сәгатькә күз төшерә дә, юри сорый, дип, көлеп, узып китә. Кайберәүләр:

— Үзең кара!

— Сукыр мәллә?

— Сәгатең кулыңда,— диләр, сорауга җавап та бирмичә. Кайсылары, чыннан да, күрмиләр.

Әсләмнең күзләре күргәндә, һәр кешедә сәгать бар кебек иде, алар һәрберсе күрә шикелле иде.

Табип язган язуларны, почта бүлеге язуларын, хет егылып үл шунда, үтүчесүтүче бирәү дә танымый. Әсләм дистә еллар редакцияләрдә эшләп, теләсә нинди язманы таный иде. Ике хәрефен таныса, калганын үзе куша, сүз ясый иде. Җөмләдә ике сүзне таныса, җөмләне үзе төзеде. Фикерне туплап, нәтиҗәне үзе ясады. Күпчелек мәкаләне гәҗиттә басарлык итеп, төзәтеп яза иде. Әллә, чыннан да, бездәге халык надан микән?!

Автовокзал кассиры сукырлар таныклыгын карап билет бирер, ялынып сорасаң да урыныңны әйтмәс. Юлаучы исә өстеңә дә борылып карамый...

Кибетләргә йөрүне әйтәсе дә юк.

Ипи кибетенә кереп, кибетче кулына бер үч тимер акча сала иде Әсләм. Ул чорда әле, ипинең уналты тиен чагы. Кибетче санап тормый, чалдыр-чолдыр итеп ул акчаларны чәшкә тәрилкәсенә сала. Әсләмгә бер бөтен ипи тоттыра.

— Кайтарып бирмисеңме?

— Мин тагын санап бирдең дип торам.

Әсләм ипи кибетенә хатыны санап биргән акча белән йөри башлады.

Бүген исә, бәяләр котырган чорда, азык-төлек кибетенә керерлек тә түгел. Кәнозын чират. Әйбер булса да, булмаса да. Синең инвалидлык кенәгәңә караучы да юк. Үлчәү тәлинкәсе янына чиратсыз якын да килмә!

Чираты житкәч, нишли инде Әсләм?

— Колбаса бармы? — ди ул.

— Әнә, витринада... Күрмәдеңме?

— Иң җүн бәялесе ничә сум?

— Язып куелган... Кара әнә!

Без сүз белән уңай җавап бирсә, эш бетә бит инде югыйсә.
— Мин күрмим бит,— ди Әсләм.
— Кү-рә-сең! Килгәнсең бит әле...
Аннары Әсләм, ирексездән, чираттагы күршесенә борыла.
— Арзанрак колбаса бәясен әйтегезче, ханым?
— Күзең маңгаеңда. Борыл да кара...
Мондый җаваплардан соң, Әсләм буш кул белән, ачынып, кибеттән чыгып китә.
Юк! Әсләмнең күзләре күрмәве авырудан гына. Гамьсез кешеләр сукырлыгы каян килә? Бу — зыянлы сукырлык... Дөнья матурлыгына шулар күләгә төшерә.

## Ак кара буталган...

Бүре Сабир токымына туган тиешле берәүләргә Җамалия кодагый булды. Җамалия үзе дә ике кыз, бер малай үстергән иде. Татар-урыс авылы булган, катнаш авылда яшиләр иде алар. Өч баласының берсенә: «Өйдә урысча сөйләшмәгез!» — дип әйтә белмәде Җамалия. Киресенчә, ул балаларының үз ана телен белмичә, иң беренче чиратта, татар телен балаларга үз анасы өйрәтергә тиешлеген аңламыйча, урысча сөйләшүләренә мактана иде. Унны урысча бетерде балалар.
Кызлар үсеп җитте. Икесе дә урыска кияүгә чыктылар. Төпчек малайлары гына Бүре Сабир токымыннан булган татар кызына өйләнде.
Ике кызның да бәбиләре туды. Берсенә — Егор, икенчесенә — Степан куштылар.
— Урыс балаларын карау рәхәтме? — диде Бүре Сабир, кодагыйлары Җамалиягә төрттереп.
Бусы «эһ» тә итмәде, җавабы әзер иде.
— Үз балаларымны яраткач, яратам оныкларымны,— диде Җамалия, бер дә эче пошмыйча. Моның белән ул акны карадан аермавын күрсәтте.
Бүре Сабир аңа:
— Татар оныкларың булса, ышаныр идем әле...— генә диде. Башка сүз куертмады. Ана сөте белән кермәгәнгә, тана сөте белән барыбер кермәс иде.

Җамалия улының татар килененнән баласы туды.
Бүре Сабир янә Җамалиягә төрттереп:
— Бусы, урыс балаларын сөю түгел инде, ә, Җамалия кодагый,— диде.
— Бары да бер,— диде Җамалия кодагый.— Үзеңнеке — үзәктә икән ул.
Бүре Сабир үзенә генә хас яңгыравык тавыш белән ачы итеп кычкырып көлде. Аннары әйтте:
— Сиңа, Җамалия кодагый,— диде борчылып, күгәреп китеп,— әлкаш ирләр шикелле икән. Булса ярый — булмаса ярый, диясе урында, алар булса ярый, булса ярый, дип кабатлыйлар. Эчәргә аракы гына булсын, янәсе. Башлары эшләми... Шулар кебек син: ак та ярый, кара да ярый сиңа! Кешене бит алай үстермиләр. Үз туган теленне яраттырып, ата-баба гореф-гадәтенә тугры калырлык һәм үз Ватаның өчен утка керерлек итеп чыныктырып үстерәләр. Ә син алай да, болай да ярый... Синең бу килешүең — керәшен маржасы кебек бер кирелегең генә. Кодагый димәсәм, хәтерең калыр.
Әйе, Бүре Сабир әйтә белде. Чөнки, Җамалия кодагый ишеләр, татарлар арасында манкортлык шаукымының башлангычы алар.

## Бәгырьсез

Әсләмнең бакча күршесе Мәүлет бик уңган кеше иде. Аксылга тартым соры чәчле. Ябык йөз. Буйчан. Чандыр гәүдә. Ачык йөз. Күк гөмбәзедәй зәңгәр күзләр. Бу якты дөньяны сөеп туя алмастай итеп тормышны ярата. Күрше-тирә биш сутый бакчаны ун көн тырышып очына чыга алмаса, Мәүлет бер үзе шундый бакчаны өч көндә эшен бетерә иде. Аның алмагачы, карлыган, кура җиләге, помидор, кыяр, яшелчәләр бик белеп утыртылган. Күп эш көче дә сорамый. Аның бәрәңгесе яңгырсыз елны да уңа. Шулар өстенә Мәүлет бакчада утыз баш умарта тота.

Казан университетының биология бүлеген бетергән егет бу. Умартачылыкка да атасыннан, яшьләй өйрәнгән. Аның, бакчадагы умарталарын карарга хәтта Мәскәү профессорлары килә иде. Бүлеп-бүлеп ясалган тоташ оялар бу. Җәен дә, кышын да картлар шул урында яшиләр. Күп бал суырта Мәүлет. Бакчада бер дигән такта куыш булса да, умартачылык буенча кышларын кандидатлык диссертациясе язар өчен, Мәүлет бакчага тагын дүрткә-дүрт метр итеп, тау ташыннан тәбәнәк кенә өй салды. Ял көннәрендә иртәнге сәгать өчтән төнге унбергәчә шул умарталар яныннан китми иде. Хатыны Нәгыймә дә, өч баласы да бакчада җәенә ике-өч кенә күренеп китә иделәр.

Мәүлет кинәттән авырды. Башына сукканнар. Иртәнгә чаклы кар өстендә яткан. Аңа икенче группа инвалидлык бирделәр. Ике җәй эчендә Мәүлетнең умарта ояларын сатып бетерде Нәгыймә.

— Тере мәет...

— Бакчага килми...

— Берни эшләми. Аннары төн буе йокламый,— дип Мәүлетне битәрли иде Нәгыймә.

— Йоклый алмагач нишләсен ул,— дип, дусты Мәүлетне яклый иде Әсләм.— Эшләрлек хәле булса, өйдә ябылып тик ята торган кешеме соң Мәүлет...

Бу җәйне Нәгыймә үзенең яшьлек мәхәббәте булган, өч бала үстергән үз ирен, Мәүлетне врачлар аша инвалидлар йортына озаттырды. Үзе озата да бармады ирен.

Тагын җәйләр үтте.

Ни балалары, ни Нәгыймә, аталарының барып хәлен белмәделәр. Бу хәлләргә Әсләмнең бәгыре киселә иде.

Институттан каникулга кайткан Мәүлетнең улына әйтте бер:

— Син башта барып әтиеңнең хәлен белеш,— диде.— Аннары бакчага төшеп эшләрсең. Бакчаң качмас. Кем белә: үзең белән дә шундый бәхетсезлек туса?! Сине хатының ташласа?! Сөенерсеңме? Авыру дигәнен кешедән сорап йөрми ул.

Мәүлетнең кызларына да шул ук сүзне әйтте Әсләм.

Бу җәйдә Нәгыймәне бакчада (үзенә калгач, ул хәзер бакчага килгәләп йөри иде) күргән саен шул ук сүзләрне кабатлады Әсләм:

— Бар, күреп кайт, ничек яши икән Мәүлетҗан...

— Үз иреңне шулай онытырга, оятың бармы синең? Ир бирмәк — җан бирмәк ди торган иде минем әни...

— Киленең шундый булса?! Сине тәрбияләмәсә?! Кызларың шулай бәгырьсез булса? Ирләрен ташласалар? Рәхәт булырмы сиңа...

Мондый сүзләрне янә дә ишетмәс өчен, Нәгыймә үз күршесе Әсләмгә күренмәскә тырышып йөри иде.

Бер көнне шулай да барды Нәгыймә ире янына.

Мәүлетне танымады. Ире аны кочып алса да, танымады. Мәүлет артык ябык иде. Тире белән сөяк кенә. Өрсәң дә егылачак. Җаны чыгарга тора. Өч тапкыр ашаталар, ди. Бәяләр котырып күтәрелгән еллар бу. Авыруларны әле дә бөтенләй онытып бетермиләр диген. Дөресе, өч тапкыр кәбестә шулпасы бирәләр. Пыяла юкалыгы ипи телеме. Кырыеннан тотсаң, өзелеп төшә. Ашыгаашыга кабып өлгерсәң, ике кабышлы. Ир кешегә түгел, мәчегә дә житми бу.

Мәүлет кат-кат хатынын үпте, кулларын аның иненнән бер дә җибәрмәде. Сагынган, бичара. Нәгыймәнең үзен ташлавына үпкә дә белдермәде.

— Олы кыз ни хәлдә?

— Кечесе...

— Малай ничек укый?

Йотлыгып-йотлыгып тыңлады. Ата кеше үз гаиләсен бик сагынган иде.

— Монда бит мәетне табут белән күмәләр, Нәгыймә,— диде.— Хәзер такта бик кыйммәт. Табып та булмыйдыр. Эзләмә! Үзләре күмәрләр әле. Булган акчаны балаларга тот. Ач яшәмәгез...

Ата кешенең хәсрәте үзе турында түгел, һаман да гаиләсе хакында иде.

Авыру Мәүлет хатынының күзләренә тилмереп-тилмереп карады: «Әйдә, сине алырга килдем, Мәүлет! дип әйтмәс микән?! Әй, шулай дисә иде...» Хатыны гамьсез. Хатынының чыраенда бу уйның әсәре дә юк иде.

Кешеләр киләләр дә, авыру кардәшләре янында көннәр буе утырып, сөйләшеп китәләр. Нәгыймә ярты сәгать тә түзә алмыйча, тизрәк урыныннан торды.

Мәүлет аны, күзләре талганчы, артыннан карап калды. Бәлки, соңгы күрүедер...

Олы юл өстендәге машинада, үзен озата килгән машина хуҗасы, сөяркәсе көтә иде Нәгыймәне...

# БАЙРАКЧЫ ГАЗИ ЗАҺИТОВ



**Рәсемдә:** *фашистларның төп оясы — рейхстаг өстенә беренче булып Кызыл Байрак кадаган Гази Заһитов (уңда) үзенең сугышчан дусты Александр Лисименко белән (Берлин. Рейхстаг. 1945 елның 1 мае).*

Безгә үткән тарихыбызны белергә, батырларыбызны кадерләргә, фидакарь җаннарның якты исемнәрен мәңгеләштерергә бик тә вакыт! Бөек Ватан сугышында дошманны җиңүебезнең 50 еллыгын билгеләп үткән бу көннәрдә без, урыс Михаил Егоров белән грузин Мелитон Кантариядән алда, 1945 елның 30 апрелендә төнге сәгать унберенче яртыда, рейхстаг түбәсенә иң беренче булып 79 нчы укчы корпус Байрагын менгезеп кадаган татар егете, өлкән сержант Гази Заһитовның исемен аеруча горурланып, бинеһая олылап искә алырга бурычлыбыз...

...В. Высоцкийның «Международное отношение» нәшриятында 1975 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Мероприятие «Терминал». Потсдам, 1945» дигән гаҗәеп кызыклы, чын хакыйкатьле сурәтләгән китабында каһарман милләттәшебезнең (тумышы белән ул Башкортстанның Мишкә районындагы Яңакош авылыннан), аның сугышчан дусларының тиңдәшсез батырлыгы турында мондый юллар бар:

*«...Бинаның һәр метры өчен сугыш башланды. Сугышчылар Г. Заһитов, А. Лисименко һәм М. Минин рейхстаг түбәсенә беренче булып ыргылып чыктылар һәм анда Кызыл Байрак кададылар. 1945 елның 30 апрелендә кич соңгына, Бөек Ватан сугышының 1410 көне якынлашканда, 3 нче Удар Армиянең 756 нчы полкы разведчиклары М. Егоров һәм М. Кантария, автоматчылар булышлыгы астында, рейхстагның сферик гөмбәзенә Җиңү Байрагын менгезеп кададылар... Бу мизгел — Мәскәү вакыты белән 22 сәгать 50 минут була».*


Галиҗәнап Тарих, әнә шулай, Дөреслекне ярата, Хаклыкны яңарта!

Рейхстаг түбәсенә Байрак элгәндә, фашист ядрәсе Гази Заһитовның сул як күкрәген һәм партбилетын үтәдән-үтә тишеп уза. Әмма Батыр исән кала. Госпитальдә дәваланганнан соң ул, күп тә үтми, орден-медальләрен тагып, туган якларына әйләнеп кайта. Якташлары Газины авыл Советы башкарма комитеты рәисе итеп сайлыйлар. 1950 елда ул, Бөре шәһәрендә авыл хуҗалыгы белгечләре әзерләүче училищедә укып, киң профильле механизатор таныклыгы ала. Фрунзе исемендәге колхозның иң алдынгы тракторчы, комбайнчыларыннан санала Гази Казыйхан улы. Искиткеч тырыш, тыйнак, сабыр, аз сүзле бу ир-егеткә — ни аяныч! — Җиңү тәмен тоеп, озак яшәргә насыйп булмаган икән — 1953 елның 23 августында ул, авыл хуҗалыгы машиналары өчен запас частьләр алырга барганда, төнлә автомобиль һәлакәтенә очрап, фаҗигале төстә гомере өзелә. Нибары 32 яшендә...

Рейхстагка Байрак кадаганы өчен Гази Заһитов һәм аның сугышчан дуслары — капитан Владимир Маков, өлкән сержантлардан Александр Лисименко, Алексей Бобров, сержант Михаил Минин Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә тәкъдим ителсәләр дә, бу эш ахыргача үтәлми кала. Фронтовик дуслары, көрәштәшләре һәм безнең милләтпәрвәрләр хәзер, Җиңүнең ярты гасырлык юбилее уңаеннан, шул Гаделлекне торгызу өчен көрәшәләр: «Гази Заһитов — Герой исеменә тулысынча лаек!» Бу хакта заманында «Правда» газетасында Советлар Союзы Маршалы В. И. Чуйков та язып чыккан иде инде...

«Гази» дигәннән, аның исеме үк тирән мәгънәгә ия. Гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, ул: «Хак юлда көрәшче», «Җиңүче батыр»,— дигәнне аңлата.

Әтисенең исеме «Казыйхан» гарәпчә «Хөкем итүче хаким», бабасының исеме «Заһит» исә «изге», «тыйнак» дигән мәгънәне аңлата... Кыскасы, Газинең нәселнәсәбенең нинди асыл сыйфатларга ия икәнлеген тулысынча ачып бирә хикмәтле бу сүзләр!



**Рәсемдә:** *рейхстагка Байрак кадау күренеше.*

**Мидхәт Шакирҗанов**
фоторепродукциясе.

Г. Заһитовның данлы исемен, олуг Батырлыгын-фидакарьлеген тиешенчә яктырту, һәркемнең күңел түренә җиткерү — туган җирендә һәйкәлен торгызу, музей-йортын ачу, рәсем-картиналарда, кинофильмнарда чагылдыру, повесть-романнар, шигырь-поэмалар, җырлар иҗат итү буенча да җиң сызганып, армыйталмый эшлисебез бар әле.

Бу өлкәдә, татар язучылары арасыннан иң беренче булып, үзенең төплесаллы сүзен әйткән һәм милләтебезнең чын мәгънәсендә йөзек кашы саналган Гази Казыйхан улы турында, Оборона министрлыгы Үзәк архивындагы тарихи гуаһнамәләрне (документларны) җентекләп өйрәнеп, «Мәңге сакларга!» дигән күләмле, дулкынландыргыч кыйсса тудырган әдибебез Шамил Рәкыйповның күркәм башлангычы — һәркайсыбызга яхшы үрнәк. Бергәләшеп, бу гаять мөһим, изге эшкә кичекмәстән тотынырга кирәк! Чөнки үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк. Төрле кыйтгаларга сибелеп яшәүче татар халкы үзенең кыю Байракчысын — Җиңү хәбәрчесе Гази Казыйхан улы Заһитовны — хәтереннән мәңге җуймаска тиеш! Юкса, безне килер буыннар, Тарих һич тә гафу итмәс...

**Шаһинур МОСТАФИН.**



Әмирхан Еники

# ФРОНТ ДӘФТӘРЕННӘН

## Кечкенә генә кереш

**«Фронт дәфтәрен»нән чүпләп алган кыска гына язмаларның бер өлеше 1994 елның маенда «Ватаным Татарстан» газитәсендә басылып чыккан иде инде. (В. Т. № 97, 20 май, 94 ел.) Быел минә бөек җиңүгә 50 ел тулу уңае белән шул ук дәфтәрдән кыска язмаларның калган өлешен дә өстәп матбугатка бирергә булдым. Ул язмалар көндәлек рәвешендә языла башлаган иде. Ротада писарь булып утырганда аен-числосын да күрсәтеп, язып бара алганмын... Караул хезмәтенә күчкәч, андый мөмкинлек бетте. Кайчан, кайда, ничек туры килсә шулай гына язып бара башлаганмын. Әйтергә кирәк, хәрәкәттәге армиянең гади солдатына ниндидер дәфтәр тоту, шуңа күргән-ишеткәннәрен язып бару бик читен һәм бик хәвефле эш иде. Ятлар кулына төшмәсен дип дәфтәрне дә инемдәге кыр сумкасында гына йөртергә туры килә иде. (Сержант дәрәҗәсендәге разводящий булгач, минем сумка асып йөрергә хакым бар иде.) Язганнарым, билгеле, бик чуар — күргәннәрем дә, кичергәннәрем дә бергә аралашып беткәннәр. Шуңа күрә мин, капчыкны төбеннән тотып селкмәс өчен, дәфтәргә язылганнарның төрлесеннән чүпләп кенә алырга булдым. (Алары да шактый ук җыелды.) Хөрмәтле укучы, әлбәттә, бер хакыйкатьне исендә тотарга тиеш: аңа тәкъдим ителгән бу кыска язмалар моннан 50—53 еллар элек авыр, газаплы, куркыныч фронт шартларында язылган иде. Хәзер исә мин шуларны иске дәфтәрдән ак кәгазьгә сүзгә-сүз күчереп кенә чыктым.**

**10 декабрь, 41 ел.**

Көн томанлы һәм җылымса... Йөрәктә җыр һәм сагыну...

Бу сугыш беренче дөнья сугышының дәвамы, һәм хәзерге һәлакәтнең башлыча гаепчесе Англия булырга тиеш... дип уйлыйм мин.

Минем белән хезмәт итүче Горбунов сөйли: без бит биш бертуган армиягә алынган идек. Берсе су асты көймәсе белән һәлак булды, икенчесе очучы иде — самолеты белән янды, өченчесе пехотада үлде. Янә иң кече сенелебез госпитальдә эшли иде, мәҗрух немец пычак белән кулына чәнечкән... Горбунов моны миңа елмайган чырай белән, кычкырып, бүлмәне яңгыратып сөйли. Гүя сүз күпме аракы эчә алу турында бара... Аңла кешене!.. Алдамаса?!

**11 декабрь, 41 ел.**

Күктә батмаган ай, моржалардан төтеннәр туры күтәрелә... Янә салкынайта.

Менә өченче көн инде йотлыгып газитә укыйбыз. Япония Америка һәм Англия өстенә ташланды. Әфәнделәр үзара килешә алмадылар: берсе сораганны икенчесе бирмәде, һәм океан сугышы башланды.

Күпләр бу яңа сугышның безнең өчен шактый зур киртә булуын әйтәләр... Ләкин һәркем диярлек Американың сугышка тартылуына эченнән куана: «үз

жилкәсендә татып карасын әле» диләр. Чыннан да, сугышмыйча гына сугышка катнашу зур оятсызлык булырга тиеш. Халык моны сизә.

**12 декабрь, 41 ел.**

Көнбатыштан җил исте... Түбәләрдән тамчы тама, кар басыла, өсте бик юка гына шадраланып ката... Юллар, сукмаклар каты, тайгак... Урман өстендә көзге томан.

...Бер генә илнең дә солдаты сугышның ни өчен кирәклеген, ни өчен сугышканын бер вакытта да белмәде һәм белми... Кан коюның чын сәбәпләрен халык бер вакытта да аңламый, чөнки бер кемнең дә вакытсыз үләсе килми... Халыкны сугыштырган нәрсә — власть, көчләү... һәм өндәү, үгетләү белән исертү...

Шекспирны укып маташам, ләкин авырлык белән... Ничектер безнең әдәбиятка хас ясалмалык аңарда бар кебек... 19 нчы гасырда бер генә бөек язучының да аңа ияреп маташканын хәтерләмим.

«Әй күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы...»

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Яшьлекнең ләззәтле сызлану яшьләренә манчылган беренче мәхәббәте хакында язасы килә... бик килә... Ә сугыш?!

**16 декабрь, 41 ел.**

Бүген ишелеп кар ява. Юлларда көрт, йөрүе авыр. Өй түбәләренә, агач ботакларына кабартылган мамыктай кар өелә... Көн шактый җылынды... Гаҗәп, һава көн саен үзгәреп тора.

Соңгы 3—4 көн эчендә фронтлардан күңелле хәбәрләр килә башлады. Егетләрдә күтәренке рух... Бу хәбәрләр белән чыккан сүз сиздермәстән һаман сугышның кайчан бетү мәсьәләсенә кайтып кала. Һәркем тизрәк бетүен тели, ләкин бик аз кеше генә тиз бетүенә ышана.

Гаҗәп, бу тирәләрдә гел урман булса да, кошлар бер дә күренмиләр. Тик ала каргалар гына юл буенда сикерә-сикерә йөриләр. Хәтта чыпчыклар да юк.

**18 декабрь.**

Нәкъ кичәге һава... Бер дә сугыш барлыгын хәтерләтә торган көн түгел.

Бу сугыштан беренче сабак: масаймау һәм чама белмичә мактанмау...

Бу сугышта җиңүнең әһәмияте Үктәбер революциясенең әһәмияте белән бәрабәр булачак. Шуңа күрә бу сугыштан җиңеп чыккан халыкның бик күп хакы булырга тиеш.

**20 декабрь.**

Кичә кичке 6 дан бүген кичке 6 га кадәр штабта дежур булып тордым. Бу үзенә күрә мәшәкатьле генә бер эш... Көннең нинди икәнен дә юньләп күрми калдым. Ләкин йомшак, матур кебек иде.

Штабка шактый картайган, ләкин чибәрлеген җуймаган бер хатын килде. Аның ире каты авыру икән, шуны күрергә килгән. Хатынының бәхете бар, күрәсең, бүген ирен каядыр икенче бер госпитальгә озатырга җыенган вакытта килеп өлгерде... Бичара хатын иртәдән алып кичкә кадәр иренең санчастьтән чыгарылганын көтеп, салкын коридорда утырды... Мин аңа кухнядан ике котелок белән аш һәм ботка китереп бирдем. Рәхмәт әйткәндә тавышы калтырап, күзеннән яшьләре тәгәрәп китте... Мин дә аның яныннан тизрәк китәргә ашыктым.

Сугыш вакытында үлемнән курку кайчагында салкын суга кереп, чиркану алу шикеллерәк булып тоела (чиркану алганнан соң курку кими дип тә өстисем калган икән).

**23 декабрь, 41 ел.**

...Юеш җил исә, ара-тирә түбәләрдән тамчылар ычкынып очып китә, кар җепшекләнеп басыла, йөргәндә кисәк-кисәк аякка ябыша... Нигәдер бик күңелсез...

...Ничәмә гасырлар буенча акыл ияләре кешелек, туганлык, гаделлек идеяләрен трибуналардан сөйләделәр, романнарда яздылар, шигырь белән җырладылар, киндергә буяу белән яздылар, музыкага салдылар... Һәм менә каяндыр бер явыз кеше килеп чыкты да, балалар уенчыгын тибеп очырган җинеллек белән ул идеяләрнең һәммәсен таптап, дөньяның астын-өскә китерде.

Идея — тормыш түгел, аның бер бизәге генә икән ул... Идеяне таптау — ачу килгәндә тоз савытын күтәреп бәрү белән бер икән.

Бу заманда идеяләргә кытлык юк. Теләсә нинди хәрәкәтне аклар өчен кешелек базарыннан яраклы идеяне табып була.

**24 декабрь.**

«Ян йөрәк, ян, кан бирелгән сина янарга».

Ә шулай да бу заман — бер-ике-өч идеянең монополия заманы... Идеяләр монополиясе тудырган бу сугыш та кешелек тарихында моңарчы күрелмәгән иң коточкыч, иң дәһшәтле бер сугыш... Ярминкә шикелле идеяләргә бай 19 гасырда мондый сугышның булуы мөмкин түгел иде.

Бүген үземә артык уйланмаска, йөрәкне сизмәскә, башкалар кебек солы боткасын тыныч кына ашарга һәм гырылдап йокларга сүз биргән булдым.

**27 декабрь.**

Бүген буран, суык мәрхәмәтсез буран... Җылы учак алдында куырган борчак ашап, әкият тыңлап утырган балачаклар кайда?!

Буран басылды, акрын гына караңгы төшә... Тынлык, моңсу тынлык... Кешеләр, кайда сезнең бәхетегез?..

**30 декабрь, 41 ел.**

Кичәдән бирле безнең полкка бик күп җәрәхәтле һәм өшегән кызылармеецлар киләләр... Йөзләрендә аларның һичбер нинди кайгы да, куаныч та юк кебек...

**Искәрмә:** 1941 елның декабрендә дәфтәргә язылганнардан чүпләп алынган кыска гына өзекләр хәзергә шуның белән тәмам. Бу өзекләр фронттан шактый еракта Кафтино дигән станция тирәсенә урнашкан 153 нче запас полкның штабында хезмәт иткәндә язылганнар иде. Күчерелгән кадәресендә дә минем шул чактагы уй-кичерешләрем күпмедер дәрәҗәдә чагылса кирәк...

Икенче искәрмә: 42 елның башыннан ук запас полкта чират көтеп ятучылардан хәрәкәттәге бер армия өчен аерым рота төзеп, тиз генә фронтка озаттылар. Мин дә шул ротада писарь булып китеп бардым. Моннан соң дәфтәргә язганнарның барысы да ротада хезмәт иткәндә күргән-кичергәннәрдән гыйбарәт. Билгеле, аларның да бик аз өлешен генә чүпләп күчерәм.

**6 гыйнвар, 42 ел.**

Бер атна вакыт яшен тизлеге белән үтте дә китте. Запас полк урнашкан, элек заманда алпавыт имениесе булган өч катлы, зур террасалы, манаралы һәм бай китапханәле йорттан ничек аерылганымны сизми дә калдым. Әйтерсең җил очырып алып китте... Кыска гына вакыт эчендә ике урынга күчү һәм яңа кешеләр белән очрашу... Кызганыч, язарга мөмкинлек юк.

Яңа ел туган булды... Ничек һәм нинди кәеф белән каршы алуымны яза алмый калдым. Тик гомеремдә беренче мәртәбә үткән елны кызгандым. Кирәсенчә, артыннан төкереп каласым килде... Барыбер гомер үтә инде, әйдә аның мәгънәсез, газаплы өлеше тизрәк, тизрәк үтә бирсен!

Дөньясын, сугышын онытып «Анна Каренина»ны укыйм. Иптәшләрдән уңайсыз, ләкин тыелырга һич тә әмәл юк.

**8 гыйнвар, 42 ел.**


Эш күп, тәртипсезлек тә җитәрлек... Хатлар язарга иде, һич бушап булмый... Яңа эш, яңа кешеләр, үзара талаш...

Гоголь, Толстой, Чехов, Горькийлар тәнкыйть иткән сыйфатлар урыс кешеләрендә бик нык саклана әле. Ул сыйфатлардан иң әшәке һәм көчлеләре — тупаслык, масаю... һәм унтер Пришибеевчылык... Күрәсең, яхшы белән яман сыйфатлар бик озак заманнар бергә килешеп яши алалар.

**11 гыйнвар, 42 ел.**

Аз гына эштән бушадым, һәм әрнеп эч поша башлады. Вак писарлык эше, талашу һәм сүгенүләр белән гасабиланып көн буена бәргәләнү вакытны үтерә, уйлар һәм дөнья хәлләре белән кызыксынулар югала... Бу кечкенә авылда яшәү — ташландык утрауда яшәү кебек... Бирегә килгәннән бирле бер газета күргән, бер сводка ишеткән юк... Берничә көн әүвәл станциядән кайткан егетләр безнекеләр Одессаны, Харьковны, Смоленскийны алганнар дип сөйләделәр. Башта ук күңел ышанып бетмәгән иде, чыннан да ялган хәбәр булды шикелле... Чөнки бу куанычлы хәбәрне егетләр бик тиз оныттылар.

Ә бу комсыз сугыш йотар әле, йотар!.. һәр иртә өмет белән уянган халыкның башын, таулар ишелгәндәй, яңадан-яңа һәлакәтләр белән исәңгерәтер әле...



*Көндәлекнең бер бите.*

**13 гыйнвар, 42 ел.**

Бүген янә алга таба китәбез... Чатнама, тешләргә тия торган суык... Алда нәрсә көтә — белгән юк.

**19 гыйнвар.**

Менә өченче көн инде дошман самолетлары һаман килеп «күчтәнәчләрен» ташлап, борчып торалар. Корбаннар аз гына булса да булгалап тора. Чын сугыш та юк, тынычлык та юк... Нервларга ходай чыдамлык бирсен. Тәрәзә янында торып китүем булды — бомба шартлавыннан бөтен өлгеләр чәчрәп төштеләр... Берничә секунд кузгалмыйча торсам, битем пыяла ватыгы белән тулган булыр иде.

**25 гыйнвар.**

Кичә һәм бүген җилекләргә үтә торган суык. Температура 40 тан түбән... Менә шул «корал» белән без шактый отып калырга тиешбез. Ә корал шулай да ике йөзле...

Немецлардан бушаган авылларда булдым... Кисәү исе көчле иде.

Мин торган йорт янына бомба төшеп, бөтен квартираларның бер таза жирен калдырмады. Ишелгән стеналар, каерылып ташланган ишек-тәрәзәләр, чәлпәрәмә килгән жиһазлар... Хәтта мичләрдә бүрек кадәр тишекләр... Берничә үлгән кеше һәм бик күп авыр яраланучылар... Әгәр шул чакта мин өйдә булган булсам?!.

**1 февраль 42 ел.**

Һәркемнең уенда бары бер сорау: кайчан бетәр икән? Һәркемнең күңелендә борчылып көтү: кайчан ул көн туар икән?.. Туасы яз — табигать язы гына түгел ул... Һәркем үз язын көтә... Табигать язы тумыйча калмаган кебек кешелек язы да тумыйча калмас.

**11 февраль.**

...Тын, кояшлы көн... Күк аяз, сыек зәңгәр... Түбәләрдән беренче тамчылар нурлар чагылдырып ак мамыктай күперенгән кар өстенә тамалар... Һавада яз сулышы... Йөрәктә озак яшәү, яңа бәхетләргә ирешү өмете... Мондый көнне сугыш та каты, үлем дә күп була гадәттә...

**17 февраль. Кыскартып күчерәм.**

Кичә кич белән безнең ротага пленга төшкән дүрт немец солдатын китергәннәр иде. Бүген шуларны кухняда күрдем. Ашап утыралар. Безнекеләр, 7 — 8 кеше, аларны чорнап алганнар һәм ашауларын зур игътибар белән карап торалар... Немецлар бик кызганыч кыяфәттә күренәләр. Дүртесе дә бик яшьләр. Өсләрендә юка, сәләмә шинель, башларында җәйге пилота, аякларында итек өстеннән кигән иләмсез зур каталар... Һәркайсының чәчләре житкән, йөзләре ак... Кулы мәжрух күзлеклесе бөтенләй бала кыяфәтендә... Ләкин алар безнекеләргә бик тыныч, бер дә шүрләмичә, ничектер ышанып карыйлар. Безнекеләр дә гадәтләре буенча сүгенмиләр дә, ачу да күрсәтмиләр, сүзсез генә карап торалар... Повар исә аларны көчле-көчле күбрәк ашарга кыстый... Немецларның берсе баш бармагын авызына куеп, әчесе килгәнен аңлатты. Бер иптәш котелок белән су китереп бирде... Бу күренешнең тәэсире кызык кына иде: гүя берниндә сугыш та, дошманнар да юк кебек... Чыннан да бу дүрт немецта аз гына булса да гаебен тою, оялу, вөждан газабы дигән нәрсә бар микән?..

**23 февраль, 42 ел.**

Кичә һәм бүген дошман самолетлары зур активлык күрсәттеләр. Корбаннар һаман булып тора.

Бүген безнең станциягә ташланган бомбадан 6 кеше үлеп, 13 кеше жәрәхәтләнде... Платформа өстендә торган бер тракторны әллә кая кадәр күтәреп ыргыткан.

**25 февраль.**

Якындагы станцияне дошман самолетлары бик каты бомбага тоттылар. Алар 4 мәртәбә безнең баш очыбызга әйләнеп килделәр. Һәр килүләрендә дистәләп ыргытылган бомба һәм пулеметтан сиптерү... Һәркемнең нервлары бик жигелде... Агарынган йөзләр, калтыранган иреннәр... Безнең бер иптәшне жәрәхәтләде, берәү һәлак булды.

...Дәһшәтле көн үткәннән соң, кич белән баракның зур, салкын бер бүлмәсендә тавышлы кино күрсәттеләр. Картина «Концерт-вальс» дип атала иде. Д. Ойстрахны, И. Козловскийны тыңладым, Лепешинскаяны күрдем. Балет «Аккош күле» иде. Картина миңа бик ошады. Тормыш иң вафасыз, иң кабахәт дәһшәтләрне дә гөлләр белән бизи белә...

Йотлыгып Сенкевичның «Без догмата»сын укыйм. Ифрат ошый. Мәгънәгә, хисләргә бай әсәр.

**7 март, 42 ел.**

Без яңа яңа урында. Бу инде дошманнан бушаган жир. Хәзергә тынычлык. Хәер, дошман без килгәнче үз эшен эшләп өлгергән инде...

Яз аеның беренче көннәре каты суыклар белән башланды.

**13 март.**

Бүген суык, буран. Яз килергә ашыкмый. Хәер, мондый һавадан зарлану юк. Киресенчә, һаман шулай булып торуын телиләр. Кичә аяз иде һәм дошман самолетлары безне яхшы ук «сыйлый» киттеләр. Бүген станция тирәсендә бик күп

ат гәүдәләре аунап ята. Бу мәхлуклар фронтта эшләп хәлсезләнгәч, авыргач ял өчен тылга кайтып баралар иде...

...Бушлык... Һич нәрсә турында уйлыйсы килми... Дөнья тарихының бөек көннәре?.. Ә иртәгә нәрсә буласы белән кызыксынырга ирендерә. Бу хәл күп кешеләрдә сизелә. Уйлау ничектер авыр йөк булып тоела башлады.

«Человеческая душа, точно пчела, которая ищет сладости даже на горьких цветах». (Г. Сенкевич. «Без догмата»).

**15 март, 42 ел.**

Кичә һәм бүген үткен пычак шикелле кисә торган җил... Бу җил тәнне генә түгел, йөрәкне дә өшетә кебек... Кичә дошман самолетлары өч тапкыр килеп, бомбага тотып киттеләр. Зарар һәм корбаннар шактый булды... Безнең бер иптәшнең бары аркасы гына торып калган иде. Башын эзләсәләр дә таба алмадылар.

Бүген бер иптәш үлекләрнең кесәләреннән вак-төяк әйберләрен җыеп алып кайтты. Кешенең кесәсеннән ниләр генә чыкмый: өеннән килгән хатлар, тузган бумажник белән акчасы, чүпрәккә төргән сабын кисәге, тәмәке янчыгы, берничә кара сохари, ниндидер каеш кисәкләре, кадаклар, атылган гильзалар... Нәрсәгә кирәк булгандыр алар бичарага?!

Кич белән сүз һаман сугышның кайчан бетүе турында булды.

**20 март, 42 ел.**

...Каяндыр шушындый хәбәр таралган: имеш, 22 мартта сугыш бетә икән... Кычкырып торган уйдырма булуына карамастан, бу хәбәр күпләрнең теленнән төшми... Күрәсең, күңелләренә якын ялганнан аерыласылары килми.

**21 март.**

Бүген иртәнге ашка дошман самолетлары килеп җиттеләр. Кызык хәл, каргалар, самолет тавышын ишетүгә көтүләре белән һавага күтәрелеп, кычкыра-кычкыра оча башлыйлар. Бичаралар, үлемнән алар да куркалар...

Үлгән вакытта кешенең уена бөтен үткәне һәм якыннары килә диләр. Белмим, ничектер... Ләкин туктаусыз үлем куркынычы астында йөргән кеше үткәнен дә онытa, киләчәге турында уйларга да иренә... Кеше ничектер үзендә авыр бер бушлык тоя, уйлыйм дисә дә, уйлый алмый... Еш кына аның йоклыйсы гына килә...

**25 март.**

Хәзергә тынычлык. Сугыш, үлем барлыгын акыл гына исендә тота.

**31 март.**

«Мечтам и годам нет возврата». (Пушкин.)

Кайчан башыма: кешелек дөньясының бөтен фаҗигасе кешеләрнең кыска гомерле булуларында түгелме икән дигән җүләр уй килә.

Мин күрәм: сугыш һәркемнең чын табигатенә каршы чиркандыргыч бер нәрсә... Бу, минемчә, бөтен дөнья, бөтен халыклар өчен дә шулай... Шул ук вакытта бөтен илләрнең халыклары җылап, сыкрап, сугышны нәләтли-нәләтли сугышалар... Йә, моңардан да зур фаҗига булырга мөмкинме?!.

**6 апрель, 42 ел.**

Язның сөенече аз. Көн аяз булган саен куркыныч шул хәтле көчлерәк... Зәңгәр күктән иңгән сөенеч, дәрт нурларына төренеп гүя үлем килә. Кичә безне иң әшәке рәвештә бомбага тоту булды.

Үлемне белмәгән кеше аңардан курыкмый, яки еш очраткан кеше аңарга ничектер иялəшә. Үлем белән очрашуның бик ансат булуын белгән, ләкин ияләнергә өлгермәгән кеше исә аңардан бик курка.

**9 апрель.**

Бүген сыерчыклар килделәр.

**11 апрель.**

Өч-дүрт көн тыныч кына торганнан соң бүген безне янә һавадан бик каты «сыйлап» киттеләр.

Аз гына томанлы, җылы, талгын көн иде... Бүрәнәләр өстендә ак кәҗә аякларын сузып йоклап ята... Бер өйдән патефон тавышы ишетелә. Тереклек —

таза үскән олы бер чәчәк ул... Үлем исә ара-тирә кинәт исеп куйган зәһәр җил... Җил чәчәкнең берәр яфрагын өзеп китсә дә, аны бервакытта да ега-сындыра алмый...

**13 апрель.**

Кояшлы тын иртә... Талпынып-талпынып сыерчыклар сайрыйлар. Юка боз астыннан чылтырап елгачыклар ага... Җир ашыкмыйча гына тирли, парлана.

Сугыш?.. Юк ул!.. Бу минутта һәркемдә бала йөрәге, ә бала йөрәге хәтәр барын белми, беләсе дә килми.

**16 апрель.**

Бүген мин үлемгә бик якын булдым, бомба миннән бер 15 метрда гына шартлады.

**24 апрель.**

Бүген дошман үзенең бомбасын без торган җиргә төбәп ыргытты. Бер бомба атлар сараеның почмагына эләкте. Хайваннар кычкырмыйча, сукранмыйча соңгы сулышларын алып яталар. Бер атның корсагы тишелеп, эченнән карта-эчәкләре чыгып, асылынып тора иде. Ат сарайдан үз аягы белән чыкты... Әкрен генә атлап китте, бераз баргач туктап, башын борып, актарылып чыккан эченә карап торды да, ашыкмыйча гына таза ягы белән җиргә ятты... Командир килеп, аның маңгаена атты һәм атыбыз «шулай кирәк» дигәндәй, тыныч кына җан бирде.

... Ат җигеп торган солдатның башын да, аякларын да таба алмадылар. Кесәсеннән күптән түгел генә төшкән фотосы чыкты... Хәзер ул миндә... Ничек кенә итеп мин аны гаиләсенә җибәрим икән?!

Нигъмәт исемле солдатка Башкортстанда яшәүче сеңлесе Шәрифәдән килгән хаттан бер өзек:

«Сезки сөекле дөньяда иң якын күргән кадерле абыем сиңа безки туганың Шәрифәдән күңелемнең иң нечкә җирләреннән парланып чыккан ялкынлы саф сәламемне җибәреп, алма бакчасында төрле матур гөлләргә кунып, тирән уйларга чумып сайраган сандугач-былбыллар санынча сагынып, саргаеп, абыем, синең нурлы йөзләреңне бер күрергә зар-интизарлар булып, өзелеп, күп сәламнәремне абыем сиңа бүләк итәм...»

Я, Хода! — нинди бәгырь өзгеч тирән сагышлар яткан кеше күңеленең төпкелләрендә! Бу хатны Нигъмәт абый түш кесәсендә догалы бер бөти итеп йөртәчәктер, мөгаен... Бәлки, әле аңа туган иленә исән-сау кайтырга да насыйп булгандыр... Һәр солдатның иң яшерен бердәнбер теләге шул иде бит!

**30 апрель, 42 ел.**

Кичә салкын иде... Бүген иртә белән кар яуды. Җир өсте янә ап-ак булды... Көн уртасына таба һава ачылды, кояш чыкты. Кар ашыга-ашыга эреде. Җир парлана, һава жылына — һәм язның куркынып агарган йөзе дә нурланып елмайган кебек булды...

Кәеф тә бүгенге һава кебек иде... Иртәгә бәйрәм дигән уйдан ул иске гадәт буенча куанып та карады, әрнүле сагышка да бирелде, өметләнеп, гамьсез дә булырга тырышты... Ләкин еракта гы хәрәкәтсез зәңгәр офык шикелле һаман да бер ялкау моңсулыкка төренеп кала бирде.

Кичке тынлык... Ә шулай да «Галиябану» бик матур көй...

**6 май.**

Беренче май көннәре үтеп китте... Яз артта калган кебек... Кичә көн буена зәһәр, суык җил исте... Бүген исә җир өсте тагын ап-ак кар... Әле дә һаман явып тора.

Кайберәүләр 4 — 5 көн буена баш күтәрмичә эчтеләр. Безнең старшина 4 көн буена кайда кунганын, наганын кайда югалтканын, кем белән сугышканын белмичә йөрде. Кансызлык, авызын ачкан саен сүгенү дә алдашу, урлашуны иң мактаулы егетлектән санау — менә аның чын йөзе... Аның ул «егетлекләрен» һәр кем белә, ләкин күпләр аңа каршы сүз әйтүдән саклана: «көчле белән көрәшмә!» янәсе. Әмма шул кабәхәтне көчле дип тану өчен никадәр түбән һәм куркак булырга кирәк.

Ә менә Чакмагыштан бер иптәшне рөхсәтсез 50 грамм аракы алып эчкән өчен 5 елга хөкем итеп, алгы сызыкка җибәрделәр... Гомумән, бездәге хаклыкны «аучының сарыгын кем ашаган?» мәсәлә белән бик яхшы аңлатып бирергә була.

**7 май, 42 ел.**

Менә икенче көн инде дошман самолетларының һавада күренгәннәре юк. Алар күренмәгәч, күпләргә сугыш та юк булып тоела башлый.

Безнең солдатлар арасында каяндыр төрле хәбәрләр дә тарала башлады инде, имеш, немецлар солых сорыйлар икән, май аенда сугыш һичшиксез бетәргә тиеш, безнең фронттан солдатларны өйләренә җибәрә дә башлаганнар, имеш... Мондый хәбәрләрнең көче шундый зур ки, кешеләр сүзләрен әйткәнче иң элек ирексездән бөтен битләре белән җәелеп елмаялар... Чыннан да, әгәр шуннан сугыш кинәт туктап куйса, кайберәүләр куанычларыннан акылдан шашырлар иде бугай.

...Язучы бер вакытта да искренно (татарчасын эзләп торырга вакыт юк) була алмый... Башына килгән берәр нәрсәне язарга утыру белән, әйтерсең, ниндидер бер күзгә күренмәс көч каләменең очыннан тотып ала да, язучының чын уйлары белән артык хисаплашмыйча, үзенчә йөртә дә башлый.

Кешенең тел байлыгы акыл байлыгыннан артта калып йөрми микән?.. Алай дисәң, Толстой бар, Ленин бар...

**10 май, 42 ел.**

Кичә без торган җирне иң әшәке рәвештә бомбага тоту булды. Бүген инде күпләр үзләренең моннан бер-ике көн элек кенә «сугыш бетә» дип балаларча куануларыннан оялып йөриләр.

Соңгы көннәрдә сугыш үзенең усал чыраен тагы да ачыграк күрсәтә башлады... Кай көннәрне һава һөҗүме безне бөтенләй җиргә кадаклап куя.

Бер бомба мин яшеренгән окоптан 2—3 метрда гына төшеп шартлады... Бәләкәе булгандыр, ахрысы...

**Искәрмә:** шушы урында бу «көндәлек» шактый озак вакыт өзелеп тора. (Фронтта бөтенләй дә өзелүе мөмкин ич!)... Бары дүрт айдан соң гына мин тагын язгалый башлаганмын. Фронтта сугышның тыныч торган чагы иде, без дә бөтен җәебезне Охват дигән зур гына күл буендагы кара урманда, караңгы землянкаларда эшсез ятып үткәрдек.

**24 август, 42 ел.**

Өч ай ярым вакыт кызу, ләкин сизелмичә аккан су шикелле үтте дә китте. Бу вакыт эчендә ниләр булды?.. Әгәр тыныч яткан күлдәге балыкларның аратирә генә чумып куюын хәтерләткән вак-төяк вакытларны бергә җыйсаң, шулар җәйнең бер озын көненә сыеп бетәр иде, мөгаен... Калган вакыт исә нәрсә белән тутырырга мөмкин булмаган ниндидер бер бушлыктан гыйбарәт. Әйләнә-тирәбездәге җанлы табигать тә бездән читтә кебек, без аны ничектер тоймыйча яшибез. Ара-тира тукранның агач чукыган тавышы, яисә берәр тиеннең ботаклар селкетеп бер агачтан икенче агачка сикерүе генә безне кайчагында барган җиребездән туктап калырга мәҗбүр итә, һәм без әйләнәбездәге шушы тере сулышлы, серле табигатькә яңа гына күргәндәй гаҗәпләнеп карыйбыз. Әмма бик тиз янә онытабыз... Ни өчен бу болай?..

Бүген беренче мәртәбә айлы кичне күрдем. Тулган ай күл аръягындагы караңгы агачлар өстендә түп-түгәрәк зур бер сары тап булып хәрәкәтсез генә тора. Аннардан нур таралганы һич тә сизелми; әйтерсең сыек зәңгәр күлне түгәрәкләп тишкәннәр дә кәгазь ябыштырып, артына лампа яндырып куйганнар.

...Кичке табигатьнең хәрәкәтсезлегенә һәм тынлыгына ис китәрлек иде. Әгәр җирдән, судан сизелер-сизелмәс җылылык бөркелеп тормаса, аны тәмам үлгән дип уйларга мөмкин булыр иде. Мин юри басмага төшеп, тирә-юньгә бик озак колак салып тордым. Судан булсын, агачлардан булсын ник бер шылт иткән тавыш ишетелсен, ник бер зәгыйфь кенә хәрәкәт барлыгы сизелсен!.. Бу тынлык, бу хәрәкәтсезлек шул кадәр тирән иде ки, хәтта минем сулыш алуым табигатьнең бу бөек тик торуын боза кебек тоела иде үземә...

**8 ноябрь, 42 ел.**

Бөек Октябрь революциясенең 25 еллыгын үткәрдек. Былтыр бу бәйрәмне мин бер авылның кара мунчасында ялгыз каршы алган идем. Инде бер ел үткәнгә һич ышанасы килми. Бәйрәмнәрнең килеп китүе гомернең никадәр тиз үткәнен генә күрсәтә. 1917 елны миңа сигез яшь иде, хәзер утыз өч яшь.

Кичә бераз аракы һәм самогон эчтем. Ихластан сөйләшергә бер генә дә якын кеше юк...

Кичкә таба ике дошман самолеты килеп, берничә бомба ташлап киттеләр. Безнең яңа начальник башына бомба кыйпылчыгы тиеп һәлак булды. Безгә килүенә бер 15 кенә көн иде. Мин аны юньләп күрмичә дә калдым.

Кич белән кәеф начар иде һәм әрнетеп эч пошты.
Юлбашчының кичә сөйләгән сүзләрен безнең ишеткәнебез юк әле. Көтәбез.
Быел һәркем дошманны тизрәк тар-мар итү, җиңү теләге белән яна.
Былтыр исә тизрәк сугыш бетсен өчен җиңелүне теләүчеләр дә юк түгел иде.

**25 ноябрь, 42 ел.**

Соңгы хәбәрләр кешеләрнен йөрәкләрен дә, хыялларын да канатландыра. Аларда шундый көчле теләк ки, дошман белән эшне, мөмкин булса бер айда, бер атнада, бер көндә бетерерләр иде. Чыннан да күпләрдә сугышның бетүе бик тиз булыр дип уйлау көчле... Тик аерым кешеләр генә хыялларын йөгәнләбрәк тоталар, вакыйгалар турында салкын кан, айнык акыл белән уйларга тырышалар. Алданудан саклыналар булса кирәк... Шулай да сугыштан тую кешеләрнең теләкләрен бик нык берләштерә...

Сугыштан соң булачак тормыш белән кызыксыну юк дәрәҗәдә аз. Ләкин бер кызыклы сөйләшү булды. Соңгы хәбәрләр турында сөйләшеп утырганда үзеннән-үзе бер сорау туды: бу сугыштан соң янадан сугыш булырмы?.. Тынычлык дәвере озак дәвам итәрме?

Сөйләшүчеләрнең фикере шул иде: тынычлык дәвере шактый озак булыр... Һәрхәлдә, соңгы ике зур сугыш арасындагы дәвергә караганда да озаграк дәвам итәргә тиеш. Ләкин, барыбер, иртәме-соңмы яна сугыш — тагын да катырак сугыш булачак... Әлбәттә, безнең белән калган илләр арасында.

«Человек, которому плоть дороже его чести — низкий тип» (автор неизвестен.)

Бу сүзләрнең мәгънәсен мин аеруча тирән аңлыйм.

«Гений никогда не упреждает своего времени, но всегда только угадывает его не для всех видимое содержание и смысл» (Белинский)

Әгәр мин бөтен уйлаганымны әйтеп бетерә алмасам, димәк, мин иректә, хәр кеше түгелмен.

**29 гыйнвар, 43 ел.**

Үткән төнне дошман самолеты станциягә бары бер бомба ташлап китте. Ләкин бу бер бомбаның афәте бик зур булды. Дистәгә якын вагон янды. Мин вагон астында янып яткан кешеләрне күрдем. Өч кеше тәмам янып беткәннәр иде. Бик кечерәеп калган һәм кеше гәүдәсе икәнен кара кисәүләрнең ни рәвештә ятуыннан гына белергә мөмкин иде. Шул кисәүләр уртасында тәрилкәгә салган шикелле, кешенен эчәкләре өелеп ята!.. Ак-сары эчәкләр күмерләнгән кара кисәүләр уртасында!.. Мин моны бер вакытта да онытмам!

Кешеләргә нәрсә кирәген белеп була, ә миңа кешегә нәрсә кирәк?

Безнең гаскәрнең соңгы зур җиңүләре уңае белән сугышның язмышы турында уйлану, хыяллану, сөйләнү тагы да көчәя төште.

Мин каршымда утырган иптәшкә сорау бирәм:

— Әгәр немецлар бер җирдә дә безнең һөҗүмне туктата алмасалар, һәр фронтта аларны чорнап алу, кырып бетерү дәвам итсә, гомумән, немецләрнең безгә каршы фронты туракланып бетсә, немец армиясендә тоташ җимерелү һәм бөтен җирдә дә тәртипсез качу башланмасмы?

Иптәшнең җавабы кыска:

— Юк, немец армиясеннән моны көтеп булмый.

Мин сорыйм:

— Әгәр Германия үзенен көчен союзниклар көче белән чагыштырып карау нәтиҗәсендә безне һәм союзникларны җиңә алмаячагын төшенсә, якын киләчәктә капитулировать итмәсме?

Иптәш янә бик мәгънәле генә итеп җавап бирә:

— Германиянең капитулировать итүе җиде кат җир астында әле... Алар хәзергә Мәскәүдән 150 километрда гына торалар.

Иптәш салкын акыл кешесе, ә мин хыялланырга яратам.

**Март, 43 ел.**

Без Великие Луки шәһәрендә.

Иң беренче уй: кеше нәрсәгә остарак — төзергәме, җимерергәме?.. Шәһәрдә бер генә исән калган телеграмм баганасы да юк, ичмасам!

Кешелек дөньясының бөтен тарихы буена җыйган акыл һәм рухи байлыгы адәмнәргә нәрсә бирде? Шушы сугышнымы?

Кеше үз-үзен алдамыйча тора алмый булса кирәк... Һәм озак та үтмәс, шушы сугышны да законлаштырырга, кешелек дөньясының үсеше өчен кирәкле булган чарасыз бер баскычы итеп күрсәтергә тырышырлар.

Менә ике ай буена шәһәрдәге үлекләрне җыеп бетерә алмыйлар. Элек кеше мәче үләксәсе яныннан да чирканмыйча үтә алмый иде. Хәзер исә үлгән солдат җимерек шәһәрнең бер чүбе булып ята бирә. Әйләнеп караучы да юк. Немец үләксәләре янышнан күлеп, сүгенеп үтәләр... Кызганыч менә, үзебезнекеләрнең гәүдәләре урам буйларында айлар буена аунап яталар... Ә без бит алар хакында күпме мактау сүзләре язабыз!

Без урнашкан ватык йорттан 100—150 метрда гына бер олы өем үлекләр ята иде. Шуларны бомба чокырына ташлап, бик юка гына итеп күмделәр. Хәзер шул җиргә көн саен каргалар көтүе төшеп утыра.

**23 март, 43 ел.**

Кичә дошман снарядыннан ике кешебез җәрәхәтләнде. Бүген аты белән үлекләр ташып йөргәндә кызыл армеец Ефимов мина шартлавыннан һәлак булды. Минага арба арткы тәгәрмәче белән менгән булса кирәк. Арбадагы үлекләр кисәкләргә өзгәләнеп һавага очалар. Арба янәшәсендә дилбегә тотып барган Ефимовның битен, ярты башын актарып ташлый... Ат исә ничектер исән кала.

Ефимов бик юаш, аз сүзле, әйбәт кеше иде. Без аның белән 42 елның гыйнвар башыннан гел бер частьта булдык. Бичара, минем белән очрашкан саен «Исәнме, писарь» дип дәшмичә калмый иде.

**27 март.**

Безнең союзниклар имеш!.. Бу «союзниклар» безнең халыкның йөрәгендә хәзер ниләр кайнаганын аз гына белсәләр иде, ичмасам! Һәр үткән көн белән безнең кешеләрдә аларга каршы ихтыярсыз ачу кабара, йөрәкләрендә нәләт үсә. Аларның икенче фронт ачып безгә ярдәм итүләренә беркем дә ышанмый, ә сүз белән юатуларына оятсыз алдау дип карый. Чөнки алар тарафыннан сөйләнгән сүзләрнең безнең бер корбан бәясенә дә тормаганын һәркем бик яхшы аңлый.

...Күпләрдән минем:

— Англиягә каршы сугышсак, ирекле булып сугышырга барыр идем,— дип әйткәннәрен еш ишетергә туры килде.

Сыерчыкның сызгыруы кайчагында пуля сызгыруына охшап куя.

Мин постка йөри торган юлдан 10—15 метрлар читтә алты немец солдатының мәетләре черен ята. Алар әйләнәсендә җирдән беренче яшь үлән баш күтәреп, чыгып килә... Һавада сабан тургайлары кояшка каршы очып—талпынып сайрашалар...

— Йә, комрадлар, яз матурмы?—дип дәшәсе килә... Тәүбә, тәүбә!..

Бүген пасха бәйрәме... Кайчандыр кешеләрнең балаларча шатлана торган көне иде. Бу гадәт күптән үтерелде. Һәм менә бүген кеше шатланасы урында үзен хәзерге олы бәхетсезлекләрнең гаепчесе итеп тоя... Унайсыз, читен, гүя шатлану хакы бөтенләйгә югалган...

Повар безгә ит сумсасы пешереп маташа. Аның бик бәйрәм итәсе килә, кешеләрне бик теләп сыйлыйсы килә, тик алар бүген бәйрәм дип белсеннәр, тойсыннар, куансыннар гына иде... Кичә ул үзе:

— Ну, иртәгә пасха!.. Мин барыгызны да сыйларга тиеш,—диде.

Без аның өчен бәйрәмнең мәгънәсе идек... Ә без сумсаның пешкәнен түземсезлек белән көтәбез, ләкин арабыздан: «Бүген бәйрәм бит, егетләр!» диюче юк.

Мин мунча кереп чыктым. Минем тәнем чиста, җиңел, ул яшь, тоя... Ә менә мунча юлы өстендә немецләр һаман череп яталар.

Сугышның кагыйдәсе шул инде. Бүген берәүләр йөри, икенчеләр аларның юлы өстендә череп яталар. Иртәгә, кем белә, тәннең чисталыгына, җиңеллегенә сокланган кеше аяк астында аунап ятыр, ә башкалар бер дә үлмәстәй булып йөрерләр.

«Я не позволю тащить меня не веревке даже в рай...»

(Горький — «Чудаки»)

Сүз дә юк, һәйбәт әйтелгән!..

**Искәрмә.**

1943 елның җәен без Великие Луки белән Невск арасындагы авылларда торып үткәрдек. Безнең фронтта һөҗүм сугышлары да шактый вакыт тынып торды. Бу, ихтимал, Латвияга бәреп керер алдыннан зур хәзерлек, күп көч туплау

белән бәйләнгән булгандыр... Шул сәбәпле минем кыска гына язмаларымда да сугыш юк диярлек. Ара-тирә ишеткән-күргәннәремне генә язып куйгалаганмын.

Бүген 22 июньдә бу тирәдә яшәүче халык печәнгә төште. Бер авылдан кайтышлый мин бер төркем печән чабучыларны күрдем. 13 кешенең берсе — карт, уникесе хатын-кыз... Алар торналарча тезелешеп, ашыкмыйча гына чабып баралар. Аякларын аерып куеп, бөгелмичә җинел, иркен чабалар... Кайчак туктап, чалгыларын кайрыйлар. Кайракларын кайда тоталардыр — күрмәдем. Безнең агайлар ыштан бөрмәләренә яки тула оек балагына тыгып куялар иде...

Яланнан бал исе килә.

Авылдан кайтышлый бер Җаек татарын очраттым. Алгы сызыктан авырып госпитальгә китеп бара. Очрашу кыска гына булса да, шактый сүз сөйләп өлгерде.

— Дүрт тапкыр сугышка кердем, бер генә тапкыр ранен да булмадым, ичмасам, ди... Мин үзем нестроевой, ашказаным авырый, йөрәкнең дә рәте юк. Шуның аркасында мине һаман позициядән артка таба озаталар. Ә мин артта тора алмыйм, эчем поша, йөрәгем ярсый... Рапорт бирәм дә кире алгы позициягә кайтам. Менә бишенче тапкыр сугышка керү нияте белән барган идем, бәхетсезлеккә каршы оборонада яталар икән, чын сугыш юк, тик шунда бер-берсен үчекләп вакыт әрәм итәләр... Көтеп ята торгач янә авырый башладым... Ахырда командирга әйттем: мин болай мылтык кочаклап ята алмыйм, разведкага җибәрегез, йә шунда үлеп калам, йә медаль алып чыгам, дидем. Көлә, мәлгунь!.. Синс, ди, кире артка җибәрәбез, әгәр янадан терелеп кайтсаң, шул кайтуың өчен генә медаль бирербез, ди... Нишлисең, китәргә туры килде... Ленинград фронтында бер ай буена яман кызу сугыш эчендә булдым, күпме халык кырылып бетте, әллә ничә тапкыр пополнение килде — алар эреп бетә торды, ә миңа бер нәрсә дә булмады. Тагын авырып чыгарга туры килде... Иптәшләр көләләр: ну, Галиев, өеңә хаҗдан кайткан шикелле кайтасың инде диләр. Алар мине бөтенләйгә кайтып китә дип уйлаганнар. Чынлап та, миндә сугыштан алып чыккан өч немец сәгате, ике немец итеге бар иде... Йөри торгач барсын да югалтып бетердем... Шулай, парин!... Иллегә житеп киләм инде, ә позициядән башка җирдә үземә тынычлык таба алмыйм.

Мин сорыйм:

— Иленә кайтасың киләме?

— Килмәгән кайда ул!... Йөгерә-йөгерә кайтып китәр идем... Миңа шул икесенең берсе булсын: йә өйгә, йә позициягә!..

Карабодай кыры яныннан үттем. Ул умарта шикелле гөжләп тора иде. Аның һәрбер ак чәчәгендә бал корты утыра.

Урманда балтырган көпшәсе табып ашадым. Мин башта аны танымадым. Тик пәке белән кисеп алып, әрчеп ашый башлагач кына тәменнән таныдым... Малай чактан ук үз кулым белән өзеп ашаганым юк иде.

Сугышның безнең территориядә бетүе дә бик мөмкин. Ләкин жиңү союзниклар тарафыннан булганга күрә, Герман гаскәрләрен безнең җирдән чыгарырлар.

Июнь аенда безнең ротадан шактый халык алгы сызыкка озатылган иде... Хәзер кайберләренең җәрәхәтләнүе яки үлүләре турында хәбәрләр килә башлады... Әле күптән түгел генә киткәнгә күрә аларның тере кыяфәтләре күз алдында саклана.

Фронтларда безнең уңышлар зур булган саен икенче фронтның ачылу ихтималы ераклаша бара. Кара реакция Гитлерның безнең тарафтан тар-мар ителүен теләми булса кирәк.

Җәй үтте...

Көн шактый кыскарды. Хәзер караңгы төшүдән алып, яктыра башлаганчыга кадәр йокыны тәмам туйдырып була... Иртә-кичләрен суык була башлады. Кеше әкренләп җирдән, табигатьтән ераклаша.

Яланнар бушап калды... Ялгыз моңаеп калган жир үзенең яңа хуҗасы — кышны көтеп алалмыйча интегер кебек... Болыннардан кешеләр эшләрен бетереп күптән киттеләр. Тик анда сирәк-мирәк, башларына корган чыбык кадаган кибәннәр генә торып калдылар... Килер вакыт, ул кибәннәр әйләнәсендә уралып бураннар уйнар... Хәзер исә ялгыз күбәләк сөйгән чәчәген эзләп, кая кунарга белмичә аптырап очынган була.

Иртәләрен жир күе салкын ак томанга төренә. Һәр көн кичегеп чыккан кояш шул томан аша, гүя теләр-теләмәс кенә күтәрелеп маташа. Көн уртасында ул юмартланып балкыса да, әвәлгечә табигатькә җан өрә алмый инде... Бары аның

жылыкай-йомшак нурлары белән җир өстенә хәлсез ялкаулык, монсу талгынлык кына җәелә. Дөнья төпсез бер, дәртсез уйга чумган кебек... Әйе, җәй үтте.

«Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы» *(«Хаҗи Морат»тан)*

Кеше үзендә зур эшләргә көч һәм сәләт барлыгын сизә. Ләкин ул кечкенә эшләр колы булып яшәргә мәҗбүр. Чөнки аның заман хорына (күмәк җырга) катнашырга тавышы ярамый... Яки аңарда әрсезлек белән ялагайлык җитәрлек булмый. Минә шундый кешеләрнең бозылуларын һәм бик бозык булуларын күп күргәнем бар.

Илдә иҗтимагый һәм сәяси тормышның какшавы яки бер эзгә ныклап төшеп җитмәве нәтиҗәсендә бозыклыкның гомуми төс алуы, «халыклашып» китүе бик мөмкин... Шулай ук фаҗигале вакыйгалар чорында (мәсәлән, сугыш вакытында) бозыклыкка каршы көрәш йомшарып, ул афәт корчаңгы чиредәй үзеннән-үзе тарала башлый. Билгеле, халыкта тормыштан гомуми ризасызлык үсүе дә аның таралуына бик нык ярдәм итә.

Минем атай карт сөйли торган иде:

— Таң Чулпаны калыкмыйча, таң әтәче кычкырмыйча торып, кеше сәфәргә чыкмый иде. Таң әтәче тавышыннан төнлә йөргән бөтен җен затлары качып бетәләр... Бөтен дөнья әтәчләре бер үк вакытларда — төн уртасында, таң атканда, көндезге сәгать 12 дә кычкыралар. Күктә Алланың бер әтәче бар, алар шуның тавышын ишетеп кычкыралар, имеш.

**9 март, 44 ел.**

Өч төрле шик безнең кешеләрнең йөрәгендә саклана:

1. Кырык дүртенче елда сугышның бетүенә ышанмау.
2. Союзникларның 44 елда икенче фронт ачуларына ышанмау.
3. Безнең белән союзниклар арасында чын дуслыкның булуына ышанып бетмәү.

Кем белән генә сөйләшергә туры килмәсен (солдаттан алып офицерга чаклы), шушы өч төрле шикне теге яки бу рәвештә әйтмичә калмыйлар. Матбугат ышандыруларына карамастан халыкта мондый шикләрнең яшәве, кешеләрнең үзләренчә уйларга тырышуларын күрсәтә.

Сугышның тизрәк бетүен теләү һәм сугышны тизрәк бетерергә тырышу өчен безнең халык татыган ике нәрсә Англия һәм Америка халыкларына җитми булса кирәк:

1. Бу сугыш китергән газап, бөлгенлек һәм бу сугыш йоткан корбаннар.
2. Дошманга карата булган ачу-нәфрәт.

Әгәр шушы ике нәрсәне алар безнең халык күргән, хис иткән дәрәҗәдә күрсәләр, хис итсәләр иде, һичшиксез сугышның тизрәк бетүен якынлаштырырлар иде.

Ач бала тук баладай уйнамас,
Тук бала һич нәрсә турында уйламас.

*(Казакъ мәкале)*

«Я ненавижу ложь и насилие во всех видах» (Чехов).

Бөек әдип! Рөхсәт итегез, Сезнең бу сүзләрегезгә бөтен тәнем-җаным белән кушылырга.

**Июль, 44 ел.**

Безнекеләр Латвиянең түренә үк кереп киттеләр. Латвиягә барып кайткан кешеләр андагы крестьяннарның сигезәр сыеры бар дип сөйлиләр. Аларда колхоз булырмы икән, юкмы икән дип кызыксыналар...

Бүген шуннан кайткан бер мәҗрух сержант белән сөйләштем... Немецләр үзләре артык каршылык күрсәтмиләр, бигрәк тә власовчылар һәм латышлар нык каршы торалар, усал сугышалар, дип сөйләде ул... Кулга төшкән власовчыларны безнекеләр шунда ук атып үтерәләр икән.

Бүген (29 июльдә) кыска гына бер төш күрдем:

Бик күп халык поездда китеп барабыз имеш. Бер мәлне вагон тәрәзәсеннән карасам, алда юлның рельслары юк имеш. Ләкин поезд тизлеген һич әкренәйтмичә, рельссыз юл белән китте дә барды... Юл бик начар, чокырлы-чакырлы... Вагоннар авып китәрдәй булып, әле бер якка, әле икенче якка селкенәләр... Ләкин бу начар юл озын булмады. Паровоз яңадан рельсле юлга чыгып, шәп кенә китеп барды, һәм озак та үтмичә без бер станциягә җитеп тә туктадык...

Бу төшне торгач, казах солдатларга сөйләдем. Барысы да — яхшы, бик яхшы! — диештеләр һәм төшне тиздән сугыш бетүгә юрадылар. Аннары төшнең чынга чыгуын теләп, кул күтәреп дога да кылдылар.

«Заря сияла, на востоке, и золотые ряды облаков, казалось, ожидали солнца, как царедворцы ожидают государя...»

(Пушкин — «Барышня-крестьянка»)

Кешенең бәхете белән бәхетсезлеге бергә култыклашып, артыннан ияреп йөриләр.

**1944 ел. Сентябрьнең егерме тугызы...** Айның янә бер көне калды... Калган бер көн эчендә сугыш бетмәс дип әйтсәк, шаять ялгышмабыз. Шулай итеп, бик күпләрнең сентябрь сугышның соңгы ае дип юраулары дөрескә чыга алмады. Сугыш октябрьдә дә дәвам итәргә булды.

Инде октябрь турында юраулар башланды. Коммунист Акшаловның төшенә караганда, сугыш 7 октябрьдә бетергә тиеш, янәсе... Солдат Байәхмәтов октябрьдә бетүе турында яз көне үк бер төш күреп куйган имеш... Күпләр исә төшләр юрап маташмыйча да, фронтлардагы җиңүләргә карап, сугышның октябрьдә бетеп куюы да мөмкин диләр. Кайберәүләр октябрь революциясе бәйрәменә кадәр һичшиксез бетәргә тиеш дип баралар. (Болар бөек бәйрәмгә һәртөрле йөкләмәләрне үтәп өйрәнүчеләр.) Скептиклар да юк түгел. Алар сугышның кайчан бетәсен төгәен әйтә алмыйлар, ләкин октябрьдә бетүенә һич тә ышанмыйлар... Мин үзем былтыр ук сугыш 45 елда бетәр диган идем, әмма октябрьдә бетүенә дә һич каршы түгелмен...

Бу язганнар барсы да гади солдатларның уйлары, ә генераллар ничек уйлый торганнардыр — ул кадәресе безгә мәгълүм түгел.

## Сугыш хикмәтләре

Былтыр, 43 елны, немецләр Великие Лукины даими рәвештә авыр туптан атып тордылар. Станция янындагы бер складны безнең рота солдатлары саклыйлар иде. Аларның торган җире тимер юл буендагы җимерек заводның кечкенә бер бинасында иде. Төннәрдән бер төнне алар торган шул бинага немецләр җибәргән снаряд килеп төшә. Бу минутта өй эчендә 9 кеше була. Шуларның җидесе сәкеләрдә йоклап яталар, ә икесе — Акшалов белән Хаҗиниязов — өстәл янында карта уйнап утыралар... Авыр снаряд өйнең түшәмен тишеп, әрлеген сындырып килеп керә дә цемент идәнне дә ватып, каядыр түбәндә бик яман шартлый... Өй эче тотен, тузан белән тула, ишек-тәрәзәләр тупсаларыннан каерыла, идән уртасындагы авыр чуен мич тә ачык ишектән тышка оча. Ләкин өй эчендәге тугыз кешенең берсенә дә берни булмый. Үлүче дә, яраланучы да юк. Башта котлары очып, исәнгерәп калалар... Бераздан исләренә килгәч, өйдән чыгып качалар... Аннары барсы бергә җыелалар — һәммәсе дә исән-саулар! Тик кайберләренең бит-куллары гына вак таш кисәкләре тиеп тырналган була... Бу искиткеч хәлдән аптырамаган кеше калмады.

Сыңар аягы өзелгән бер солдатны носилкага салып санбатка китерәләр. Кемдер солдатка бер сухари биргән. Солдат шуны акрын гына кимереп носилкасында ята икән. Шуны күргән Дурду әйтә:

— Тамакның никадәр яман нәрсә булуына шул чакта иман китердем, — ди.

Танаев сөйли:

— Кышкы суык төнне бер урман кырыена постка куйдылар. Бу урынга безнең часть яңа гына килеп туктаган иде... Йөри торгач минем аякларым арды, утырып ял итмәкче булдым. Төн караңгы, берни күренми, мин аягым белән капшанып, берәр агач-бүрәнә кебек нәрсә эзләргә тотындым. Ахырда эзләнә торгач, аякларым озынча бер каты нәрсәгә бәрелде: бүрәнә булса кирәк... Иплэп кенә шуның өстенә утырдым, аякларымны суздым, рәхәтләнеп ял итәм... Шактый вакыт узгач, акрын гына таң ата башлады, тирә-юнь дә әзрәк яктырды... Бер мәлне утырган нәрсәмә карасам, ни күрим, астымда туңып каткан немец ята, гой! Атаңа нәләт...

Танаевны тыңлаган башкалар да менә ышандылар — кышкы караңгы төннәрдә туңып каткан мәеткә абынып егылу яки ышыкланып ятулар була икән.

20 июньгә каршы төндә немец самолетлары В. Луки станциясен бик яман бомбага тоттылар. Шул тирәдәрәк булган берәү безгә самолетлар киткәннән соң бер хатынның телеграф баганасына итәге белән эләгеп асылынып торуын сөйләде. Хатын үлек, ләкин яраланган җире юк — бомба шартлавы аны шулай багана очына чөйгән булырга тиеш, ди.

**Май башы, 44 ел.**

Вакыт-вакыт күңел сәбәпсезгә нечкәреп куя... Әле дә менә җиргә ятып, яңа баш күтәргән яшь үләнгә битне ышкыйсы килә.

Вакыт-вакыт йөрәк шундый әрнү белән сызлана ки, ирексездән чәчләргә ябышып үкерәсе килә.

**1944 ел.**

Бүген 5 нче октябрь. Октябрьдә сугыш бетмәде. Ноябрьнең бу 5 көнендә дә нәрсә булыр икән дип көтеп карадык, ләкин сугыш исереп тилергән фахишә шикелле кабахәт котыруыннан туктамады. Октябрьдә сугыш бетә, өйләребезгә кайтабыз дип төш күргән солдатлар (мәсәлән, Байәхмәтов) алгы сызыкка китеп бардылар. Хәзер инде кешеләр төшне сирәк күрә һәм сакланып юрый башладылар. Бөек бәйрәмгә бетә дип торучылар да тынып калдылар... Хәер, кайберәүләр сугышның 1 майга бетүе турында кыюсыз гына сүз ачкалыйлар... Йокләмә үтәп өйрәнгән кешеләр сугыш шикелле һичбер кеше ихтыярына буйсынмый торган вакыйганы да хуҗалык планын үтәү кебек бер эш итеп караудан котыла алмыйлар.

Ничек кенә булмасын, ләкин сугышның тизрәк бетүен теләмәгән солдат юк. Гитлер никадәр катырак каршы торып маташкан саен, аңа карата булган ачу-нәфрәт шулкадәр көчәя бара... Бу хәл һәркемнең сүзеннән сизелеп тора.

Фронт дәфтәреннән чүпләп күчергәнем шушының белән тәмамлана. Бер кадәресе хәзергә калып тора... Билгеле, фронт шартларында, кешеләрдән яшеренә-яшеренә күргән-ишеткәннәрнең йөздән берен дә дәфтәргә теркәп булмады. Мәгәр язылган кадәресе дә 50 елдан соң укыр өчен кызыклы булыр дип уйлыйм.

Аеруча бер нәрсәгә укучы игътибар итмичә калмас мөгаен: дүрт елдан артык дәвам иткән сугыштан солдатлар тәмам туйды, гарык булды... Бөтен уйлаганнары сугышның тизрәк бетүен теләү иде... Берәүләргә аның беткәнен күрү насыйп булды, бик күпләр исә күрә алмыйча, эче тулы өмет-сагышлары белән сугыш кырында ятып калдылар...

Сугыш кеше табигатенә каршы нәрсә, кеше үләргә теләми, яшәргә тели — мәҗбүр ителгәнгә күрә генә ул үлемгә бара. Әмма мәҗбүр итүчеләр үзләре күп вакытта исән калалар. Кешелек дөньясының олы бер фаҗигасе бу...



# Фәрит Солтанбәков

## ҮЛЕМ СӘГАТЕН КӨТКӘНДӘ

(М. ЖӘЛИЛ ҺӘМ ЖӘЛИЛЧЕЛӘР ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР)

Минем әтием Сәхиулла Гарифулла улы Солтанбәков Казан губернасының Мамадыш өязендәге Югары Ушмы авылында туып үскән. Ул Түнтәр мәдрәсәсендә укып белем ала, андагы авылда эш таба алмагач, Украинага китә. Луганск өязенең Ирмино шәһәрендә шахтер булып шактый еллар эшли. 1915 елда ул Казанга кайта, Мамадыш өязенең Алкин авылында үскән, аннан соң Казанда тегүче булып эшләгән һәм электән үк таныш булган Тажетдин кызы Гамиләгә өйләнә. Туйларны үткәргәч, алар тагын Украинаның Ирмино шәһәренә китәләр. Һәм шунда, 1916 елның 15 маенда, мин дөньяга килгәнмен. Без 1923 елда үзебезнең Татарстанга кайттык. Мин инде дөньямны бераз аңлый башлаган идем. Әти, дини мәктәптә укыганлыктан, күп догалар белә иде. Ул хәзерге Кукмара районының Тарлау авылына мулла булып урнашты.

Менә бер көнне әти мине Саба районындагы урта мәктәпкә укырга кертергә алып барды. Мәктәпне сөйләшеп, мине бер кешедә яшәргә урнаштырып, үзе өйгә кайтып китте. Без укый башладык. 10 көн дә үтмәде, мине һәм минем кебек мулла-мөәзин гаиләсендә үскән малайларны сыйныфтан чыгарып җибәрделәр. Без күзләребезгә яшьләр тулып, өйләребезгә таралыштык. Шулай итеп без «килмешәк» булып калдык. Әтине дә мөәзин улы дип кыса башладылар. Шуның аркасында 1928 елны ул Үзбәкстанга китәргә мәҗбүр булды. Бөтен гаиләбез белән 1930 елны Үзбәкстанга күченеп киллек.

Мин башта авыл хуҗалыгы техникумында, аннан соң рабфакта укыдым. Укып бетергәч, Сәмәрканд шәһәрендәге университетка укырга кереп, 1940 елда физика-математика факультетын тәмамлап чыктым. Шәһрисабз районы урта мәктәбендә 2 айдан артык эшләгәннән соң Совет армиясенә хәрби хезмәткә алдылар...

АВТОР.

* * *

Муса Җәлил белән мин 1943 елны март ае ахырларында Демблин әсирләр лагеренда таныштым. Аны яшерен оешмада эшли башлаганнан соң гына ныклап белә башладым. Муса Җәлил Демблин кальгасына бер эмигрант — Шәфи Алмаз — белән килде. Аның өстендә кара костюм, ак күлмәк иде, муенына кара галстук бәйләгән, башында кара эшләпә һәм

кулына кара макентош тоткан иде. Йөзе чиста, кара чәчен пөхтәләп тараган, кара күзләре уйнап тора иде.

Муса Җәлил Гайнан Кормаш белән кочаклашып күреште. Бераздан Шәфи Алмаз немецлар комендатурасына китте. Лагерьдагы әсирләрнең хәлләрен сораша, имеш. Аның юклыгыннан файдаланып, Муса белән Гайнан, лагерьның бер читенәрәк киттеләр дә, рәхәтләнеп шактый вакыт сөйләштеләр. Соңрак Гайнан мине үзләре янына чакырды һәм:

— Менә, Фәрит — татар егете,— дип, мине дә Муса белән таныштырды. Муса Җәлил Гайнан Кормаш, Зиннәт Хәсәнов, Габдулла Батталов һәм минем белән шактый вакыт сөйләшеп торды.

Мин Муса Җәлилнең ни өчен Демблин кальгасына килүенең сәбәбен ачык белмәдем. Шуның өчен дә Муса белән танышканчы: «Кем икән соң бу?»— дип уйлап та куйган идем.

Әйткәнемчә, бу минем Муса Җәлилне беренче күрүем иде. Кормаш миңа карап: «Бу егет, беләсеңме, кем була? Бу — безнең татар халкының зур шагыйре Муса Җәлил!»— диде.

## Радом яшерен оешмасының эше

Полк мәктәбендә тырышып укып йөрим. Бу мәктәп Житомир өлкәсендәге Барановка дигән авылда урнашкан. Безнең часть 19 нчы полкның 86 нчы батальоны иде. Бөтен батальонда урта һәм югары белемле кешеләр генә укый. Югары белемлеләр бер ел гына хезмәт итеп, командирлыкка имтихан тапшыргач, запастагы лейтенант булып, армиягә алынган җирләренә кайтып китәргә тиешләр иде. Мин дә Сәмәрканд дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлагач, шушы мәктәпкә җибәрелдем. Тагын ике айдан, запастагы лейтенант булып, үзем үскән шәһәргә, әти-әни, туганнарым, сөйгән ярым янына кайтам дип өметләнеп йөргән бер вакытта...

22 июнь, якшәмбе көн, без ял итәбез. Әйбәтләп кенә иртәнге ашны ашадык та, бөтен батальоныбыз белән су коенырга киттек. Бер-беребезгә су чәчрәтешеп рәхәт чиккән бер мәлдә «Тревога!» игълан ителде. Һәммәбез ярга атылып чыгып, тиз генә киендек тә, казармага таба йөгердек. Әлегә берни белмибез. Батальон командиры һәм политрук митингны ачып җибәрделәр. 22 июнь көнне иртә белән Гитлер гаскәрләре илебезнең чиген үтеп, җиребезгә басып кергәннәр икән. Без, дошманны бик тиз тар-мар итәрбез, илебезнең тынычлыгын актык сулышыбызга чаклы саклarбыз дип, антлар бирдек. Ләкин эш башкачарак булып чыкты. Дошман бик нык коралланган икән шул. 1941 елның 4 июлендә без урнашкан районны бик каты бомбага тоттылар. Алтынчы июльдә безнең дот блокадага эләкте. Без өч сержант, ике солдат һәм бер лейтенант өч көн йокламаган, ашамаган көенчә оборонада утырабыз. Дошманга каршы доттан бер туктамый станковой пулеметлардан атабыз. Өч көн эчендә бик күп патроннар һәм гранаталар сарыф ителде. Бөтен запаслар бетте. Амбразураны ябып та өлгермәдек, огнеметтан безнең дотка төбәп атылган ут ташкыны эчкә бәреп керде, ялкыны минем башымны, битемне, кулларымны өтеп-яндырып алды. Көчле дулкын аяктан егуга мин аңымны җуйдым.

Менә мин дошман кулында әсирлектә. Әсирләр лазаретында ятам. Күзем күрми, сукыр калам инде диеп әрнеп кайгырам. Врачларга, санитарларга: «Сукыр килеш дошман кулында азапланып үлгәнче, хәзер үк үлсәм яхшырак, берәр дару бирегез!»— диеп ялынам. Әсир врачлар: «Синең битләрең янып, күзеңдәге тиреләрең генә ябышып калган, күзең ачыла, сукыр калмыйсың»,— дип мине юаталар. Шулай дөнья яктысын күрмичә җиде көн лазаретта яттым. Сигезенче көнне күзем аз гына яктылыкны шәйли башлады.

1941 елның август ахырларында безне Перемешель шәһәрендәге концлагерьга алып киттеләр. Бу лагерь тау кырыенда урнашкан булып, аның дүрт почмагына дүрт манара ясалган. Анда автоматлар белән сакчылар утыралар. Бараклар урынына землянкалар казылган. Алар эчендә бер катлы нарлар урнашкан. Коры такта өстендә ятабыз. Суык көннәрдә бер-беребезгә сыенып җылынабыз. Көндез кояшка чыгып тәмәке тартабыз, һава сулыйбыз. Ашарга да бик аз бирәләр. Бу лагерьда бер ай чамасы булырга туры килде. Шул вакыт эчендә һәммәбез коры сөяккә калдык. Шулай итеп сентябрь ахырлары җитте. Бер көнне безне стройга тезделәр, берәр буханка агач чүбе кушылган ипи дә бирделәр. Аннары көчле сак астында җәяүләп каядыр алып киттеләр.

Өч тәүлек бардык. Яңгыр астында чыланып, ач-ялангач килеш, ниһаять, элек үзебезнең частьләр торган казармаларга килеп җиттек. Бу Львов өлкәсендәге Раво-Русский шәһәренең читендә урнашкан 328 А концлагеры иде.

Монда авырулар бик күбәйгәч, үзенә күрә санчасть оештырдылар. Әсирләр арасыннан табиплар, фельдшерлар, санитарлар да табылды. Мин, хәлем булмагач, башым да авыртып торгач, берәр ярдәм булмасмы, дип санчастька бардым. Анда, якташлар юкмы икән дип, караштырып йөри идем, санитар булып эшләүче милләттәшләремне — Наил белән Фуатны күреп алдым (аларның фамилияләре истә калмаган). Алар белән ныклап дуслашып киттем. Үткәннәр турында сөйләшәбез, кайгыларны уртаклашабыз. Бөтен җир кычыта, мунча да, дезинфекция дә юк. Сакал-мыеклар хәйран үсеп җитте, сакал төпләрендәге серкәләр дә борчый. Шулай йөри торгач, Фуат миңа бер калай кисәге табып бирде. Мин аны кирпечкә ышкып кайрадым. Башта дусларымның сакалын кырып, шуннан соң, ватык пыяла кисәген көзге итеп, үземнең сакал-мыекны кырдым. Яңаклар кычытудан туктады.

Бервакыт гестапо офицерлары, безне стройга тезделәр дә, һәммәбезнең күзенә дикъкать белән карап, берәм-берәм чүпли башладылар. 140 кешене, коммунистлар дип, аерып алдылар. Шундыйлар арасына мин дә эләктем. Бер кечкенә генә подвалга барыбызны шыплап тутырдылар, һава юк, салкын, көненә бер тапкыр гына ярты литр баланда бирәләр. Ул да булса ташландык азыклардан, шикәр заводыннан чыккан чөгендер сыгынтысыннан пешерелә. Ипинең төсен дә күрсәтмиләр. Берничә көн үткәннән соң, хәлдән тайган әсирләр унарлап үлә башладылар. Мин дә хәлсез ятам. Үлем көтәм. Санитарлар мәетләрне ташый торалар. Санитарлар арасында дусларым Наил белән Фуат та бар иде. Наил Әзәрбайҗаннан, ул әти-әнисе һәм туганнары булуы турында сөйләгән иде. Фуат — Татарстан егете. Кайсы төбәктән икәне хәтердә калмаган. Наил миңа карап торды да: «Син иртәгә без килгәндә үлгәнгә салышып ят, сине бу җәһәннәмнән коткарырбыз»,— дип китте. Менә мин икенче көнне үлгәнгә салышып ятам. Санитарлар килеп җиттеләр. Үлекләрне арбага салдылар, мине дә шул мәетләр өстенә илтеп ыргыттылар. Үлекләрне часовняга алып барып ташладылар. Соңыннан, төнлә белән килеп, мине әсирләр торган баракка алып керделәр. Иртә белән инде мин, дусларым ярдәме белән санчастьта идем.

Берничә көннән соң, коммунистлар дип япкан әлеге 140 кешенең исән калганнарын строй белән, йөри алмаганнарын трактор арбасына төяп, бик көчле сак астында урманга алып барып, зур чокыр кырыена тезеп автоматлардан атканнар. Бу хәлне трактор йөртүче урыс егете безгә килеп сөйләде. Шулай итеп, әлеге ике иптәшем мине үлемнән саклап калдылар.

Наил белән Фуат килеп минем хәлне белешәләр, үзләре белән төрле ризык заты алып киләләр. Шулай беркөн алар каяндыр бәрәңге табып алганнар, беренче этажда мичкә ут элдереп, котелокта бәрәңге пешерә башлаганнар. Көтмәгәндә килеп чыккан исерек немец офицеры боларның икесенә дә пистолеттан ата. Наил белән Фуатны санчастька әсирләр күтәреп килделәр. Ядрә Фуатның башына тигән икән. Ул бер сүз дә әйтә алмыйча, шунда ук җан биргән. Наилнең үпкәсенә тигән, ул бик азапланып, озак вакытлар авырып ятты. Мин үзем дә тимгелле тиф белән авырып егылу сәбәпле, аңарга ярдәм итә алмадым. Бу дустым да дошман кулында корбан булды. Миңа бу ике якын иптәшне югалту бик авыр иде. Алар бит мине үлемнән коткардылар. Шуның өчен дә бу иптәшләремне мин һаман да истән чыгармыйм, алар минем йөрәктә гомерлеккә урнашып калдылар...

Менә мин рәтләнеп барам. Житомир егете, фельдшер Николай мине култыклап һәр көн йөрергә өйрәтә башлады.

Март ахырларында безне, этап белән, Львовтагы 328 нче әсирләр лагерена күчерделәр. Бу лагерь иске төрмә булып, калын таш койма, чәнечкеле тимер чыбык һәм су тутырылган канау белән әйләндереп алынган. Моннан бер генә кеше дә чыга алмый. Мин, дизентерия белән авырып, тагын санчастька эләктем. Монда мине үлемнән Сәмәрканд мединститутын тәмамлаган әсир врач Антонина Васильевна Яковлева йолып калды. Ул мине санчастька башта кара эшче, аннары санитар итеп урнаштырды. Ул чакта Антонина Васильевна 40—45 яшьләрдәге ханым иде. Уртача буйлы, кара чәчле, битендә җыерчыклар да күренә башлаган. Ул авыру әсирләрне ничек булса да дәваларга, ярдәм итәргә тырыша, төн йокыларын йокламастан шулар янында борчылып йөри. Яшь-яшь егетләрнең үлүләрен күреп бик кайгыра иде ул. Сәмәркандта гаиләсе булуы, армиягә киткән бердәнбер улы турында гел сөйли иде.

1942 елның декабрендә мине тагын әсирләр янына лагерьга чыгардылар. Ә 1943 елның январь башларында безне эшелоннарга төяп, этап белән, тагын каядыр алып киттеләр. Без килеп төшкән җир Демблин концлагеры икән. Бу кальганы кайчандыр Әби патша — Екатерина II Висла елгасы буенда салдырган. Лагерь блокларга бүленгән, анда әсирләр ач үлемгә хөкем ителгән иде. Ашау начар, медицина ярдәме юк дәрәҗәсендә. Әсирләр монда ачтан, авырудан үлгән иптәшләрен җыеп бетерә алмыйлар. Бер төркем әсирләрдән немецлар «капут команда» төзегән. Алар иртәдән кичкә кадәр мәет җыялар һәм крепость янындагы зур чокырга алып барып күмәләр иде. Бу крепостьта без килгәнче үк 95 мең кеше үлгән, дип сөйләделәр шундагы әсирләр.

1942 ел ахырында немец командованиесе, легионнар төзү максаты белән, Демблин крепостен ике бүлеккә аера. Беренче бүлектә әсирләрне каты режим астында саклыйлар, икенче бүлектә исә ярым легион төзеп, андагы кешеләрне яхшырак ашаталар, киендерәләр, аларга азрак иркенлек бирәләр. Боларны сирәк булса да крепостьтан алып чыгып, строй белән болыннарга да алып баралар. Фашистлар тәмам җәфаланган, хәлдән тайган әсирләрне кызыктырып, легионга язылсыннар өчен шундый хәйләгә баралар иде.

Яман суык бер көндә, йөрергә хәлем булмаса да, барактан чыгып әкрен генә лагерь ашханәсенә бардым. Кулына себерке тоткан, билен буган, тәбәнәгрәк буйлы бер кара гына егет ашханә идәнен себереп йөри. Мин аңарга: «Исәнмесез, иптәш!» — дип эндәштем. Ул да миңа карап кайгылы төстә генә сәлам бирде. Бу яңа танышым Гайнан Кормаш булып чыкты. Мин аның белән еш кына очраша башладым. Ул миңа ашханәдән, котелогын тутырып, бәрәңге һәм башка азыклар китерә башлады. Шулай итеп, ул мине үлемнән саклап калды. Тәнгә көч керде, рәтләнә башладым.

Гайнан бик акыллы, җинел сөякле, киң күкрәкле, таза кеше иде. Саф татар телендә сөйләшә, үзе бик укымышлы. Ул — 1919 елгы. Бәрәңге районында (Мари-Эль Республикасы) педучилище бетергәч, әнисе, сеңлесе, энесе янына Актүбә шәһәренә килеп, татар урта мәктәбендә физика укытучысы, соңрак директор булып эшли. Бу мәктәптә ул хор түгәрәге оештыра. Концертлар, спектакльләрне еш куялар. Үзе дә сәхнәдә төрле рольләр башкара. Кызыл Армия сафында ул офицер була. Чолганышта калып дошман кулына әсир төшә. Гайнан Кормаш белән безнең дуслык көннән-көн ныгый барды. Икебез дә физика укытучысы булгач, уй-фикерләр, дөньяга карашлар бигрәк тә якын иде — сердәшләр булып киттек. Гайнан Кормаш мине бу кальгада Габдулла Батталов һәм Зиннәт Хәсәнов белән таныштырды. Без дүртебез якын дусларга әвереләдек.

Менә бер көнне, ишегалдын себерергә дип, берничә әсирне кузгаттылар. Аларга Батталов белән мин дә иярдем. Кальга эчендәге чиркәүнең тышкы ягын да, эчен дә чистарттык. Шунда поп тора торган икенче катка менсәм, анда фисгармония тора икән. Батталовка мин фисгармониягә һава җибәрә торган күрекны тибрәтергә куштым. Ул тибрәтә, ә мин клавишаларга басып уйныйм. Элек пианинода уйнаштырган бармакларым көйгә сусаган. Озын татар көйләре яхшы гына чыга. Шуннан соң Кормаш белән Зиннәтне чакырдык. Шунда без бер-беребездән музыка һәм җырлар турында сораша башладык. Мин үземнең бераз гына мандолинада да уйный белүемне әйттем. Зиннәт тә җырга һәвәс икән. Әмма монда озак тора алмадык — тавышны ишетеп менгән немец солдаты безне бәргәләп куып чыгарды.

Гайнан үзенең сөйгән кызы Дания турында оста итеп сөйли. Алар педучилищеда бергә укыганнар. Бер-берсе белән ярышып икесе дә педучилищены яхшы билгеләр белән генә бетергәннәр. Даниянең бөдрә алтынсу чәчләре, зур өметләр белән янган сөйкемле зәңгәр күзләре, акыллы, мәгънәле матур сүзләре, зифа буе Гайнанны сокландырган, көннән-көн үзенә якынлаштырган. Егет үзе дә бик житез, унган, төпле, чибәр иде шул. Шулай итеп, ике арада мәхәббәт тойгылары үсә. Педучилищены бетергәч эшкә китәләр. Дания Бәрәңге районында кала, Гайнанга Актүбәгә китәргә туры килә. Менә алар бер-беренә хатлар язышып торалар. Шул елны икесе дә Учительский институтка читтән торып укырга керәләр. Алар инде хәзер Казанда очрашалар. Укуны бетергәч, бергә тормыш итәргә дип, бер-берсенә вәгъдәләр бирәләр. Шулай укып һәм эшләп йөргәндә Гайнан армиягә китеп бара. Дания аңа бик еш хатлар яза, көтәм сине, бәгърем, син тыныч бул, илне сакла, без мәңге бергә булырбыз, дип вәгъдәләр бирә, түземсезлек белән аның сау-сәламәт кайтуын көткәнлеген әйтә. Гайнан да үзенең хатларында аны чын күңелдән сөйгәнен, мәңге аннан аерылмаслыгын әйтеп яза. Ләкин язмыш башкача юл сайлаган икән шул. Менә хәзер инде Гайнан дошман кулында әсирлектә. Сөйгән Даниясеннән әллә кайчан инде хатлар килми, үзе дә

яза алмый. Немец офицеры Даниянең элеккеге хатларын да, тентү вакытында табып алып, ертып ташлаган. Шул вакытта Гайнанга бик авыр булган. Даниянең үзен күрә алмаса да аның рәсемен, язмаларын карап ул куана, өметләнә иде бит әле! Хәзер инде ул хатларны күңелдән генә искә ала. Сөйгәнен көннәр буена уйлап йөргәч, ул төшләрендә Даниясе белән күрешә, төннәрен аның белән саташып чыга. Гайнанның сагышы шул дәрәҗәгә барып житте ки, бер мәлне ул Даниягә багышлап «Ил кызы» дигән пьеса яза башлады. Аның «Дания» дигән шигыре дә бар иде. Гайнан үзенең әнисе һәм туганнарын да гел искә ала, аларны да чын күңелдән тәкъдир итә иде.

Аның әтисе яшьли үлеп китә. Әнисе, тол хатын, балаларын бик авырлык белән үстерә. Шулай да яраткан улы Гайнанны укыту әмәлен таба. Гайнан үзен әнисе алдында бик зур бурычлы дип саный, аны бик еш хәтергә төшерә һәм нык кайгыра иде. Ул әнисенә «Үлгән улыңнан хат» дигән шигырен дә шул вакытта язды.

Габдулла Батталов белән күрешү бүгенгедәй күз алдында. Башына кубанка, өстенә иске шинель, аягына агач башмак кигән иде. Сипкелле йөз, уртача буй. Сугышка кадәр аяк бармакларын өздергән икән — аксабрак йөри. Ул үзен шагыйрь дип танытты. Без аның шагыйрь булмаганлыгын соңыннан гына белдек. Ул үзе түгел, ә абыйсы Салих Батталның шагыйрь булуын, авиация офицеры икәнен сөйләде. Габдулла Казанда укыган икән. Ул нык рухлы, нинди генә авыр хәлләрне дә шаярып, көлке сүзләр белән үткәрергә тырыша, сүзгә гаять оста, төрле хикәяләр сөйләп, әсирләрне рухландыра, шигырьләр укый. Үзе житез — һәр көн бер мәртәбә баракларны әйләнеп чыга, төрле яна хәбәрләр ишетеп кайта һәм безгә сөйли. Аның шундый нык рухлы булуы башка әсирләргә бик ошый. Шуңа күрә аны һәр әсир белә һәм хөрмәт итә. Габдулла Батталов туган иленә жаны-тәне белән бирелгән чын Ватан улы иде.

Зиннәт Хәсәнов — пилоткадан, өстендә иске шинель, аягында агач башмак. Түгәрәк кенә битле, саргылт чәчле, уртача буйлы сөйкемле генә егет. Ул ашханәдә Гайнан Кормашның ярдәмчесе булып эшләде.

Зиннәт — Татарстанның Сарман районы Иске Кәшер авылыннан, сугышка кадәр Казанда кооператив техникумын тәмамлаган. Аннары офицерлар мәктәбендә укыган, лейтенант дәрәҗәсе алган, Совет Армиясендә строй командиры булган. Сарман районында әтисе һәм туганнары бар икән.

Зиннәт спорт белән шөгыльләнә, әлек берничә тапкыр ярышларда катнашкан. Тәне тимер шикелле тыгыз. Бик көчле, таза егет. Урманда, репетицияләрдән соң, тәнәфес вакытларында ул безнең белән көрәшә. Зиннәт һәммәбезне берәмберәм ега башлагач, Гарәф Фәхретдинов, батыраеп, көрәшкә чыга. Шактый тартыша торгач, Гарәфнең дә арка чокыры жиргә тия. Зиннәт чыдамлылык һәм куркусызлык үрнәге күрсәтүче егетләрнең берсе иде.

Без Демблин кальгасыннан ничек итеп партизаннарга качып китү турында күп баш ваттык. Берничә тапкыр тырышып карасак та, мөмкин булмады. Чөнки ул кальга бик зур хәрби ныгытма, аны баштан-аяк коралланган сакчылар саклый иде.

1943 елның февралендә безнең киңәшмә булды. Шунда Кормаш крепостьтагы әсирләрне ничек тә үлемнән саклап калырга кирәклеген әйтеп чыкты. Шул максаттан Зиннәт Хәсәновка ничек булса да азык-төлекне крепость эчендәге әсирләргә тарату эше йөкләнелде. Габдулла Батталовка, әсирләр арасында йөреп, безне сатарга мөмкин булган шикле бәндәләрне ачыкларга, авыру, урында яткан әсирләрнең исәбен алырга, гомумән, барыбызга да берләшү кирәклеге максат итеп куелды. Кормаш менә кер юу бүлегенә рус фельдшерының ярдәмчесе итеп урнаштырды. Кер юу бүлеге кальга эчендә иде. Ул ике катлы бина, беренче катында мунча, икенче катында кер юалар. Шул бина янында дезинфекция камерасы урнашкан. Аның янына тимер юл килә. Шуннан кальга эченә әсирләр китерелә һәм аларны санитария бүлеге аша үткәрә иделәр.

Мунча һәм кер юу бүлегендә без 35—40 әсир эшләдек. Лагерьга көн саен 10—15 ләп шинель, гимнастерка, чалбар һәм башка эчке киемнәр алып чыгабыз. Аларны «капут команда»сында эшләүче әсирләргә бирәбез, ә алар, үз чиратында, бу әйберләрне поляк эшчеләре, крестьяннары аркылы партизаннарга жибәрәләр. Поляк партизаннары исә шушы ук кешеләр аша әсирләргә азык-төлек, тәмәке кебек әйберләр юллыйлар иде.

Шулай итеп, аз гына вакыт эчендә ике складтагы киемнәрнең яртысын «шудырттык». Склад мөдире немец офицеры иде, кием-салымнарны югалтканы өчен аны фронтка жибәрделәр. Ашханәдә эшләгән Кормаш һәм Хәсәнов та әсирләргә күп кенә азык-төлек чыгара тордылар. Тора-бара әсирләрнең тор-

мышы аз-азлап булса да рәтләнә башлады. Кальга эчендә үлем-китемнәр әзәйде. Аз гына хәл алган әсирләрне мәҗбүри, үлем белән куркытып, стройга тезеп, крепостьның икенче бүлемендәге ярым легионга алып киләләр дә, анда яхшырак кием һәм итек киертәләр, ашарга да яхшырак ризык бирәләр. Әсирләрне шулай бер айдан артыграк тотып, ачык лагерьдагы легионга алып китә башладылар.

Нәкъ менә шундый вакытта эмигрант Шәфи Алмаз белән Муса Җәлил крепостька килделәр. Алар китеп берничә көн узгач, Гайнан Кормаш Муса Җәлилнең әйткәннәрен сак кына безгә дә җиткерде. Едлинода татар артистлары труппасы эшли, анда Муса Җәлил тарафыннан төзелгән яшерен оешма да бар икән.

Муса Җәлил Кормашка яшерен оешмада эшләргә ышанычлы егетләр тупларга кирәклеген дә әйткән. Бераз җырлый, бераз музыка коралын шыңгырдатса ярый, без аларны труппада артистлар, музыкантлар итеп йөртербез, дигән. Труппа маскировка гына булачак икән. Без ышанычлы егетләргә таянып кына немец пропагандасына каршы актив рәвештә үз сәясәтебезне алып бара алачакбыз, дигән.

Бу турыда без күп уйладык. Бу эшнең файдалы һәм хәтәр якларын бизмәнгә салып карадык. Шулай уйланып йөргән көннәрдә кальгага берничә немец офицеры һәм солдаты белән бергә Рушад Хисаметдинов белән Галимов дигән егет килеп төштеләр. Муса Җәлил аларны артистлар тупларга җибәргән икән. Рушад белән Кормаш артистлар труппасына алырдай әсирләрнең исемлеген төзеделәр.

Шул көнне Рушад Хисаметдинов белән Галимов (Галимовны соңыннан фашистларга каршы пропаганда таратканы өчен строй каршында чишендереп бик каты кыйныйлар һәм Бухенвальд лагерена озаталар), Габдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов һәм башка әсирләрне Едлино ачык лагерена алып китәләр. Мин ул чакта авырып санчастьта ята идем. Гайнан Кормаш нишләптер алар белән бергә китәргә ашыкмаган, әллә инде мине ялгыз калдырасы килмәде микән?

Кич белән ул минем янга килеп Хәсәнов һәм Батталовның киткәннәрен сөйләде. Күпмедер вакыттан соң Муса Җәлил бер немец офицеры белән тагын кальгага килде. Ул Берлиннан Едлинога килгән артистлар труппасы белән очрашкан. Караса, алар арасында Гайнан Кормаш юк. Үзенең иң ышанычлы дусты, курыкмас батырны һәм киләчәктә аның иң якын ярдәмчесе булачак кешене ул ничек инде истән чыгарсын?! Җәлил, легион командиры фон-Зекендорф ризалыгын алып, кальгага килгән.

Муса безнең белән бик җылы итеп күреште. Менә Җәлил, Гайнан һәм мин Демблин кальгасында сөйләшеп торабыз. Бу 1943 елның 15 апреле. Безнең икеләнебрәк калуыбызны күреп, Муса Җәлилнең кәефе китте. Кыза төшеп ул: «Их, егетләр, миңа да җиңел түгел бит ул комитетта! Мин анда фашистларга хезмәт итү өчен язылмадым. Сезне дә капеллага алып баруның максатын аңлагыз, егетләр! Сез бит анда яшерен оешмада эшләү өчен барасыз. Сезнең капеллага артист булып баруыгыз — ул бер маскировка гына. Без бергәләп фашистларга каршы көрәш алып барып, легионнардан фашистларны тар-мар итүдә файдаланырбыз. Сезнең лагерьда, дошман кулыннан, ил-халкым өчен хезмәт итмәстән, үлеп бетүегездән ни мәгънә бар? Капеллага барып яшерен оешмада хезмәт итсәгез, легиондагы әсирләрнең качуын оештырырга тырышырбыз, һәм уңайлы вакыт туры китереп, бөтен оешма әгъзаларын партизаннарга алып китәрбез. Дөреслекне төрмә коймалары эчендә яшереп булмый, әлбәттә. Безнең турыдагы дөреслек кайчан да булса ватаныбызга барып җитәчәк. Ил өчен, халкыбыз өчен әйдәгез, егетләр, киттек!»

Шагыйрьнең бу мәгънәле сүзләре минем күңелемә мәңгегә уелып калды. Шуннан соң Муса Җәлил безне Едлинога алып китте.

Берәр сәгать поездда барып, Едлино исемле зур гына авылга килеп төштек. Стансада азрак торгач, 2—3 чакрым җирне җәяү барасы. Бик матур җирләрдән үтеп, урман кырыена урнашкан ачык лагерьга якынлашабыз. Безгә инде немец киеме кигән, җиңнәренә «Идел-Урал» дигән эмблема тегелгән татар, башкорт, чуваш, мордва егетләре очрый башлады. Кормаш белән бер-беребезгә карашабыз — безгә дә шундыйны кияргә туры килер микәнни?! Лагерьга житкәндә корал склады алдындагы сакчылар янынннан үттек. Атлар сараен узып, бераз барганнан соң, артистлар барагына да килеп кердек. Анда торучы артистлар һәм музыкантлар бөтенесе немец киемендә иде. Зиннәт Хәсәнов һәм Габдулла Батталов белән кочаклашып күрештек, аларның да немец киемендә булулары безгә башта бик сәер тоелды.

* * *

**1943** елның 15 апреленнән бирле Радом шәһәре янындагы Едлино дигән авыл кырыена урнашкан легионда яшибез. Безне артистлар барагына урнаштырдылар. Муса Җәлил белән Гайнан Кормаш урманга барып бик озак сөйләшеп кайттылар. Муса икенче көнне китте. Ул киткәч, Кормаш Габдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов һәм мине чакырып: «Әйдәгез әле, егетләр, урманга барып, саф һава сулап кайтыйк. Урманның матуррак урыннарын караштырыйк. Безгә бит спектакль-концертларны шунда әзерләргә туры килер»,— дип, үзе белән ияртте. Без, урман эчен хозур кылып йөри торгач, бер чишмә буена килеп утырдык. Шунда Кормаш безгә Муса Җәлилдән ишеткән хәбәрләрне сөйләп бирде. Ул безгә беренче батальон язмышын хәбәр итте. Немецлар икенче батальонны, фронтка бара торган җиреннән кайтарып, Франциягә илтеп, сакчылар сыйфатында һәм француз партизаннарына каршы көрәшүдә файдаланмакчы булалар икән. Икенче батальонда да яшерен оешма әгъзалары бар, аларга Франциягә баргач та агитация эшләре алып барырга, партизаннарга качып китүне оештырырга һәм француз партизаннары белән бергә, немецларга каршы көрәшергә кушылган. Беренче батальон белән авызлары пешкән фашистлар, бу батальондагы шикле, ягъни совет пропагандасы алып баруы мөмкин дип исәпләнгән әсирләрне чүпләп, концлагерьларга озатканнар.

Кормаш безнең күзләргә туп-туры карап әйтте: «Беләсезме, без ни өчен капеллага килдек? Без монда яшерен оешманың барлыгын белеп һәм анда эшләргә дип килдек. Муса Җәлил тарафыннан төзелгән оешманы кинәйтергә кирәк. Моның турында күп сөйләргә ярамый. Үзегез беләсез. Муса Җәлил миңа әйтте, яшерен оешмага керүче егетләрнең ант итүләре кирәк. Оешмага серне кемгә дә сөйләмәслек, ил өчен үз җанын корбан итәргә әзер торучы, Ватанга чын йөрәктән бирелгән егетләр генә кирәк, диде. Муса Җәлил тиз көннәрдә Едлинога киләм, дип китте».

Без урманнан туп-туры баракка кайттык. Капеллада барлыгы 14 кеше бар иде. Шуннан уникебез бер баракта торабыз. Муса Җәлилнең тәкъдиме белән Рушад Хисаметдинов труппа башлыгы, Гайнан Кормаш художество җитәкчесе һәм режиссер булып эшләде. Алар икесе дә артист та, музыкант та түгел. Үз гомерләрендә сәхнә күрмәгән Хәсәнов белән Батталов та артист булдылар. Мин исә — мандолинада бик үк яхшы уйный алмыйм, нота белән уйнау түгел, аны укый да белми торган бер кеше — музыкант булдым.

Рушад мандолинада яхшырак уйный, әмма ул да нотаны белми иде, шулай да дирижер булып алды. Гарәф Фәхретдинов (Дим Алиш) яхшы гына җырласа да, беркайчан да артист булмаган. Бу эшләр безгә фәкать маскировка өчен генә кирәк иде. Капелла артистларының яртысы — яшерен оешма әгъзалары. Артист булу фашистларга каршы пропаганда эшләрен алып баруда иң яхшы корал иде.

Апрель ахырында Муса Җәлил Едлинога килде. Без инде берәм-берәм урманга, чишмә буена җыелдык. Муса Җәлил алдында ант итәбез. Беренче — Кормаш, икенче — Хәсәнов, өченче — мин, дүртенче булып Батталов... Бу антның мәгънәсе болайрак иде:

> **«Командирның боерыгын сүзсез үтәргә. Ил өчен чын йөрәктән хезмәт итәргә, кирәк җирдә җанны корбан итәргә, дошман кулына төшкән чакта яшерен оешманың серен ачмаска, нинди авырлыклар булса да түзәргә, серне йөрәктә генә сакларга. Кем антны боза, шуны Ватанны сатучы, фашистлар ялчысы дип хисапларга!»**

Ант итү тәмамлангач, Муса Җәлил: «Егетләр, ни өчен капеллага килүегезне яхшы беләсез. Безнең төп бурычыбыз совет хәрби әсирләренең качуын оештыру, дошманның эчендә фашистларга каршы агитация эшләрен алып бару. Дошманны тар-мар итүдә күмәк эшләвебез кирәк. Без илне бернәрсәгә дә алмаштырып булмаячагын легиондагы әсирләргә аңлатырга тиешбез»,— диде.

1943 елның май башында, бер немец офицеры күзәтүе астында, артистлар труппасын Узедомга концерт куярга һәм экскурсиягә дип алып киттеләр. Безнең Берлинга баруның төп максаты — андагы яшерен оешманың кайбер әгъзалары белән танышу һәм листовкаларны алып кайту чарасын күрү иде. Берлинда безне Муса Җәлил каршы алды.

Берлинда бер төнгә калдык. Кичен киногa кердек. Кинодан соң Муса Җәлил Кормашев, Хәсәнов, Батталов һәм мине Абдулла Алиш торган җиргә алып барды. Таррак бер урамнан Муса белән Гайнан алданрак сөйләшеп баралар.

Алар артыннан без өчәү иярдек. Урамда бик караңгы түгел, анда-монда электр лампочкалары да янып тора. Пыяла ишекләре аша эчтән якты төшкән бина турына житкәч, Муса белән Гайнан шунда кереп киттеләр. Алар артыннан без дә иярдек. Уң кул яктагы ишектән кечкенә генә бүлмәле фатирга кердек. Шунда мин язучы Алишны беренче мәртәбә күрдем. Ул уртача буйлы, куе кара кашлы, кара күзле, чәчен уң якка тараган, иягендә азрак чокыры да бар. Сөйкемле генә кеше, өстендә немец солдаты формасы, башында немец пилоткасы. Һәммәбез дә өстәл янына утырыштык. Өстәлдә — газеталар өеме, тәлинкәләр. Алишның язуы да, ашавы да шул өстәлдә икән. Муса Жәлил безне берәм-берәм аның белән таныштырды. Чират миңа житкәч: «Алиш! Менә Фәрит, сиңа кирәк кеше»,— диде. Бу сүзләре: «Фәритне танып кал, синнән листовкалар килеп алыр»,—дигәне иде.

Алиш фатирында берәр сәгать чамасы сөйләшеп утырдык. Хужа безнең һәммәбез белән ныклап танышты. Кемнең кайда туганлыгын, сугышка чаклы нинди эшләрдә эшләгәнебезне, армиядә кем булып хезмәт иткәннәребезне сораштырды. Соңыннан без солдат өенә кайтып йокладык, ә Муса Жәлил Алиш белән сөйләшеп калды.

Узедом — Берлиннан 150 чакрым чамасы ераклыкта, Балтыйк диңгезендәге кечкенә бер утрау. Легионерларның ял йорты шул утраудагы авылда бер байның өендә урнашкан. Без барында монда Шәфи Алмаз, аның хатыны һәм профессор Фон-Менде килде. Монда без бер атнадан артыграк булдык, концертлар куйдык. Муса Жәлил гел безнең белән бергә иде. Ул «Шүрәле» дигән пьесасын яза башлады. Жәлил музыканы бик ярата. Гарәф Фәхретдиновның жырлавын бирелеп тыңлый, минем мандолинаны алып уйный, моңлана иде. Муса Жәлил безгә үзенең язган шигырьләрен берничә тапкыр укыды, шигырьләре күңелгә нык тәэсир итә иде.

Узедомда Кормаш та үзенең «Ил кызы» пьесасын язып бетерде. Кормаш аны язганда Мусадан бик күп киңәшләр алды.

Узедом янында, Балтыйк диңгезе ярында кечкенә генә бер шәһәр бар. Без анда барып йөрибез, диңгездә су коенабыз. Бу шәһәрдә Украина, Белоруссиядән куып китерелгән егет һәм кызлар күп иде. Алар завод-фабрикаларда һәм байларда эшлиләр. Муса Жәлил бу яшьләр танцыга жыела торган жиргә безне дә алып бара, үзе, биемичә, ыгы-зыгыдан файдаланып, үзенә кирәкле кешеләрне күрә, немецлар белән ни турындадыр гәпләшә иде.

Без Берлинга китәр алдыннан Узедомга Симаев, Шабаев һәм Булатов килеп китте. Алар белән дә таныштык. Без аларның монда ни өчен килгәннәрен белмәдек. Алар Муса Жәлил белән генә серләштеләр. Мин аларның яшерен оешма әгъзалары икәнлекләрен белми дә калдым.

Узедомнан кайтышлый Берлинда тагын ике көн булдык. Беренче көнне безне Шәфи Алмазның ышанычлы кешесе Солтан Гарипов һәм безне күзәтүче немец офицеры Тергартен зоопаркына экскурсиягә алып бардылар. Экскурсиядә Муса да безнең белән йөрде. Зоопаркның эчендә без берничә төркемгә бүленеп, төрлебез төрле якка таралдык. Солтан белән немец офицеры башка төркем белән китте. Шунда Гайнан Кормаш белән Рушад Хисаметдинов маймыллар читлеге тирәсендә арткарак калдылар. Алар янына Муса Жәлил килеп, читлекнең икенче ягына чыгарга ымлады. Муса Жәлил туган илдәге хәлләр, фронт вакыйгалары, Совет армиясенең жиңүләре хакында сөйләде. Муса Радом яшерен оешмасы ничек эш алып барырга тиешлеге турында әйтте. Яшерен оешма аерым төркемнәрдән торырга, һәр төркемдә өч-дүрт кешедән артык булмаска тиеш, чөнки бер төркем фаш ителсә дә, башкалары сакланачак. Шуңа күрә төркем эчендәгеләр башка төркемдәгеләрне һәм аларның эшләрен белмәскә тиешләр.

Соңыннан һәммәбез зоопарк ишегалдына жыелдык. Безне капка янында Солтан һәм немец офицеры көтә иде. Без янадан солдат өенә кайттык. Кичен күпләр кинога киттеләр. Без, Кормаш, Хәсәнов, Батталов һәм мин, Абдулла Алиш торган жиргә тагын бардык. Анда Әхмәт Симаевны очраттык. Ул гадәти киемнән, ябык кына, сарырак бер егет. Аның сөйләшү рәвешеннән кызу канлы, бик үткен, житез мишәр егете икәнен чамаларга була. Үзе радиоузелда эшли икән. Әхмәт: «Иптәшләр, миңа эшкә барырга кирәк»,— дигән булып, бераздан чыгып та китте. Алишның әле сакал-мыегы да кырылмаган, ахрысы эше тыгыз булган. Шунда Батталов: «Алиш, әллә син Лев Толстой булмакчысыңмы, сакал жибәргәнсең»,— дип шаяртты. Алиш та елмаеп кына: «Вакыт житкәч, егет тә булырбыз әле»,— дип куйды.

Кормаш Алишка безнең иртәгә кич белән китәчәгебезне әйтте. Бу аның листовкаларны әзерләп куярсыз, дигән ишарәсе иде. Абдулланың күңеле күтәренке иде. Ул үз башыннан кичергәннәрне, ачлык-ялангачлык, жәбер-золым һәм

кыйналулар күрүе турында сөйләп утырды. Үзенең балалар язучысы икәнлеген әйтте. Алиш күп сөйләми, куркусыз һәм сер саклый белә торган кешедер, дигән тәэсир калдыра.

Икенче көнне безне тагын экскурсиягә алып киттеләр. Күп кенә тарихи-истәлекле урыннарны күрсәттеләр. Кытай артистлары уйный торган циркта да булдык. Төнлә белән тагын Алиш квартирасына бардык. Монда, Әхмәт Симаевтан башка, Фоат Булатов, Гариф Шабаев та бар иде. Алар ашыгып чыгып киттеләр. Алиш, бу егетләр үзебезнекеләр, типографиядә эшләүче иптәшләр, дигәч, без тынычландык. Без инде аларның да яшерен оешма әгъзалары икәнлеген чамаладык.

Алиш бүлмәдән чыгып китте һәм озакламый үзенең яшергән жиреннән немец телендәге газеталарга чорналган листовкаларны алып керде. Листовкалар ике кечкенә кул чемоданына тутырылган иде. Өскә теш щеткасы, теш порошогы, сабын һәм тагын немец телендә язылган газеталар куйдык. Алиш безгә ул чемоданны вагонда барганда тәрәзә янына куярга, андый-мондый хәвеф чыкса, шыпырт кына тәрәзәдән ташларга кирәклеге турында әйтте. Ташларга өлгерми калган очракта, аның кемнеке икәнен белдермәскә кирәк, дип искәртте Алиш. Чемоданнарның берсен Зиннәт Хәсәнов, икенчесен мин алдым.

Листовкалар концертлардан соң лагерьларда немецлар аз булган чакларда яки алар эчү мәжлесләре үткәргән вакытта таратылды.

Аларның эчтәлеген Муса Җәлил белән Гайнан Кормаш яза иде. Листовкалар Берлиндагы газета типографиясендә Абдулла Алиш житәкчелегендә яшерен рәвештә басылды. Листовкалар башка группаларда да, шулай ук өченче батальонда һәм эшче лагерьларда да таратылды.

Июнь башларында Муса Җәлил тагын Едлинога килде. Берничә көн буе капелла һәм яшерен оешма эшләрен күзәтте, киңәшмә үткәрде. Без тагын урманга жыйналдык. Муса Җәлил: «Инде фашистлар өченче һәм дүртенче батальоннарны фронтка жибәрмәскә булдылар. Бу батальоннарны немецлар каравыл хезмәтенә, партизаннарга каршы көрәштә, эшелоннар озатуда файдаланалар. Батальоннардан партизаннарга китүчеләр күп булса да, аларны яңа кешеләр белән тутырып торалар. Чынлыкта, без күпме генә тырышсак та, батальоннарның күче зәгыйфьләнми. Инде нишләргә кирәк? Инде без легиондагы батальоннарны коралы восстаниегә әзерләргә тиешбез. Моның өчен партизаннар белән нык элемтә булдырырга, шул максаттан легионерларның күбесен партизаннар ягына чыгарырга кирәк»,— диде.

Ул Радом яшерен оешмасының житәкчесе итеп Гайнан Кормашевны билгеләде. Алар, үзара киңәшләшеп, оешманы берничә группага бүлделәр. Безнең беренче элемтә группасының житәкчесе Кормаш үзе булды. Икенче — пропагандистлар группасының житәкчесе итеп Фоат Сәйфелмөлеков, өченче — радистлар группасы житәкчесе итеп Рушад Хисаметдинов билгеләнде. Моннан соң инде Муса Җәлил фәкать группа башлыклары белән генә очраша, киңәшмәләрне алар белән генә үткәрә башлады. Группа башлыклары исә үз кул астындагылар белән эш алып бардылар. Рушад Хисаметдинов Едлинога 1943 елның башларында китерелде һәм музыка капелласында эшли башлады. Ул безгә Алма-Атада туганнары, хатыны Таифә һәм улы барлыгын сөйләгән иде. Аның группасында радист Омаров, Әхмәтов, Маликовлар бар иде. Омаров белән Әхмәтов легион радиоузелында эшләделәр. Әхмәтов яшерен оешма тәкъдиме буенча денщик булып урнашып, Фон-Зикендорф радиоалгычыннан да оста файдаланды, кирәкле хәбәрләрне житкереп торды. Яңа хәбәрләр ышанычлы кешеләр аркылы башка әсирләргә таратылды.

Радиоалгычтан Совинформбюро хәбәрләрен тыңлау бик мөһим һәм куркынычлы эш, әлбәттә. Боерыкны үтәү вакытында кулга төшкән кеше үзен фәкать үлем җәзасы гына көтүен белсә дә, радистлар бу эшне чын батырларча башкардылар.

Пропагандистлар группасында Гали Корбанов (Мичурин), өченче батальоннан Абдуллин һәм Әмировлар эш алып бардылар. Бу группаның житәкчесе — 1915 елгы Фоат Сәйфелмөлеков уртача буйлы, озынчарак битле, сирәгрәк чәчле, күзлек киеп, чәчен артка тарап йөри иде. Ул үзенең Сәмәрканд планлаштыру институтында укыганын, аны тәмамлагач плановик булып эшләгәнен сөйләде. Фоат дүртенче батальонда пропагандист иде. Алар ышанычлы кешеләрне жыеп, «Идел-Урал» газетасын укыйлар, Совет Армиясенең хәрәкәте турында Совинформбюро хәбәрләре хакында фикер алышалар, дошманның ялган хәбәрләрен фаш итәләр. Пропаганда эшендә бөтен нәрсә файдаланыла. Мәсәлән, легионның командирлары һәммәсе немецлар, димәк, немец безгә ышанмый, аның мак-

саты — безне үз туганнарыбызга каршы күтәреп, пушка корбаны итеп файдалану. Безнең кебек көнчыгыш халыкларын кешегә дә санамауларын фашистлар үз газета-журналларында әледән-әле язып торалар. Шушы шартларда антипропаганда эшен саклык белән генә алып бару кулай, чөнки арада шымчылар да булырга мөмкин иде.

Өченче батальонда пропагандист булып эшләгән, Крушинодагы яшерен оешма башлыгы Габдуллинга листовкаларның бер өлешен тарату өчен Кормаш бирә иде. Мине Габдуллин һәм Әмиров белән (Әмировның нинди эштә эшләгәнен белмәдем), өченче батальонга концерт куярга баргач, Гайнан Кормаш таныштырды. Яшерен оешма әгъзасы, дигәне, танышыгыз, дип әйткәне хәзер дә исемдә. Кормаш белән Габдуллин урманда очрашып сөйләшәләр иде. Алар сөйләшкән арада мин күп чакта күзәтеп, сакта тора идем.

Ватан сугышына чаклы Габдуллин Башкортстанның кайсыдыр районында райисполком председателе булып эшләгән. Армиядә — өлкән лейтенант. Ул кара кашлы, кара күзле, түгәрәк битле иде, борын төбендә кечкенә генә мыегы да бар. Ул 35—40 яшьләр тирәсендәге кеше иде. Июль башларында немецлар Крушинода урнашкан өченче батальонны Советка каршы сугышка җибәрмәкче булдылар. Габдуллин да шулар белән китәргә тиеш иде. Бу батальон, беренчесе шикелле үк, партизаннар ягына чыгарга алдан хәзерлек күрде. Гайнан Кормаш, Муса Җәлил кушуы буенча, Габдуллинга яшерен оешмада эшләүчеләр исемлеген совет властьларына илтеп тапшыру эшен йөкләде. Кызганычка каршы, өченче батальонны фронтка җибәрмәделәр. Исемлек Габдуллинда калды.

Яшерен оешманың башка группалары да бар иде. Сугышчан ротада Уфадан башкорт егете Садыйков, чуваш һәм мордва ротасында Скоболевлар житәкчелек итә иде. Тора-бара яшерен оешма бик зураеп китте, күп тармакларга бүленгәнө өчен, аны, «Едлино оешмасы» дип кенә түгел, ә «Радом яшерен оешмасы» дип йөрттеләр.

Берлинда «Идел-Урал» газетасы татар телендә латин хәрефләре белән басылды. Абдулла Алиш җитәкчелегендә чыккан бу газеталарда фашистларга каршы сак кинаяләр белән язылган мәкаләләр һәм шигырьләр еш күренә иде.

Июнь башларында Кормаш чакырып алды да: «Мине Муса Җәлил Берлинга пьесамны тикшерергә һәм сәхнәгә куярга рөхсәт алырга чакырды, хәзер шунда китәм»,— диде. Муса белән Кормаш, Шәфи Алмазның баш авыртуыннан һәм сәяси наданлыгынннан файдаланып, пьесаны сәхнәгә куярга рөхсәт алалар. Кормаш Берлиннан кайтканда Алиштан күп итеп листовкалар да алган иде. Муса Җәлил дә Берлиннан килгәндә листовкалар салынган чемоданны үзе белән йөри торган җырчы Фәтхуллиннан күтәртеп йөргәләде. Әлбәттә, Фәтхуллин чемодан эчендә нәрсә барлыгын белмәгәндер. Бу чорда фашистлар легион батальоннарын каравыл эшендә, поляк партизаннарына каршы көрәштә һәм товар эшелоннары озатып баруда файдаландылар. Бу эшелоннар Белоруссия һәм Украина байлыкларын Германиягә, Германиядән фронтка керосин, бензин һәм башка хәрби продукция, кирәк-ярак ташыйлар иде. Аларны озата килгән 25—30 легионердан 10—15 е генә кире легионга кайта. Калганнары, Польшадан безнең чикне узганда, Украина, Белоруссия партизаннарына качып китәләр. Легионның үзеннән поляк партизаннарына, яки немец формасын ташлап, гражданский өс-баш киеме киеп, Польша авылларына качкан әсирләр дә хәтсез булды.

Июль башларында эшелон озатучылар арасыннан 5 кеше Муса Җәлил тарафыннан партизаннар һәм Совет Армиясе белән бәйләнеш тоту өчен җибәрелгән иде. Кызганычка каршы, бу кешеләрнең алдагы язмышы безгә мәгълүм булмады.

Безнең артистлар капелласында Шәрифҗан Гарифҗанов (Әмиров) дигән җырчы бар иде. Ул бик таза, киң күкрәкле, табак битле карарак егет. Үзе Казанда артист булып эшләгән. Калын бас тавыш белән бик матур җырлый иде. Муса Җәлил белән алар Казанда ук таныш булганнар. Аны Муса Кормаш җитәкчелегендәге элемтә группасына кertertте. Гарәф Фәхретдиновка нинди бурычлар билгеләнгән булса, аңа да шундый ук эшләр тапшырылды. Ул тиз арада Муса Җәлил һәм Кормаш шигырьләрен өйрәнеп алды һәм аларны сәхнәдә җырлый иде. Шәрифҗанга поляк авылларындагы аерым кешеләр белән танышып, партизаннар белән элемтә булдыру эше дә тапшырылды. Ул бик күп авылларга барды, күп кешеләр белән танышты. Берничә тапкыр үзе белән Мусаны да авылларга алып барганы хәтеремдә калган. Шуны да әйтәсем килә, Муса Җәлил куль-

твзводтан күп нәрсә көтә, аны яшерен оешманың иң көчле үзәге итеп саный иде. Муса Едлинога килгән чакларында легион кунакханәсендә тора иде. Күп вакытын безнең белән үткәрә. Без аны «Бөркет» дип йөри идек. Чөнки ул һәр жиргә барырга өлгерә, кош шикелле әле Едлинода, әле Крушинода, әле Берлинда, әле Узедомда чагылып китә иде. Без Абдулла Алишны «бөркетнең уң канаты», Гайнан Кормашны «сул канаты» дип, яшерен оешма әгъзаларын исә «бөркет балалары» дип йөртә идек...

Июль ахырында Муса Җәлил тагын Едлинога килде. Беренче көнне артистлар группасы белән шөгыльләнде. Үзенең «Шүрәле» пьесасын, Кормаш белән бергәләп, сәхнәгә куярга әзерләделәр. Ләкин бу эш фәкать маскировка, немецларны алдау гына иде. Легионда кораллы восстание оештырып, баштан партизаннарга, аннан Совет Армиясенә кушылу өчен кичектергесез эш алып барырга вакыт житте. Җәлил үзе белән бер татар офицерын да (аның фамилиясе Саттаров иде шикелле) алып килде. Саттаров, радистлар группасында эшләүче Омаров һәм тагын ике кешене ияртеп, Муса Җәлил әмере буенча, поляк партизаннары белән бәйләнешкә керү өчен легионнан качтылар. Аларның алдагы язмышы турында Муса, әлбәттә, белгәндер, әмма без бернәрсә дә ишетмәдек. Бу вакытта оешма әгъзалары арасында көчле эш алып барылды, әледән-әле яшерен киңәшмәләр үткәрелде. Безнең элемтә группасы белән Муса Җәлил үзе киңәшмә үткәрде. Бу яшерен киңәшмәдә Муса Җәлил, Совет Армиясе һәм партизаннар белән элемтә хәл ителде, дигән иде. «Инде, егетләр, бердәнбер юл калды: йә — жиңү, йә — үлем! Безгә кораллы восстаниегә күтәрелергә вакыт житте. Бөтен легионны партизаннарга алып китәргә кирәк. Партизаннар белән бергә фашистларга каршы көрәшеп, үзебезнең Совет Армиясенә барып кушылу — безнең төп максат булырга тиеш». Восстаниенең 14 августта булырга тиешлеге соңгы минутларда гына беленде. Восстаниегә күтәрелү мәсьәләләре яшерен оешма тарафыннан әзерләнеп беткән иде инде.

Август башларында Муса Җәлил группа башлыклары белән киңәшмә үткәрә. Сакта Гарәф Фәхретдинов тора. Бу киңәшмәдә восстаниегә әзерләнү мәсьәләсе карала. Аерым группаларга заданиеләр бирелә. Пропагандистлар группасы легион командованиесен юкка чыгарырга тиеш. Безнең элемтә группасы корал складын басып алып, коралны легиондагы ышанычлы кешеләргә таратырга, радистлар группасы исә атларны һәм пушкаларны кулга төшерергә тиеш (чөнки Рушад Хисаметдинов, ветврач буларак, ат абзарларындагы кешеләрне таный, ишекләр, юлларны яхшы белә). Гали Корбановка (Мичуринга) немецларның элемтә чараларын юкка чыгару бурычы йөкләнде.

Гали Корбанов Ташкентта юристлар мәктәбен бетергән, армиядә дә юрист булып хезмәт иткән. Бөтен кануннарны яхшы белә, бик үткер һәм житез кеше. Туганнарының Үзбәкстанда яшәвен сөйләгәне бар.

Восстание жиңгәннән соң, легионерлар Крушино аркылы поляк партизаннарына кушылырга тиеш иде. Муса Җәлил тарафыннан Фоат Сәйфелмөлеков Крушинога сугышчан задание белән жибәрелде. Анда батальонны восстаниегә хәзерләү һәм партизаннарга күчү юлларын ачыклау максаты куелган иде. Әмма немецлар Фоатны анда кулга алалар.

Август башында Кормаш мине чакырып: «Син Берлинга барып Алиштан листовкалар алып кайтасың, аның үзенә дә Едлинога килергә кирәк»,— дигән задание бирде. Бу листовкалар кораллы баш күтәрү көнендә таратылырга планлаштырылды. Шуннан соң Кормаш мине Әмирханов дигән скрипач белән Узедомга концерт куярга жибәрде. Ике кешедән нинди концерт булсын инде?! Бу минем Берлинга баруымны каплау өчен маскировка гына иде. Без Узедомда берәр көн торырга, Берлинда пересадка ясаганда Алишны күрергә һәм, заданиене тиз генә үтәп, Едлинога кайтып житәргә тиеш идек. Ләкин мине Узедомда ике гестапо офицеры кулга алды.

Муса 1943 елның 10 августы көнне фашистлар гестапосы тарафыннан кулга алына һәм Варшава төрмәсенә китерелә. Соңыннан, Берлин яшерен оешмасын да «каптыргач», Муса Җәлилне дә башкала төрмәсенә күчерәләр. Без бу хәбәрне Берлиндагы Тегель төрмәсендә ишеттек. 1943 елның 11 августында Радом яшерен оешмасы әгъзаларының күбесе кулга алына. Легионда, эшче лагерьларда, Берлинда кулга алулар һәм яшерен оешма кешеләрен концлагерьларга озатулар август ахырына кадәр дәвам итә. Бу хәбәрне мин Лембург 12а штраф концлагеренда Рәшит исемле егеттән ишеттем.

Шулай итеп, Муса Җәлил яшерен оешмасының бик күп кешесе фашист төрмәсенә эләкте...

* * *

Музыкаль капелла турында аерым, киңрәк итеп сөйлисем килә. Ул Муса Җәлил тарафыннан төзелеп, Радом шәһәре тирәсендә урнашкан легионның дүртенче батальонында «культвзвод» булып саналды. Баштарак бу капелла составында җиде генә кеше иде. Соңыннан, апрель урталарында, ул яңа «музыкантлар» белән тулыланды. Капеллада 14 кеше булып, аларның яртысыннан күбрәге яшерен оешма әгъзалары иде. Культвзводка бернинди корал бирелмәде. Һәм ул хәрби өйрәнүләрдә, сугыш операцияләрендә катнашмады, каравылда тормады. Музыкаль капелладагы артистлар, музыкантлар гитлерчыларга ант итмәделәр. Шуның өчен аларга дошманның иске мундирларын кидерделәр. Бу мундирны кию безгә гарьлек булды, әлбәттә. Фашист концлагерьларында күргән газаплардан да авыррак тоелды. Ләкин яшерен оешманың кушуы буенча без бу эшне үтәргә тиеш идек. Муса Җәлил тарафыннан капелланың художество җитәкчесе, режиссеры булып Гайнан Кормаш билгеләнде. Ә гомуми җитәкчебез һәм дирижерыбыз Рушад Хисаметдинов иде. Капеллада музыкантлардан Гәрәев — аккордеонда, Шәехнур Хәмиев хромкада һәм баянда уйный иде. Сабитов, Маликов, Рәшит Ибраһимов, Кәрим Ходжаев һәм мин кыллы уен коралларында уйнадык. Зиннәт Хәсәнов, Габдулла Батталов, Әмирханов, Шәрифҗан Гарифҗанов (Әмиров), Гарәф Фәхретдинов (Дим Алиш) һәм башка егетләр капелла артистлары булып саналдылар. Болардан тыш, Николай Малышев дигән кеше бар иде. Ул үзе урта яшьләрдә, Горькийда эшләгән һәм шунда гитарада уйнарга, биергә өйрәнгән. Николай фашистларга булган нәфрәтен һич тыя алмады, аларны күзләренә карап сүгә, төрле ямьсез сүзләр әйтә иде. Моны немецлар кичерә алмадылар. Аны лагерь уртасында чишендереп, әсир киеменә киендерделәр дә кайсыдыр концлагерьга озаттылар.

Одесса консерваториясе студенты Борис (яһүд егете) аеруча талантлы булып чыкты. Без аны Бари Кәримов дип йөртә идек. Яһүд икәнен белсәләр, немецлар аны, һичшиксез, юк итәчәкләр иде. Үләсе килмәгәч, ул татарча җырларны бик тиз өйрәнде һәм ягымлы тавыш белән «Урман кызы»н, башка җырларыбызны уңышлы гына башкарды.

Менә шул составта капелла концертлар, спектакльләр куяр өчен әзерлек башлап җибәрде. Репетицияләрне үзебезнең барак янындагы бинада һәм урманнарда үткәрәбез. Без Рушад Хисаметдинов дирижерлыгында шактый гына көйләрне — «Тукай маршы»н, «Сагыну», «Урман кызы», «Дүдәк» дигән җырларны, бию көйләрен һәм тагын ун-унбишләп көйне яхшы гына уйный башладык. Биергә Сабитов, Әмирханов, Ибраһимов, ә русча җырларга («Яблочка»ны) Николай Малышев бик маһир иде. Гәрәев, старшина буларак, артистлар өчен складтан һәм авыллардан өч костюм, берничә күлмәк, ботинкалар һәм кызлар күлмәге алып кайтты. Әмма башка кияргә кәләпүш табылмады. Безгә сәхнәгә яланбаш чыгарга туры килде.

Беренче концерт куйган көн бүгенгедәй хәтердә. Гармунчы Хәмитов «Зур концерт була», дип, рәсемләп афишалар язды. Ул укыган чагында ук рәсем ясау белән шөгыльләнгән икән. Без бу афишаларны клуб, ашханә һәм башка җирләргә ябыштырып чыктык. Концертны якшәмбе көнне төштән соң куярга билгеләнгән иде.

Менә клубка меңләп кеше җыелып, концерт башланды. Конферансье дилбегәсен көлкеле сүзләрне, матур шигырьләрне яттан белүче Гайнан Кормаш алды. Һәм ул иң беренче итеп сәхнәгә безне чакырды. Көчле кул чабулар белән каршы алдылар. «Тукай маршы»н башкардык. Аннары бик шәп итеп Гарәф Фәхретдинов «Сагыну»ны җырлады. «Җизнәкәй»не Гарәф белән кыз ролендәге Әмирханов башкарды. Габдулла Батталов исә Муса Җәлилнең «Хәдичә» исемле шигырен бик матур итеп укыды.

Шул вакытта мин клубта немецлардан кемнәр барлыгын күзәттем. Алар аз иде. Татар телен белмәүләре дә безгә файдалы булды. Шуңа да бернидән шикләнмичә сүзгә керештек. Гайнан Кормаш Муса Җәлилнең «Томаулы гыйшык» шигырен укыгач, тамашачылар гөр килеп кул чаптылар, аны сәхнәгә кабат-кабат чакырдылар. Көрәштәшебез бу юлы Муса Җәлилнең «Кошчык» дигән шигырен укыды. Зиннәт Хәсәнов исә «Висла» дигән шигырь сөйләгәч, бик яхшы җырлый белмәсә дә, «Шахтер», «Сарман» көйләрен башкарды. Хәмиев дигән тоткын бик матур итеп «Сәйдәш маршы»н гармунда уйнады. Аны тамашачылар берничә мәртәбә сәхнәгә чакырдылар. Без — музыкантлар да коры калмадык. «Дүдәк» көен уйнадык.

Гайнан Кормаш тәмам образга керде бит, номерлар арасында көлкеле сүзләрне бик күп сөйләде. Концертның икенче бүлегендә Бари һәүдебез «Урман кызы»н җырлады, берничә бию башкарды. Аны Сабитов алыштырды. Икесенең чыгышы да тамашачыларга бик ошады. Концертның ахырында Гайнан Кормаш «Идел кызына» дигән шигырен укыгач, зал алкышлар белән тулды. Без тагын «Тукай маршы»н башкардык. Шушы беренче концертта ук бик көчле патриотик шигырьләр һәм җырлар яңгырады, әмма аларның авторлары, мәгълүм сәбәпләр аркасында, аталмады:

> Оч, син, кошчык,
> Көчле җырым булып —
> Шушы сиңа соңгы теләгем.
> Тәнем калсын монда
> (Нәрсә ул тән?)
> Барсын илгә минем йөрәгем!
>
> *(«Кошчык»).*

Без, ясканып, яңа концерт программасы әзерләргә тотындык. Яңа патриотик шигырьләр һәм җырлар табу эшенә Кормаш алынды. Башкаларыбыз да тик йөрмәде, яңа көйләр, җырлар, шигырьләр өйрәндек. Концертларны атнага бер мәртәбә куя идек. Артыгына немецлардан рөхсәт булмады.

Менә бер көнне яшерен оешма әгъзалары бергә җыелдык. Шунда Кормаш безгә карап: «Егетләр, бу концертлардан гына файда көтү безгә килешмәс. Үзебезнең пропаганданы көчәйтү өчен башка юллар табарга кирәк. Мәсәлән, радиоузелын файдалана алабыз»,— диде. Әлбәттә, бу фикергә без һәммәбез дә кушылдык.

Шулай көннәрне үткәреп йөргәндә, май ахырларындарак бугай, безнең янга, Едлинога Муса Җәлил килеп төште. Без бу вакытта икенче концертны да бик шәп кенә үткәргән идек инде. Муса Җәлил белән Гайнан Кормаш радиоузел турында фикерләшеп, легион командиры Фон-Зикендорф янына керделәр һәм һәр көнне төш вакытында бер сәгать эфирдан концерт бирергә рөхсәт алдылар. Моңа сөендек, әлбәттә. Тоткынлыкта татар моңнары еш яңгырый башлады. Программаны Г. Кормаш үзе бик оста төзи иде. Ватанга багышланган шигырьләр, җырлар безне тагын да якынайтты. Совинформбюро хәбәрләрен ишетеп тору ниятебез дә тормышка ашты. Рушад Хисаметдинов музыкаль капелла башлыгы сыйфатында, радиога көнгә ике-өч мәртәбә бара һәм андагы егетләр белән нык аралаша башлады.

Музыкаль капеллада җырланган җырлар, укылган шигырьләр, куелган пьесалар, үз халкыбызны, ата-аналарны, сөйгән ярларны сагыну хисен арттыра, дошманга карата нәфрәтне көчәйтә иде. Легионерлар сафларда атлаган чакта да кыю гына җырлар яңгырата иделәр. Менә берсе әле дә исемдә:

> Казарма биек булса да,
> Кошлар оя ясамый.
> Ал булса да, гөл булса да
> Туган илгә охшамый.

Мондый җырлар башка эшче лагерьларда да җырлана иде...

* * *

Тора-бара легионда хәл кискенләште, аерым-аерым качулар, эшелоннарны озатучы легионерлардан партизаннарга китеп баручылар ешайды. Франциягә киткән батальоннан француз партизаннары ягына чыгучылар да хәтсез булган. Легионда листовкалар күренә башлагач, гестапо офицерлары, бигрәк тә капитан Линкс тоткыннар арасыннан яшерен оешма серен ачардай кешене бик җентекләп эзләгәндер. Бер көнне Мәхмүт Ямалетдинов дигән әсирне сугышчан ротадан пропагандистлар янына күчерделәр. Бу июнь азаклары иде. Безнең белән элек бер дә аралашмый торган әлеге әсир баракларга һәр көн керә һәм кичләрен дә безнең белән сөйләшеп утыра башлады. Аннан без шикләнә калдык. Шул вакытта безгә Кормаш: «Егетләр, бу кешедән сакланыгыз!» — дип әйтте. Әмма сынамый торып, кеше турында кистереп кенә хөкем чыгарып булмый иде.

Август башларында Батталов аны Берлинга газета һәм башка кирәк-ярак алып кайту өчен үзе белән ияртеп китә. Алар артыннан шымчылык итәргә фельдфебель Блок та тагыла. «Коерык»ны юлдан яздырып, Батталов Алиштан

листовкалар ала һәм алар Берлиннан 10 август көнне Едлинога кайталар. Батталов алып кайткан листовкаларын Кормашка тапшыра. Зиннәт Хәсәнов белән киңәшләшеп, шул төнне листовкаларны, иске гадәт буенча, үзләренең матрас эченә яшерәләр. Мәхмүт Ямалетдинов бөтен күргәннәрен Линкс белән Блокка житкерә. Кичкә таба легионда гестапо кешеләре, солдатлар һәм офицерлар күренә башлый. Төнге сәгать икедән соң, листовкаларны таратмакчы булып, Кормаш белән Хәсәнов тышка чыгып карыйлар. Анда немецча сөйләшкән тавышларны ишетеп, баракка кире керен яталар. Листовкаларны тарату эше икенче көнгә кала.

1943 елның 11 августында артистлар труппасын һәм пропагандистларны солдатлар ашханәсенә алып китеп, берәм-берәм кулга алу башлана. Шулвакыт гестапочыларның бер төркеме баракта тентү ясыйлар. Кормаш, Хәсәнов, Батталов матрасы эчендә листовкалар табыла. Бу листовкалар кулга төшкәч, Линкснең шатлыгы эченә сыймый. Кулга алынганнарны легион изоляторына ябалар.

Шулай бер көнне Уседомда концерт куярга әзерләнеп йөрибез. Бер гестапо офицеры безнең янда чуала бит. Ул мине күзәтеп йөргән икән. Икенче көнне иртә белән икенче офицер килеп: «Сине Муса Җәлил Берлинга чакырды»,— диде. Минем йөрәгем жу итеп куйды. Ул арада тагын бер гестапо офицеры килеп басты, икәүләп мине тенти дә башладылар. Ләкин берни дә таба алмадылар. Муса Җәлил һәм Кормаш шигырьләре язылган дәфтәремне, кайтып алырмын дип, Едлинода калдырып киткән идем.

Мине Берлинга алып киттеләр. Юл буе кайгырып, үз антыма тугрылыкны сакларга кирәк, дип уйлап бардым. Моабит төрмәсенә яптылар. Төрмә камерасында ике көн буе бер француз егете белән утырдым. Аңардан кәгазь һәм каләм сорап алдым. Ике көннән соң, мине Берлин төрмәсеннән Варшава төрмәсенә алып китү өчен көтү залына алып чыктылар. Залда күзлекле, бил каешы салдырылган Мәхмүт Ямалетдинов утыра иде. Ул миңа сәлам бирде. Теге чакта аңардан шикләнүләребез исемә төште. Безне бер немец солдаты һәм унтер офицер Берлин төрмәсеннән вокзалга китереп, Варшава төрмәсенә алып киттеләр. Ул шунда үзен кулга алынган мескен итеп күрсәтмәкче булды. Поездда Мәхмүт миңа:«Мин Едлинодагы иптәшләрне кулга алганнар дип ишеттем, кемнәр эләкте микән?» — дип сорады. «Мин кайдан белим, аннан киткәнемә берничә көн булды бит инде»,— дип җавап бирдем. «Безне нәрсә өчен кулга алдылар икән?»— ди бу. Мин аның мәгънәсез сорауларына ачуым килеп: «Легионда немецларга хезмәт иткән өчен безне һәм аларны кулга алдылар»,— дидем. Ул шунда миңа бик сынап карады да башын селкеп куйды. Мин тагын: «Туган илгә хыянәт иткән өчен немецларның безгә сөйләшергә рөхсәт бирүләре мине отыры шиккә салды. Шуңа күрә: «Башым бик авырта», дип, күземне йомып йоклаганга салыштым.

Варшава станциясеннән «черный ворон»да мине һәм Мәхмүтне Варшава төрмәсенә китерделәр. Мине «одиночка»га яптылар, ә Мәхмүт машинада утырып калды.

Варшава төрмәсе — биек койма белән әйләндереп алынган ике катлы хәрби төрмә. Койма өстеннән чәнечкеле тимерчыбык тарттырылган, капкадан кергәч, прогулка мәйданы бар. Төрмәдәге тоткыннар арасында немецлар да, руслар да һәм Радом яшерен оешмасындагы татар егетләре дә бар иде. Безнең иптәшләрне бер-ике көн легиондагы изоляторда тотып, ашыгыч сорау алганнан соң, монда китергәннәр. Гали Корбановны азат итеп, үз эшенә кайтарып җибәрделәр. Бу вакытта инде монда Муса Җәлил юк иде. Аны алып киткән вакытта төрмә капкасы янында бик каты кыйнаганнар дип, Кормашка төрмәдәгеләр сөйләгән.

Икенче көнне тоткыннарны йөрергә алып чыктылар. Төрмә рәшәткәсеннән карап торам, Гайнан Кормаш, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, аннары Әмиров, Рушад Хисаметдиновларны күрдем. Прогулка вакытында сөйләшергә рөхсәт итмиләр. Шуңа күрә сүзсез генә аңлашабыз. Өченче көнне Кормашның рәшәткә арасыннан бер кәгазь кисәген җиргә ташлавын күрдем һәм йөрергә чыккач, бик саклык белән генә аны иелеп алдым. Ул миңа: «Онытма антны!» дип язган иде. Мин дә кечкенә генә кәгазьгә: «Үлсәм дә онытмыйм!» дип язып, аны икенче көнне шул ук урынга ташладым. Мондый ысул белән без тагын берничә мәртәбә «хәбәрләштек» әле. Икенче «хат»ында Кормаш Мәхмүт исеме янына фашист билгесе куйган иде. Димәк, безне шул саткан. «Мин дә шулай уйлыйм»,— дип җавап бирдем.

Берничә көн үткәч, сорау алулар башланды. Бер палач башыма, икенчесе аякларыма утырып, мине шланг белән кыйныйлар. Тешемне кысып чыдарга тырышам. «Белмим, бернәрсә дә белмим»,— дигән сүздән башка берни әйтмим.

Кыйнап аргач, аякка бастыралар. Башым әйләнеп тагын егылам. Шуннан соң тагын «одиночка»га ябалар. Аннары тагын — сорау алу, тагын — кыйнау... «Юк, мин бернәрсә дә белмим, белмим!» — диям. Авыз-борыннан кан ага. Фашистлар рәхимсез җәзалыйлар. Хәл беткәч, янадан камерага ябып куялар...

Беркөнне шулай, урындыкка басып, прогулкага чыккан иптәшләрне камера рәшәткәсеннән күзәтәм. Унтер-офицер ишеккә куелган түгәрәк тәрәзәчектән миңе карап торган. Болай әрсезләнүемне ошатмаган, күрәсең, кереп, куллы арганчы, штык белән кыйнады. Аннары, хәле бетеп, тиргә баткач, сүгенә-сүгенә камерадан чыгып китте. Мин бик хурландым, чарасызлыгымнан елап алдым. Бу нинди хәл? Немецлар безне кешегә дә санамыйлар, хайваннан да түбән күрәләр бит!

Сугышчан бурыч үтәгәндә кулга төшкән яшерен оешма әгъзалары бездән күбрәк җәза алдылар. Гарипләнеп йөри алмас хәлгә килделәр. Гайнан Кормашның аксаклап йөргәне хәтердә калган. Батталовның бөтен йөзе шешенке иде...

1943 елның октябрь ахырларында җәлилчеләрне Варшава төрмәсеннән Берлин төрмәсенә күчерделәр. Тоткыннарны ташучы машинада Кормаш, Хәсәнов, Батталов, Хисаметдинов һәм миннән башка кеше юк иде. Гарифҗанов Варшава төрмәсендә калды. Аны гомерлек каторгага, Бухенвальд концлагерена җибәргәннәр. Әмма ул берничә тапкыр үлемнән котылып, бик күп газаплар күреп, туган илгә кайта алган. Бу хәбәрне мин күп еллар үткәч ишеттем...

Һәммәбезнең дә кулы богаулы. Бер-беребезгә сүз катарга рөхсәт юк иде. Менә шунда Хәсәнов нәрсәдер әйтмәкче булып ым каккан иде дә, гестапо офицеры аны штык белән бәргәләп алды.

Төрмәдән вокзалга чаклы «черный ворон»да, Варшавадан Берлинга кадәр поездда алып бардылар. Вагонда Батталовның бер ягында — мин, икенче ягында Хисаметдинов утырып бардык. Төнлә белән шыпырт кына сөйләшеп алырга да җай чыкты. Хисаметдинов пышылдап кына Батталовтан: «Безне кем сатты икән, белмисеңме?» — дип сорады. Баттал: «Мәхмүт саткан», — диде.

Берлин вокзалыннан төрмәгә безне тагын «черный ворон»да алып бардылар. Кулларда — богау. Бер-беребезгә карашабыз. Безне Моабит төрмәсенә алып килделәр. Анда 2-3 сәгать чамасы тотканнан соң, — бирелә урын булмагандыр инде, — Вейдель-Штрасседа урнашкан Тегель төрмәсенә китереп яптылар.

Безнең камераларыбыз өченче катта, бер-берсеннән ерак. Алар барысы да караңгы. Югарыда тимер рәшәткәле кечкенә генә тәрәзә, камера эчендә тумбочка, урындык һәм карават бар иде. Яту урыны вакыт җиткәндә генә ачыла, шуңа күрә теләгәндә сузылып ятарга мөмкинлек юк. Идәне, кирпеч тезеп ясалганга күрә, салкын. Мин прогулкага чыккан кешеләрне рәшәткә аркылы карап торам. Капитан Русановның бер француз офицеры белән сөйләшеп йөрүе күзгә чалына. Йөрергә аларны фәкать икесен бергә генә чыгаралар иде ахрысы. Русанов — Совет Армиясе формасында, башында партизаннар бүреге, озынчарак буйлы, кыскасы, карап торышка матур гына кеше иде.

Союзниклар авиациясе Берлинны бомбага тота башлагач, төрмә сакчылары подвалга төшеп качалар. Тоткыннар, сакчылар юклыктан файдаланып, төрле телдә кычкырышып, иптәшләрен эзлиләр. Без, җәлилчеләр дә, бер-беребезне табарга тырышып, кычкырабыз, җырлыйбыз, сызгырабыз. Баксаң, Зиннәт Хәсәновның камерасы минеке каршысында гына икән. Ул әнә татарча көйләрне сызгыра башлады. Мин дә аңар каршы сызгырып янсә әкрен генә җырлап җавап бирәм.

Бераздан барысы да тына. Сакчылар үз урыннарын алалар. Без тагын һава һөҗүмен көтә башлыйбыз. Бомбалар «телгә килгәч», төрмәдә янадан ыгы-зыгы куба.

Төрмә ишегалдына йөрергә чыккач, Кормаш алдыннан үтешли, аның кулындагы кәгазьне сак кына алып китәм һәм үзем язган «хат»ны бирәм. Шушы юл белән ул миңа «Төн. Төрмә», «Карчыга», «Сез бәхетлесез», «Соңгы сүз» шигырьләрен тапшырды. Кормаш «Карчыга» шигырендә Мәхмүт Ямалетдиновка нәфрәт, ләгънәт белдерә, аның фашистлар ялчысы икәнен фаш итә.

**Бер көнне душта мин Кормаш белән янәшә туры килдем. Күрешкәч, ул миңа карап әкрен генә болай диде: «Фәрит дустым, ишеткәнең бардыр, халыкта моңлырак сүз бар: «Күк күкрәми — яшен яшьнәми, корбан бирми — халык яшәми...» Без корбан булырбыз инде. Ләкин синең турыда бер иптәш тә бернәрсә дә сөйләгәне юк. Ышанам, син туган илгә кайтырсың, атаң, анаң, туганнарың һәм сөйгән ярың белән күрешерсең. Без корбан булсак та, безне ил онытмас, бу эшләр турында халкыма, туганнарыма, Даниямә сөйлә, бу тарихны яз син!»**

**Шунда мин: «Әгәр туган илгә исән-сау кайтсам, үлем сәгатен көтеп ятканда кылган эш-гамәлләребез турында сөйгән халкыма сөйләрмен, кулдан килгәнчә язармын»,— дип дустыма сүз бирдем. Һәм, менә күп еллар узгач, шул изге әманәтемне үтим...**

1944 елның январь-февраль айларында Англия, Америка самолетлары Берлинны бик каты бомбага тота башладылар. Фашистлар өне ут эчендә калды. Мин, шатланып, тумбочка өстенә менеп камера рәшәткәсеннән карыйм. «Фашист-ләгьнәт, ян, син янып бетсәң, җиңү якынлашыр, безне Совет Армиясе килеп коткарыр»,— дип, бомба төшкән саен сөенеп, Бөек Җиңү көне килгәнне көтеп ята идем. Беркөнне бәхетсезлек булды: тәрәзә өлгесе ватылып пыяла кисәге минем битемә килеп керде һәм шактый гына канатты. Әле ярый, күзгә кермәде...

Күп тапкырлар сорау алулардан соң, 1944 елның февраль башларында безне — Кормаш, Хәсәнов, Батталов, Хисаметдинов һәм мине, «черный ворон»га утыртып, автоматлы сакчылар каядыр алып киттеләр. Озак бардык. Килеп төшкәч, бер машинада Җәлилне һәм бер төркем көрәштәшләребезне күреп калдым. «Аларны кайда алып баралар икән?» — дигән уй башыма һич тынгылык бирмәде. Соңыннан белдем: бу җир — суд бинасы икән.

Менә безне бер өйгә алып керделәр. Утырыштык. Башта Кормашны алып киттеләр, соңыннан Хәсәновны, мине, Хисаметдиновны һәм Батталовны, аерым-аерым, сорау алырга чакырдылар. Куллар — богаулы, артымнан пистолет тоткан унтер-офицер бара. Суд залына алып керделәр. Бездән өч немец офицеры (суд «өчлеге») сорау алды. Бер унтер-офицер тәрҗемә итеп торды.

— Яшерен оешмада кайчаннан бирле эшләдегез?

— Белмим, мин һичнинди яшерен оешманы белмим,— дим сорау алучыга. Ул җикеренеп кычкыра:

— Яшерен оешмада эшләүчеләрнең исемнәрен атагыз!

— Мин сезнең «яшерен оешма» дигәнегезне аңламыйм, нәрсә ул? Артистлар капелласын әйтәсезме?

— Хайван, яшерен оешманы белмим, дигән була. Ә бу листовкаларны кем таратты?

— Белмим, бернинди листовканы да күргәнем юк. Атсагыз да сезгә ярдәм итә алмыйм,— дидем һәм үзем, ни генә булса да, тыныч калырга тырыштым. Ул тагын:

— Бу листовкаларны кемнәр таратты?

— Белмим, мин листовкаларны күргәнем дә юк. Белмәгән нәрсәне беләм дип сезне алдарга теләмим. Юк, бернәрсә дә белмим!

— Менә сезнең яшерен оешманың исемлеге, монда син дә язылган, иптәшләрең сине дә яздырдылар,— диде бу.

— Юк, мин бернәрсә дә белмим.

— Без сине үлемгә хөкем итәбез. Әйт дөресен, сөйлә, җиңеллек булыр.

— Юк, белмим, атсагыз да белмәгән нәрсәне беләм дия алмыйм! — Шушы сүзләрне ишеткәч, фашист:

— Сез — хайваннар! Һәммәгезне атарга хөкем итәбез! — дип кычкырды.

Сорау алу нәтиҗәсез тәгәлләнгәч, безне сафка тезеп, суд карары белән таныштырдылар. Тәрҗемәче унтер-офицер безгә: — Сезнең һәммәгезне атабыз,— диде.

Шуннан соң безне сакчылар, машинага утыртып, вокзалга алып бардылар да поезд белән каядыр алып киттеләр. Бу юлы кулларга богау салмадылар. Тегель төрмәсендә Гайнан Кормаш, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Батталов һәм капитан Русанов калды. Аларның язмышын соңрак ишеттем.

Шулай итеп, без, Рушад Хисаметдинов белән үлем камераларында коточкыч газаплар күреп, алты ай да 15 көн яттык... Лембург станциясенә килгәч, сакчы белән гестапо фельдфебеле Блок мине үзе поездан төшерде. Иптәшләрем белән саубуллаштым, ә аларны каядыр арырак алып киттеләр. Менә шул вакытта инде мин кадерле сугышчан дусларымнан мәңгегә аерылуымны аңладым...

Мине бер немец солдаты белән фельдфебель Блок Лембургтагы 12а штраф-ной концлагере начальнигына алып барды. Аның кабинетында бер тәрҗемәче дә утыра иде. Мин шул вакыт кыюланып, Блоктан көрәштәшләремнең язмышы һәм ни өчен мине монда алып килүе турында сорадым. Ул бер кәгазь кисәге чыгарып күрсәтте. «Берлин хәрби судының карары нигезендә Ф. Солтанбәковка, Г. Кормашның якын дусты булганы һәм листовкаларны таратуда актив катнашканы өчен, гомерлек төрмә җәзасы бирелде»,— диелгән иде анда. Башка күпме генә иптәшләремнең язмышын белергә теләсәм дә, ул бер сүз дә әйтмәде.

* * *

Мин штрафной лагерьда. Өскә ертылган киемнәр, аякка агач башмак киерттеләр. Мәхшәрнең тагын бер этабы башланды. Бараклар күп, аларда французлар, итальяннар һәм совет әсирләре. Мине япкан баракта 25—30 кеше, анда рус, украин, үзбәк, татар, әрмән һәм башка милләт кешеләре шыплап тутырылган. Идән цементтан эшләнгән, ана һәрвакыт су сибеп торалар. Прогулкада 30 минут кына булабыз. Ишекләр йозакта, хәтта хаҗәтебезне үтәү дә баракта башкарыла, шуна күрә һава бик начар, дымлы. Немецларга инде безнең яшәвебез кирәк түгел, алар ничек булса да безне сындырырга тырышалар, төрле авыруларга дучар итәләр.

Бу концлагерьда Сәмәркандта үзем белән бергә укыган үзбәк егете Ибәтовны һәм татар егете Рәшитне очраттым. Өчәүләшеп кайгыларны бүлешә идек. Беркөн шулай барак эчен карап йөргәндә, аның стеналарында, ишекләрендә, тәрәзә яңакларында пәке белән уелып язылган сүзләрне укый башладык. Бу язуларда рус фамилияләре һәм еллар язылган. Исебез китте: монда Беренче бөтендөнья сугышы вакытында ук әсир төшкәннәр утырган икән бит. Ләгънәт төшкән ошбу төрмәгә без дә эләктек, дип сөйләшәбез.

Бер айдан соң авыр эшләрдә эшләтер өчен безне этап белән Болхин концлагерена алып киттеләр. Биредә ашауны бераз яхшырттылар. Бер барактан икенче баракка йөрергә дә рөхсәт итәләр иде. Салам өстендә, нарларда ятабыз. Ләкин, каһәр төшкере, борча төннәр буе йоклатмый иде. Бер айдан соң 258 нче концлагерьга, шахтада эшләргә киттек.

Бу лагерь Эльзас-Латорингиядә булып, Франция белән Германия чигенә якын гына урнашкан иде. Без тимер руда чыгара торган шахтада эшлибез. Кич белән бараклар ябыла, өстән бикләп куялар. Иртә белән сәгать биштә уятып, чәй белән 200 грамм ипи бирәләр һәм, стройга тезеп, конвой белән шахтага алып китәләр.

Көннәрдән беркөнне Хәмзә Еналиев белән таныштым. Ул Пенза өлкәсе Мазарлы авылыннан, үзе шофер икән. Хәмзә мине Якушев белән таныштырды. Сөйләштек. Урманда француз партизаннары бар, диләр. Эшне кайдан башларга соң? Соңгы чара — концлагерьдан качу!

Беркөнне шахтада, зур гына руданы вагонеткага күтәреп салам дигәндә, кулдан төшеп китте дә сул кулымны суеп та алды. Мин моңа артык игътибар бирмичә, тоттым да чүпрәк белән бәйләп куйдым. Шахтадан чыккач, рәтләп юмыйча, бер-ике көн шулай йөрдем. Өченче көнне кулымның суелгән җире үтереп сызлый башлады, шешеп чыкты. Миңа иптәшләр: «Санчастька бар, кулыңны да төзәтерсең, хәл дә алырсың», — диделәр.

Мин ризалаштым. Санчастьтагы врач әсирлеккә төшкән үзебезнең совет докторы булып чыкты. Ул, дарулар сөртеп, кулымны бик шәпләп бәйләп куйды һәм үземне авырулар янына яткырды. Монда баланданы мулрак бирәләр икән. Эш тә юк, туйганчы йокларга да була.

Мин санчастьтә шактый көннәр хәл җыеп яттым. Аякларга да көч керде. Тик бу «җәннәт» озакка бармады. Менә беркөнне санчастька немец офицеры килде дә мине тагын баракка куып чыгарды. Янә шахтада эшли башладым. Хәл бар, инде безгә качарга кирәк. Ә ничек итеп? Юлын-әмәлен эзлибез. Безне 2-3 кешелек төркемнәргә бүлеп, анда эшли торган шахтерларга беркеттеләр. Хәмзә белән мин шул җирдә торучы шахтер француз картына эләктек. Ул безнең белән немецча сөйләшә, ә без бернәрсә дә аңламыйбыз. Шулай да тормыш мәҗбүр итте, бер-беребезне аңларга тырыштык. Аның белән якынаеп киттек. Ул безгә һәр көн, аз булса да, ипи, сигарет бирә башлады. Үзенең күп еллар шушы шахтада эшләгәнен аңлатты.

Тор-бара без аннан француз партизаннарының кайсы тирәдә урнашканын сорадык. Ул шүрләп калмады, үзе белгәнчә сөйләде, шуңа күрә аның җавабыннан канәгать калдык. Соңрак аннан компас һәм карта табып бирүен үтенеп сорасак та, булдыра алмады. Бәлки ул теләмәгәндер, әгәр без качсак, аңарга да авырлык төшүен белә иде ул. Шулай булса да, партизаннарның кайсы җирдә икәнен аңлатты.

Качасы көнне шахтада озаграк торып, өскә соңлап чыгарга һәм икенче группа составында кайтырга план кордык. Чөнки монда сакчылар азрак була иде.

1944 ел. Июль аеның ахыргы көне. Менә без стройда барабыз. Шахтадан берәр чакрымнар киттек инде. Таш юлдан 100—150 метр чамасында, куаклыклар башлана торган җиргә җитү белән, мин команда бирдем. Капылт кына карбит

лампаларын, аяктагы колодкаларны ташладык та, өчебез өч якка сибелдек. Бөтен көчкә чабабыз. Артыбыздан ата башладылар. Пулялар сызгырышып колак төбеннән үтә. Җән-фәрман йөгереп куаклыкка барып кердек. Өчебез дә исән-сау, сөенешәбез. Шулай итеп, без дошман кулыннан котылдык...

Без партизаннарны 15 көн эзләдек. Көндез белән урман читенә чыгып, юлларны тикшереп куябыз. Төнлә белән шул юл белән китәбез. Авылларга барып, бакчаларга кереп, бәрәңге, алма җыябыз, кайчакта немец абзарыннан тавыклар да эләктерәбез һәм пешереп ашыйбыз. Урманда партизаннар торган урыннар күп, ләкин аларның учаклары күптән суынган...

Беркөнне тамак туйдыргач, юлга чыгып караштыргалап торганда, авылдан килүче немец крестьяннарын күрдек. Алар янына барып, ипи, тәмәке сорап алдык. Кәеф күтәрелеп китте. Урманга кереп яттык. Шулай күпме вакыт үткәндер, колакка тавышлар ишетелә башлады. Карасак, немец солдатлары безне урап алганнар. Кулларны күтәрттеләр дә частька алып киттеләр. Немец офицеры ниндидер приказ бирде һәм безгә кирәкләр тоттырдылар. Басуга юнәлдек. Ике метр озынлыгында, бер метр киңлегендә чокыр казырга куштылар. Харап булдык, үзебездән кабер казыталар, безне шушында күмәчәкләр икән, дип тирән шөбһәгә калдык. Берәр метр тирәнлектә казыгач, бер солдат килеп, безне тагын частька алып китте. Анда: «Сез — партизаннармы?» — дип, сорау алып, берничә мәртәбә каты гына кыйнадылар, хәтта бер мәлне атмакчы да булдылар. Шуннан соң без үзебезнең 258 нче концлагерьдан качканыбызны әйттек. Алар шул концлагерьга шалтыраттылар һәм күпмедер вакыттан соң аннан бер унтер офицер белән ике солдат килеп тә житте...

Бу партизаннар лагере без торган концлагерьдан алты чакрым ераклыкта иде. Безне таш юлдан бер торгызып, бер яткырып алып бардылар.

Мәнә берничә көн элек качып киткән лагеребез. Унтер офицер мине тентеп, үз кулым белән ясаган блокнотымны ертып ташлады, мылтык приклады белән сугып җибәрде. Бу блокнотта Муса Җәлил һәм Гайнан Кормаш шигырьләре язылган иде. Кадерле ядкарьдән аерылу бик авыр булды.

Шуннан элекке иптәшләребез янына баракка кайттык. Бездән яңа хәбәрләр сорашалар һәм үзләренең паекларыннан сындырып ипи, тәмәке бирәләр. Без үз башыбыздан үткән хәлләрне сөйләдек. Мәнә иртә белән тагын шахтага барабыз, үзебезнең француз мастерын күпме генә эзләсәк тә таба алмадык. Аны инде гестапо әллә кайчан кулга алган икән. Калган язмышын белә алмадык.

Беркөнне шахтаны самолетлар бомбага тоткач, безне этап белән башка лагерьга алып киттеләр. Бу вакытта фашистлар чигенә башлаганнар иде. Шуңа күрәдер, рәтле-башлы эш булмады.

Берникадәр вакыт узгач, безне Радалбин концлагерена алып килделәр. Бу лагерь тау кырыена урнашкан, анда да бик күп әсирләр газап чигеп яталар иде. Союзникларның самолетларын күзәтәбез. Алар бик еш очалар. Фашистлар исә, котырган эт шикелле, күзләре кызарган, нишләргә дә белмиләр. Аларга инде үлем исереклеге кергән иде.

Мәнә кыш та килеп житте. 1945 елның январь-февраль айлары.Союзниклар бу шәһәрне бомбага еш тота башладылар. Бәлки шуңадыр, безне эшкә йөртмәделәр...

Март башларында фронт без торган шәһәргә якынлашкач, әсирләрне җыеп, каядыр күчерергә карар кылдылар. Көндезен авылларда, урманнарда тоталар да, төне буе куалап алып баралар. 15 көннәр үткәч, күп әсирләрнең хәле бетә башлады, авырулар да күбәйде. Андыйлар белән бик чиләнмәделәр, сафтан чыгарып алып калалар да, берәр чакрым киткәч, автоматлардан атып калдыралар иде. Бу бит: «Сугыш бетә!» — дип торган вакытта! Без ничек тә егылмаска тырыштык, җае чыккан саен, кулдагы йөзекләрне, уенчыкларны авылларда ипигә, бәрәңгегә алыштыра идек.

Америка, Англия самолетлары шәһәрне дә, тимер юлларны да бертуктаусыз бомбага тоталар иде. Без шатланабыз. Мәнә тиздән азат булырбыз, дип өметләнәбез. Инде лагерьдан качуны да файдасыз дип таптык. Бу вакытта качкан кешеләрне сүзсез ату турында приказ бар иде. Һәм фашистлар аны «намус» белән үтәделәр дә.

1945 елның 24 апрелендә бу лагерьны «нейтраль зона» дип билгеләп, ак флаг элеп куйдылар. 25 апрель көнне иртә белән чыгып карасак, бөтен сакчылар качып беткәннәр. Безгә тәрҗемәче килеп, бараклардан чыкмаска, лагерь эчендә бер генә әсир дә йөрмәскә тиеш, дип әйтеп китте. Шуннан 3-4 сәгать үткәндерме, Америка танклары килеп житте. Солдатлар, лагерь эченә кереп, безнең белән исәнләштеләр һәм әлегә беркая да таралмаска тиешлегебез турында әйтеп чыгып кит-

теләр. Менә без канэчкеч унтер офицерны эзлибез. Аны табып, кирәген бирмәкче булабыз. Ләкин аның инде монда эзе дә, исе дә калмаган...

Шуннан соң без бишәүләшеп лагерьдан чыгып киттек һәм тау кырыендагы көтү йөргән якка чаптык. Бер сарыкны эләктереп, тиз генә суеп чистарттык та, баракка алып кайттык. Менә беребез кәстрүл алып килә, беребез утын әзерли, беребез су китерә. Мин, итне турап, пешерергә куйдым. Шуннан, бишәүләп утырдык та, бер сарыкны ашап та бетердек.

Безне Америка армиясе коткарды. Һич онытасым юк: 1945 елның 25 апреле иде бу!

Мин бер татар капитаны белән таныштым. Анарга үземнең баштан үткән хәлләрне сөйләдем. Муса Җәлил белән яшерен оешмада эшләгәнемне әйттем. Үземнең төрмәләрдә күргән газапларны сөйләдем. Ул миңа: «Әгәр легион сүзен әйтсәң, шаһитлар булмау сәбәпле, сине 25 елга төрмәгә ябачаклар. Бу турыда син әлегә бер сүз дә ычкындырма! Кайчан исән калган иптәшләреңне табарсың, шул вакытта сөйләрсең»,— диде.

Фильтрация үткәч, мине 27 нче гвардияче мотоукчы полкка сапер-танкист итеп алдылар. Мин тагын үзебезнең армиядә 6 ай хезмәт иттем. Урманнарда качып калган «СС» солдатлары белән көрәш алып бардык. Ләкин бу вакытта фашистлар армиясе көчсез иде инде...

Укытучы буларак, мине 1945 елның 15 декабрендә армия хезмәтеннән азат иттеләр. 1946 елның 15 гыйнвар көнне өемә кайтып җиттем.

Мин Карши шәһәренә барып педтехникумның читтән торып уку бүлегенә завуч булып урнаштым. Бераз вакыт үткәч, урта мәктәптә математика укытучысы Мәрвә Шәриф кызы Семикова белән 1946 елның март аенда туебыз булды. Матур гына яши башладык.

Көннәрдән беркөнне мине төнге сәгать 3 тә КГБга чакырдылар. Анда татар майоры сорау ала башлады. Русча гына сөйләшә. Пистолетын өстәлгә куеп, минем атам-анамны кабәхәт сүзләр белән сүгеп: «Син нигә әсирлеккә төштең?»— дип мәсхәрәләргә тотынды. «Син кемнәрне беләсең? Әсирлектә кем булып эшләдең? Синең фамилияң ничек иде?»— мин бу сорауларга уйлап кына җаваплар бирдем. Бераздан ул бер лейтенантны чакыртып кертте. Ул мине башка бүлмәгә чыгарып, тәмәке тарттырды. Әзрәк тынычлангач, өйгә кайтарып җибәрде. Икенче көнне шул ук майорга тагын чакырттылар. Ни хикмәт, бүген ул ипле генә сөйләште. «Мин кичә кызыбрак киткәнмен, кичерегез»,— диде. Мондый чакырулар айга бер кабатланып торды. Ләкин әле мин Муса Җәлил турында бер сүз дә әйтмәдем. Чөнки көрәштәшләремнән исән калган иптәшләр миңа билгеле түгел иде.

Менә Муса Җәлил турында мәкаләләр, аның шигырьләре газет-журналларда чыга башлады. Радиодан М. Җәлилгә Герой исеме бирелү хакында әйтелде. Шуннан соң мин, өлкә комитетында эшләүче бүлек башлыгы Усмановка барып, Муса Җәлил турында сөйләдем. Ул миңа Казанга, Гази Кашшафка истәлек язып җибәрергә киңәш бирде. Шуннан соң, мин «Аларны ил тәкъдир итәр» дигән мәкалә җибәрдем.

Гази абый белән хатлар алыша башладык. Ул мине ике елдан бирле эзләткән икән. Минем исән калуым турында аңа Рушад Хисаметдинов сөйләгән...

«Син әсирлектә булгансың, тәрбияче була алмыйсың!»— дип мине өч мәртәбә эштән чыгардылар. Ләкин мин, бүтән җирләргә барып, тагын педагог булып урнаштым.

Бу дәвердә хатыным Мәрвә Шәриф кызы белән өч бала — Фоат, Флера, Венераларны үстердек, тәрбия бирдек. Улыбыз аспирантура бетереп, хәзер Казан дәүләт университетында доцент булып эшли. Математикадан дәрес бирә. Флера кызым — инженер-химик. Венера кызым — теш табибы булып эшли. Хәзерге көндә алты оныгыбыз бар...

1959 елның августыннан башлап, мине Муса Җәлил юбилейларына чакырып торалар. Андый чакта инде без истәлекләр сөйлибез. «Дөреслек барыбер җиңде,— дип шатланабыз. Фашист тоткынлыгында башлары киселгән көрәштәшләребез орденнар белән бүләкләнделәр. Миңа да орден һәм күп кенә медальләр бирелде. «Үзбәкстанның халык мәгарифе отличнигы» дигән бүләккә дә лаек булдым. Хәзер пенсиядә ял итеп, илгә тынычлык теләп, картлык көнебездә шөкер кылып яшибез...

# ШАГЫЙРЬЛӘР, ФРОНТ ҺӘМ ХАТЛАР...

* * *

*Полевая почта*
*06572 «Е»*

*19.VI.43 ел.*

**Нури дус!**

Сагынычлы сәлам сиңа. Терелгәнсең, «Зоя»ны уңышлы итеп бетергәнсең. Котлап кулларыңны кысам. Тулысы белән «Зоя»ны һәм аннан соң язганнарыңны бик укыйсым килә дә бит, каян алыйм. «Зоя»ны Мәрьям Дибаева да мактап язган.

Язгалыйм. «Совет әдәбияты»н, «К. Татарстан»ны караштыргаласаң, күргәлисеңдер. Ләкин барысы да чыгып өлгерә алмый. Май-июньдә «Шакир Шигаев» дигән пьеса бетердем. Озакламый Казанга җибәрәм. 4 пәрдә, 9 күренештә. Үземчә, начар түгел кебек. Ачулары килсә, бәлки Академия театрында куеп ташлаулары бар. Пьесаны озаткач, яңадан шигырьләргә керешәм. Ул зур проза өстендә арыдым. Сәламәтлегем, кәефем яхшы. Госпитальдән соң яңадан сугышка кергәнем юк әле. Урта командир хезмәтен үтим. Үзең беләсең, безнең монда алгы сызык тормышы. Нервылар һәрвакыт уйнаклап, ашкынып тора. Хәзергә хуш. Коптилкамның мае бетеп бара. Хат көтәм.

Кулыңны кысып: **Фатих Кәрим.**

*18.VIII.43 ел.*

**Нури дускай!**

Еракларлан торып кайнар сәлам үзенә. Мин үзем хәзергә исән-сау. Бөтен көч белән хезмәт итеп, көрәшеп яткан көн. Соңгы хатыңны алдым. Йөрәкне аңлап, чын иптәш итеп язган хат күңелне күтәрә, өметне канатландыра, рәхмәт, дус. Шуңа күрә дә синең белән тизрәк күрешәсе, бәхәсләшә-бәхәсләшә, янып-ялкынланып бергәләп иҗат итәсе килә, шулай иҗат итеп, туган поэзиябез күгенә җәүһәрләр тезәсе килә. Үзең аңлыйсың, бу көннәрдә иҗат белән шөгыльләнеп булмый, шигърият юлларын рифмалар белән бизәү урынына автомат дисксына патрон тутыру һәм аны дошманга яудыру белән мәшгуль. Шулай да «Мортаза» дигән поэма төсендәрәк бер башланган әсәрнең черновигы шинель кесәсендә йөри. Ара-тирә шуны тартып чыгарып, берәр генә юл булса да язгалап куям. Бәлки, шулай итә-итә язып бетерермен әле берәр заман. Син үзең нәрсәләр иҗат итәсең? Әдәбият дөньясы ничек сулый? Нинди яңа әсәрләр барлыкка килә? Мин «Моң һәм көч» дигән яңа шигырьләр җыентыгы җибәргән идем. Басабыз, дип хәбәр килде.

Хәзергә хуш. Кулларыңны кысып: **Фатих Кәрим.**

*Татарская АССР*
*г. Буинск, Буинский РВК,*
*лейтенанту Арсланову Н.*

**Нури дус!**

Сәлам үзенә. Әминәгә сәлам.

Шат, күңелле яшисезме, шулай яшәвегезне телим, бергә яшәвегезне телим. Ә менә без хат белән бер-беребезне 6-7 ел буе юатышып, картаеп барабыз инде. Нури, хәзергә үзем исән-сау. Эш күп, көн-төн юлда. Ләкин күңелле. «Кызыл Татарстан»га: «Совет солдаты», «Без бергә», «Сагыну җыры» исемнәрендә өч шигырь җибәрдем, бассалар, укырсың. «Совет әдәбияты»ның 6 нчы санын алдым, шигырьләреңне укыдым, яратып укыдым. Бу сан журналда, синең әйбер-

лардән тыш, калган әдәби әйберләр сыеграклар. Бу фикерләремне редакциянең үзенә дә язып җибәрдем. Тагын ниләр язасың, көтәм. «Рус кызы» чыктымы, кайчан миңа җибәрәсең? Минем «Мортаза» тукталып тора әле, вакыт юк, үзең беләсең. Казанда әдәбият мәйданында тагын нинди яңалыклар бар? Яз. Сагынып: дустың **Фатих.**

*10.10.43.*

**Нури дус!**

Яңа елның беренче көнендә ерактан үзеңә һәм, үзең әйтмешли, илһамчыңа миннән кайнар сәлам. Үзем хәзергә исән-сау әле. «Рус кызы»н алдым. Рәхәтләнеп, игътибар белән укып чыктым. Гомумән, бик ошады. Татар поэзиясенә куанычлы бүләк. Шагыйрьләрчә дуслык белән сөйләшә торган кайбер урыннары бар. Алары инде исән-сау булып, очрашкач сөйләшергә калсын. Поэзия фондыбызга уңышлы хезмәтең белән кулыңны кысам, тәбрик итәм.

Миндә артык үзгәрешләр юк. Артык язган нәрсә дә юк. Язасы килү генә бар. Хәзергә исән-сау. Тагын да көчле, яңа әйберләр яз. Бу яңа ел җиңү һәм безгә илһам дәрьясы китерсен.

Дустың **Фатих.**

*1.1.1944.*

**Нури!**

Ялкынлы сәлам. Хатларыңны алып торам. Рәхмәт. Син эшлисең, иҗат итәсең, мин шатланам һәм сокланам. Минем менә берничә ай инде кулыма каләм алып, бер юл шигырь язганым юк. Беләсең иде, һич кенә дә вакыт юк. Ә язасы килә, башта әллә нинди темалар кайный. Юк, миңа оешмаларыбыз бертөрле дә иҗат шартлары тудыра алмадылар.

«Совет әдәбияты» журналын 7 нче саныннан соң күргәнем юк. Әллә чыкмый, әллә җибәрмиләр. Соңгы Казан, әдәбият хәбәрләрен ишеткәнем юк. Ярый, хәзергә исән-сау бул. Яңа кызыклы хәбәрләр булса, тулырак итеп хат яз. Әминәгә миннән күп сәлам. Гимн тәрҗемә итүгә катнашмадыңмы? Татарча текстны басылса, миңа җибәрегез әле.

Кулыңны кысып: **Фатих.**

*13.2.44.*

## Шәрәф Мөдәррис хатлары

*Полевая почта*
*18715-«А»*

**Туганкай Нури!**

Идрис Туктарның акыллы бер сүзен хәтереңә төшерәм: «Җил шәмне сүндерә, ә ялкынны көчәйтә». Әйдә шулай булсын, аның шулай булуы яхшы да.

Нури! Мин никадәр шат, дустым. Синең хакта, синең сугышчан юлың һәм атаклы «Зоя» хакында миңа томанлы гына хәбәрләр килгәләде, ә мин кызу һәм өлешчә псих бер егет, синең соңгы уңышларың белән котырына-котырына шатландым. Сиңа рәхмәт әйтәсем килә, чын патриот, саф, олы хисле шагыйрь булуың өчен рәхмәт әйтәсе килә.

Ян, туганкай, ялкын булып, үс гөл булып! Син сугыш тәтенен суладың, ә сугыш ялкынын чәч.

Ничек тә җылы хисләр язасым килә, йә ярый, дус, үзең аңла инде. Мин кичә, төнлә, алгы сызыктын кайттым, бүген тагын китәм.

Кичә Фатих Хөснидән хат алдым.

Мин хәзер «Полководец» дигән аһәңле, югары пафослы зур бер әйбер эшлим. Син укырсың, үзеңә җибәрермен.

Нури! Син шигырьләреңнең күбесен безгә җибәр. Безгә ул бик кирәк. Бәлки, «Зоя»ны җибәрерсен. Һичшиксез, басылачак.

Туганкай, хәзергә гафу ит. Менә полкка барып житим, анда, аулак блиндажда, сукыр лампа яктысында озынрак хат язармын. Минем туган авылым — Чүпрәле районы, Каракитә авылы. Чүпрәлегә барсаң — күз сал. Сәлам белән: **Шәрәф.**

*1943.*

**Дустым Нури!**

«Сиңа озак хат яза алмавым өчен үпкәләмә. Хатыңны һәм «Рус кызы»ны алдым. «Рус кызы»н алу белән үк бер тапкыр укып чыктым. Мин аны

хатымда сиңа киңрәк язармын дигән идем, ярый инде, хәзергә болай гына языйм әле.

Табигать шуның өчен дә ул табигать: анда һәртөрле могҗизалар булып тора. Кыш та шулай ук. Ил өчен, халык өчен булган кискен моментларда намусы бар кеше искиткеч сәләткә ия булганын күрсәтә. Бу көч, бу сәләт аның йөрәгеннән ярсулы ташкын булып агып чыга. Мин сине сугышка кадәр шагыйрь итеп таныганым да юк иде. Ә хәзер синең иҗатка баш иям. Сукыр рәвештә түгел, идеал итеп түгел, ә намуслы рәвештә, шигъриятне аңлап, һәм астан түгел — яннан карап.

Менә шундый әсәрләр белән әсәрләнергә була. Шундый кешеләр белән көнләшә-көнләшә, этешә-тартыша үсәргә, татар әдәбиятының бәхете өчен бөтен көчен сарыф итәргә мөмкин. Дөньяда дуслыктан, туганлыктан да өстен булган хакыйкать бар, менә шушы хакыйкатьне, мин, безнең арада мөгамәлә ничек кенә булса да, тартынмый әйтер идем.

Дөрес, безнең иҗатлар күп яктан төрле-төрле. Минем үземнең юлым бар, синең — үзеңнеке. Минем үземнең туганнарым бар,— синең үзеңнеке. Әмма шигърият өчен уртак бер сызык бар, аннан кем дә чыга алмый, һәм әйтергә кирәк — билгеле бер чорга кадәр шагыйрь аңар тиз генә керә дә алмый.

Мин синең поэмаңның гүзәл якларын санап чыгуны үземнең бурычым итеп куймыйм, тик шуны гына әйтәм, ул минем күз алдымда, синең фронтка китәргә рөхсәт алган Зояң кебек — ягъни күгәрчен баласы кебек очып йөри. Поэма кул белән язылмаган, йөрәк белән. Кара белән түгел — кан белән. Гакыл белән түгел — шашкынлык белән.

Тик мин шунысыннан куркам, бу поэма синең көчеңнең эпизодик рәвештә иң югары ноктага җитеп, ялтырап калуы гына булмасын. Дөньяда шундый хәлләр дә очрый. Шуннан шагыйрь үз-үзен узып китә алмый. Хәзергә бу хакта бер сүз дә әйтмим.

Поэмаңда шигырь төзелеше, техникасы ягыннан аксак урыннар бар. Моны бик тиз һәм гаять оста рәвештә бетерергә мөмкин иде.

Мин сиңа тагын бер нәрсә тәкъдим итәргә телим. Син аралаш рифма белән язып кара әле, сына, ничек булыр.

Бәлки, син аралаш кафияләргә бик начар карый торгансың. Әгәр шулай икән — бу синең ялгышың. Ә менә мин, аралаш рифма булмаса, яза алмыйм. Кечкенәдән бирле принцибым шушы. Кычкырып әйтәм — бу яктан мин хаклы. Чөнки татар шигыре дә чын мәгънәсендә шигырь хокукын алырга тиеш.

Әллә ниләр генә язасы килә дә, сиңа мәгълүм ахры, минем бик тиз фикер туза. Кыскасы, үзебез яхшы гына яшибез әле. Шәһәрдә торабыз — хәзергә чыкмый. Кайчан — кая? — шайтан белсен.

Шигырь язганым юк. Менә декабрь үтеп бара, ә бер генә кулай әйбер дә язмадым. Яңа елдан кечерәк бер поэмага тотынырга исәбем бар, нәрсә килеп чыгар. Аның каравы, хәзер «Полк намусы» исемле пьеса бетердем.

Сиңа кайбер нәрсәләр язар идем дә, цензор бик усал бугай. Барын да сызып атар. Кыз кеше дә булса, кая кирәргә урын тапмассың. Кыскасы, бик нык итеп сүгенәсем килә. Ни өчен диген. Басылган китапларның һәм журналның тиражы бик аз: 3000! Бу бит ахмаклык. Гонорар турында әйтәсе дә юк, хәерче өлеше. Бу яктан яңалыклар булдымы, юкмы?

Син Буада торасың бугай. Сиңа бер йомыш кушам. Минем институтта укыганда Шәрәф Һибатов дигән бер дустым бар иде. Хәзер аның хакында белмим. Ул Адав-Толымбай авылыныкы. Әгәр буш вакытың булса, яки махсус шуның өчен барып, аның хакында бел әле. Ул авыл Буа белән янәшә генә. Исеме Шәрәф, әтисе — Әхмәдулла, фамилиясе — Ибәтов. Аның карт әнкәсе генә бар иде. Гомумән, сельсоветтан телефон аша булса да белеш әле. Ул сиңа да таныш булса кирәк. Яхшы гына нәрсәләр дә яза иде.

Кайтып килергә туры килсә, һичшиксез, Буага таяр идем. Шунда бетерәм.

Сиңа саулык-исәнлек теләп: **Шәрәф.**

*Полевая почта 18715-А*
*Мударрисову Шарафу Хасиятулловичу*

Басмага әзерләде Татарстан Дәүләт музее фәнни хезмәткәре.

Равилә **МӨБАРӘКШИНА.**

# Әдип Маликов

## Озын гомерле хат

Әйе, хатларның андые да була. Ерак Сахалин атавында, чик буе землянкасында мине эзләп тапкан, самурайларны тар-мар иткәндә үзем белән ут эченә кергән, дары исе сеңгән сихерле ул хатны мин кадерләп саклыйм. «Борын төшкән» чакларда ачып-ачып укыйм.

Бер сәбәпсез хат язылмый. Ә аның төп «гөнаһлы» кешесе мин үзем булдым. Бераз чигенү ясыйк.

...Бөек Ватан сугышы башлануга күп тә үтмәде, илнең хәрби картасына «Ерак Көнчыгыш фронты» дигән билгеләмә өстәлде. Без хезмәт иткән Төньяк Сахалин гарнизоны да чик буе землянкаларына, дотларга, окопларга күченде.

Самурайларның азынган чагы. Үз башларына булгыры, дибез. Мәкерле провокацияләр... Төн пәрдәсен ертып, безнең якка кинәт кызыл-сары ракеталар оча. Кайдадыр «банзай!» кычкыралар, «Гочкес» пулеметыннан такылдаталар: та-та-та... Тавышыннан ук таныйбыз. Разведчиклар өйрәнә иде андый коралларны да. Атып караганыбыз да булды.

«Башлануы шулдыр»... Төнге татлы йокыны хуш исле ылыс «түшәк»ләрдә калдырып, окопларга чабабыз, сугышка керергә приказ көтәбез.

Мин ул чагында разведчиклар отделениесе командиры идем. Взвод комсоргы да. Дивизия газитенә үзебезнең тормыштан мәкаләләр, зарисовкалар язгалыйм. Ерак Көнчыгыш фронтында татар телендә чыккан «Тревога» газитендә (редакторы Бари Корбанов) шигырьләрем дә күренгәли. Тревогалар эчендә, без өстендә утыргандай яшәсәк тә, күңел төшенкелегенә бирелмәдек. Хәтта күңелемдә бер поэма да житлегеп килә. Герое да бар: Сахалин каторжаны улы, карт солдат Мортаза Мусин. Карт дигәч тә, безгә генә шулай күренгәндер. Аңа 40 яшьләр тирәсе иде. Атасын тайгада агач баскан. Анасын да югалткан Мортаза бик яшьли ятим кала, чит кулларда тәрбияләнеп үсә. Менә шул гаять сөйкемле, атабыз урынына күргән Мусин безне — җәяүле разведчикларны тарихи каторжаннар сукмагы буйлап йөртте. Озын бауларга тотынып, баш әйләндергеч кыяларга үрмәләдек. Ил чиге буйларын капшап чыктык. Кыскасы, сугышка хәзерләндек.

Бөек Җиңү бәйрәмен каршылаганда, поэманы кәгазьгә төшереп, Мусинга һәм атлы разведка взводында хезмәт итүче татар, казакъ егетләренә укып күрсәттем. «Әйбәт,— диештеләр,— жибәр, старшой (ягъни, старший сержант), йә Казанга, йә Уфага».

Мин, әлбәттә, хыялым түрендә йөрткән, төшләремдә күргән нурлы Казанга — «Совет әдәбияты» журналына юлладым аны.

Поэма башында мондый юллар:

> Бу жиремнең кочып нарат ларын,
> Чәчәкләрен үбеп узам мин.
> Бир урынны
> Ерак атаулагы
> Солдат хисләренә, Казаным!

Ай ярымнан соң уңай җавап алгач, ышанмый да тордым. Өнемме бу, әллә төшемме! — дим.

Менә ул хат:

*«9.VI.45 ел. Казан*

**Хөрмәтле Әдип туган!**

Сезнең «Атаудагы хисләр» дигән поэмагыз һәм аңа тагып җибәргән хатыгыз «Совет әдәбияты» редакциясенә (димәк, Казанга!) килеп житте. Укып чыктык, хәтта берничә кеше, шулардан Кави Нәҗми, Газиз Иделле укыдык. Мортаза солдат юкка гына «во!» дип баш бармагын күрсәтмәгәндер, ахыры, әсәр безнең егетләргә дә яхшы тәэсир калдырды. Безнең халык баш бармак күрсәтүгә алай юмарт түгел-түгелен дә, шулай да «матур!», «матур әйтелгән!» дип телләрен чатылдатып, башларын селкеп утырулар булды.

Чынлап та, шигырьдә бик күчле урыннар, оригинал образлар, яңа, моңа чаклы күрелмәгән буяулар бар. Мусин үзе — просто хәзинә. Бездән Сезгә — атау егетләренә, ак чәчле карт солдат Мусин агага бик күп сәлам. Поэмагыз журнал-

ның чираттагы № 7 гә керер һәм журналның ул номерын Сезгә җибәрергә тырышырбыз. Ашык-пошык кына язылган бу кечкенә хат кисәге өчен ачуланмагыз, үзегез күбрәк һәм тулырак итеп язып торыгыз. Менә син, уйланмаган бер көндә яңа бер шагыйрь килеп чыгып тора һәм үз авазы, үз почеркы белән. Изге юл булсын!

Сезнең киләчәктә дә әдәбиятта армый-талмый һәм күңелсез минутларда борын төшерми эшләвегезне теләп, хөрмәт һәм сәлам белән: **Фатих Хөсни»**

Нәрсәсе белән дулкынландырды соң үтә күренмәле гади генә шушы хат? Саф күңелдән язылган булуы, изге юл теләве беләндер, мөгаен. Бер карасаң, Фатих абый теленә ни килсә, шуны язгандыр шикелле. Ә юл араларында — образлар... Мәктәптә иҗатын өйрәнгән олы язучы Кави Нәҗми күз алдыма килеп басты, журнал редакторы Газиз Иделле. Аларның «телләрен чатылдатып, башларын селкеп утырулары»... Юлымны яктыртып, киләчәккә өмет бирде бу хат.

Мин яшәргә тиеш,— дидем үз-үземә.— Казанга җиңүче булып кайтырга!

«Совет әдәбияты» журналының 1945 елгы 7 саны мине, самурайларны тар-мар иткәч, Тойохарэ (Хәзерге Южно-Сахалинск) шәһәрендә куып җитте. Яраткан дустыбыз, атабыз урынына күргән ефрейтор Мусин арабызда юк иде инде. Безнең взвод разведкадан кайтканда, ул япон минасына юлыкты. Кыска вакытлы, әмма бик тә ярсулы, дәһшәтле, канлы бу сугышта күпләрне югалттык без.

Кемдер түгел,
Без өйрәттек
Самурайны корал салырга.
Туздырылды сугыш учагы
Бөек Тын океан ярында.
Давыл кичтек,
Хәсрәт-ут эчтек,
Ни гомер бит өйдән киткәнгә...
Ауды солдат
Җиңү юлының
Соңгы сызыгына җиткәндә.

* * *

1965 елда, Бөек Җиңүнең 20 еллыгы уңае белән, Сахалинның партия Өлкә һәм Өлкә башкарма комитетлары мине юбилей тантанасына чакырды. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән, сугышта үзләрен аеруча яхшы күрсәткән ветераннар арасында Советлар Союзы Геройлары, генераллар, полк командирлары бар иде. Сержант составыннан мин бер үзем булып чыктым. Сугыш узган истәлекле урыннарда булдык, туганнар каберлекләренә чәчәкләр салдык. Бер атна эчендә миңа 16 очрашуда катнашырга, радио һәм телевидениеләрдән чыгыш ясарга туры килде. Гомергә онытылмаслык тәэсирләр белән Әлмәткә кайтып, «Яшьлек утравы» повестен язарга утырдым...

* * *

Фатих ага Хөсни соңыннан да минем иҗатыма битараф булмады. «Яшьлек утравы» повестен укып чыккач, аңардан бик тә сөенечле хат килде. Мактанудан түгел, шатланудан бер өзек китерәм:

*...«Минемчә, бу китап татар әдәбиятында үзенә бер төрле хуш ис, кырыс җил бөркеп торучы «утрау» булып калыр, аңарга «аяк баскан» кешеләр башка бер җирдә дә таба алмаган яңа рәхәтлек табарлар... Хәер-фатиха китабыңа, хәер-фатиха үзеңә... 6.XII.1974.»*

Әдәби энекәшләрен барлап, иҗатка рухландырып торучы, «күңелсез минутларда борын төшерми» эшләргә өндәүче аксакаллар — Татарстанның халык язучысы Фатих Хөсни шикелле изге затлар күбрәк булсын иде. Озын гомер телим, озын гомерле хат иясенә!

## Хәтер яралары

Гүрдәгеләр, Сезнең өлешкә дә
Кошлар сайрый, алсу таң ата.
Кабере табылмаган полкташым
Төшләремә кереп уята.

Карый сыман минем күзем белән
Сабыйларга, якты дөньяга.
Сөенәдер сыман яхшылыкка,
Вәхшилеккә җаны кыйнала.

Тел тидерсә кемдер ветераннарга,
Кан койгансыз диеп, тикмәгә,—
Җаным рәнҗи:
— Кагылма син, юньсез,
Изге хәтер — бөек үткәнгә!

Туган илне сатсак, Илсез калсак,
Чыкмас идек коллык, җәбердән.
Туар буын, күзәнәктә килеш,
Керер иде күптән кабергә.

Тумас идең син дә, тәти егет,
Кизәнсәң дә кайчак бабаңа.
Ә ул баскан, җанын аямыйча,
Фашист белән синең арага.

Яшьлегебез утта янды диеп,
Каһәрләмим узган гомерне.
Янсак — яндык, ләкин җиңеп чыктык,
Үтердек без явыз үлемне!

Хәтер яралары тиз төзәлми,
Аңлатуы кыен сөйләп тә...
Гүрдәгеләр искә төшкән саен
Кан сава да тора йөрәккә.

# ФАСИЛНЕҢ ТОРМЫШ ФАСЫЛЛАРЫ

КОМПОЗИТОР ФАСИЛ ӘХМӘТКӘ — 60 ЯШЬ



Физиклар белән лириклар никадәр генә бәхәсләшмәсен, адәм баласы барыбер иң элек — табигать баласы. Тукай әйтмешли, табигать иркәсе. Шуңа күрә дә кешенең тормыш юлы табигать күренешләрен, ел фасылларын хәтерләтә. Әйе, аның да балачак, үсмерчак язы, яшьлек җәе, өлгергәнлек, житлегү көзе һәм, ниһаять, гомер азагы — кышы була...

Бу хакта композитор Фасил Әхмәт каләмдәш дусты шагыйрь Равил Фәйзуллин белән берәүнең дә күңелен битараф калдырмаслык, үзәк өзгеч «Аккошлар» жырында үтә дә үтемле вә тәэсирле итеп әйтеп биргәннәр:

Күзләрдән соң язлар килми —
алда — салкын ак кышлар.
Китәсез дәмени,
китәсез дәмени,
китәсез дәмени, аккошлар?

Әлбәттә, табигать тә, аның фасыллары да — мәңгелек бакый, ә кеше гомере, бар тереклеккә хас булганча, бик кыска вә чикле, ә инде үз гомерен сәнгатькә багышлаган талант иясенең иҗат гомере кешелек тарихында гөлт итеп янып алган очракны йә булмаса метеорны хәтерләтә. Әмма чын талант иясенең башкалардан гайре бер өстенлеге бар — халык күңелендә ул тудырган, ул калдырган мәңгелек иҗади мирас үз гомерен дәвам итә. Еллар үткән саен бу үлемсез әсәрләрнең бәһасе, әһәмияте, тәэсир итү көче арта гына төшә. Даһи Кол Галигә ничә йөз яшь тулмасын, ул барыбер изге Йосыф белән гүзәл Зөләйханың мәхәббәт җырчысы булып кала, ә егерме җиде яшьлек Тукай шүрәлесе, үз вакытында кара урман булып шаулап утырган төбәктә соңгы тирәк киселеп бетсә дә, барыбер үзенә елышыр урын табар, кеше җаны белән «кети-кети» уйнавын дәвам итәр...

Хәер, бу бәхетле мисалларны, теләгәндә, бик күп китерергә мөмкин булыр иде... Тик, Тукай әйтмешли, «язмыйммын куркып, ераkларга китәр дип уйларым... тукта, мин юлдан адашканмын икән бит, күр әле, әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит» — композитор Фасил Әхмәт.

Әйе, әйе, май азагында, шомырт, алмагач-чия шау чәчәктә коенган гүзәл мизгелдә — майның 23 ендә Кукмара ягында, салмак кына агып ятучы нәни генә Шөн елгасы буенда урманнан Салтын Ерыклы авылында XX гасыр азагы татар милли музыкасының иң шөһрәтле композиторы, Россия һәм Татарстанның халык артисты, Россия Федерациясенең Глинка исемендәге, Татарстан Республикасының Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Фасил Әхмәт дөньяга килгән. Дөрес, булачак композитор ул елларда сөекле даһи шагыйре Һади Такташ кебек: «Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны еглатырга. Әйе, миндә көчле Байроннар җаны. Көн килер, күз яшьләрем тормыш күгендә ялтырар... Дәртле җырларым моңыннан ил елар...» — дип, бар дөньяга оран салмагандыр, тик шунысы гаҗәп: әтисе Әхмәтгали, гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килгән төпчек улына татарда моңарчы һич очрамаган, җырлап торган музыкаль исем — Фасил исеме кушкан. Каян тапкан ул аны — бер Алла

гына белә! Мин үзем гомерем буе бу исемнең килеп чыгышын төрле чыганаклардан эзләдем: Васил, Василийлар, Васялар буа буарлык, ә Фасил — юк... Хәер, алдыйм, ахрысы. Кайчандыр Куба утравында чыгышы белән испан затыннан булган үтә кансыз пират король Фасиль хөкем сөргән икән...

Ничек кенә булмасын, зирәк ата улына тәңгәл исем биреп кенә калмаган, аның тәүге остазы, мөгаллиме дә булган. Фасил язмышында бу күркәм затның роле чиксез зур булуын искә алып, аның да катлаулы тормыш юлын кыскача гына булса да сөйләп китәргә изге бурычым дип саныйм. Шушы ук авылда 1907 елның 8 сентябрендә урта хәлле крестьян гаиләсендә туган ул. Бабабыз Хәҗиәхмәт тырыш игенче булган, шуңа күрә ишле гаилә (5 ул!) тук, имин яшәгән, тик 12 яшендә Әхмәтгалинең сөекле әнкәсе дөнья куя, өйгә үги ана керә... Авыл мәдрәсәсендә башлангыч белем алган, күрше удмурт авылындагы мәктәптә бераз урыс телен сукаларга өйрәнгән яшүсмер егет көннәрнең берендә инәнә биштәр асып, күптәнге хыялы — Казан каласына юл тота һәм анда ярлы-гидайлар өчен ачылган курсларның берсенә укырга керә һәм тиздән бухгалтер счетовод һөнәрен үзләштереп чыга. Казанда үткән бу ачлы-туклы, әмма бәхетле мизгелләр Әхмәтгали күңелендә мәңгегә уелып кала. Әле яңа дөньяга күзе ачылып килгән авыл егете НЭП елларында шау-гөр килеп кайнап торган Казанның бәрәкәтле мәдәният дөньясына баш-аягы белән чума. Үзе лаеш шулпасы чөмерсә дә, вак-төяк эшләрдә катнашып туплаган тиеннәрен төрле тамашалар, театрлар, концертлар карауга сарыф итә, гармун алып җибәрә, анда ишеткән көйләрен «шыңгырдатып» алгалый. Ул яшәгән тулай торакка еш кына яшь шагыйрьләр — Кутуйлар, Такташлар, Нәҗмиләр килеп йөри, үзләренең шигырьләрен укый. Ара-тирә укучы яшьләр Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Мөхетдин Корбангалиев кебек затларның лекцияләрен тыңлау бәхетенә дә ирешәләр...

Кыскасы, авылга Әхмәтгали балигъ кеше булып, башына картуз, өстенә кәчтүм, аягына ботинка киеп кайта. Тиздән «Казаннан азып, озын чәч үстереп кайткан» Хәҗиәхмәт углы авыл активисты булып китә, партиягә керә, колхоз төзүдә актив катнаша, аңа Тукай исемен үзе бирдерә (соңга таба Кукмара районындагы бу колхоз исемен «Ударник» дип алыштыралар, тик соңгы елларда гына бу горур, тарихи исем колхозга янә кайтарыла).

Тукай, Такташ шигырьләрен яттан белгән, Г. Ибраһимов, Ш. Камалларның әсәрләрен кат-кат укыган, Г. Камал, К. Тинчурин спектакльләрен үз күзләре белән күрү бәхетенә ирешкән Әхмәтгали яңа тормыш өчен авылда аяусыз көрәш башлап җибәрә. Әмма элек тә бу «юктан көрәк булган» егетне җене сөймәгән авыл агайлары тиздән аның язмышын үзләренчә хәл итәләр: янап та, юмалап та эш чыкмагач, яла ягып төрмәгә яптыралар. Чоры да мач килеп тора бит: ил буйлап «халык дошманнары»н эзләү, эзәрлекләү башланып китә... Һәм менә чәче кырылган, партбилеттан колак каккан гыйсьянчы Әхмәтгали конвой астында Черек күл буена атлый. Сөекле Казанның, Тукайча сокланган башкаланың төрмә ташларын аңа шактый татырга туры килә...

Ә өйдә өч бала белән (иң өлкәне яшь ярымда вафат була) кәләше Бибисара утырып кала. Бу вакытта Фасилгә нибары 11 ай. Нык бәдәнле, таза малай. Киткәндә әтисе төпчек улын «булырдайның б...нан билгеле» дип, аны арт санынынан яратып чәбәкли.

Бибисара «утырып кала» дидемме? Утыртырлар сина колхозның Давыдов белән Нагульнов кебек килмешәкләре: «халык дошманы» хатынын көн дә эшкә куалар, ә өч бала өйдә ялгыз калып, әниләрен көтеп, елап утыра... Еш кына нәни улын ана салкын ишек тупсасында йоклап киткән, туңып-күшегеп беткән хәлдә кулына алып, җылы ястыкка үз янына сала. Тиздән бала авырый башлый. Авылдагы ярым-йорты белемле фельдшер: «Малаеның аяк буыннарына салкын тигән, тоз суына утырт, мунчада чап», — дип киңәш бирә... Бичара Фасилнең арт саны ул тоз суларында утырып чиләнеп бетә, ә файдасы тими. Ярый әле 4 айдан соң өйгә, алҗып-йончып, әмма акланып, гаепләрен җуеп әти кеше кайтып төшә. Нинди куаныч! Тик төпчек улы гына һаман тәпи йөрми, ике аягы да шыр сөяккә калган, сөйрәлеп йөриләр. Әхмәтгали гарип улын кая гына алып бармый, аякларын нәрсә белән генә умый, юк, файдасы тими. Соңрак, инде Фасил үзе Казанга барып, профессорларга күренгәч, авыруының чын исемен белә: балалар параличе, полиомелит. Бу — мәңгелеккә, әле ярый, куллары, биле исән-сау, алайса гомер буена җан көеге булып, күзле бүкән сыман утырган булыр иде.

Колхоздан, авылдан җаны бизгән Әхмәтгали башта күрше авыл конторларында эшләп йөри, ниһаять, Кляуш урман хуҗалыгына бухгалтер булып урнаша һәм тиздән ишле гаиләсен әле яңа гына төзелеп беткән, нарат сагызы исен аңкытып торган ике катлы йортның өске катына алып килә...

Ул вакытта бу хуҗалык «Тулбинский лесхоз» дип атала. Вятка елгасыннан әлләни ерак түгел, хәзер — Мамадыш районында. Малайның иң бәхетле, иң тәэсирле балачак еллары биредә үтә. Тирә-якта — кара урман, икенче каттан әллә кайдагы мең яшьлек төз нарат-чыршылар күренә... Ә урман чатыр-аланына керден исә — җиләге, бөрлегәне, кузгалак-какысы, гөмбәсе дисеңме! Култыкса белән генә йөрсә дә, малай кордашлары, яшьтәшләреннән, апа-абыйсыннан калмаска тырыша, үрмәләп, җиргә ятып булса да юмарт урман сыен татый. Тик шулай да күпчелек вакыты өйдә, ялгыз үтә. Дөрес, янында 3—4 яшьлек сеңлесе Вәсилә нидер лепелдәп йөри... Малай хәтерендә шундый бер хатирә уелып калган. Әти-әнисе каядыр кунакка киткәч, Фасил белән Вәсилә балконда уйнап утыралар. Сеңлесе абыйсын чәй белән сыйлый. Ялгыш Фасил кулындагы чыйнаягын кулыннан төшереп җибәрә дә, ул, зеңгелдәп, җиргә түшәлгән ташка барып төшеп, кисәкләргә уала. Бу зеңгелдәү шундый тәэсирле, матур була ки, малай сеңлесеннән тагын бер чәшке сорап ала, анысы тагын да матур, затлы тавыш чыгарып ватыла... Тиздән шкафта бер савыт-саба да калмый, ә сабыйлар лампа куыкларына тотыналар... Абыйсының сөенечен сеңлесе кул чәбәкләп, бии-бии бүлешә...

Гомумән, мәҗбүри рәвештә ялгыз калырга дучар ителгән гарип малай үзе өчен тиздән өр-яңа дөнья — авазлар дөньясын ачып җибәрә. Урман шавы да, кошлар сайравы да, арба тәгәрмәче шыгырдавы да, әнисенең җиз самавыр агартканда чыгарган сәер авазлар да, бала-чаганың күл буендагы ыгы-зыгы тавышлары, бака концертлары һәм, бигрәк тә, таң алдында сандугач сайравы — болар барысы бала күңеленә сихри әкият булып иңә, сыкрану-сызлануын, ялгызлыгын оныттырып, олы дөньяга — бөек табигать галиҗәнабләре иленә алып чыга төсле.

Улының бу ихласлылыгын тоеп алган әтисе (табак-савыт тарихы үзе күп нәрсәне аңлаткан аңа) улына гармун алып кайтып, кулына тоттыра. Бу матур уенчык гармун әллә нинди серле авазлар көйли. Каян чыга алар? Шуңа төшенергә теләп, Фасил кайчы белән аның күреген кисә дә, әчтәге сәхтияннарын үз куллары белән капшап карый... Аптырагач, әтисе улына үз гармунын тоттыра...

Әйтергә кирәк, сугыш алды еллары, хәзер ничаклы кара буяулар белән сурәтләнмәсен, чагыштырмача тыныч, имин, тук еллар була. Халык күңелендә әле өмет чаткылары дөрли, радиодан Дунаевский, Сәйдәшләрнең якты рухлы музыкасы яңгырый, клубта бәхетле балачак, яңа тормыш төзүче баһадир-энтузиастлар турында берсеннән-берсе күңелле кинолар бара... Әхмәтгали өенә дә ял көннәрендә дус-ишләре, туганнары җыела. Күңел ачу, җыр, бию башлана. Төп тамада — хуҗа үзе. Ара-тирә гармунын да кулына алып, әле яңа гына каяндыр ишетеп кайткан ят көйне сузып җибәрә. Әти аларның чын исемен белми дә — ишеткән авыл исеме белән атап йөртә: «Дусай көе», «Туеш көе», «Тәкәнеш көе». Соңга таба Фасил аларның кайберләрен фольклорчы Мәхмүт Нигъмәтҗановка нотага төшереп бирә һәм алар җыентыкларның берсендә дөнья күрәләр...

Әмма тиздән авыр заманалар башлана. Башта ата кешене фин сугышына алалар, аннан ул авыр яраланып, бил сөяген чатнатып кайта. Врачлар аңа ак чыршы ылысы кайнатмасында утырырга киңәш бирәләр. Әхмәтгали махсус заказ белән агачтан зур тагарак-ванна ясата һәм көнаралаш ак чыршы шифасын кабул итә, үзе белән Фасилне дә елата-елата муеннан суга чумдыра. Ходайның рәхмәте, тиздән әти кеше аякка баса, ә улының аяклары шактый ныгый төшә. Шатлык озакка бармый. Тиздән Бөек Ватан сугышы башланып китә, әтине янә фронтка алалар. Бибисара янә дүрт баласы белән йорт тоткасы булып кала. Әтисенең гармуны исә тулы карамакка яшь гармунчыга күчә...

Ир-атсыз калып, көне буе авыр эштә алҗып бетеп, кич белән соңгы хәбәрләрне ишетергә дип бергә җыела торган хатын-кыз аулак өйләрен, укучым, шәт, яхшы беләсең, кузаллый торгандыр. Бу хакта дистәләгән китап язылган, кино төшерелгән. Тиздән Фасил гармуны мондый кичәләрнең төп фигура-хуҗасына әверелеп килә...

44 нең язында, сигез ай госпитальдә иза чигеп, Әхмәтгали дә кайтып төшә. Иңенә саллы биштәр аскан һәм тагын кеше аякларын хәтерләткән ап-ак төенчекне уң иңенә аркылы салган... Баку госпиталендә ятып чыккач (ә ул Төньяк Кавказ фронтында, бүген мәгънәсез канлы сугыш барган Моздок, Грозный тирәсендә көрәшеп, авыр яраланып), өйгә кайтып барганда поезд Эльтон белән Баскунчак тоз күлләре янында туктый. Бибисарасының өйдә сабын, шырпы, тоз юк дип язган сүзләре кылт итеп исенә төшә, ә станса тирәсендә тау-тау тоз пирамидалары. Аны-моны уйлап тормый, авыр булса булыр, Әхмәтгали запаска бирелгән өр-яңа кальсон балакларын бәйли дә, икесенә дә тоз тутыра... Күрше-күлән,

туган-тумача аның бу тапкырлыгына һәм соңыннан күрсәткән юмартлыгына бик озак вакыт рәхмәт укыйлар әле... Фасил белән Вәсиләсен ул су буенда очрата. Башта әтисен Фасил күреп ала, аның артыннан Вәсилә атылып килеп, әтисен кочып ала... Менә шулай «йөк өстенә чүмәлә» күтәреп, ике баласын ун кулы белән кочып, әти кеше таныш бусага аркылы атлап керә... Бу да Фасилнең хәтеренә мәңге уелып калган якты хатирә...

Тиздән Әхмәтгалине Казанга чакырып яна эш тәкъдим итәләр: берсе — Казанда, берсе — Саба урман хуҗалыгында. Бу авыр, кытлык, ач 1946 ел. Казанда хәлләр мөшкел. Биш бала атасы (ә бу вакытта инде мин дә туган булганмын) Саба ягын сайлап ала...

Киров тайгасына тоташкан, Мишә елгасы башында урнашкан бу урман хуҗалыгы әле чагыштырмача яңа хуҗалык була. Бер үзенә ике хуҗалык — лесхоз һәм леспромхоз. Берсе агач — чыршы-нарат үстерә, урман саклый, икенчесе — көне-төне урман кисә, Иштуган стансасына ташый. Поселок тиз үсә. Өлкән апа белән абый 5—7 классны Завод нырты мәктәбенә җәяү йөреп укыса, Фасилгә, Вәсиләгә һәм миңа Лесхоз җидееллык мәктәбен тәмамларга насыйп була. Биредә дә Фасил үзен оста гармунчы итеп таныта, сугыштан соңгы күңелле уенлыклар аның гармуныннан башка бармый, мәктәптәге концерт һәм кичәләрдә дә аның урыны — түрдә. Тиздән ул фронттан контузия алып кайткан Миша абзыйның затлы баянында уйнарга өйрәнә...

Ниһаять, 1952 ел җитә. Мәктәп тәмам. Әтисе белән Казанга киләләр. Әти улының музыка училищесына керә алуына ышанып бетми: улы нота танымый диярлек, ишеткәнен генә уйный, шуңа күрә аны учет-кредит техникумына урнаштырмакчы була. Тик бу юлы инде Фасил үз характерын күрсәтә — музыка училищесына барып карыйк, ди. Нота танымаса да, егетнең сәләтле булуын Фасилнең булачак остазлары бик тиз сизеп алалар. Бигрәк тә училище директоры Ильяс Вакасович Әүхәдиев мәрхәмәтле булып чыга: документларны тапшырып, имтиханга килергә рөхсәт бирә...

Һәм менә Фасил, бер иңенә култыкса кыстырып, икенче кулына таяк тотып, имтихан барган, паркеты балкып торган мәһабәт залга керә. Дулкынлануыннан тез буыннары калтырый, болай да ап-ак, ябык-чандыр йөз тагын да агарыбрак киткән. Шул вакытта көтелмәгән хәл була: аксак егетнең култык таяклары як-якка таеп китә дә, ул гөрселдәп идәнгә килеп төшә... Булачак композиторның иң аяныч хатирәләреннән берсе, мөгаен, шушысыдыр... Ана комиссия рәисе аякка басарга үзе ярдәм итә, урындыкка утырта, күзеннән яшь, борыныннан кан аккан «дәгъвәче» кулына балкып торган баян тоттыра. Фасил ихлас күңелдән бар белгәнен уйнап күрсәтә. Нотаны начар таныса да, егетнең колагы үтә сизгер, җыр-көйләрне бернинди хатасыз уйный диярлек...

Кыскасы, Фасил училищеда укый башлый. Композитор гомеренең яңа фасылы башлана...

* * *

Әти — Салих Сәйдәшне күреп белгән генә түгел, якыннан таныш та булган. Бу хакта үзе үк сөйли торган иде. Сугышка алынгач, ул, офицер буларак, Казан тирәсендәге гарнизоннарның берсендә гаскәр формалаштыру эше белән мәшгуль була һәм сентябрь аена хәтле Казанга көн дә килеп-китеп йөри. Әлбәттә инде, рухи Мәккәсе — Камал театры спектакльләрен калдырмый. Шунда Сәйдәш һәм Таҗи Гыйззәт белән танышa, офицер пәегына бирелгән сигарет белән артистларны сыйлый. Өенә кайткач, әти, гармунын алып, «Менә, тыңлагыз әле, бу Сәйдәш абзагызның фәлән увертюрасы, фәлән ариясе», — дип, 14 телдә әллә нинди катлаулы музыка уйнап күрсәтергә азаплана торган иде... Хәер, аларның күбесен Фасил инде радиодан тыңлап та, ятлап та бетергән иде.

Ә училищеда Фасилне «тере» композиторлар укыта — Әгъзәм Фәттах, Арнольд Бренинг. Җитмәсә, Әгъзәм ага, күңелне ымсындырып, училищеда яшь композиторлар түгәрәге дә ачып җибәрә. Фасил аңа очынып, бирелеп йөри һәм беренче көйләрен шул чорда иҗат итә. Әлбәттә инде, беренче җыр — беренче сөйгән яры Люция турында... Бу көй әле бүген дә еш яңгырый, ә бит язылуына инде ярты гасыр диярлек. Бер-бер артлы «Карашларың» (М. Җәлил шигыре), «Шомырт чәчәк аткан чакта» (Э. Мөэминова шигыре), «Тамчылар тамар чаклар» (Ш. Галиев шигыре), «Бию» һ. б. туа.

Кыскасы, Фасил күңелендә баянчы гына түгел, композитор булу теләге дә туа, ныгый бара. Врачлар да, аксак кешегә авыр баян күтәреп йөрү зыянлы, дип,

күнелгә шом салалар. И. Әүхәдиев белән киңәшеп, Фасил тиздән теория һәм композиция классына да йөри башлый, чордашларына караганда озаграк (5 ел) укыса да, ике һөнәр алып чыга. Һәм шул ук елны Казан дәүләт консерваториясенең композиция бүлегенә кереп, тәҗрибәле педагог, үзе дә мәшһүр композитор, профессор Альберт Семенович Леман классында укый башлый...



*Композиторлар Заһидулла Яруллин һәм Фасил Әхмәтов.*

Композиторның халык арасында танылa башлавы шушы елларга туры килә. Бер-бер артлы радиодан, эстрададан аның җыр һәм романслары яңгырый башлый. Фортепиано өчен язылган сонатинасы белгечләр тарафыннан бертавыштан татар музыкасында новаторлык әсәре дип бәяләнә, адашы Эльза Әхмәтова һәм бик күп башка пианистларның даими репертуарында урын ала. Аеруча композиторның беренче кыллы квартеты шөһрәт казана. Казанга килгәч, аны даһи Шостакович тыңлый һәм композиторны булачак бөек симфонист дип бәяли, үзенең китапларын бүләк итә, яшь композитор һәм аның остазы А. С. Леман белән фотога төшә... Тора-бара кызыклы әсәр, бөтен дөньяга мәшһүр Бородин исемендәге кыллы квартет репертуарына кереп, безнең илдә генә түгел, Франция, Англия, ФРГ, АКШ һ. б. илләрдә башкарыла.

Алга таба да композитор камера музыкасы өстендә күп, нәтиҗәле һәм уңышлы эшли. Бу хакта аның кыллы Партитасы, тынлы уен кораллары өчен Квинтеты һ. б. әсәрләре сөйли. Үз вакытында һәркайсы үзәк матбугатта танылган композиторлар һәм белгечләр тарафыннан югары бәяләнде.

Композитор төрле уен кораллары өчен музыка язып, үзен төп эшкә — симфоник музыка иҗат итүгә әзерли. Һәм күп тә үтми, үзен бу жанрда һәрьяклап бөтен илгә таныта. Бигрәк тә Бөек Ватан сугышында вакытсыз һәлак булган, даһи «Шүрәле» балеты авторы Фәрит Яруллинның якты истәлегенә багышланган симфоник поэма киң резонанс ала һәм Россия музыка дөньясындагы иң олы бүләккә — М. И. Глинка исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Бу уңыштан канатланып киткән композитор бер-бер артлы «Адажио», «Казан симфониясе», «Фортепиано һәм симфоник оркестр өчен концерт», «Скрипка һәм симфоник оркестр өчен концерт» кебек күләмле, катлаулы әсәрләр иҗат итә.

Арада «Казан симфониясе» тыңлаучыны аеруча үзенә җәлеп итә. Көчле драматик рухта язылган бу әсәр тарих һәм бүгенге чынбарлык турында сөйли, татар халкының катлаулы, фаҗигале тарихын ачып сала. Бу әсәрдә моңарчы татар музыкасында, симфонизмда күзәтелмәгән кадәр яңалык, энҗе бөртекләре,

табышлар тулып ята. Шунысы куанычлы: катлаулы булуына карамастан, ул берәүне дә битараф калдырмый, ихлас уйландыра, сокландыра, елата да.

Ф. Әхмәтнең якты, оптимистик рухта язылган «Сабантуй» симфоник сюитасы да, Татар дәүләт жыр һәм бию ансамбле өчен махсус язылган «Сабантуй» хореографик композициясе дә, спектакльләргә ижат ителгән дистәгә якын музыка, балалар өчен дистәләгән жыр һәм пьесалар, бик күп башка әсәрләре бар.

Һәм, әлбәттә, Фасилне халык иң элек жыр остасы итеп белә, таный, ярата. Дөрес, соңгы елларда эре күләмле әсәрләр өстендә эшләп, ул бу жанрдан бераз читләшә төште сыман. Әмма һәр язганы татар жыр сәнгатенә яңалык булып керен калды. Ул саф татар моны, пентатониканы яңа алымнар белән баета. «Таң йолдызы», «Ишкәк ишкәндә» кебек серенадаларны гына искә төшерегез! Күпме үзенчәлекле моң, аһәң, яңгыраш бар аларда? Фасил Әхмәт, гомумән, татар жыры — итальян, испан, башка халыкларның көйләреннән калышмый, киресенчә, Көнбатыш белән Көнчыгыш музыкасының иң матур алымнарын үзендә чагылдыра, дигән фикердә тора. Композиторның жыр өлкәсендәге фидакарь, новаторларча эшчәнлеге, татар жырына ул керткән яңалык югары бәя алды — ул сөекле Тукае исемен йөрткән Татарстан Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Фасил Әхмәт бүген дә яңа ижат планнары белән янып яши. Гомеренең иң житлеккән, бәрәкәтле өченче фасылын ул яңа әсәрләр белән баетып үтмәкче. Ижат планнарында — балет, яңа симфоник әсәрләр, жыр һәм романслар, музыкаль комедия һ. б.

Еллар аның кара чәчләрен дә шомырт чәчәге төсенә мандылар. Сөекле әти-әнисе инде күптән, 1981 елда ук дөнья куйдылар һәм Яңа Бистә зиратында Тукайлар, Сәйдәшләр, Карилар белән янәшә соңгы ятакларын таптылар. Әсәрләренең берсе «Адажио»ны композитор аларның якты истәлегенә багышлады. Моңлы, хәсрәтле, фажигале музыка... Кайчандыр даһи Сәйдәш Сакай дустын шундый моң белән соңгы юлга озаткан... Әмма әле алда башланмаган яңа фасыл бар, аның каршында көр күңелле, тапкыр телле, үз сүзен әйтә, үз гамәлен кыла белгән батыр йөрәкле, принципиаль карашлы, туры сүзле, искиткеч талантлы Олуг Ижатчы бар. Димәк, жыр дәвам итә:

Бездә әле бу дөньяга
Күңел тулы алкышлар.
Китәсез дәмени,
китәсез дәмени,
китәсез дәмени, аккошлар?

**Рафис ӘХМӘТ.**





# Габделбари Баттал

# КАЗАН ТӨРКИЛӘРЕ

«1. Бүгенге тормыш таләпләре буларак барлыкка килгән сәяси, иҗтимагый һәм фәнни эшләрнең барысында да Бөтенрусия мөселманнарының берләшүе кирәк.

2. Бу максатка ирешү юлында Русия мөселманнары, урысларның тәрәккъый яклылары белән бер фикердә булып, халыкның теләге белән сайланган вәкилләрнең дәүләтне идарә итү һәм кануннар кабул итү эшләренә катышулары нигезендә корылган хокукый оешмалар барлыкка китерү белән шөгыльләнер.

3. Русия мөселманнары, бөтен хокукларда урыслар белән бер дәрәҗәгә куелмасалар, 2 нче маддәдә күрсәтелгән максатка ирешү мөмкин була алмас. Русия мөселманнары моңа канәгать булып, сәяси, иҗтимагый һәм дини хокукларның һәммәсендә урыслар белән һәрьяктан тигез булу; кирәк бүгенге кануннарда, кирәксә хөкүмәтнең чараларында, кирәк чиновникларның эшләрендә — Русия мөселманнарына карата чикләүләрне, басым һәм читләүләрне юк итү өчен мөмкин булган бөтен чараларны кулланачаклар.

4. Русия мөселманнары эшчәнлекләренә бүгенге һәм киләчәктәге ихтыяҗларын күздә тотып юнәлеш бирәчәкләр. Мөселманнарның ихтыяҗларына туры килгән мәктәпләр ачарга, китаплар, газета-журналлар, китапханәләр, уку заллары һәм курслар юлы белән заманча тормышның төп фикерләрен таратырга тырышырлар.

5. Шул планы сызылган максатларга ирешү өчен, мөселманнарның вакыт-вакыт җыелачак корылтайлары тарафыннан кабул ителгән карарлар буенча эш алып барачак «Мәҗлесләр» оештырылачак».

Бу партия ул заманда күбрәк «Русия мөселманнары иттифакы» исеме белән танылa. Партиянең югарыдагы карарларыннан аңлашылганча, көнбатыштагы мәгънәсенә туры килгән бер сәяси фирка түгел иде, чөнки аны оештыручылар Бөтенрусия мөселманнарын бер байрак астына тупларга тырышып, кешелек җәмгыятендәге иҗтимагый сыйныфларны танырга теләмиләр иде. Хәлбуки, мондый сыйныфларның яралгылары гына булса да Русия төркиләре арасында да, әлбәттә, бар иде. Шул сәбәпле, урта хәлле һәм фәкыйрь авыл кешесенең мәнфәгатьләрен яклау максаты белән корылган урыс социалист-революционерлар партиясенә охшарга тырышкан һәм башында мөхәррир Гаяз Исхакый белән Фуат Туктар кебек ялкынлы яшьләр торган бер казанлылар төркеме «Мөселман иттифакы...» фиркасына каршы фронтка басты. Болар, ул көннәрдә үзләре

Ахыры. Башы 3 һәм 4 саннарда.

чыгарган «Таң» газетасының исеменнән алып, «таңчылар» дип атала иде. Болар «Мөселман иттифакы»ның конгрессларына баралар. Русия мөселманнарын бер генә байрак астына, тик бер генә партия эченә туплауның мөмкин түгеллеген, чөнки алар арасында да мәнфәгатьләре капма-каршы торган төркемнәрнен һәм сыйныфларның булуын сөйлиләр вә тавыш-гауга чыгаралар иде.

Моннан тыш, үзләрен «социал-демократ» дип атаучы кечкенә бер төркем бар иде ки, боларның башында Хөсәен Ямашев, һәм соңыннан бу идеядән ваз кичкән Гомәр Терегулов булды. Болар, Оренбург каласында югарыда телгә алынган «Урал» исемле газета чыгарганнары өчен, «уралчылар» дип атала иде. (Язучы Галимҗан Ибраһимов һәм хезмәткәрләре, «урал»чыларның большевик булуын дәгъва иттеләр һәм бу черек нигез өстенә шактый яна дәгъвалар кордылар. Хәлбуки, «урал»чыларның житәкчесе Хөсәен Ямашев 1917 ел февраль һәм октябрь революцияләренә кадәр яшәмәгәнлектән, бу вакыйгалар вакытында нинди сәяси юл тотачаклары билгесез калган иде: шулай да аның дусларыннан булган «уралчы» Гомәр Терегулов та ул революцияләргә кадәр үк бер төрки милләтче булып, буржуазия «хезмәткәрләре» белән хезмәттәшлек итә һәм соңыннан большевиклар әзәрлекләвеннән качып, Русиядән читтә үлә.

«Уралчы»ларның икенче житәкчесе булган Галимҗан Сәйфетдинов исә, Совет хөкүмәте жиңгәннән соң большевиклардан качып Уралга һәм Себергә китә. Үзе кебек социал-демократ булган һәм ирен эзләп Себергә юл тоткан хатыны белән мин бер поездда барган идем. Менә, кызыл тарихчы Г. Ибраһимовның да 1905—1906 елларда большевик булуын исбат итүче кешеләрнең исән калганнары большевиклар хакимияте дәверендә шундый бер хәлдә иделәр. Шулай итеп, Г. Ибраһимов һәм шәкертләре бу дәгъваларын бары тик Х. Ямашев турында гына әйтә алалар, чөнки ул мондый «тарихчыларны» кире кагып, дәшмәслек итәрлек хәлдә түгел.

Бу төркем кешеләре «Иттифак...» корылтайларына бармыйлар һәм үз башлары белән уйлап хәрәкәт итәләр иде. «Мөселман иттифакы»ның билгеле бер ижтимагый сыйныф исеменнән эш алып бармавы һәм шуңа күрә көнбатыштагы мәгънәсендәге бер сәяси партия булмавын «тәрәккъый» яклы муллалар бик аңламасалар да, хокукчы вә сәясәтче булган оештыручылар, әлбәттә, моның аермасын күрәләр иде.

1906 елның 28 январь белән 5 февраль араларында Петербургта узган Икенче гомум Русия мөселманнары корылтаенда «Иттифак»ның уставы һәм программасы кабул ителә һәм раслана. Партия программасының сәяси-икътисади өлеше, ул замандагы урыс сәяси партияләреннән социалист булмаганнарның иң тәрәккъый яклы, иң либерал булган «Конституцион монархия яклы демократлар» (Кадетлар) фиркасының программасына туры килә иде. Милли мәсьәләләрдә, дини эшләрдә исә, тулы автономиясе, телләрнең тулы хокуклылыгы, башлангыч белем бирүнең һәр халык өчен ана телендә булуы кебек дәгъвалар да программада каралган иде. Программаның тормышка ашырылуы өчен, уставның беренче маддәсе буенча, Русия мөселманнары үзәкләре билгеләнгән 16 өлкәгә бүленгән иде. Әмма башка тәрәккъый яклы һәм либерал партияләр кебек, «Мөселман иттифакы» фиркасының да хөкүмәт тарафыннан расланмаган һәм әлегә гамәли эшчәнлеккә күчмәгән бер заманда, Русиядә реакцион режим өстенлек ала башлый.

«Мөселман иттифакы» партиясе әле оеша гына башлаганда, I һәм II Дәүләт Думаларына сайлаулар вакытында, шактый эшчәнлек күрсәткән һәм шуның нәтижәсендә Казан, Кавказия, Төркестан һәм Казакъ иле белән Кырым кебек төрки өлкәләрдән шактый мөселман вәкилләр сайланган. I Думада, мәсәлән, 24 мөселман депутаты бар иде, боларның яртысы Казан татарларыннан иде. II Думада исә мөселман депутатларының саны 34 булып, унбише Казанлы иде. Бу Думаларның һәр икесендә төзелгән «мөселман фракциясе»нә татар депутатлар да кергән иде...

Дума хөкүмәт тарафыннан таратылганнан соң, «Мөселман фракциясе»нең тугыз әгъзасы мәшһүр «Выборг өндәмәсе»нә кул куялар. Боларның өчесе Казан татарлары: Сәетгәрәй Алкин Казаннан, Сәлимгәрәй Жантурин белән Әбүсогуд Әхтәм икесе дә Уфадан иде. Мәгълүм булганча, бу өндәмәгә кул куйган депутатлар, хөкем карары буенча, сәяси хокукларыннан мәхрүм ителеп, өчәр ай төрмәдә ябып тотылалар. II Дума таратылганнан соң, 1907 елның 3 (16) июнь карары буенча, III Думага катнашачак мөселман депутатларының саны бик нык кимetelә. Ә көньяк һәм төньяк Төркестан төркиләре Думага вәкил сайлау хокукыннан бөтенләй мәхрүм ителә. Шул сәбәпле III Думага бары тик ун мөселман депутат кына үтә алган, боларның жидесе Казан татарларыннан була.

Реакция көннәрендә кануннарга каршы торып яки тора алмаганлыктан, «Мөселман иттифакы» таркала. Шуннан соң, реакция көннәре басымы шартларында, төрле өлкәләрнең мөселман төркиләре бары тик мәдәни, иҗтимагый һәм икътисади эшләр белән генә шөгыльләнә алалар.

1917 ел революциясенә кадәрге ун ел эчендә, 3 (16) июнь карары буенча сайланып III һәм IV Думаларга үткән бик аз санлы мөселман депутатлар, кечкенә бер «Мөселман фракциясе» төзеп, үзләренә ярдәмгә җибәрелгән «мөселман бюросы» әгъзаларына да таянып, «Иттифак...» традицияләрен дәвам иттерергә тырышканнар. Әмма Думадагы уң урыс депутатлары массасы эчендә зәгыйфь тавышларын бик сирәк кенә ишеттерә алганнар.

Казан татарлары арасында беренче драма — Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» әсәре 1887 елның ноябрь аенда, Фатих Халиди иҗат иткән икенче драма — «Рәдде бачара кыз» әсәре 1890 елда; бер мәшһүр авторның әсәре булган беренче комедия «Комедия Чистайда» 1895 елда, Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы белән Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» пьесасы 1900 елда чыкса да, 1905 елга кадәр Казан милли татар сәхнәсе төзелмәгән иде әле. Ул 1905 елда мәрхүм Габдулла Кариев тарафыннан оештырыла. «Сәяр» исемен йөрткән бу труппа бик тиз аякка баса һәм үсә башлый. Ике революция арасында «Сәяр»челәр регуляр рәвештә спектакльләр куялар. Репертуарларында оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр булып, ул торган саен киңәя һәм байый. Оригиналь әсәрләрдән Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һәм Кәрим Тинчуринның пьесалары еш уйнала.

Милли театр бары тик Казан белән генә чикләнмичә, милләттәшләр яшәгән башка шәһәр һәм бистәләрдә дә үзешчән сәхнә оешмалары төзелеп, бик еш спектакльләр куела, әдәбият һәм музыка кичәләре оештырыла. Мәгълүм булганча, Кавказиядә һәм Төркиядә баштарак хатын-кыз рольләрен ирләр яки төрки булмаган хатыннар башкарган. Казанда исә, спектакльләр куела башлаганда ук, хатын-кыз рольләрен татар кызлары уйный. Ике революция арасында үткән ун ел эчендә Казан төбәге милли сәхнәсе шактый алга китә һәм бу вакыт арасында «Сәяр» труппасыннан башка да берничә яңа театр оеша һәм бик күп оста, көчле актер һәм актрисалар җитешә.

1905 елдан соң Казан төркиләренең мәдәният, мәгариф-мәктәп эшләре өлкәсендәге эшчәнлеге тагын да көчәя. Ислах ителгән шактый мәдрәсәләр, әйтергә мөмкин, укытучылар әзерләү мәктәбенә әверелдерелә һәм аларда яңа ысулдагы мәктәпләр өчен укытучылар җитештерелә башлый. Дөресрәге, мондый мәктәпләр, «дини мәдрәсәләр» битлеге астында канунннан тыш буларак яшиләр. Әмма урыс хөкүмәте сүздә «дини» йөргән бу мәдрәсәләрнең чын асылын аңлап алгач, аларда тикшерүләр үткәрә башлый, кайберләренең мөдирләрен хөкемгә тарттыра, кайбер мөдирләрне, «административ чара» күреп, ерак җирләргә сөрә. Мәсәлән, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең мөдире Галимҗан Баруди әфәнде 1908 елда ике ел мөддәт (срок) белән төньяктагы Вологда өлкәсенә сөрелә. 1912 елда зур бер «мөселман мәктәбе мәсьәләсе» Сарапул шәһәрендә күзәтелә һәм гаепләнүчеләр эскәмиясенә Буби мәдрәсәсе мөдирләре булган бертуган Гобәйдулла белән Габдулла Бубиләр һәм бу мәдрәсәнең берничә укытучысы утыралар. Соңра болар суд карары белән ике-өч елга төрмәгә утыртылалар. Кечерәк күләмле мондый тыкшынулар еш кабатлана: полиция чиновниклары Казан төбәге мәктәпләренә кинәт кенә һөҗүм итеп, тикшерү үткәрәләр.

Әмма уянган милли аңны полиция чаралары белән буу мөмкинме соң? Ул көннәрдә, урыс хөкүмәте, бер яктан, Казан татарларының мәгариф һәм милли мәдәният хәрәкәтләренә киртә куярга маташканда, ил агалары төрле юллар белән мөселман кардәшләре яшәгән төбәкләрдәге «земство» идарәләренең үзләренә йогынты ясарга тырышалар иде. Бу тырышулар нәтиҗәсендә кайбер «земство»ларның мәгариф бүлекләре янында мөдире татардан булган бүлекчәләр төзи башлыйлар. Менә шундый мәгариф бүлекчәләре татар башлангыч мәктәпләрен, укыту ысулын өйрәтү курсларын ача һәм укытучы-тәрбиячеләр киңәшмәләрен җыя ала иде.

Шул рәвешле, башлангыч белем бирү эшләренең җанлануы һәм тизлек алуы нәтиҗәсендә, заманча педагогика һәм методика таләпләре буенча язылган дәреслекләрнең басылуы да арта. Икенче яктан, ул вакытларда гарәп язуының төрки телгә туры килгән бер сурәттә имлясын алыштыру белән дә шөгыльләнәләр. Башлангыч мәктәпләрне ислах итү дәверендә «ысулы җәдит» мәктәпләре ир балалар өчен генә түгел, бер үк вакытта кызлар өчен дә ачыла. Татар хатын-кыз укытучы, мәдәният, укыту-тәрбия эшләрендә ир укытучылар кебек үк, балалар укыту өчен зур кыюлык белән салкын Себергә, эссе Төркестанга һәм ерак Җидесу

өлкәләренә кадәр китәләр иде. Казан төбәге хатыннары матбага эшләрендә дә ир-атның ышанычлы ярдәмчесе иделәр. Вакытлы матбугат мәйданга килгән дәвердә һәм аннан соң газета һәм журналларда язышкан шактый хатын-кыз исемнәре күзгә ташлана. Соңыннан теш табибы булган Хәдичә Танач (ова) 1907 елда социал-демократ мәсләкле «Урал» газетасының җаваплы мөхәррире иде. Фәхрелбанат Сөләйман Казанда «Сөембикә» исемле хатын-кыз басмасының баш мөхәррире була. Кырымлы Исмәгыйль бәк Гаспралының газетачылык һәм мәктәп эшләрендә уң кулы булган Зөһрә Акчура да казанлы татар кызы иде. Казанлы татар кызлары шактый элек урысның заманча гимназияләрендә, белгечлек бирә торган мәктәпләрендә һәм югары уку йортларында белем ала башлыйлар. Башка ислам өлкәләре белән чагыштырганда, иң беренче булып шулар арасында укыган акушеркалар, теш табиплары, докторлар һәм башкалар өлгерә. 1905 ел революциясеннән соң Казан иле мөселман хатын-кызы азат хәлдә җыелышларга бара, сөйләшүләрдә катнаша, нотык сөйли, гомумән, үз фикерен ачык белдерә ала иде.

1905 ел революциясе елларында әдәбият үсешенә параллель рәвештә ул вакыттагы гарәп хәрефләре белән китап басу машиналары булган басмаханәләр дә арта, нәшрият эшләре дә шактый алга китә. 1914 елда Казан шәһәрендә гарәп язулы ун матбага эшли. Боларның бишесе төрки ширкәтләрнең яисә аерым кешеләрнең шәхси милке иде (Бертуган Кәримиләр; «Өмет», «Милләт» ширкәтләре; бертуган Шәрәфләр һәм элеккеге Харитонов матбагалары).

Бары Казан шәһәрендә генә дә җиде милли сәүдә китап йорты ачыла (Бертуган Кәримиләр, «Сабах», «Мәгариф», «Гасыр», «Юл» ширкәтләре, Һади Максуди, Хөсәеновлар сәүдәсе). Ул елларда китап кибетләре һәм басмаханәләр башка шәһәрләрдә дә (Оренбург, Уфа, Әстерхан, Троицк, Орск һәм хәтта Петербургта да) бар иде.

Идел буенда гарәп хәрефләре белән басылган әсәрләрнең исемлеге 1915 елда Петербургта оештырылган матбугат күргәзмәсенә куела. Бу исемлек игътибарны җәлеп итәрлек дәрәҗәдә зур була.

1905—1907 елларда Казан татарларының икътисади хәле шактый яхшыра. Авыл кешеләре игенчелектә төрле машиналар куллана башлый, кооперативлар, кечкенә кредит банклары төзиләр. Шәһәр һәм бистәләрдә житештерүнең төрле өлкәләренә караган татар ширкәтләре һәм бай кешеләрнең житештерү һәм сәүдә йортлары шактый арта.

Шул рәвешле Казан һәм Урал төркиләре мәдәни һәм икътисади өлкәләрдә үсү, алга китү дәверен кичергәндә, 1914 елның җәендә, Русия дә катнашкан Беренче бөтендөнья сугышы башлана, ә 1917 елның язында, әле сугыш та тәмамланмаганда, икенче урыс революциясе кабынып китә.

## XV

## Икенче урыс революциясе (1917)

Мәгълүм ки, әле беренче Бөтендөнья сугышы дәвам иткәндә үк кабынып киткән икенче урыс революциясе, 1905 елгы революциягә капма-каршы буларак, кинәт җәелә, кыска бер вакыт эчендә патша режимын җимерә һәм бөтен русиялеләр өчен киң өмет офыклары ача. Революциянең беренче көннәрендә үк Казан татарлары да, милли-иҗтимагый, сәяси эшләрне юлга салу өчен, милли комитетлар кора башлыйлар һәм бераздан бу комитетлар «Милли шура» исемен ала. Әмма бу комитет-шуралар ачык сыйфатта булмаган хәлдә, Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан һ. б. шундый шәһәрләрдә кайбер яшьләр тарафыннан сыйныф мәнфәгатьләре нигезендә төзелгән эшче һәм крестьян оешмалары да барлыкка килә. Казанда Мулланур Вахитов мөселман эшчеләрдән социал-демократлар оешмасы төзи һәм «Кызыл Байрак» исемле газета чыгара башлый. Уфада исә югарыда әдәбият турында сүз алып барганда искә алынган мөхәррир Галимҗан Ибраһим, урысларның социалист-революционер партиясенә кушылып, мөселман таскәрләрен «буржуазиягә» каршы оештырырга вә баш күтәрергә тырыша һәм «Ирек» исемле бер кечкенә газета да чыгара. Бу юлы Вахитов төркеме мөселман эшчеләре исеменнән, ә Галимҗан Ибраһимов белән Фатих Сәйфи «фиркасы» исә крестьяннар исеменнән, «буржуазия» дип санап, «Милли шура» чыларга каршы позиция алалар һәм шулай итеп, 1905 ел революциясе көннәрендәге «уралчылар» белән «таңчылар» урынына киләләр. Хәлбуки, бирге яктагыларның калдыклары бу юлы «буржуазия» сафларына күчәләр һәм

ун ел элек тамыр жибәргән «Иттифак»ның калдыклары белән бергә эшлиләр. Әмма милли шурачылар, никтер, бер сәяси партия төзү омтылышында булмыйлар һәм аларның төп кимчелекләре дә шунда иде.

1917 елның май аенда Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының корылтае жыела һәм монда, табигый ки, Казан белән Урал татарлары да катнаша. Бу конгресста тикшерелгән һәм бер карарга киленгән әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе — дәүләт төзелеше (унитаризм-федерализм) мәсьәләсе булып, бу мәсьәләдә Казан вәкилләре ике төркемгә аерылалар. Аларның бер өлеше федерация яклы булып, ә икенче өлеше унитаризм (бер һәм бүленмәс Русия) фикерен яклый. Кавказия, Төркестан, Казакь иле вәкилләре федерация тарафдарлары булып, Башкорт иле вәкиле булган Зәки Вәлиди һәм аның иптәшләре дә боларга кушылалар.

Уфа Диния нәзарәтенә дә элеккеләре урынына халыкның ышанычын казанган мөхтәрәм затлардан мөфти һәм яңа әгъзалар шушы конгресста сайланыла. Мөфтилеккә Казан татарлары арасында гына түгел, ул замандагы Бөтенрусия мөселман төркиләре арасында да танылган һәм хөрмәт казанган педагог, жәдитче галим Галимжан әфәнде Баруди сайлана. (Шушы конгресста бер хатын — Мөхлисә Буби да дини мәжлес әгъзалыгына сайлана. Димәк ки, бер мөселман хатыны, ир-ат белән бертигез хокуклы әгъза булып, югары дини оешма эшендә катнаша башлый. Мондый хәл башка һичбер мөселман өлкәсендә әлегә кадәр күрелмәгән була).

Бу Мәскәү мөселман корылтаенда, унике ел элек булган Түбән Новгород мөселман съездындагы кебек, Бөтен Русия мөселманнары өчен элекке «Иттифак» фиркасына охшаган бер сәяси партия төзү мәсьәләсе уртага куелмаса да, гомум «Мөселман мәркәз шурасы» төзелә һәм аңа әгъзалар да шушы съездда сайланыла. Әмма бераз соңрак, революциянең «тирәнәюе» аркасында, Бөтен Русиядә үзәктән качу һәм таралу хәрәкәте башлану өчен киңрәк мөмкинлекләр ачылганга, Русия читләрендә яшәгән мөселманнар башында унитарист осетин Әхмәт Цаликов булган бу Үзәк советка бик аз әһәмият бирәләр. Соңыннан бер ара Үзәк совет бары Казан татарлары биргән акча хисабына гына эшли.

1917 елның жәй башында Казанда «Мөселман Хәрби Шурасы» төзелә. Моның максаты — Русия гаскәрендә таралган хәлдә булган мөселман солдат һәм офицерларын туплап, аерым мөселман гаскәрләре төзү иде. Дөрестән дә, бу оешма берничә мөселман гаскәри берәмлеген барлыкка китерә һәм ике тапкыр Бөтен Русия мөселман хәрби съездын жыя. Бу Хәрби Шура, исеме һәм төзелеше ягыннан «Бөтенрусия мөселман Хәрби Шурасы» дип аталса да, чыгымнарын бары тик Казан Татарлары гына күтәрә иде.

1917 елның 1 (14) маенда Мәскәүдә Бөтен Русия мөселманнарының беренче съезды ачыла һәм 11 (24) майга кадәр дәвам итә. Монда Русиянең киләчәктәге дәүләт төзелеше турында сүз алып барыла һәм съезд делегатлары берәүләре федерализм тарафдарлары, икенчеләре унитаризм тарафдарлары булып икегә аерылалар. Бу ике төрдәге дәүләт төзелешен яклап чыгыш ясаучыларның икесе дә кавказлылар була. Киләчәктә Русиянең федерация һәм үзәкләштермәү нигезендә төзелүенең мөһимлеге хакында әзәрбайжанлы мәшһүр Мөхәммәт Әмин Рәсүлзадә чыгыш ясый. Ә үзәкләштерү ысулын исә төньяк кавказлы осетин, социал-демократ Әхмәт Цаликов яклап чыга. Бу ике төрле дәгъва съездда бик көчле һәм шау-шулы бәхәс китереп чыгара. Нәтиҗәдә съезд, федерация ысулын кабул итеп, карар чыгара. Көньяк Кавказ (Әзәрбайжан), Төркестан, Казагыстан һәм Башкорт иле кебек Русиянең читләрендә урнашкан төрки өлкәләрнең вәкилләре бер яклы, ә федерация һәм үзәкләштерү тарафдарлары булган хәлдә, Русиянең эчендә урыслар белән аралашып көн иткән Казан татар вәкилләре исә бу хосуста ике төркемгә аерылалар. Мөхәррир Фатих Кәрими һәм Фуат Туктар төркеме федерация тарафдарлары була, ә мөхәррир Гаяз Исхакый төркеме (бу төркемнең күпчелеген гаскәриләр тәшкил итә иде) социал-демократ осетин Цаликовка ияреп, унитаризмны (бүленмәс һәм үзәк Русияне) яклыйлар. Социал-демократ Әхмәт Цаликовның «иҗтимагый-икътисади яктан артта калган мохтариятлы өлкәләрдәге эшчеләрнең изелгән һәм алданган хәлдә калулары мөмкин», дигән фаразыннан чыгып, «бүленмәс Русия» тарафдары булуы аңлашылыр иде дә, әмма электән үк социалист-революционерларның сәяси программасын өстен күргән һәм Мәскәү съезды жыелган вакытта ялкынлы милләтче булып күренгән Гаяз Исхакыйның ни өчен унитаризм яклы булуын аңлавы авыр. Чөнки төп социалист-революционерлар дәүләт төзелеше өлкәсендә федерация яклы иделәр. Төрки бер милләтче өчен төрки өлкәләрнең һич югы автономиягә генә булса да ия булулары милли һәм изге бер дәгъва булмас идеме? Соңыннан

мөһаҗирлектә «Идел-Урал төркиләренең азатлык дәгъвасын» алга сөрүче булган Г. Исхакый Мәскәү съездында «бүленмәс Русия» дәгъвасын яклап бер чыгыш та ясый.

Менә бу корылтай фикерләре:

«а) Мөселман милләтләренең мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен иң унайлы идарә ысулы — милли федерация һәм территория нигезендә төзелгән, һәм дә билгеле бер территорияләре булмаган кавемнәр өчен милли-мәдәни автономияне дә ныгытучы халык җөмһүриятедер.

б) Русиядә яшәгән мөселман милләтләренең бөтен дини һәм мәдәни мәсьәләләрен даими рәвештә алып бару һәм мөселманнарның берлек буларак хәрәкәт итүләрен ныгыту максаты белән гомум Русия мөселманнары өчен законнар чыгару хакына ия булган бер үзәк оешма барлыкка китерелер. Оешманың шәкеле, төзелеше һәм үзенчәлекләре исә бөтен мохтариятле өлкәләрдән чакырылган вәкилләрнең Оештыручы Мәҗлесе тарафыннан расланыр.»

Күренә ки, «билгеле өлкәләре булмаган кавемнәр өчен милли-мәдәни мохтарият» ысулы беренче бөтен Русия мөселманнары съезды карарлары арасында бар.

1917 елның июлендә Казанда бер үк вакытта өч съезд җыела: 1) Икенче бөтен Русия мөселманнары корылтае; 2) Мөселман дине галимнәре җыены; 3) «Хәрби Шура» тарафыннан тупланган гаскәриләрнең беренче съезды. Менә шул өч съезд делегатларының Казан шәһәре театры бинасындагы берләшкән җыелышында элекке Дәүләт Думасы әгъзаларыннан, ул вакытта адвокат булган Садрый Максудиның чыгышы тыңланганнан соң, «Эчке Русия һәм Себер мөселман төрки-татарларның милли-мәдәни мохтарияте» игълан ителә һәм җиде кешелек бер «Мохтарият комитеты» сайлана. Комитет җитәкчесе итеп Садрый Максуди билгеләнә. Уфа шәһәренең милли-тарихи яктан, әллә ни зур кыйммәте булмаса да, мөгаен, башкорт иленә һәм Себергә якын булуы, шунда ук Дини нәзариятнең дә урнашуы игътибарга алынса кирәк, «Мохтарият комитеты»ның эш урыны итеп шушы шәһәр сайланыла. Бу комитетка милли хәзинә тупларга тырышу һәм «Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының Милләт Мәҗлесе»н җыю вазифасы да йөкләтелә.

1917 елның 25 нче октябрендә Русиядә Өченче революция вакыйгасы була. Ул вакытта Русиядә әле иске Григориян календаре кулланылганга, аны «Октябрь революциясе» дип тә, «большевик революциясе» яки «совет революциясе», хәтта «иҗтимагый революция» дип тә атыйлар. Бу революциянең төп үзенчәлеге шунда: аның нәтиҗәсендә Русиядә февраль-март революциясе вакытында төзелгән демократик идарәгә чик куелып, яңа бер диктаторлык идарәсе төзелә. Әмма, большевиклар үзәктә (Петроградта) Керенский хөкүмәтен җимереп, дәүләт властен үз кулларына алсалар да, чит өлкәләрдә аларның хакимияте бик тиз төзелә алмый. Шуңа күрә алар Бөтенрусия Оештыру Мәҗлесе (Учредительное собрание) сайлауларына каршы була алмаган кебек, чит төбәкләрдә җәелгән кечкенә масштабтагы кайбер сәяси һәм милли омтылыш һәм хәрәкәтләргә дә аркылы төшә алмыйлар. Мондый милли омтылышларның берсе — «Эчке Русия һәм Себер төрки-татарлары милләт мәҗлесе»нә депутатлар сайлау һәм Милләт Мәҗлесенең Уфада тупланып, милли эшләрне хәл итүе иде. Чынлыкта, Уфада Милләт мәҗлесе Советлар властька килгәннән соң — 1917 елның 30 ноябрендә җыела һәм 1918 елның 22 гыйнварена кадәр эшли. Милләт Мәҗлесе бу 52 көн дәвам иткән беренче һәм соңгы җыелуында милли-мәдәни мохтариятнең конституциясен тикшерә һәм кабул итә. Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының динимилли ихтыяҗларын чагылдырган кануннар чыгара һәм «милли өлкә»ләрнең чикләрен билгели.

Моннан тыш, ул вакытта Казан университетының тарих-филология факультеты студенты һәм «Милли-мәдәни мохтарият комитеты» әгъзасы Галимҗан Шәрәф, «рәсми эшләреннән тыш», әле «Идел Урал штаты» (дәүләте) проекты белән дә шөгыльләнә. Күз алдында тотылган бу яңа дәүләтнең чикләрен билгели, бу чикләр эчендә төрки халыклар бераз булса да күпчелекне тәшкил итәчәк очракта, андагы халыклар санына караган статистик мәгълүматларны тәртипкә китерә. Бу темага карата ул Милләт Мәҗлесенә тәкъдим итәр өчен җентекле бер чыгыш та әзерләгән булса кирәк. Милләт Мәҗлесе әгъзаларыннан Галимҗан Ибраһим(ов) белән Ильяс Алкинның тырышлыгы нәтиҗәсендә төзелгән «җирчеләр» төркеме шунда ук бу проектка тотына һәм аның Мәҗлестә тикшерелүен таләп итә. Һәм, чыннан да, Милли Мәҗлес Г. Шәрәфнең бу мәсьәләгә караган чыгышын тыңлый һәм әлеге мәсьәләне ахыргача хәл итү максатында Казанда эшләячәк «Җирле мохтарият комитеты»н сайлый.

Миллэт Мэҗлесендэ 120 депутат була. Болар билгеле бер сэяси һэм икътисади программага ия ниндидер бер сэяси партиягэ туплану нигезендэ түгел, э «көн мэсьэлэлэре» буенча фикерлэрнең туры килүе нигезендэ ике фракциягэ аерылалар. Берсе «җирчелэр (тупракчылар) фракциясе» була. Аның вэкиллэре, әле генә искә алынганча, Г. Шэрэфнең проектын кабул итеп, милли-мэдэни мохтарият белэн генэ чиклэнмичэ, территория нигезендэ өлкэ мохтариятен яклаучылар булып та күренэлэр иде. Бу фракция вэкиллэре нигездэ революция елларында төзелгэн солдат комитетларыннан сайланган офицерлар, солдатлар, югары уку йортларында укучы студентлар, «Хэрби Шура» вэкиллэре, шул елның мартында социалист һэм революционер булып йөргэн яшь язучылар, укытучылар һэм большевиклыкка кайбер кандидатлар бар иде.

Икенчесе «Төркичелэр фракциясе» иде. Аны күбесенчэ мөхтэрэм зыялылар, тэрэккый яклы муллалар һэм кайбер тыныч сэяси фикерле яшьлэр тэшкил итэ. Бу фракциядэ утызлап мулла була. Фракциянең башында Садрый Максуди, адвокат Биниэмин Әхтэм һэм мөхэррир Гаяз Исхакыйлар тора.

Уфа «Миллэт Мэҗлесе» вакытлы «Мохтарият комитеты» урынына даими башкарма комитеты булган «Милли Идарэ»не сайлый. Аның Диния нэзарэте, Мэгариф нэзарэте, Малия (финанс) нэзарэте кебек өч министрлыгы бар иде. Һэр нэзарэтнең биш эгъзасы булып, араларыннан берсе нэзарэтнең рэисе булачак һэм бөтен бу өч нэзарэтнең башында Милли Идарэ рэисе торачак иде. Милли Идарэ рэисе итеп Садрый Максуди сайланылган иде.

Милли Идарэ 1918 елның гыйнвар ахырында, мэмлэкэтнең иске идарэ системасы инде тэмам җимерелгэн, э яңасы элегэ тиешенчэ төзелеп җитмэгэн бер дэвердэ, үзенэ тапшырылган эшлэрне идарэ итэргэ керешэ. Миллэт Мэҗлесе эгъзалары исэ өйлэренэ таралалар.

Югарыда да искэ алып киткэнебезчэ, «Эчке Русия һэм Себер төрки-татарларының Миллэт Мэҗлесе большевиклар хакимиятне үз кулларына алгач» тупланган булса да, большевик идарэсен вакытлы бер вакыйга гына итеп санаганга күрэ, Совет режимына карата нинди позиция алачагын ачыклап торуны кирэк тапмаган. Хэлбуки, яңа властьның иртэме-соңмы Уфадагы Милли Идарэ белэн дэ шөгыльлэнэчэге һэм көннэрнең берендэ аның белэн исэп-хисапны өзэчэге мэгълүм иде. Нэкъ шулай булды да. Эшнең башында торучы Совет чиновниклары эүвэлрэк Милли Идарэгэ кагылмасалар да, 1918 елның февралендэ «Брест — Литовск тынычлык килешүе» төзелеп, ил эчендэ революциянең «кинэюе-тирэнэюе» өчен иркенлек кысылгач, Казан һэм Уфадагы төрки милли оешмаларга рэхимсез һөҗүм башлыйлар. Шул елның язына таба Казандагы Хэрби Шура таратыла, э инде 25 апрельдэ Уфа Милли Идарэсен дэ җимерэлэр. Бу милли оешманың өч нэзарэтеннэн бары тик берсе — Диния нэзарэте генэ сэясэткэ катнашмау шарты белэн калдырыла. Ягъни яңа режимның да, иске патшалык режимы кебек үк, асылы калган, бары исеме генэ үзгэргэн «Духовное собрание»нең генэ яшэвенэ юл куя. Милли Идарэ рэисе Мэскэүгэ барып кайбер омтылышлар ясап караса да, бер нэтиҗэ дэ чыгара алмыйча, Петроград аша Финляндиягэ китэргэ мэҗбүр була.

Милли Идарэдэн соң Милли Шуралар да таркатыла, бөтен милли газета һэм журналлар ябыла, матбагалар конфискациялэнэ. Миллиятче җэмэгать эшлеклелэренең бер өлеше кулга алына һэм башка бер өлеше эз яшерергэ мэҗбүр була.

Мэгълүм ки, 1918 елның җэендэ Идел буенда, тагы да дэресрэге, Урта Иделдэ, Советларга каршы коралды халык хэрэкэте кабына. Бу — Русиядэ ике елга якын барган эчке сугышның башлануы иде. Әүвэл бу хэрэкэтнең житэкчелэре «Бөтен Русия Оештыру Мэҗлесе»нең («Учредилка») кайбер революцион социалист фиркалар эгъзалары була. Болар Самара шэһэрендэ «Оештыручы Мэҗлес эгъзалары комитеты» исемле бер сэяси оешма барлыкка китерэлэр. Бу комитетка Русия Оештыручы Мэҗлесенең кайбер казанлы татар эгъзалары да катнаша.

Коралды көрэштэ Казан татарлары һич тэ урыс эшчелэре һэм авыл кешелэреннэн ким эшчэнлек күрсэтми. Август башларында Казан аклар («Халык армиясе») тарафыннан алынгач, шэһэрдэ аерым бер кечерэк «мөселман атлы гаскэре» оеша.

Бу хэрэкэт вакытында Советлардан азат ителгэн Уфа шэһэрендэ Милли Идарэнең анда җыела алган эгъзалары бер кечкенэрэк «Милли идарэ» ачалар. «Эчке Русия һэм Себер төрки-татарларының милли идарэсе»нең вэкиллэре Уфада 1918 елның сентябрендэ җыелган «Дэүлэт киңэшмэсе мэҗлесе»нэ дэ катнашалар.

Мәгълүм ки, бу «Дәүләт киңәшмәсе мәҗлесе»н төзүгә, Советларга көрәш оештыру һәм җәелдерү максаты белән тудырган, югарыда телгә алынган Самара комитеты вәкилләре һәм Омскидагы вакытлы Себер хөкүмәте вәкилләре арасындагы килешү нәтиҗәсендә карар бирелә. Ул көннәрдә Советларга каршы көрәшкән яки көрәштә катнашмасалар да, бу көрәш тарафдары булган бөтен төркем оешмаларның вәкилләре шушы киңәшмәгә чакырылачаклар иде. Бу вакытта, Милли-мәдәни мохтарият вәкилләреннән тыш, тагын казакъларның Алаш Урдасы, Башкорт иле һәм Төркестан «хөкүмәт»ләренең делегатлары белән «Русияне Оештыру мәҗлесе»нең төрки әгъзалары да ул киңәшмә эшенә катнашалар.

Русиянең Уфадагы Киңәшмә мәҗлесе 1918 елның 21 сентябрендә ачыла, 8 октябрьдә ябыла. Биш кешелек бер Идарә оештырыла һәм аның башына тыныч революционер, социалистлар партиясе тарафдары Авксентьев куела. Киңәшмә мәҗлесенең ахырларына таба, Самара шәһәре кызыллар тарафыннан басып алынгач һәм Уфаның да шул хәл алдында торуы сәбәпле, Идарә үзенең эш урыны итеп ул вакыттагы Себер хөкүмәтенең үзәге булган Омск шәһәрен сайлый. «Оештыручы Мәҗлес әгъзалары конгрессы» бер даими оешма төзиләр һәм монда кайбер Казан татар депутатлары да катнашалар. Бу оешма ул көннәрдә кызылларга каршы көрәшкән чех гаскәрләре тарафыннан басып алынган Екатеринбург шәһәренә урнашуны уңайлырак таба.

Безнең «Күчмә Милли Идарә»дә, әлбәттә, Уфада кала алмаячак иде. Шуңа күрә ул Себердә, Омск янында урнашкан һәм халкының күбесе төрки булган Кызылъяр (Петропавловск) шәһәренә күченергә карар бирде һәм Милли Идарәгә рәсми карылышы булмаган кайбер төрки җәмгыять хезмәткәрләре вә газетачылар да шунда килделәр. «Күчмә Милли Идарә» монда бер «күчмә оешма» хәлендә иде. Ашыгыч һәм әһәмиятле эшләре дә юк иде, чөнки «Милли Идарә»гә караган иң күләмле төбәк — «Эчке Русия төрки-татарлары» артта, бик еракларда калган. Анда Совет хакимияте урнашкан яки урыны-урыны белән сугыш бара иде.

Милли Идарә әгъзалары, ара-тирә бергә җыелып, кайбер милли эшләр белән, бигрәк тә «Себер төрки-татарлары»ның милли-мәдәни ихтыяҗлары белән шөгыльләнә иде. Күчмә Милли Идарә Кызылъярда акрын-акрын булса да эшен дәвам итеп, Омскида булган бер хөкүмәт түнтәреше аның хәлен бөтенләй авырайта. Ягъни, 1918 елның 30 ноябрендә Омскидан урыс генераллары һәм үтә дә милләтче либераллар, «большевиклар белән сугыш хәрәкәтләренә комачау итүдән башка бер эшкә дә ярамаган» демократ Идарәне таратырга карар бирәләр һәм иртәгәсе көнне бу оешманың дүрт социалист әгъзасын кулга алалар. 1918 елның 2 декабрендә исә Омск Идарәсендәге «милли оборона министры» булган адмирал Колчакны «Бөтен Русиянең баш хакиме» дәрәҗәсенә күтәрәләр. Бу инде Омскида үзенә бертөрле диктаторлыкның төзелүе дигән сүз иде. Омскидагы Идарә белән бергә Екатеринбургтагы Оештыручы Мәҗлес әгъзалары оешмасы да таратыла.

«Кызыл» диктаторлыкка каршы бертөрле «кара» диктаторлык кебек булган Колчак хөкүмәте бары тик большевикларга гына түгел, барлык социалистлар, демократлар һәм урыс булмаган милли оешмаларга да сугыш ачканга, Советлар деспотизмына каршы сугышкан демократик көчләрнең каршысында ул деспотизмнан аз гына да хәвефсезрәк булмаган башка бер дошман — реакцион урыс шовинистлыгы баш күтәргән була.

Шулай итеп, Себергә күченгән милли оешмабыз һәм сәясәтчеләребез ике ут арасында калган бер хәлгә төшкәннәр иде: бер яктан, алар большевикларга каршы көрәш аркасында шул хәлгә калган булсалар, икенче яктан, Колчак хөкүмәте Милли Идарәгә үз тәртип-программалары буенча эш итәргә рөхсәт бирми. Киресенчә, бу оешманың вәкилләренә дини-милли эшләребездә элекке Русия империясе кануннары җыентыгының вакыты үткән 11 нче томының билгеле маддәләре буенча эш йөртергә әмер итә иде.

Күчмә Милли Идарәнең Кызылъярдагы эшләреннән берсе — 1919 елның язына таба Колчак хакимияте астында булган кайбер «Милли Шура»ларның вәкилләрен чакырып, бер «Күчмә Милләт мәҗлесе» җыеп, ул көннәрдә Версальдә җыела торган тынычлык конгрессына Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының милли һәм сәяси теләкләрен белдерү өчен делегатлар сайлау булды. Мөхәррир Гаяз Исхакый «Тынычлык оешмасы» әгъзасы итеп Уфада узган Милләт Мәҗлесендә үк сайланган була. Шунда ук сайланган мөхәррир Фатих Кәрими араларында (Кызылъярда) булмаганга, аның урынына Русияне Оештыру Мәҗлесенең төрки әгъзаларыннан булган һәм ул вакытта Кызылъярда торган Фуат Туктар сайлана. Бу ике кеше, Парижга китә алсалар, ул вакытта анда яшәве ихтимал булган Милли Идарә рәисе Садрый Максуди белән берләшеп, үзләренә йөкләтелгән вазифаны җиренә җиткереп башкарырга тырышачаклар иде.

Казандагы Оештыру Мәҗлесе әгъзалары Фуат Туктар белән Гомәр Терегулов Екатеринбургтагы Оештыру Мәҗлесе комитетыннан, Татар нәшрияте ачачакбыз дип, берникадәр акча алалар. Менә шул акчага Кызылъяр шәһәрендә «Маяк» исемле бер кечкенә газета чыга башлый. Аны бирегә качып килгән кайбер мөхәррирләр чыгара. Әмма матбага, хәреф җыючылар һәм шрифт кытлыгыннан, шуның өстенә сәяси әсәрләрнең дә уңышсыз булуы сәбәпле, газета тиешенчә таралып китә алмый. Ул утыз нөсхә генә чыгып кала.

1917 ел революциясенә кадәр бездә «Башкорт иле мәсьәләсе» дигән бер мәсьәлә юк иде. Чөнки Урта Идел (Казан) татарлары белән Кама аръягы һәм Урал (Башкорт иле) төркиләре арасындагы икътисади һәм сәяси бәйләнешләрнең мең ел элек башланган булуы мөмкин. Уртак бер афәт булган урыс басып алуы исә, башта сәяси өлкәдә, соңыннан иҗтимагый-мәдәни өлкәдә, аларның чынчынлап берләшеп кайнашуларына сәбәп була. Бу афәт һәр ике өлкәгә дә бер үк вакытта диярлек килә. Ул заманнардан бирле дүрт гасырга якын вакыт үтеп киткән. Бу озын вакыт аралыгында татарлар белән башкортлар тәмам аралашып, кайнашып яшиләр. Дин, әхлак, холык, гореф-гадәт, йола, тел һәм мәдәният ягыннан бер-берләренә сизелерлек тәэсир итешәләр. Бу катышу һәм үзара тәэсир итешүләр нәтиҗәсендә уртак язу теле һәм әдәбият мәйданга килә. Бу яңа телне эшкәртү һәм яңа әдәбиятны үстерүдә һәр ике халыкның фикер һәм гыйлем ияләре зур көч куялар. Югарыда да искә алып үткәнебезчә, бу фикер һәм гыйлем ияләре мәдрәсәдә белем алып житешәләр иде. Казан өлкәсендәге мәдрәсәләр белән Башкорт илендәге, Оренбург, Каргалы, Уфа, Троицк, Эстәрлебаш һ. б. шәһәр һәм авыл мәдрәсәләре арасында укыту һәм тәрбия ысуллары ягыннан һичбер төрле аерма юк иде. Имамнар һәм мөдәррисләр арасында татарлар күп, башкортлар да шактый иде. Бу хосуста бертөрле дә аерымлану, читләшү юк иде. Мондый мәдрәсәләрдә укучы башкорт телендә язмый, бу тел халык сөйләм теле буларак кына яши иде. Казан илендәге Тәтеш шәһәре тирәсендә яшәгән бер имам (Җамалетдин Бикташи — ред. искәрмәсе) язган «Фәзаилеш-шөһүр» белән, асылында башкорт булган Таҗетдин Ялчыгол углының «Рисаләи газизә» исемле әсәренең телләре арасында һичбер төрле аерма юк. Соңыннан Башкорт иленнән Хабибеннәҗар Үтәки, Зәки Вәлиди кебек авторлар әсәрләрен, Шәехзадә Бабич һәм башкалары шигырьләрен башкорт телендә түгел, формалашып килә торган уртак язу телендә язганнар. Башкорт язучысы Х. Үтәки, Казанда мәшһүр динче һәм тарихчы Ш. Мәрҗани мәдрәсәсеннән белем алып чыга; атаклы тарихчы вә фикер иясе Зәки Вәлиди Туган да әнисенең абыйсы булган бу Х. Үтәки мәдрәсәсендә укыган һәм соңыннан Казанда, «Күл буе» мәдрәсәсендә тарих укыткан. Бу мисалларны тагын да китерергә мөмкин. Бу хәл казанлылар белән башкорт иле халкының ни дәрәҗәдә катышкан булуларын күрсәткән үрнәкләр түгелме соң? Кыскасы, башкортлар, сан ягыннан төп казанлылардан соң анда иң зур төрки кавем булса да, казанлылардан аерым һәм аларга мөнәсәбәтсез оешкан бер милләт булып саналмый иде.

Шулай да башкортлык мәсьәләсе кайдан килеп чыкты соң?

Безнең фикеребезчә, 1917 ел революциясе кабынгач, «башкортлык мәсьәләсе» булмаса да, «башкортлык өлкәсе» мәсьәләсе мәйданга чыга. Бу исә бер сәяси төшенчә, ягъни югарыда да искә алганыбызча, 1917 елның май аенда Мәскәүдә җыелган Беренче Бөтен Русия мөселманнары съездында, дәүләтнең төзелеше мәсьәләсе каралганда, делегатлар «унитарист» вә «федералист»лар булып, ике төркемгә аерылганда, Кавказия, Төркестан, Казакъ иле делегатлары федерация тарафдарлары булган кебек, Башкорт иле вәкилләре дә аларга кушылалар. Башкортлар федерация нигезендә төзелгән Русиядә бер «Башкортлык өлкәсе» кирәк булачак, дигән фикерне алга сөрәләр. Димәк, Мәскәү съездында Башкорт иле вәкилләре «Мохтариятле Башкорт өлкәсе» мәсьәләсен уртага куюлары белән Казан делегатларыннан аерылалар. Чөнки казанлыларның федералистлары Башкорт иленең мохтариятле (автономияле) бер өлкә була алачагына бөтенләй дә ышанмаганга, бу фикерне бик нык каршылыклы дип табалар.

Менә, казанлылар белән башкортлар арасында сәяси аерымлык диелгән бер нәрсә шул рәвешле күренә башлый.

«Башкорт өлкәсе» мәсьәләсенең уртага чыгуы ничек була соң? Сәяси эшчәнлеге өчен тарихтан илһам алган тарихчы Зәки Вәлиди, бөтен русиялеләр өчен киң офыклар ачкан 1917 елгы Бөек урыс революциясе булганнан соң, Русия федерациясе эчендә бер мохтариятле Башкорт өлкәсенең булырга тиешлеге турында уйланган һәм бу фикерне Башкорт иле съездларында уртага куйган кебек, Мәскәүдәге зур корылтайда да алга сөргән. Ихтилял көннәрендә җыелган Башкорт җыеннарында иң зур әһәмият бирелгән мәсьәлә җир мәсьәләсе булганга,

З. Вәлиди тарихтан илһамланып уртага чыгарган мохтариятле Башкорт иле хакындагы проблема җирле халыкның җир мәсьәләсендәге теләкләре белән туры килә.

Бу эшнең теоретигы һәм соңыннан тормышка ашыручысы булган З. Вәлиди тарафыннан берсе «Зур Башкорт иле», икенчесе «Кече Башкорт иле» булып, ике төрле мохтар Башкорт иле проекты төзелә. Болардан берсенә башкортларның барысы да диярлек керәчәк, ләкин анда урысларның сан өстенлеге артачак иде. Икенчесенә исә башкортларның бары зур бер өлеше генә алыначак, әмма урысларның сан проценты нисбәте кимиячәк иде. «Зур Башкортстан»ны ерак бер хыял хәлендә ташлап, халкының дүрттән өч нисбәтендә төркиләрне эченә алачак булган «Кече Башкортстан» мохтариятен төзергә карар бирелә.

Мәскәү дәүләте басып алынган чит өлкәләрне административ берәмлекләргә аерганда, җирле халыкны географик һәм административ яктан бүлгәләү, аларны бер-берсеннән аеру, берләшүләренә комачау итәчәк чаралар куллану максатын алга сөргәнлеге турында югарыда да искә алган идек. Соңыннан, Петербург дәверендә, Беренче Петр һәм Икенче Екатерина заманында, ул дәвердәге Русияне губерналарга аерганда да җирле халыкны, бигрәк тә мөселман төркиләрне, төрле вилаятләргә тарату һәм бүлгәләү максаты күз уңында тотыла. Бу шәйтани чаралар нәтиҗәсендә төрле өлкәләрдә яшәгән төркиләрнең (төп казанлылар белән башкортларның) ул вилаятләрдәге гомум халыкка нисбәте 1917 ел ихтилялыннан алда шул күренештә иде.

Казан губернасында 31%, Самара губернасында 11%, Сембер губернасында 9%, Вятка губернасында 5%, Уфа губернасында 52%, Оренбург губернасында 22%.

Күренә ки, урысларның төрки-татарлар яшәгән бу өлкәләрне кисеп, теткәләүләренә дә карамастан, Казан иле (Урта Идел төбәге), Уфа һәм Оренбург губерналары (Көньяк Урал төбәге) һаман әле җирле халыклар күпләп яшәгән урыннар булып калалар. Кече Башкортстан мохтарияте элекке Уфа, Оренбург, Пермь һәм Самара губерналарының карталары төзәтелеп төзелә һәм бу яңа мохтариятле өлкәдә 75% нисбәтендә төрки халык булачагы планлаштырыла. Шул рәвешле, Казан вә Башкорт иле төркиләре өчен «була алмас» кебек күренгән аерым бер мохтариятле өлкә турында фикер беренче тапкыр уртага чыгарыла. Бу фикер башкортларны канатландырган кебек, башкаларны да шактый уйланырга этәрә. Безнең уебызча, Башкорт мохтарияте турындагы фикернең уртага чыгарылуының әһәмияте дә менә шунда.

Шулай да «Кече Башкортстан»ны барлыкка китерү белән бөтен Урта Идел һәм Көньяк Урал төркиләренең сәяси язмышы хәл ителүе турында сүз булуы да мөмкин түгел әле. Хәтта башкортларның сәяси язмышын да хәл итми иде. Шуның белән бергә, төп Казан татарларының федерация һәм өлкәчелек тарафдары булганнары Башкорт өлкәчелеге хәрәкәтенә теләктәшлек күрсәткән кыяфәт алалар. Ләкин алар бу хәрәкәтнең бары тик сәяси-икътисади кыса эчендә калуын, тел һәм мәдәният аерымлыгы турындагы мәсьәләгә кадәр җитмәвен телиләр иде.

## XVI

## Совет дәвере

Югарыда да искә алганыбызча, Казан һәм Урал төбәкләрендә мохтариятле бер төрки өлкә барлыкка китерү мәсьәләсе, иң беренче башкортлар тарафыннан уртага чыгарылган булса да, 1917 елның ахырларына таба «Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының Милләт Мәҗлесе»ндә бу мәсьәлә тагын да киңрәк бәхәс тудыра. Анда мәсьәлә «Идел-Урал штаты» шәкелендә уртага чыга. Урта Иделдә һәм Көньяк Уралда яшәгән төркиләрнең бөтенесен дә диярлек бу мохтариятле өлкә эченә алу максаты күз алдында тотыла. Бу өлкәнең мәйданы 221 мең км², халкының 6,5 миллион булачагы исәпләнә. Димәк, халкының якынча 3,5 миллионы төркиләр, калганы урыслар һәм башка азчылык милләт вәкилләре булачак иде. 1918 елның кыш ахырына таба Казанда бу «штатлар»ны рәсми игълан итү омтылышы булса да, моңа Совет власте каршы төште. Аннан соң большевиклар Казанда «Җирле мохтарият комитеты»ндагы барлык материалларны мөсадәрә итеп (конфискацияләп), Мәскәүгә китерәләр һәм 1918 елның март аенда «Идел-Урал штатлары» урынына бер «Татар-Башкорт Совет Җөмһүрияте» барлыкка китерeләчәген игълан

итәләр. Бу турыдагы Декретка ул көннәрдә Милләтләр эшләре буенча халык комиссары булган Иосиф Сталин, Эчке Русия мөселман эшләре буенча комиссар Мулланур Вахитов, шул оешма әгъзасы булган Галимҗан Ибраһим(ов), шунда башкорт вәкиле Шәриф Манатов һәм Милләтләр эше буенча халык комиссарлыгының баш секретаре Деманштейн кул куялар. Бу мәсьәләне карау өчен 1918 елның җәендә бернечә тапкыр киңәшмә мәҗлесе җыела һәм сентябрь аенда күз алдында тотылган җөмһүриятне төзергә тиешле съезд җыю турында карар чыгарыла. Әмма җәй ахырына таба Урта Иделдә Советларга каршы баш күтәрү уты кабына һәм кызыллар-аклар сугышы башланып китә. Шул сәбәпле әлеге мәсьәлә хәл ителмичә, ачык килеш кала.

Эчке сугышлар башланганда һәм соңыннан да, Себер ягыннан карагруһ урыс милләтчеләре булган Колчак гаскәрләренең янавы аркасында, 1919 елның 18 февралендә Советлар тарафына күчергә мәҗбүр булган башкорт җитәкчеләре Мәскәүдәге Совет юлбашчылары белән (ул вакытта әле Ленин да исән) килешү төзиләр. Нәтиҗәдә Башкорт Мохтариятле Совет Җөмһүрияте игълан ителә. 1920 елның 9 июнендә исә Татар Мохтариятле Совет Җөмһүрияте төзелә. Бу җөмһүриятне төзү турында Бөтен Русия Советлар Башкарма Комитеты белән Халык Комиссарлары Советының май аенда декреты чыга. Шул ук елның 25 июнендә Казан Өлкә Советы башкарма комитеты үз власть һәм вәкаләтен яңа оештырылган Татар җөмһүрияте ревкомына тапшыра.

Ул замандагы Башкорт җөмһүриятенең мәйданы 141 884 км² булып, халкы 1 259 059 кешедән гыйбарәт иде. Болардан:

төркиләр — 747 000 кеше, ягъни 58%,
урыслар — 467 000 кеше, ягъни 35%,
башка халыклар — 103 000 кеше, ягъни 8%.

Кайчандыр бер өязнең үзәге булган Эстәрлетамак каласы башта башкала иде. Ләкин үзәк бераздан Уфа шәһәренә күчерелә. Яңа җирләр хисабына җөмһүрият зурайтыла. Моның нәтиҗәсендә урысларның процент нисбәте дә арта. Электән үк бу җөмһүриятнең 12 кантоны вә Оренбург һәм Самара губерналарының эчендә калган «утраулар»ы бар иде.

Татар җөмһүриятенә килсәк, ул исә элекке Казан губернасының өчтән ике өлешен, элекке Уфа губернасының Минзәлә өязен, Самара өлкәсеннән Бөгелмә өязенең иң зур өлешен, Сембер губернасыннан Сембер һәм Буа өязләрен, Вятка өлкәсеннән Малмыж һәм Алабуга өязләренең берәр өлешен кертеп төзелә. Башкаласы Казан шәһәре була. Бу җөмһүриятнең дә 12 кантоны һәм мөстәкыйль идарәгә ия булган бер шәһәре — Казан була. Мәйданы 81 379 км², ә халык саны 3 276 000 кешедән гыйбарәт дип күрсәтелә...

Шулардан:

төркиләр — 1 644 000, ягъни 50%,
урыслар — 1 332 000, ягъни 41%,
чувашлар һ. б. халыклар — 300 000, ягъни 9%.

Күренә ки, Татар Җөмһүриятенең мәйданы Кече Башкорт җөмһүрияте белән чагыштырганда да кечкенәрәк булса да, халкы анықыннан артыграк булган.

Бу җөмһүриятләр СССР конфедерациясен тәшкил иткән «мөстәкыйль» җөмһүриятләрнең берсе булган РСФСР составына керәләр һәм аның чикләре эчендә «мохтариятле» иделәр. Бу мохтарият җөмһүриятнең эчке эшләре, юстиция, милли мәгариф, сәламәтлек саклау һәм социаль ярдәм, авыл хуҗалыгы министрлыкларына рәсми яктан ия булса да, әлеге министрлыклар Мәскәүдәге Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты каршында җаваплы иделәр.

Мохтариятле җөмһүриятләрнең азык-төлек, малия нәзарәтләре *(министрлык)*, халык хуҗалыгы советы, хезмәт һәм төзекләндерү оешмалары, эшче-крестьян инспекциясе, почта-телеграф идарәсе һәм Чека турыдан-туры Мәскәүгә карап, үзәкнең директиваларына һәм әмерләренә туры китереп хәрәкәт итәргә бурычлы иделәр.

Татар Җөмһүриятенең үзәге булган Казанның шәһәр советы рәисе Җөмһүриятнең Министрлар Советына тавыш бирү хокукы белән катнаша иде.

Татар һәм Башкорт җөмһүриятләренең хәле. Бу ике җөмһүрият бәйле булган Русия Социалистик Федератив Совет Җөмһүрияте (РСФСР), өчсыз-кырыйсыз СССР берлеген төзүче 10—11 «мөстәкыйль» җөмһүриятнең берсе, иң көчлесе, һәр яктан өстен, алдынгы һәм мәйданы буенча да иң зурысы иде. Ул Балтыйк буе җөмһүриятләре (Эстония, Латвия һәм Литва), Белоруссия һәм Украинадан тыш, бөтен Көнчыгыш Европаны, Төньяк Кавказны, Кырымны һәм Тын океанга кадәрле бөтен Себерне эченә ала. Бу федератив җөмһүриятнең мәйданы 19 753 000 км²., халкы 113 651 000 кеше иде.

Федератив Русия җөмһүриятендә, күпчелекне тәшкил иткән урыслардан кала, уннарча башка халыклар да яши. Аларның билгеле бер төбәктә азмы-күпме тотрыклы, тыгыз урнашканнарына Мохтариятле Совет Җөмһүриятләре яки Өлкәләре төзергә рөхсәт бирелә. 1938 елда Русия федерациясендә 17 мохтариятле милли җөмһүрият һәм мохтариятле өлкә бар иде. Соңыннан боларның кайберләре (шул исәптән Кырым җөмһүрияте дә) юкка чыгарылды. Советлар Берлеге җирләренең 80%ы, халкының 60%ы, житештерү предприятияләренең 70%ы, сөрү мәйданының 70%ы Русия Федератив Җөмһүрияте өлешенә туры килә. Советлар Берлегенең башкаласы булган Мәскәү шәһәре, Русия Федерациясенең дә башкаласы. Казан, Уфа, Оренбург, Троицк кебек элек-электән милләтебезнең мәдәни үзәкләре булган шәһәрләр дә кайберләре автономияле җөмһүриятләр эчендә, ә кайберләре алардан читтә булып, Русия Федерациясе эчендә иделәр. Күренә ки, гаҗәеп зур Русия Федератив Җөмһүрияте эчендә калган безнең мохтариятле җөмһүриятләр, бары тик «дөядәге колак» кебегрәк кенә яшиләр иде.

Милли мәдәният ягыннан чыгып караганда исә шунысы ачык күренә: акылыбызга килгән — башыбызга төшкән. Ягъни бик борынгы заманнардан бирле бер мәдәниятка ия булган бу ике төрки халык бүген бары тик сәяси-икътисадый һәм географик яктан гына икегә аерылып калмыйча, мәдәниятләре дә бербереннән ераклашкан. Татарларның да, башкортларның да яңа әлифбасы урыс алфавиты нигезендә төзелсә дә, алар арасында, фонетик үзенчәлекләр таләп иткәнчә, кайбер аерымлыклар да юк түгел. XIX гасыр ахырларында барлыкка китерелгән һәм акрынлап җәелә барган татар әдәби теленнән тыш, башкорт сөйләм теленә таянып, яңа бер башкорт язу теле дә ясала. Бу яңа тел ярдәмендә яңа башкорт әдәбияты да барлыкка китерелә башлый.

Асылы белән башкорт булган язучы һәм фикер иясе Габделкадыйр Инан миңа җибәргән язмаларында: «1880 елларда Казанда барлыкка килә башлаган әдәби тел (татар теле) башкортларның уянышында зур роль уйнаган», дип белдерә. Моңа түбәндәге фикерләрен дә өсти: әле XX гасыр ахырларында ук кайбер башкорт зыялылары татар әдәби теленә каршы үз сөйләшләрендә әдәби тел барлыкка китерү тәҗрибәсе ясыйлар. Бу зыялыларның иң танылганы Мөхәммәт Сәлим Өметбай иде. Ул «Ядегәр» исемле әсәрен башта башкортча язган булган да, моның барып чыкмаячагын төшенгәч, татарчага күчергән. Әсәр шул рәвешле Казанда 1892 елда басылып чыга. Соңыннан бу тәҗрибәне Г. Инан үзе дә дәвам иткән. 1913 елда катай башкортчасы белән «Башкорт җәйләвендә» исемле бер хикәя язып, Оренбургта чыга торган «Шура» журналына китерә, әмма баш мөхәррир казый Ризаэтдин әфәнде хикәяне басмый. Автор әсәрен татарчага күчерергә мәҗбүр була, шуннан соң гына хикәя журналда басылып чыга. Мондый күренешләр, аерым омтылыш-тәҗрибәләр дә тагын булгалап алдылар, ди.

Бүген исә, Совет дәверендә, аерым бер башкорт мәдәнияте, башкорт язу теле һәм әдәбияты барлыкка килде. Шулай итеп, мондый бер кызганыч хәл дә туды: инде Татарстанда яшәгән башкортлар һәм Башкорт Җөмһүриятендә калган татарлар бу мәмләкәтләрдә азчылык булып саналалар.

Мәгълүм булганча, большевиклар, 1917 елның ноябрендә властька килгәч ясаган бер игъланнарында, Русиядә яшәгән бөтен халыкларга «Русиядән аерылып чыгуга кадәр, үз язмышларын үзләре хәл итү хокукын» вәгъдә итә. Дәүләт төзелеше мәсьәләсендә исә социал-демократлар партиясенең сәяси программасында булмаган федерация нигезен кабул итәләр, соңыннан милләт нигезендә «мөстәкыйль» һәм «мохтариятле» җөмһүриятләр, «мохтариятле» өлкәләр барлыкка китерәләр. Әмма большевиклар төзегән Совет хөкүмәте, тантаналы декларацияне онытып, Русиядән аерылып берара вакыт мөстәкыйль яшәгән Әзәрбайҗан, Грузия кебек мәмләкәтләрне янадан көчләп Русиягә кушудан тайчанмаган кебек, соңгы вакытларда Русиядән аерылып, 20 еллап мөстәкыйль тормыш иткән демократик Балтыйк буе җөмһүриятләрен дә басып алып советлаштырудан да тыелып кала алмады.

Совет системасында «мөстәкыйль» һәм «мөхтарият» (автономия) сүзләре, идарә эшләрендә кырыс бер үзәкләштерү барганга, «миллият» һәм «милли мәдәният» дигәннәре дә буш сүзләр булып кына калдылар. Сталинның афоризмыннан күренгәнчә: Совет мәдәнияте «бары тышкы калыбы белән генә милли булып, асылы һәм эчтәлеге буенча бәйнәлмиләл». Ягъни Совет системасы без аңлаган мәгънәдәге «миллият»не танымый. «Милли мәдәният» дигәне дә бары тик «тарихи материализм» нигезенә корылган һәм пролетариат максатларына хезмәт иткән вакытта гына яши ала. Милли телләр бары тик материализм фикерен җәелдерү һәм хезмәт ияләренең теләк-омтылышларын яклау чарасы

гына. Шуңа күрә Совет хөкүмәте, кайда да булса берәр милли мәдәният билгеләре күзенә чалынса, аны шунда ук рәхимсез рәвештә изеп юкка чыгара. Советлар берлеге эчендәге кайбер төрки өлкәләрдә төрки яшьләр, Советларның вәгъдәсенә ышанып, милли омтылышлар ясап карыйлар. Милли максатларга хезмәт итәргә теләп, алар хәтта коммунистлар партиясенә дә язылалар. Әмма аларның бөтен омтылышлары «чын» коммунистларның каршылыкларына очрап чәлпәрәмә килә. Үзләре дә бу «җөрьәт»ләре өчен төрмәгә ябылалар, ерак, кеше яшәмәгән җирләргә сөреләләр һәм, хәтта, үтереләләр.

Мондый вакыйгалар Кавказиядә һәм Кырымда, Төркестанда һәм Казан төбәгендә дә булып тора. Советлар белән аңлашып, аның ымсындыргыч вәгъдәләреннән милли максатларда файдалану хыялына күмелгән Сәетгалиев[1], Мохтаров кебек «милли коммунистлар», эш башыннан ераклаштырылып, төрмәгә ябылалар, сөргенгә җибәреләләр һәм юк ителәләр. Әдәбият, культура һәм мәгариф өлкәсендә исә башта мөхәррир Җамал Вәлиди, тарихчы Газиз Гобәйдулла, әдәбиятчы Гали Рәхим кебек коммунист булмаган, фәкать Совет режимына гына яраклашкан зыялыларга үз өлкәләрендә эшләү мөмкинлеге бирелсә дә, соңыннан алар да «зарарлы миллиятчеләр» дип тамгаланалар, мең төрле каршылыкларга очрыйлар һәм хезмәт мәйданыннан чигенергә мәҗбүр булалар. (Биредә исемнәре телгә алынган өч шәхеснең берсе — Җамал Вәлиди яза башлаган «Татар теленең тулы сүзлеге» дигән мөһим хезмәтен дә тәмамлый алмыйча, Чека зинданында туберкулездан үлә. Газиз Гобәйдулла Казаннан Бакуга китә һәм анда профессор булып хезмәтен дәвам итә. Сугыш елларында алган хәбәрем буенча, ул да соңыннан атып үтерелгән. Гали Рәхим сөргенгә сөрелгән булса кирәк. Башкаларны да болар белән чагыштырып карый аласыз...) Совет чорында мондый аяныч язмыш, әлбәттә, бары бу өч казанлы зыялы белән генә чикләнмәгән.

Советлар, ачыктан-ачык, «интернационализм» һәм «материализм» исеме белән, урыс булмаган халыкларны урыслаштыру юлына басалар. 1930 елларда Советлар Берлегендәге төрки халыклар гарәп хәрефләрен калдырып, латин хәрефләре нигезендә төзелгән алфавитны кабул итәләр. Бераздан бу алфавитларны берләштерергә, ягъни бер шәкелгә китерергә омтылдылар. Моңа «бердәйләштерү» дип исем бирелде. Әмма бу бердәйләштерүдә яңа бер берләшү ишарәте сизгән Совет (Мәскәү) хөкүмәте, латин алфавитын ташлатып, төрки халыкларга урыс алфавиты (кириллица) нигезендә төзелгән яңа алфавит кабул иттерергә карар кыла. Бүгенге көндә инде Советлар Берлегендә шактый төрки халыклар тарафыннан бу яңа алфавит кулланыла. Шулай итеп, заманында Николай Ильминский, Ефим Малов, Остроумов кебек миссионер ориенталистлары православие исеменнән тормышка ашыра алмаган эшне большевиклар, материализм-интернационализм исеменнән тормышка ашыра алдылар. Хәтта теләгән алфавитларын кабул итү хокукына да ия булмаган бу нинди милли-мохтар җөмһүриятләр соң?

Югарыда сүз алып барылган җөмһүриятләр «милли» дип аталалар гына иде. Аларда өстенлек алган мәдәният, Сталин әйткәнчә, шәкеле белән «милли», эчтәлеге белән тәмам сыйнфый-интернациональ. Әйе, бу яктан иске «губерналар»ның чикләре үзгәртелеп, татар-башкортлар күпчелекне тәшкил иткән өлкәләрдә берәр идарә берәмлекләре төзелә һәм боларга «Республика» исеме бирелә. Шул ук вакытта Советлар тарафыннан милли мәдәниятне юкка чыгару өчен чаралар да күрелә башлый.

Бу хәлне сизеп торган кайбер зыялылар шул коммунизм дөньясы эчендә милли мәдәниятне коткарырга керешәләр. Монда мисал итеп мөхәррир Галимҗан Ибраһимов белән дин һәм иҗтимагыять белгече Муса Ярулла Бигине алыйк.

Боларның беренчесе 1905 ел революциясе вакытында ук каләм тибрәтә башлаган бер хикәяче. Ике революция (1905—1917) арасында Әхмәтгәрәй Хәсәни, бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр чыгарган газета-журналларда, ул вакытларда иң юаш-өркәк бер нәшер органы булып саналган «Йолдыз» газетасында язмаларын бастыра. Язган нәрсәләре — төрки-татар тормышын сурәтләгән хикәяләр һәм берәзы әдәби тәнкыйть мәкаләләре иде. Болардан тыш, 1911 елдан башлап, Казан татар теленең грамматикасы, әдәбият нәзариясе *(теориясе)* һәм антологиясе буенча да хезмәтләр бастырды. Үзе төп-төгәл без аңлаган мәгънәдә милләтче булып күренә иде. Ул елларда сәясәт белән шөгыльләнүен һич ишетмәдек. Шулай да 1917 ел революциясендә бөтен барлыгы белән политикага кереп китә, сулчы була. Көннәр үтү белән суллашкан, хәтта де-

[1] Бәлки автор Солтангалиевне күздә тотадыр — *Ред. искәрмәсе.*

градацияләнгән урыс революциясе вакыйгалары аны да бетереп ала һәм монын нәтиҗәсе — большевиклык һәм коммунистлык була. Тик Г. Ибраһимов «милли коммунист» иде. Ягъни Русиядә урнаша барган яңа режимга яраклашып үз халкына-милләтенә файдалы булачагына, «милли культура», үз сүзләре белән әйткәндә, «татар мәдәнияте» төзи алачагына ышана иде. Әмма коммунистлар партиясенә рәсми рәвештә керергә бик ашкынып тормый. Сул социалист-революционерлар партиясеннән 1918 елда аерылса да, коммунистлар партиясенә бары тик 1920 елда гына языла. Шул ук елда Автономияле Совет Татар Җөмһүрияте оештырыла, аны Гыйльми Үзәк рәисе итеп куялар. Бу вазифаны башкарганда, ул чынлап та татар мәдәниятен барлыкка китерү юлында шактый хезмәт күрсәтә. Ул елларда бер төркем татар гыйлем һәм фикер ияләренә фәнни оешмаларда эшләү мөмкинлеге ачыла, тикшеренү өлкәләре киңәя. Гыйльми Үзәкнең бу юлдагы хәрәкәте дә жанлана төшә. 1920—1925 елларны эченә алган вакыт аралыгында татар телендә шактый гыйльми, әдәби һәм тарихи язмалар, хезмәтләр басыла. Боларның һәммәсе гарәп хәрефләрендә нәшер ителәләр. 1926 елда Бакы шәһәрендә узган тюркологик конгресста Г. Ибраһимов алфавит алыштыруга каршы булган төркем арасында була.

Әмма ахыры ни булды? 1927 елда мөхәррирнең әдәби иҗатына егерме ел тула. Дуслары бу юбилей хезмәтенә кичә оештырып, аны котлыйлар. Бер күмәк әсәр нәшер ителә. Әмма бөтен бу чаралар бик уңайсыз бер заманга туры килә. Югарыда да искә алганыбызча, Г. Ибраһимов «милли культура» яклы кеше иде. Ә коммунистлар арасында бу фикергә каршы булганнар да бар иде. Моның сәбәпләреннән берсе — мөхәррирне үз итмәү, көнләшү булса, икенче мөһим сәбәбе — Мәскәүләргә ярарга тырышу иде. Мәскәү, әлбәттә, боларны яклый иде. «Милли коммунист» мөхәррир Бакыда узган тюркология конгрессыннан соң ук инде шик астына алына. Ул көннәрдә Галимҗан нык авыру — чахотка авыруының соңгы дәверенә кергән була. Шулай булса да, ул татар мәдәнияте өчен тырыша. Ул партия өлкә комитетының матбугат бүлегендә оештырылган бер конференциядә әлеге мәсьәлә буенча чыгыш та ясый. Бу чыгышы «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән исем астында рисалә (брошюра) итеп бастырып таратыла. Әмма инде бу тезис аның соңгы чыгышы була. Аннан соң рухи яктан да, саулыгы ягыннан да бер дә күтәрелеп китә алмады. 1928 елда Казанда гарәп хәрефләрен калдырып, латин алфавитына күчәләр. Әмма эш моның белән генә бетми. Г. Ибраһимов 1938 елда вафат булып бер ел үткәннән соң, латин хәрефләрен дә ташлап, аның урынына урыс хәрефләре кабул ителә.

Шулай итеп, кызыл режим күләгәсе астында милли татар мәдәнияте барлыкка китерү өчен тырышкан, иске хәрефләрне алыштыруга каршы торган бу милли кызыл мөхәррир, үзенә күнел тынычлыгы булсын, әсәрләренең урыс хәрефләре белән басылуын, иң бөек максаты булган татар мәдәниятенең куркыныч рәвештә таланып җимерелүен күрмичә дөньядан китте.

Муса Ярулла Биги зыялы бер дин галиме. Әмма, дин һәм шәригать мәсьәләләре белән генә чикләнмәгән, дөньядан артта калмаска тырышкан, кешелек җәмгыятендә, бигрәк тә ислам һәм Шәрекъ галәмендә булып торган вакыйгалар белән кызыксынган бер җәмгыятьче, хәтта сәясәтче бер фикер иясе иде. Монда аның турында озаклап сөйләргә җыенмыйм. Гомумән, ул Көнчыгышта һәм хәтта Көнбатышта танылган бер кеше иде. 1904 елда чит илдән Русиягә кире кайткан көненнән алып, Русия мөселманнарының җәмгыять эшләре белән кызыксынган, бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң бөтен Русия мөселманнарының сәяси хәрәкәтләрендә катнашкан. 1905—1917 еллар арасында «Ислахат әсаслары» («Реформа нигезләре») дигән баш астында бу хәрәкәтләрнең кыскача тарихын да язган. Шул ук чорда дини-фәлсәфи темаларга шактый әсәрләр язып бастырган. 1917 ел революциясендә исә, ни өчендер, Муса әфәнде икеләнеп кала. Большевиклар көне килгәч тә яңа режимга яраклашкан кебегрәк итенә дә пассивлаша. Башта бик кызыктыргыч вәгъдәләр биргән Советлар режимыннан мөселманнар иркен файдалана алачаклар дип саный иде булса кирәк галимебез. Моннан тыш, гражданнар сугышы көннәрендә кызыллар ягында кала, башка кайбер татар зыялыларыннан аермалы буларак, Русиядән дә китми. Эчке сугышлар тәмамланганнан соң, Совет хөкүмәтенең рөхсәте белән, бер-ике тапкыр чит илгә дә чыга ала, әмма «качып» китми, кире Советлар иленә кайта. Әйе, ул мәмләкәттә калырга тырыша иде. Хәтта Германиядә Советлар күңеленә хуш килмәячәк «Ислам милләтләренә» исемле хезмәте басылган вакытта да үзе Ленинградта яши иде. Остаз бу юлы, әлбәттә, инде ут белән уйный иде. Советлар аның бу уенын

үткәреп җибәрә алмыйлар, тоткын итеп Мәскәүгә китерәләр һәм төрмәгә ябалар. Ул аннан Финляндиядә яшәгән татарларның соравы һәм Төрия хөкүмәтенең арадашчылыгы аркасында гына котыла алды. Шуннан соң да 1926 елда остаз Мәккәгә — ислам конгрессына китә һәм янадан Русиягә әйләнеп кайта.

Белүемчә, Муса әфәндегә хаҗ фасылында Мәккәгә бару өчен алдагы елда да мөмкинлек бирелә. Бу юлы да ул, «хөрриятне сайламыйча», илгә кире кайта. Аннан соң Русиядә тагын өч ел яши. Ниһаять, Советларга үзен берничек тә яраттыра алмавын аңлап, өметен өзеп, 1930 елда бөтән бер дә кайтмаска дип, Советлар иленнән яшерен рәвештә чыгып китә.

Әмма Советларда яшәгән заманын остаз башка уздырмый: Русия мөселманнарының язмышы, киләчәге турында уйлана: аларның диннәрен һәм мәдәниятләрен коткарып калу юлларын эзли. Муса әфәнде фикеренчә, Русиядә яшәгән мөселманнар барысы да бер милләт. Ул болай ди: «Мөэмин-мөселман, кайда булса да, милләти исламия әгъзасыдыр. Әйаләт (өлкә), виләят аерымлыклары, җөмһүрият бүленешләре Русия мөселманнарын бүлмәс». Аның 1920 елда Уфада җыелган голәмә нәдвәсендә (галимнәр киңәшмәсендә) укыган, 68 маддәдән торган проекты да шушы инануына нигезләнгән иде, (бу проект та Берлинда басылган мәгълүм китабына кертелгән). Остазның бу проекты буенча: «Русия мөселманнары дини, әдәби (мәдәни дияргә теләгән булса кирәк) милли, иҗтимагый эшләрдә тулысынча мөхтар булып, Милләт Мәҗлесе, Милли Идарә, Виләят Мәҗлесе, Авыл идарәсе кебек милли оешмалар юлы белән, милли, дини һәм мәдәни эшләрне хәл итеп идарә итәчәкләр».

Муса Ярулланың бу проекты нигезе белән мәшһүр Садрый Максудиның «Милли-мәдәни мохтарият» проектыннан аерылмый. Ләкин шуның белән бергә, куллану өлкәсендә бу ике проект арасында аерма бар иде. Садрый Максуди «Милли-мәдәни мохтарият» режимын бары тик «Эчке Русия һәм Себер төркитатарлары» өчен планлаштырса, Муса әфәнде эшне тагын да киңрәк тота. Аның милли-мәдәни (һәм дә дини) мохтарият проекты бөтен Русия мөселманнарын үз эченә ала. Шунысы да бар: һәр ике проект җирсезлек бүлегендә туры киләләр иде.

Тар үлчәмдәге С. Максуди проекты 1917 елның җәендә, Икенче бөтен Русия мөселманнары съездында кабул һәм игълан ителә. Ул вакытта большевиклар әле властька килмәгәннәр иде. Бу елның ахырларына таба, власть башында торулары әле бик зәгыйфь хәлдә булганда, безнең «милли-мәдәни мохтарият» режимын танымыйлар, аның гамәлгә ашуына каршы төшәләр, оешмаларын тәртипсез хәлгә китерәләр. Шуннан өч ел вакыт үткәннән соң, яңа идарә шактый көчәйгәч, кызыл хөкүмәт Муса әфәнденең киң колачлы мохтарият режимының тормышка ашып яшәвенә рөхсәт итәме соң инде? Моңа ышану, йомшак итеп әйткәндә, беркатлылыктан башка берни түгел иде. Бу проектның да кәгазьдә генә калачагы ачык билгеле иде. Нәкъ шулай булды да. Бу проектны да эченә алган бер китапның Русиядән читтә басылуына хәтта автор үз тормышы белән түли язды.

Ахыры ни булды? Инде хәзер «милли мәдәниятне коткару» өчен тырышкан кешеләрне ахырда ни көткәнен күздән кичерик. Әле большевиклар властька килгәнче милли-мәдәни мохтарият режимын төзү эшенә керешкән Садрый Максуди, Уфадагы оешмасы таратылганнан соң, Совет власте белән аңлашырга тели. Ә соңыннан Русияне ташлап китәргә мәҗбүр була һәм озын-озак уйламыйча, Финляндиягә кача.

Муса Ярулла Биги хәзрәт, Совет хөкүмәте белән аңлашып, «социалист» императорлыкта яшәгән бөтен мөселманнар өчен гаять киң хокук-мөмкинлекләргә ия булган дини-милли мохтарият режимын төзергә тели. Мәрхүм остаз бу планның татлы хыялы белән һәм әле тегендә, әле монда шуны пропагандалау белән шөгыльләнеп, Русиядә тагын 10 ел яшәде, әмма һичбер уңай нәтиҗә ала алмады. Бөтен идеяләрнең чәлпәрәмә килүен күргәч, Советлар иленнән китеп котылды.

Галимҗан Ибраһимовка килсәк, коммунистлыкны хәтта үз итеп, Советлар белән бергә эшләп, аларның кайгыртучан күләгәсе астында мөстәкыйль «Татар мәдәнияте»н барлыкка китерү теләге белән яна башлый. Бу милли эчтәлекле, гарәп шрифтлы бер татар мәдәнияте булачак иде. «Җан-фәрман чапкан» бу «милли коммунист» язучы планлаштырган татар мәдәнияте турындагы хыялы, әдип әле үлем түшәгенә ятканчыга кадәр дә аяныч бер хәлдә җимерелеп төште.

Шулай итеп, Садрый Максуди омтылган «милли-мәдәни мохтарият» системасы да, Муса Ярулла Биги планлаштырган «милләти исламия мохтарият» режимы да, мөхәррир Галимҗан Ибраһимов хыялланган «татар мәдәнияте» рәвешендәге күренеш тә бүгенге көндә юк.

XIII гасырда (1236—1240) кыпчак, болгар төркиләре һәм урыс (көнчыгыш славян) өлкәләрен буйсындырган Чыңгыз туруны Батый хан гаскәрләрендә төрле ыругклардан бик күп төркиләр була. Әмма бу төркиләрнең ул вакытта Урта Идел өлкәсендә (Болгар төркиләре илендә) урнашып калуларын исбат итәрлек бер генә дәлил дә юк. Урыс елъязмаларыннан без моның киресен беләбез. Бу елъязмалардан күренгәнчә, «татар-монгол гаскәрләре» Болгар иле буйлап бер давыл кебек үтеп, Иделнең уң (көнбатыш) ягына аяк басалар һәм, яшен тизлеге белән хәрәкәт итеп, урысларның Рязань кенәзлегенә керәләр вә, ул замандагы төньяк урыс кенәзлекләренең зур өлешен үзләренә буйсындырганнан һәм хараж түләргә мәҗбүр иткәннән соң, көньяктагы далаларга чигенеп китәләр. Соңыннан Иделнең түбәнге агымында «Алтын Урда» дәүләтен төзиләр. Димәк, Батый хан гаскәрләрендә булган төркиләр белән монголларның ул заманда Русия илендә дә, Болгар илендә дә урнашып калмаулары аңлашыла. Көнчыгыш Европага XIII гасырда килгән төркиләрнең жирле төркиләр (болгарлар) белән кушылып-катнашулары Алтын Урда дәверендә һәм аннан соң акрынлап тормышка аша. Кайбер авторлар бу кушылуларның бигрәк тә XV гасырның икенче яртысында, Алтын Урдада булган тәртипсезлек аркасында Иделнең түбәнге агымында утрак тормышның һәм икътисадый хәрәкәтләрнең алга үсүе туктаган бер вакытта, Казан ханлыгы төзелгәннән соң, шәһәр халкының мөһим бер өлешенең төньякка күчеп китүе нәтиҗәсендә барлыкка килүен фараз итәләр.

XV гасырның башларына таба элеккеге Болгар илендә «болгар» сүзе бер төрки кавем исеме булудан туктаган була һәм шул ук вакытта бу өлкәдә элеккеге кабилә исемнәре дә акрынлап онытыла. Бу хосуста урыс авторы Н. Аристов болай ди: «һәрхәлдә, Урта Иделнең төрки халкы, күчмә тормыш өчен кирәкле шартларның булмавы сәбәпле, бары тик утрак тормышта яши башлаган иде һәм шуңа күрә Идел буе татарлары арасында кабилә гореф-гадәтләре вә исемнәре юк.

Татар нинди сүз һәм кемнең исеме? Борынгы заманнарда татарның бер төрки кабилә исеме булуын беләбез. Кытай язма чыганакларында «тата» шәкелендә теркәлгән исем. Шул ерак һәм караңгы үткәнне бер якка куеп, бераз бирегә таба килсәм, татар сүзе XIII гасырда куелган Орхон истәлекләрендәге язуларда да бар. Берничә урында «утыз татар» шәкелендә очрый. XI гасыр язма истәлеге булган мәшһүр «Диване лөгатет-төрек» тә гарәпчә «Татар жилүн мин әт — төрек» (Татар төркиләрнең бер тармагыдыр) диелгән. Дивандагы төрки кабиләләр исемлегендә татар да бар. Димәк, бүген татар исемен йөрткән бер төркем дә зур төрки берләшмәнең бер бүлеменнән башка берни дә була алмас. XIII гасырда Чыңгызның туруны Батый житәкчелегендәге төрки-монгол гаскәренең Көнчыгыш Европага һөҗүменнән алда, әле X гасырда ук мөселманлыкны кабул иткән болгар төркиләре Иделнең урта, Кама елгасының түбәнге агымы буйларында яшиләр. Тарихчыларның әйтүенә караганда, Батый хан гаскәрләренең башлыклары һәм житәкчеләре татар кабиләсеннән була. Диннәре буенча шаманга табынучылар (Мөселманнарга карата мәҗүси, потпәрәст дигән сүз). Жирле төркиләр исә бик нык берелгән мөселман булулары сәбәпле, аларны яратмыйлар, хәтта алардан жирәнәләр. Мәгълүм ки, ул заманнарда кешелек җәмгыятендә бу җәмгыятьләрнең мөнәсәбәтләрендә дини нигезнең роле зур була. Шуңа күрә Идел болгарларының һәм алар урынын алган казанлыларның «татар» исеменнән качулары йөз еллар буенча, дини нигезләр бераз йомшап, милләт тойгысы уяна башлаганчыга кадәр дәвам итә. Милли аңның уянуы исә бары тик XIX гасыр ахырларында гына үзен сиздерә. Алдынгы фәннәр турында ишетеп белгән, Көнбатыш дөньясының мәдәният юлындагы үсешен күргән казанлы зыялылар, «фикри уянган, көнкүреше үзгәрә башлаган бер җәмгыять бары тик «мөселман» исемен генә йөртүен дәвам итә алмас, инде аңа бер милли исем дә кирәк», дип уйлыйлар. «Салабәти диниясе» (дини инанычларының ныклыгы) һичбер мөселманнкыннан ким булмаган, иске Бохарада белем алган һәм Казан иленә яңа фикерләр китергән мулла Шиһабетдин Мәрҗани милли тарихны өйрәнергә керешә вә бу эзләнүләрнең нәтиҗәсен тарата һәм үз халкына шулай мөрәҗәгать итә: «Кайберәүләр татар булуны бер кимчелек санап, ул исеменнән чирканып, «без татар түгел, без — мөселман», дип тавыш-җәнҗал чыгаручылар да бар... И мескен! Әгәр синең «мөселман»нан бер исемеңне дин һәм милләтең дошманы белмәсә иде, сине, әлбәттә, «мөселман» дип дошман күрерләр иде. Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, урыс, француз һәм немец тә түгел — инде кем буласың?»

Мәржани милли тарихны өйрәнү белән шөгыльләнгәндә, шул ук дәвердә икенче бер фикер иясе Каюм Насыйри да тел вә этнография өлкәсендә бөтен күңелен биреп хезмәт итә һәм яңа бер саф язу теле барлыкка китерергә тырыша. Ул хәтта аңа «татарча» исемен бирүгә дә керелек күрсәтми. Димәк, бүген безнең Казан татарлары дигән халыкка бу ике Казанлы галим «татар» исеме бирүдә берләшәләр икән. Әмма бу ике фикер һәм гыйлем иясе «татар»ның килеп чыгышын өйрәнеп, тарих һәм этнографиянең караңгы һәм буталчык лабиринтына кермичә, бүгенге казанлы төркиләргә нигә «татар» дию кирәклеген исбат итү юлында җиң сызганып көрәш мәйданына ташланмыйлар. Татарның да төрки булуына инанганга, һичшиксез, ачыктан-ачык моның шулай кирәклеген күзәтеп белү белән чикләнәләр. Әмма бу ике галимнең күзәтүләре генә дә хәтта бу өлкәдәге икеләнүләрнең юкка чыга баруында зур роль уйнадылар.

Урыслар мондагы төркиләрне һаман «татар» дип атасалар да, бу исем ул төркиләрнең үз араларында тиз урнашмый һәм җәелми; хәтта халык үзен татар дип атауга каршы да тора. Бу хәл кайбер урыс авторларының да игътибарын җәлеп иткән. Шул исәптән, Рычков, мәсәлән, бу турыда шул сүзләрне язган: «Аурупада татар исеме белән танылган кавемнәр үзләрен гомумән «төрки» дип атыйлар. Алар, тел хакында сораганда: «Татарча беләсеңме?» — дип түгел, «Төркичә беләсеңме?» — дип сорыйлар. Безнең (урыслар күз алдында тотыла) «татар китабы» тәгъбире урынына алар «төрки китап» тәгъбирен кулланалар. «Татар» сүзе, алар фикеренчә, түбән бер мәгънә белдерә; канун танымый торган, кешелексез һәм дошман бер кавемнәр хакында кулланыла. Шулай ук борынгы грекларда «варвар» сүзе дә бу мәгънәдә кулланылган».

Казан университеты профессоры, асылы белән сагай төркие (хакас) Н. Катанов: «Көнчыгыш Төркестан төркиләрен татар дип атау дөрес булмаса кирәк. Ялгыш аңлашылмасын өчен, шуңа дәлил булмаса, бу ялгыш тәгъбирне үзүзләренә татар димәгән һәм күрше илләр тарафыннан да алай аталмаган кавемнәр өчен җәелдерү турында сүз дә була алмый, киресенчә, бу исемнең акрынлап, юкка чыгарылуы яхшырак булыр», ди. Тарихчы Зәки Вәлиди Туган фикеренчә, «Татар исеме Орхон язмалары буенча да мәгълүм булса да, бу исем күк төркиләр (алтай төркиләре) һәм уйгырлар дәвереннән соң Монголиядә яшәгән монгол һәм төрки кавемнәренең, мөгаен, бер катнашмасына карыйдыр. Енисейда татарлар монголча сөйләшкәннәр, фәкать Бөек Кытай стенасына якын яшәгән «чаган татарлар» (онгутлар) гына төркичә сөйләшкән. Шулай ук саф төрки булган Иртеш кимакларының бер кабиләсе дә татар дип аталган. Димәк, татар исеме генә Чыңгызга кадәрле Монголиядә яшәгән бер кабиләнең кауми (этник) үзенчәлеген өйрәнү өчен җитәрлек түгел».

Идел буе төркиләре этник яктан татармы соң? Тагын да шул ук Зәки Вәлиди Туган әйтә: «... Шулай ук татар исеме элгәрәк монголлар хакимияте заманында аларга кушылган кавемнәргә дә бирелгәнгә, Казан татары, Кырым татары, Нугай татары, Алтай татары, Әзәрбайҗан татары кебек исемнәр хасил була. Бу исемнәр этник мөнәсәбәткә дәлил түгелләр. Мәсәлән, борынгы болгарларның һәм кыпчакларның катышуыннан хасил булган (бүгенге) Казан төркиләре белән татарлар арасында һичбер этник бәйләнеш юк. Әзәрбайҗан төркиләре өчен дә бу шулай».

Урыс авторы Аристов Идел буе төркиләренең этник яктан куе бер конгломерат булуын күрсәтә.

Шулай итеп, бу кавемнең составына кергән этник төркемнәр кайсылары соң? Болар, димәк, Идел болгарларының ислам динен кабул иткән өлеше белән кыпчак (команн) төркиләренең бер бүлегеннән, Урта Азиядән Көнчыгыш Европага XIII гасырда килгән бер төркем төркиләрдән һәм жирле угыр-финнәрнең төркиләшкән бер катламыннан гыйбарәт.

Идел буе төркиләренең үз-үзләрен татар дип атауга каршы торулары турында югарыда сүз булды. Алар (ягъни X гасырда ислам динен кабул иткән болгарлар һәм араларында бу диннең киң күләмдә җәелгәнлеге аңлашылган кыпчак-команнар) татарларга нинди бер курку белән һәм дошманнарча караганнар булса кирәк. Соңгы елларга кадәр Идел буе төркиләре арасында «татар барда хәтәр бар», «татар түрә булса, чабатасын түргә элә» кебек, татарларга каршы нәфрәт һәм куралмау тойгысы белдергән әйтемнәр яши. Баскынчыларның кодрәтле дәверендә һәм аннан соң да җирлеләр арасында һәм кайбер тарихчылар телендә «татар» сүзе этник мәгънәсен бөтенләй югалтып, заманыбыздагы «фашист», «нацист», «большевик» сүзләре кебек, сәяси-гаскәри мәгънәне белдергән, ахрысы. Гарәп һәм фарсы тарихчылары да, төркиләрне кауми исемнәре белән атап йөрткән хәлдә, «татар» сүзен баскынчы һәм тиран монголларга карата

кулланганнар. Шул рәвешле, билгеле бер дәвердә татар исеменең зур бер мәгънә белдерүе һәм шактый төрки төркемнәргә дә тагылганлыгы аңлашыла.

«Татар» исемен Идел буе төркиләре өчен беренче мәртәбә житди рәвештә әдәбиятка керткән кешеләр казанлы мәшһүр тарихчы һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗани белән язучы һәм тәрҗемәче Каюм Насыйри иде. Алардан соң, XIX гасыр азакларында һәм XX гасырның башларында каләмгә тотынган казанлы мөхәррир һәм язучыларның бөтенесе диярлек Казан төркиләре өчен татар исемен кулланалар. Хәтта бу ике фикер иясеннән соң килгән буын тарихчысы казанлы Газиз Гобәйдулла, казанлыларны татар дип атау буенча башка халыклардан мисал китереп болай ди: «Баскынчы татарлар төркиләшәләр дә (*гомумән дә төрки иделәр* — Г. Б. Т.). Урта Идел, Түбән Кама үзәннәрендә яшәгән халыкларга да татар исеме тагыла. Моңа мисаллар күп: асылы белән славян булган, Туна ярларында яшәгән бер кавем болгар төркиләренең хакимияте аркасында болгар исемен, көнчыгыш славяннар диелгән һәм бүген урыс дип аталган кавем Скандинавиядәге тевтон (германлы) ыруыннан булган рус кабиләсенә караган өч кардәшнең идарәсе астында калганнан соң «рус» исемен, франкларның хакимияте аркасында гальләр француз исемен үзләштермәделәрме?»

Милли тарих бу илнең ике исемен белә: Болгар һәм Казан. Болгар исеме Идел буенда якынча V гасырдан XIV гасырга кадәр дәвам иткән һәм аннан соң бөтенләй онытылган. Аның урынын Казан исеме алган. Урыс басып алулары вакытында бу өлкә Казан ханлыгы исемен йөрткәнгә, безнең иң кыйммәтле тарихи истәлекләребез Казан исеменә бәйле. Казанның тарихи һәм милли әһәмияте зур. Чынлап та Казан, кечкенә бер елга исеме һәм тарихи бер баш шәһәрнең исеме генә булмыйча, шул ук вакытта киң бер өлкәнең дә исеме иде. Димәк, Казан исеменең тарихи кыйммәте булгач һәм ул өлкәнең исеме дә Казан булгач, Идел буе төркиләренең иң дөрес исеме «Казан төрекләре, казанлылар» булачагына шөбһә калырмы? [...]

Казан татарлары арасында ике төрле тип күзгә ташлана. Кайберләре озынча йөзле, туры, төз борынлы, күз уентыклары төгәл уелган бер тип. Икенчеләре чыгынкырак яңаклы, бераз җәенкерәк борынлы һәм кысыграк күзле. Башка халык этнологлары да моны шул рәвешле билгелиләр. Мәгълүм классификация буенча Казан татарлары да төрки халыкларның үзәк төркеменә карый. В. Радловның төрки телләрне фонетик яктан төркемләгән классификациясе буенча, аларның теле урта төрки телләр төркеменә керә. Казан төбәгендә шулай ук бүген дә бер төркем шивә сөйләшләре бар, болар әлегә тиешенчә тикшерелмәгәннәр.

Язмышның авыр сынауларын кичеп чарланган Казан татарларының рухлары нык, алар эшсөяр халык. Аларның иң төп үзенчәлекләре — намуслылык, тугрылык, аеклык, кыюлык һәм арулык — чисталыктыр. Аларның аеклыгын, өйләренең ару һәм төзек булуын чит халыкларның сәяхәтчеләре һәм этнографлары да теркәп калдырганнар. Алар үз ватаннарына тугрылык, мәхәббәт һәм гаилә учакларына бәйле булу белән танылганнар.

Казан татарларының күбесе — авылларда игенчелек белән, шәһәрләрдә исә сәүдәгәрлек белән шөгыльләнәләр иде. 1917 ел революциясе алдыннан алар арасында зур сәүдәгәрләр шактый иде, фабрика хуҗалары да бар иде. Сембердә Акчура, Саратау өлкәсендә Диберди угылларының постау фабрикалары, Казанда исә Үтәмеш, Әҗем, Арыслан һәм Әлмәт угылларының нәселе бәз, сабын һәм пыяла фабрикалары белән мәшһүр иде. Вак һөнәрчелеккә килгәндә, Шәрекътә киелә торган читек һәм кәвеш эшләү, казан татарларының ир-аты һәр җирдә кия торган түбәтәй, хатын-кызлары кия торган калфак исемле баш киемнәрен тегү һәм эшләү шулай ук алар арасында бик таралган бер һөнәр иде. Зәргәрлек тә казанлылар арасында борынгы һәм бик мәгълүм бер һөнәр. Шунысы да игътибарга лаек: бүген Искешәһәрдә яшәгән казанлы мөһаҗирләренең дә бер өлеше зәргәрлек (алтын-көмеш кою) белән шөгыльләнәләр.

Казанлы төрки хатын-кызларының мөлаем йөзле икәнлеген, урыс хатыннары белән чагыштырганда хәл-торышлары күпкә яхшырак булуын, һәм башка мөселман хатын-кызлар белән чагыштырганда, күпкә һөр һәм шәхсиятле булуын чит халыкларның өйрәнүчеләре теркәп калдырганнар. Чынлап та, кайбер мөселман илләрендәге хатын-кызлар төшкән жария хәленә Казан татарларының хатын-кызы һичбер вакыт төшмәгән.

Китап күзәтү

# ӘДӘБИЯТ — ӘХЛАК ТОТКАСЫ

Кеше шәхесен формалаштыруда матур әдәбиятның роле гаять зур. Ул, аң һәм хисләргә берьюлы тәэсир итеп, әхлак нормаларын һәм эстетик карашларны тәрбияли. Нәкъ әнә шул факторлар кешене кеше итә дә инде.

Кайберәүләр, бүгенге яшьләр китап укырга яратмый, диләр. Әйе, андыйлар да бардыр һәм моңа без — өлкәннәр үзебез гаепле. Аяныч хәл бу. Бервакыт атаклы украин педагогы В. Сухомлинский, балалар колониясендә булганда, яшүсмерләр белән сөйләшкән һәм берсенең дә бер генә китап та кулына алмаганлыгын белгән. Алар хәтта бер генә язучының да исемен атый алмаганнар...

Балада китапка мәхәббәт кечкенәдән, гаилә шартларында ук тәрбияләнергә тиеш. Мин шуны хәтерлим: без беренче класста 45 әү идек. Әмма шуның 37 се генә алдагы класска күчте. Сәбәбе: алар — 8 бала — уку кебек җитди хезмәткә әзерләнмәгәннәр, гаиләдә китап-фәлән күрмәгәннәр иде... Укытучыбыз безне гыйнвар уртасында мәктәп китапханәсенә яздырды, китап укуыбызны күзәтеп барды. Әлеге 8 укучы гына китапханәгә йөрмәде, чөнки алар рәтләп укырга да өйрәнмәгән иде шул әле...

Бүген яшь буында китап сүзенә ихтирам тәрбияләү — мәктәп китапханәләренең төп бурычы. Ә ул китапханәләр фондын баетуда исә «Мәгариф китапханәсе» сериясендә чыккан китаплар зур урын тота. Түбәндә шуларның берсе — «Көмеш беләзек» (Казан. «Мәгариф», 1995) җыентыгына кергән хикәяләр турында сүз барачак. Китапка чагыштырмача яшьрәк буыннан 19 авторның әсәре тупланган.

Флүс Латыйфиның «Көмеш беләзек» хикәясендәге баш герой Җиһан апа җиде бала үстергән. Фронттан күп яралар алып кайткан ире исә озак яши алмаган. Үсеп җиткәч, балалары «бәхетле илнең» төрле почмакларына бәхет эзләп киткәннәр. Хәзер аның янында инкубатордан чыккан тавыклардан (хәер, тагын бер йорт тавыгы — чуар тавык та була әле) башка беркем дә юк. Чуар тавык йомыркаларны алай ук күп салмый. Әмма аның һәр салганы — йортта, ә инкубаторныкылар — бөтенләй читтә... Карчык чуар тавыкны «элекке дөньяның истәлеге» итеп саклый. Монда авторның ишарәсе сизелә: ничек кенә булса да, үз иленне ташлама...

Җиһан карчык әле аяк өстендә, әмма картлык басуын бик тоя, исән чакта балаларымны тагын бер кат күреп калыр идем дип хыяллана. Күрше Хәят аркылы: «Сабан туйга кайтыгыз» дип телеграмма суктыртырга уйлый. Әмма Хәят: «Әниегез авыр хәлдә, тиз генә кайтып җитегез»,— дигән сүзләр яза. Чөнки Сабан туена гына берсенең дә кайтмаячагын белә. Ул арада Җиһан апа сандыгындагы әйберләрен барлый, бианасы бүләк иткән көмеш беләзекне таба, аны сатарга ярамаганлыгын искә төшерә. Бианасы: «Бу беләзек өч буыннан килгән һәм өч хикмәткә ия: өч теләкне үти»,— дигән аңа.

Күп тә үтми, карчыкның балалары Ташкенттан, Бохарадан, Сверлаудан, Ижаудан, Төмәннән, Сахалиннан кайтып төшәләр. Нинди җилләр очырткан соң аларны бөтен ил буйлап? Минемчә, тормыш авырлыгы гына түгел. Төп сәбәпләрнең берсе — милли үзаңның зәгыйфь булуы. Мәсәлән, Камчаткада ун меңләп татар яши. Нәрсә югалтканнар алар анда? Иң аянычы шул: балалары телне, халык гореф-гадәтләрен оныта, белми һәм башкалар эченә кереп эри, ассимиляцияләшә. Әнә шулай итеп, халык бетә. Бары тик үзең турында гына уйлау, «озын акча артыннан чабу» милләтне юкка чыгаручы эгоизм чире түгел мени?

Ярый әле Хәят җаен тапкан, югыйсә балалары аналарын күрә дә алмаслар иде. Карчыкның соңгы сүзләре шул була: «Мин китәм... Соңгы үтенечем... беләзекне саклагыз... нәселебезнең яшәү көче... иң өметсез чакта...».

Хикәя шактый монсу нотада бетә: чуар тавыкны тотып суялар. Беләзеккә әһәмият бирүче дә булмый. Дәүләтнең улы Нурдәүләт кенә беләзектән медальон ясап, муенга тагып йөриячәген әйтә. Әгәр бу әсәр соңындагы монсулык татар балаларының милли үзаңын үстерүгә күпмедер өлеш кертә алса, автор да, без дә бәхетле булыр идек... Өстәп шуны гына әйтик, Флүс Латыйфиның әдәби теле саф һәм күркәм.

Солтан Шәмсинең «Каты чикләвек» хикәясе дә дулкынландыра, яшьлек елларын искә төшерә. Югыйсә сюжет нәкышы да, эчтәлеге дә әлләни катлаулы түгел. Әмма эш башкада: яшьлек, беренче мәхәббәт һәркемнең диярлек юлдашы ич... 17 яшьлек Рәмзиягә студент Фаязның күзе төшә. Тик Рәмзия генә моңа салкын карый. Урта мәктәптән соң вузга керә. Егеткә мөнәсәбәте һаман үзгәрми. Табигый ки, моңа студентның кәефе китә, кызның йөрәге таштыр, дип уйлый. Шулай да Фаяз, җаен туры китереп, Рәмзияне үзе белән «Ял» кафесына барырга күндерә. Анда кызларның үзләрен «йөгәнсез тотулары» Рәмзиягә бер дә ошамый. Өстәвенә, котмәгәндә Фаяз кызны үбә башлый. Моңа җавап итеп, Рәмзия кичәне ташлап китә, чөнки колагында әнисенең: «Кызым, сереңне бирәүгә дә чишмә, бигрәк тә ир-аттан саклан»,— дигән сүзләре яңгырап тора. ...Рәмзия карт кыз булып кала. Финал бик үкенечле. Әлбәттә, кызлар горурлыгы, саф тән һәм күңел — әйбәт нәрсә, әмма үзара мөнәсәбәтләрдә дә чама белергә кирәк икәнлеге көн кебек ачык...

Марсель Галиев «Сина мин кирәк» дигән хикәясендә тормышның реаль вакыйгалар аркылы сурәтли, «аталар белән балалар» проблемасын үзенчә яктырта. Хәлләр болай башланып китә: бервакыт Марат Уразовка кызы Сөембикәдән: «Миңа 17 яшь, мине каршы ал»,— дигән телеграмма килеп төшә. Әмма әтисе кызын каршы алмый, яңгыр яуды дип, сылтау таба. Бу очракта, әлбәттә, ата хаклы түгел — яңгыр түгел, таш яуса да, ул кызын каршыларга тиеш иде. Әйе, кем әйтмешли, чит илләрдә йөрсәң, үз ярың да ят була икән шул. Бу инде әхлакка, җаваплылык хисенә, кешелеклелеккә бәйләнгән. Бүген ата-аналар, тормышларын куркыныч астына куеп, улларын эзләп, Чечняга баралар, ил буйлап сибелгән госпитальләрне айкап чыгалар. Үз чиратында, атадан кечкенә булып калганнар, үсеп җиткәч, әтиләренең каберен зыярат итү өчен, Европа илләренә барып җитәләр... Ә монда исә ата үз кызының гади генә үтенечен дә үтәми. Биредә атаның шактый эгоист, үзен генә яратучы икәнлеген әйтергә була. Тик бер сорау туа: кешене эгоизмга нәрсәләр, нинди шартлар китерә икән соң?

Сөембикәгә биш яшь ярым чакта, Марат Уразов хатыны белән аерылыша. Уйласаң, моның өчен төпле җирлек-сәбәп тә булмый. Ир дә хатын да — эгоистлар, бала турында уйлап та карамыйлар. Берсе атаклы рәссам, икенчесе — күренекле галим булу турында хыяллана, ә гаилә тормышы теләкләрне үтәүдә комачаулык итәчәк икән. Кыз аларга кирәкми, ул болай да дүрт яшеннән алып бабасында тәрбияләнә. Ләкин, ата-анасы исән чакта, бала алар тәрбиясендә үсәргә тиеш ич. Башка якларын исәпкә алмаганда да, баланың ата-анадан башка яшәве үзара якынлык хисләрен сүндерә. Ә Уразовларда андый хисләр, гомумән, булмаган, ахрысы. Кыз әтисенә: «Мин сине гафу итә алмыйм, әнине дә... вакытында аңлашмаганыгыз өчен»,— ди. Әмма әсәр оптимистик рухта тәмамлана. Монда ясалмалылык юк, чөнки өлкәннәр нинди генә булмасын, бала күңеле ата-анага омтыла.

Альберт Сафинның «Юлда» хикәясе дә тормышчан, ышандырырлык вакыйгаларга нигезләнеп иҗат ителгән. Шуңа күрә аның тәрбияви мөмкинлеге шактый зур. Алсу дигән кыз поездлан Сарылан станциясенә төшәргә тиеш. Ул тышта буран котырганны да шәйләми, нәрсәдер уйланып бара. Әмма күршедә генә утырган агай аның кәефен боза. Дөресен генә әйткәндә, моның өчен сәбәп тә юк. Агайның сорашуы кызны тезгеннән ычкындыра: «И вообще, отстаньте от меня, ради бога»,— дип җибәрә. Әмма юлчы мондый дорфалыкка дорфалык белән җавап бирми, башкалар белән сөйләшә. Ул — сүзчән кеше, табигате шундый.

Менә поезд Сарыланга туктый. Кечкенә будкадан башка берни дә юк, аның да ишеген көрт баскан. Ә авыл ерак, туңып үлү ихтималы зур. Ләкин кызны агай коткара. Үзе башка авылга кайтырга тиеш булса да, кызганып, кызны авылына илтеп куя. Шуннан соң кызның авыл кешеләре турында фикере тамырдан үзгәрә.

Язучы табигать күренешләрен, ачы буранда бу икәүнең никадәр көч куеп атлауларын шулкадәр оста итеп сурәтләгән ки, һәммәсе дә кинодагы кебек күз алдына килә. Ләкин хикәянең кыйммәте анда гына түгел, ә бәлки әхлак мәсьәләләрен калку итеп куя алуында, яшьләрдә әхлакый-этик омтылыш тудыруда...

Тормыш гаҗәеп катлаулы, ул шаблоннарга, стереотипларга буйсынмый; һәрнәрсәнең үз мантыйгы бар. Зиннур Хөсниярнең «Кичү» хикәясен укып чыккач,

күңелгә шундыйрак уйлар килә. (Җәя эчендә генә әйтик: әлеге хикәя В. Распутинның «Матера» дигән әсәре белән шактый аваздаш...).

Зур Су бик күп авылларны баса. Дулкын зираттагы сөякләрне, кеше башларын яр буена чыгарып ыргыта... Хикәянең төп мәгънәсе, лейтмотивы: «власть башында «временщиклар» утырганда гади халыкка көн булмаячак, чөнки ул җитәкчеләргә йөз меңнәрчә гектар уңдырышлы җирләр дә, зират кебек «вактөякләр дә» кызганыч түгел.

Бу хикәядә бераз натурализм элементлары да бар, «турыдан ярулар» да күренә (Хуҗаны сурәтләү моментлары һ. б.). Әмма шома тел белән язылган бу әсәр укучының игътибарын җәлеп итәчәк.

Нияз Акмалның «Бер кашык дегет» хикәясе миңа — урта мәктәптә һәм вузда укыткан педагог-психологка ошады, күңел кылларымны тибрәтте. Биредә сүз ата-анасы ташлап киткән малай турында бара. Аның исеме Наять. Ул ятимлек шулпасын эчә. Наять табигате белән кызыксынучан малай. Әдәбият дәресләрендә дә Наять «стандарт булмаган» сораулар бирә. Мәсәлән, ул Павка Корчагинның поп камырына тәмәке сибүен дөрес түгел дип бәяли. Бу хәл укытучыны гаҗәпләндерә дә, уйланырга да мәҗбүр итә. Китапханәче аркылы ул Наятьнең бик күп китаплар укуын белә. Кыскасы, укытучы Наятьнең җанын аңлый һәм аңа карашын үзгәртә. Ә зиһенле ятим бала өчен бу инде бик мөһим...

Рашат Низамиевның иҗатын мин соңгы елларда кызыксынып, хәтта куанып күзәтәм. Моның төп сәбәбе: әдипнең кеше шәхесе формалашу процессына әһәмият бирүе. Белгәнебезчә, һәр бала сәләт алшартлары белән туа. Шуларны сәләткә әйләндерү өчен, аңа ярдәм итәргә кирәк. Бу исә конкрет мохиткә, аерым шәхесләргә бәйләнгән. «Яһүдләр — талантлы халык» дигәнне күпләр ишеткәндер. Әмма бит сәләтсез халык, гомумән, булмый. Эш башкада: әлеге алшартларны ничек сәләткә әверелдерергә? Бу яктан яһүдләрне, чыннан да, мактарга кирәк. Алар бервакытта да үз акылларын хәмер белән агуламыйлар. Бала тәрбияләүгә бик зур әһәмият бирәләр. Сер тик шунда гына! Ә бездә ничек? 11—12 яшьлек малайлар тәмәке көйрәтәләр, хәтта «яшел елан» белән дуслашудан да тартынмыйлар, сүгенәләр. Икенче төрле әйткәндә, өйдә күргәннәрне тулысы белән кабатлыйлар.

Табигать тарафыннан кешегә бирелгән иң зур бүләкләрнең берсе — кызыксыну. Шунсыз фән дә, башка өлкәләр дә үсми. Кем әйтмешли, Ньютонның маңгаена алма өзелеп төшмәгән булса, ул Җирнең тарту көче турындагы законны ачмаган булыр иде. Ул моңа күзәтү аркылы ирешкән. Рашат Низамиевның «Көнбагыш» хикәясе дә шул темага язылган. Автор: «Алар көтмәгәндә, уйламаганда дуслаштылар»,— ди. Сүз Кәрим исемле малай һәм көнбагыш турында бара. Ялгыз көнбагыш бәрәңге белән ярышып үсә. Малай һәммәсен дә күзәтә: әнә көнбагыш яфрак җибәрә, әнә ул чәчәк ата. Көнбагыш белән сөйләшкәндә малай: «Син кояшка ошагансың»,— дип хисләнә. «Кәрим сизенә килде: кояш белән көнбагыш арасында ниндидер уртак, яшерен бәйләнеш бар. Чыннан да, шулай икән — бакчадагы дусты кояш әйләнеше уңаена көнозын талгын гына борыла икән ләбаса». Моны кем аңлатыр икән: ни өчен башкалар түгел, нәкъ көнбагышлар кояш артыннан «йөриләр?» Бәлки, киләчәктә бу сорауга Кәрим җавап бирер, бөек ачышны ул ясар...

Дөньяда юньсезләр, матурлыкны аңламаучылар да бар. Шуларның берсе «көнбагыш башын рәхимсез төстә умырып, аны төптән үк өзеп, каерып алган». Бу хәл малайның күңелен бик нык рәнҗетә. «Кем өзде сине?» — дип өзгәләнә ул. Биредә шуны әйтергә була: хикәя күңелне дулкынландыра гына түгел, сафландыра да.

«Кече туганнарыбыз» дигән термин-төшенчә күптән кулланылса да, һәркем аңа үзенчә мәгънә бирә. Кече туганнарыбыз безне ашата, киендерә һәм күңелебезне хушландыра, тынычландыра. Чыпчыкларсыз, песнәкләрсез, хәтта сасксансыз, каргасыз дөньяда яшәүнең яме ким булыр иде. Чыпчыкны гына алыйк — аларга карап, тынычланабыз, тормышның тымызык кына агуын тоябыз. Өстәвенә, алар бик файдалы да. Бервакыт Мао Цзе-дун дигән тиран күрсәтмәсе белән, Кытайда бер көн эчендә бөтен чыпчыкларны кырып бетерәләр. Имеш, чыпчыклар бөртекне күп чүплиләр. Ярый, шулай да булсын, ди. Әмма бер елдан Кытай чит илләрдән бик күп чыпчык сатып алырга мәҗбүр булды. Шул ачыкланды: чыпчык йөз грамм бөртек ашый икән, бер килограмм ашлыкны янда калдыра, чөнки бик күп бөҗәкләрне юк итә. Без сандугач, карлыгачларны күбрәк матур тавышлары өчен яратабыз. Әмма алар да бихисап корткыч бөҗәкләрне ашыйлар, шулар белән балаларын туйдыралар. Мондый мисалларны бик күп китерергә булыр иде.

Кеше кулга иялəштергəн һəм үзенə дус иткəн иң борынгы җан иясе — эт. Без этлəргə шулкадəр күнеккəнбез ки, аларсыз дөнья көтеп булмас кебек тоела. Этлəр кебек хуҗасына бирелгəн зат дөньяда юктыр. Бервакыт, матбугатта менə нəрсə язылган иде: хуҗасы үлгəч, эт табут артыннан баручы кешелəргə ияргəн... Хуҗаны ничек җиргə төшереп, күмүлəрен карап торган. Халык моңа əһəмият тə бирмəгəн. Тиздəн барысы да кайтып киткəннəр, этнең зиратта торып калуын сизүче дə булмаган. Икенче көнне хуҗа хатын этен эзлəп чыккан һəм аның ире кабере янында улап-елап утыруын күреп гаҗəплəнгəн. Эт хуҗа хатынның «əйдə кайтыйк» дигəн сүзен тыңламаган һəм зиратта торып калган.

Бер немец галиме «этлəрдə кеше акылы бар, алар ярымкешелəр», дигəн. Мөгаен, шулайдыр. Нəбирə Гыйматдинованың «Соңгы очрашу» хикəясе дə шуны раслый кебек. Авторның бу хикəясе əхлак проблемаларын яктыртуга үзеннəн лаеклы өлеш кертə.

Рəфис Гыйззəтуллинның «Сиртмəле кое» хикəясе исə совет тоталитар системасының никадəр кансызлык күрсəтүе хакында. Ул заманны яшьлəр яхшы белергə һəм аның башка бервакытта да кире кайтмаслыгы өчен чаралар күрергə тиешлəр.

Əйе, бу җыентыкка кергəн əсəрлəр һəркайсы үзенчə сабак бирə, яшь укучы күңелен тəрбияли. Уйлый китсəң: əле күптəн түгел генə оешып зур һəм изге эш башлап җибəргəн «Мəгариф» нəшрияты менə шушындый тирəн эчтəлекле китапларны инде шактый күп бастырып чыгарды бит. Аларның һəммəсе яшь укучының рухи дөньясында үз урынын тапты. Рəхмəт бу коллективка!

**Мəхмүт ƏХМƏТҖАНОВ.**

# Вакыйф Нуруллинга 60 яшь



Һәр каләм иясен чын-чынлап язучы, әдип иткән, халыкка танытkан, аңа үз укучыларын табарга булышкан аеруча уңышлы әсәрләре була. Без Вакыйф Нуруллин, дидекме, шундук «Шинельсез солдатлар» повесте хәтергә килеп төшә. Ул үз иҗатын алтмышынчы еллар башында хикәяләр язудан башласа да, тәүге тапкыр әдәби тәнкыйть теленә дә, укучы күңеленә дә әнә шушы повесте белән килеп керде. Вакыйф Нуруллин «Шинельсез солдатлар»ында яшүсмер малайның табигый, самими кичерешләре, гыйбрәтле язмышы аша сугыш чоры авылының фаҗигале вакыйгаларын сурәтләде, үзе яхшы белгән тормыш чынлыгын сәнгать югарылыгына күтәреп тасвирлый алды. Язучының бу алымы соңыннан иҗат ителгән «Күпер чыкканда», «Аккан су юлын табар», «Әгәр син булмасаң», «Һәлакәт», «Ике урам арасы», «Җавап бир, кеше!», «Сагынырсыз әле» һ. б. әсәрләрендә дә камилләшү рәвешендә дәвам иттерелде. Әдип әлеге әсәрләрендә бүгенге авылның катлаулы хәл-әхвәлләрен бәян итте, колхоз җитәкчеләренең истә калырлык образларын тудырды, шәһәр зыялылары арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне чагылдырды. Гражданнар сугышы чоры герое Нурулла Айсинның көрәш юлын тасвирлаган «Яшьнәп үткән яшьлек» әсәрендә дә без документаль материалларга таянып иҗат ителгән геройлар белән очрашабыз.

Әдәби тәнкыйть билгеләп үткәнчә, Вакыйф Нуруллинның документаль нигезле әдәби әсәр язганда тарихи материалларга таянуы аңа, бер яктан, ярдәм итсә, икенче яктан, автор алдына өстәмә таләпләр дә куя. Әлеге очракта «материал каршылыгын» җиңеп, югары сәнгатьлелеккә ирешү кыенлаша, хыялны тезгенләбрәк, тормыш чынлыгыннан артык ерак китмичә язарга туры килә. Вакыйф Нуруллин әнә шушы кыенлыкларны җиңеп, чама хисен югалтмаган хәлдә, чын мәгънәсендә әдәби әсәрләр иҗат итүгә ирешә, публицистика белән җан җылымлы лиризмны, документаль төгәллек белән сәнгатьчә гомумиләштерүне оста итеп үреп бирә алды.

Вакыйф Нуруллинның әдәбият мәйданына чыгу еллары — һәркайсыбызның күз алдында.

Ул 1935 елның 1 маенда Татарстанның Балык Бистәсе районы Югары Әшнәк авылында туган. Яшүсмер еллары сугыш гарасатына туры килгәнлектән, бик иртә тормыш арбасына җигелә.

1957 елда солдат хезмәтен үтәп кайтканнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1961 елны «Совет әдәбияты» (хәзерге — «Казан утлары») журналы редакциясенә хезмәткә килә. Биредә ул башта хатлар бүлегендә әдәби хезмәткәр, аннары проза бүлеге мөдире булып 1977 елның июненә кадәр эшли. Шуннан ары Вакыйф Нуруллин 1989 елгача — Татарстан китап нәшриятының баш редакторы.

Вакыйф Нуруллин әле дә җәмгыятебез, милләтебез өчен актив эштә вә иҗатта ялкынланып яши. Ул РСФСРның һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемне йөртә.

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә кушылып, без — «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы — хезмәттәшебез һәм каләмдәшебезне түгәрәк туган көне белән ихлас котлыйбыз, аңа исәнлек-саулык, яңа иҗади сөенечләр телибез.**

## Нур Баян

(1905—1945)

Татар халкының шагыйрь йөрәкле, каһарман улы Нур Баянның 1943 елны ут эчендә язган «Сандугачка» дигән шигыре бар:

...Кызык кош син, сандугачым-дустым,
Туп ярыла, ә син — сайрыйсың.
Тормыш итәр өчен Туган илдә,
Оян өчен куак сайлыйсың...

Бер уйлаганда, әлеге юллар шагыйрьнең үзенә үк багышланган кебек. Чөнки ул, нинди генә кыен шартларда да, сайравыннан — иҗат итүеннән һич туктамаган, гомеренең соңгы минутларына хәтле әнә шул җырчы сандугач халәтендә булган...

...Биографиясе дә гаҗәеп кызыклы, үзенчәлекле аның. Нур Баян (Нур Галим улы Баянов) 1905 елның 15 маенда Татарстанның хәзерге Актаныш районындагы Әнәк авылында ярлы игенче гаиләсендә туа. Тормышлары авыр булганлыктан, булачак әдип, һәр елны җәйге айларда, төрле җирләрдә эшкә ялланып, бераз акча юнәтеп кайта.

1921 елгы ачлык исә аны туган авылыннан бөтенләй китәргә мәҗбүр итә. Нур Баян, Пермь шәһәренә барып, кара эшче булып эшли, аннары 1923 елда, укуын дәвам итү теләге белән, Казанга килә һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбенә курсант итеп алына. Шушында укыганда аның әдәби иҗатка зур омтылышы уяна. Үзенең беренче шигырьләрендә егет туган авылы турында яза, гражданнар сугышы һәм илне саклау темаларын яктырта.

1925 елдан башлап Нур Баянның исеме матбугат битләрендә ешрак күренә башлый. 1928 елда ул «Кызылармеец» дигән хәрби газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып урнаша һәм шул ук елны, бер-бер артлы, «Уракчы кызлар», «Җимерелгән окоплар» дип исемләнгән ике шигъри җыентыгын бастырып чыгарырга өлгерә...

1929—1930 елларда Н. Баян «Колхоз яшьләре» журналы сәркатибе булып эшли, аннары Чаллы район газетасына мөхәррир итеп билгеләнә. Шул чорда ул, үзенең язылачак әсәрләре өчен, авылдагы үзгәрешләргә, күмәкләшү хәрәкәтенә караган бай фактик материал туплый. Соңыннан, шуларга таянып, «Клеверлы кырлар» (1929), «Яңгырлы төн» (1933) кебек поэмаларын, күп санлы шигырьләрен иҗат итә...

1932 елда Н. Баян янадан Казанга әйләнеп кайта һәм 1932—38 елларда Татарстан Язучылар союзын оештыру комитетында инструктор, Таттосиздатта мөхәррир, аннары матур әдәбият бүлегенең өлкән мөхәррире булып эшли. 1938 елдан, Бөек Ватан сугышы башланганчыга кадәр, профессиональ язучы буларак, тулысынча иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Бу елларда Н. Баян зур күләмле «Гөләндәм» (1939), «Җимерелгән дворец янында» (1940), Г. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш»ына иярел, «Карахмәт» (1940) поэмаларын яза, «Язгы төн», «Туган авыл», «Шат җырлар» исемле шигъри җыентыкларын бастырып чыгара. Әдәби уңышлары өчен ул 1940 елда «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә...

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк, Н. Баян фронтка китә. Полк партия оешмасы сәркатибе, дивизия газетасы мөхәррире, полк командирының сәяси эшләр буенча урынбасары буларак, Бөгелмәдән Австриягә хәтле данлы сугышчан юл үтә ул. Әмма Җиңү көнен күрергә өлгерми кала — 1945 елның 23 апрелендә Совет Армиясе подполковнигы, танылган шагыйрь Нур Баян 40 яшендә һәлак була...

Формасы ягыннан һ. Такташ шигъри традицияләре йогынтысында үсеп, үз заманының тормыш сулышын, кискен социаль вакыйгаларын, бигрәк тә, күмәкләшү хәрәкәте чорында татар авылындагы иҗтимагый үзгәрешләрне, яңа тормыш өчен көрәш мотивларын романтик рух, публицистик пафос белән сурәтләгән Нур Баян иҗаты утызынчы-кырыгынчы еллар татар шигъриятенең үзенчәлекле, кабатланмас бер өлешен тәшкил итә...

Шагыйрьне биргән Әнәк авылы — бәхетле, бай тарихлы авыл. Бирөдән аның шигырьләрен дә тыңлап-өйрәнеп үскән Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев, язучы Рәхмәтулла Хисмәтуллин чыккан.

Нур Баянның исеме, кылган изге эшләре, батырлыгы хәзер дә күңелләрдә. Аның исемен республикабызда колхоз һәм урамнар йөртә.

**Шаһинур ӘХМӘТСАФА**

# Әхмәт Исхакның тууына 90 ел

Шагыйрь Әхмәт Исхак — 1905 елның 1 маенда туган. Бишенче елгылар... Әдәбиятка, шигырьгә, ничектер, бергәләп киләләр, үзенчәлекле бер буын әдипләр, шагыйрьләр булып яшиләр... Әхмәт ага Исхаклар буыны да шундый язмышлы: башкалардан аерылып торган холык-характерлы, максатчан, үҗәт һәм, шиксез, талантлы буын. Әйе, бу буынга — Ватан сугышында һәлак булган шагыйрь Нур Баян да, сугышлардан соң да иҗат иткән, 1976 елда вафат булган прозаик Абдулла Әхмәт тә, шулай ук зур гомер, иҗат юлы үтеп, 1980 елда вафат «орденлы шагыйрь», көрәшчән, ярсу җанлы әдип Шәйхи Маннур да, һәм менә әле шушы көннәрдә генә, 90 яшькә якынлашканда арабыздан киткән шагыйрь Салих Баттал да керә. Әйе, араларында иң озын, әмма катлаулы, гыйбрәтле язмышлысы — Салих ага булды һәм ул иң авыр чорларда да зур шагыйрь, халык, туган тел язмышы өчен куркусыз көрәшүче булып калды. Болар — бар да безнең күз алдында иде: шөкер, без аларның әдәби эшләрен дә, яшәү, кешелек рәвешләрен дә күреп, аралашып яшәдек. Үзләрен «Гулливерлар» дип атаган бу олпат буын безне бик еш сагындырыр, уйландырыр әле, мөгаен... Әхмәт ага Исхакны да — әнә шул буынның үзенчәлекле, хәтта колоритлы бер вәкиле, кызыклы шәхес дип әйтә алабыз. Ул — Казанда, конторщик гаиләсендә туган. Шәһәрдә туган шагыйрь... Бүгенге көн өчен бу гаҗәбрәк тә: барыбыз да диярлек — авылдан чыккан бит...

Әмма чордашлары, яшьтәшләре кебек үк, Әхмәт ага да, Октябрь фетнәсенә кадәрге «университет» — мәдрәсәдә белем, дин-иман тәрбиясе алган, борынгы төрки-татар һәм шәһәр милли культурасын өйрәнгән, үзләштергән шагыйрь. Ул — атаклы «Мөхәммәдия», олуг Г. Баруди кебек остазлар шәкерте. Ул сабый чагында Тукайны да күреп калу бәхетенә ирешкән һәм гомере буе рухта аңа тугры калган, мең еллык мәдәни байлыгыбызны, туган шигъриятебезне тирәнтен өйрәнгән шәхес. Революция булмаса, кем булыр иде икән ул? Әлбәттә, бер зыялы хәлфә, йә мөхәррир, мәгърифәт кешесе булып милләтенә хезмәт итәр дип ышанып әйтеп була... Әмма...

1917 елдан соң ул да — «яңа тормыш», «ирекле социализм иле» кешесе. Шул юлда армый-талмый хезмәт итүче. Татар педагогия (Казан) һәм кино (Мәскәү) техникумнарында уку, «Эшче» газетасында эшләү, М. Җәлил белән дуслык... Иң беренче шигыре — «Кызыл кошлар» исемле. Ул «Кызыл Шәрекъ яшьләре» журналында 1923 елда басыла. Г. Кутуй шунда ук: «Аллага шөкер, бездән дә бер декадент чыкты!» дип язып, котлап чыга. 1929 елда исә беренче китабы басыла — «Таш урамнар җыры». Такташча «яңа» сурәт, яңа темалар... Элекке татар милли рухы арткы планга күчә, чигенә. Әхмәт ага — «Кызыл Татарстан» (бүгенге «Ватаным Татарстан») газетасында озак еллар эшли: гади хезмәткәр, аннары газетаны чыгаручы редактор, бүлек мөдире, җаваплы секретарь һ. б. 1939—42 елларда ул — СССР Литфондының Татарстандагы вәкиле.

1942 елда Совет Армиясенә чакырыла ул һәм пехота училищесын тәмамлагач, Ерак Көнчыгышта, Украинадагы частьларда хезмәт итә (1945 елның декабренә кадәр). Аннары тулаем иҗат эше белән шөгыльләнә. 1963—67 елларда «Чаян» журналында баш редактор булып эшләгәннән соң, тагын язучылык хезмәте... Әдип 1991 елның 24 июнендә Казанда вафат булды.

Шагыйрьнең иҗат мирасы зур: күпсанлы шигырь, поэмалар, балалар өчен әкиятләр, публицистика, Г. Тукай һәм М. Җәлилләрнең шигъри осталыгына багышланган әдәби-гыйльми китаплар, либреттолар һәм сатира-юмор әсәрләре. Аеруча калку булып күз алдына басканы — шигъри форма ягыннан да кызыклы мәсәлләре, «Мактанчык әтәч» һәм башкалар... Берничә тапкыр «Сайланма әсәрләр»е басылу (соңгысы 1975 елда дөнья күрә), хезмәт Кызыл Байрагы (1955), «Халыклар дуслыгы» (1970) орденнары һәм медальләре белән бүләкләнү... Күп җәмәгать эшләрендә катнашу, яшьләр белән эшләү, шагыйрьләр секциясен җитәкләү... Әмма, минем карашка, әдипне еш искә төшергән, аның зур эрудициясен, белемен, омтылышларын чагылдырган бер өлкә бар: ул — тәрҗемә. Әхмәт ага Исхак дистәләрчә мең юл шигырь тәрҗемә иткән! Пушкинны, Лермонтовны, Некрасовны һ. б. Күңелгә якыны, әлбәттә, Көнчыгыш халыкларыннан һәм бөек төрки шагыйрьләреннән тәрҗемәләр. Мәсәлән, Нәваинең «Фәрһат һәм Ширин» поэмасы, Нәсими, Абай, Мәхтүмколый шигырьләре, газәлләр, робагыйлар...

1985 елларда бу тәрҗемәләренең яхшы сайланмасы «Илһамнар чишмәсе» исемендә калын бер китап булып басылды. Шигърият сөючеләргә матур бер бүләк булды ул китап, бу — бәхәссез.

Борынгы татар шигъриятен өйрәнү, җөмләдән, Кол Галинең мәгълүм «Кыйссаи Йосыф» әсәрен бүгенге әдәби телгә тәрҗемә итүе дә онытылмаслык күркәм эшләрдәндер. Кыскасы, Әхмәт ага Исхакның яшьләргә «илһам чишмәсе» булырлык күп, матур мирас ядкарьләре бар һәм без аларга игътибарсыз һәм ихтирамсыз кала алмыйбыз.

«Бишенче елгылар»ның күренекле бер вәкиле булган Әхмәт ага Исхакны бүген җылы сүз белән яд итик. Әйе, Тукайча әйткәндә: «Шадыман бул мәркадеңдә, без онытмыйбыз сине!..»

**Рәдиф ГАТАШ.**

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕ

26—27 апрель көннәрендә Казанда ТР Дәүләт Советының икенче пленар сессиясе булды.

Анда Дәүләт Советындагы 7 даими комиссиясенең персональ составы каралды, рәисләре сайланды. Шулай ук республика парламентында даими эшләүче халык депутатларының 37 кешелек составы да сайланды.

Сессиядә 1995 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы, Дәүләт Советы регламенты проекты, Чечен Республикасындагы хәлләр турындагы һәм республикабыз тормышына кагылышлы тагын бик күп мәсьәләләр каралды.

Утырышларны ТР Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев алып барды.

Сессия эшендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев катнашты.

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ГЕРМАНИЯДӘ ҺӘМ ДАНИЯДӘ

Татарстан Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге делегация апрель башында Германиядә булды. Казан белән тугандашлык урнаштырган Брауншвейг шәһәрендә узган тантанада ике тугандаш шәһәрнең мэрлары А. Ленц әфәнде һәм К. Исхаков тәбрик сүзе әйттеләр, алты ел буе дәвам иткән дуслык элемтәләренең үзара хезмәттәшлеккә нигезләнгән булуын ассызыклап, киләчәктә дә аны үстерү өчен...

2 апрельдә делегация Ганновер шәһәр ярминкәсен рәсми ачып җибәрүдә катнашты. Биредә дөньяның 71 иленнән 700 дән артык экспонат куелган иде. Ярминкәне ачу тантанасында Индонезия президенты Сухарто һәм Германиянең федераль канцлеры Г. Коль катнашты. Соңыннан М. Шәймиев Г. Коль әфәнде һәм ярминкә җитәкчелеге белән очрашты. Татарстан делегациясе шулай ук Ганновер шәһәре ратушасында булды.

Германиянең гомуммәгълүмат чаралары Татарстан Республикасының бу визитына зур кызыксыну белдерделәр. М. Шәймиев Германиянең төп информация чараларына берничә интервью бирде.

* * *

Татарстан делегациясенең Европага визиты Даниядә дәвам итте. Шул көннәрдә Президент Шәймиев корольлекнең тышкы эшләр министры Н. Петерсен әфәнде белән очрашты.

М. Шәймиев Татарстан дәүләтчелегенең тергезелүе, аның мөстәкыйльлеккә катлаулы юлы, Россия Федерациясе белән үзара мөнәсәбәтләре, республикабызның дөньядагы бик күп илләр белән үзара файдалы сәүдә-икътисади элемтәләр урнаштырырга мөмкинлекләре хакында әйтте. Н. Петерсен әфәнде белдергәнчә, Россия һәм Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләр тәҗрибәсе башка илләрдә дә кулланыла ала.

Очрашулар вакытында агропромышленность, уртак предприятиеләр булдыру, аларга инвестиция мәсьәләләре дә тикшерелде. Татарстан делегациясе шулай ук «Ниро» фирмасында булды. Анда республикабыздагы кайбер сөт һәм шикәр заводларына реконструкция ясау проектлары тикшерелде.

## МӘСКӘҮ ТАТАРСТАН КӨННӘРЕНӘ ӘЗЕРЛӘНӘ

Русия башкаласында 30 майдан 4 июньгә кадәр үтәчәк ТР Мәдәнияты көннәренә әзерлек мәсьәләсен бу юлы Мәскәүдә РФның беренче вице-премьеры Ю. Яров рәислегендәге оештыру комитеты тикшерде. Аннан аңлашылганча, Татарстан көннәренә бик ныклап әзерләнәләр. Кунакларны кабул итү (аларның саны 800 гә якын булыр дип көтелә), урнаштыру, аларга хезмәт күрсәтү, сәнгать коллективларының кайларда чыгыш ясаячаклыгы һәм башка күп кенә мәсьәләләр инде, нигездә, хәл ителгән.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

25 апрельдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев җитәкчелегендәге бер төркем әдипләр Арчада, Тукай-Кырлай авылында булып, чыгышлар ясап, әдәбият сөючеләр белән очраштылар.

26 апрельдә иртән Тукайның татар зиратындагы каберенә чәчәкләр салынды. Ә көндезен М. Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы шагыйрь һәйкәле алдында шигъри бәйге башланып китте. Бәйгене алып баручы шагыйрь З. Мансуров Президент М. Шәймиевнең 1995 ел өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге премиясен язучы Фәнис Яруллинга бирелүе хакындагы Указ белән таныштырды, яңа лауреатка сүз бирде.

Тантанага җыелган халык алдында шагыйрьләребездән Р. Фәйзуллин, Р. Вәлиев, Ш. Галиев, Л. Шагыйрьҗан, Р. Гаташ, Ш. Маннап, Зөлфәт, М. Әгъләмов һ. б. чыгыш ясады.

* * *

Тукай көненә багышланган шигырь бәйрәмнәре Әлмәт, Чаллы, Балтач һәм тагын күп кенә төбәкләрдә дә үткәрелде.

## ОКОП ЕЛЬЯЗМАСЫ

Татар әдипләре Бөек Ватан сугышы елларында каләм белән дә, штык белән дә фашизмга каршы көрәштә актив катнаштылар. 17 апрельдә Казанның Г. Тукай музеенда Җиңүнең 50 еллыгына багышлап ачылган күргәзмә дә әнә шул хакта бик ачык сөйли.

Бу күргәзмә — фронтовик әдипләребезнең дәһшәтле сугыш кырларында, окопларда язылган китаплары һәм шулай ук сугыш чоры плакатлары хакында. М. Җәлил, А. Алиш, Ш. Мөдәррис, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, С. Хәким, Х. Мөҗәй һәм башка күп кенә татар язучыларының китаплары, хатлары инде күптән фронт әдәбиятының алтын фондын тәшкил итә. Әле тагын сугыш елларында күпме әдипләрнең төрле фронтларда чыгып килгән 16 татар газетасында эшләүләрен дә искә алсак, окоп ельязмасының колачы тагын да киңәя төшәчәк.

## ҖӘЛИЛГӘ ҺӘЙКӘЛ ӨЧЕН

1996 елның 15 февралендә Муса Җәлилнең тууына 90 ел тула. Шагыйрь буларак, аның Ватанга бирелгәнлек рухы һәм батырлыгы Оренбург җирендә формалашкан. Шуңа да Оренбург шәһәре хакимияте, «Туган тел» татар мәдәнияген яңарту өлкә иҗтимагый үзәге, сәнгать әһелләре һәм иҗади интеллигенция, шәһәр җәмәгатьчелеге Җәлил истәлеген мәңгеләштерү һәм аның юбилей көненә кадәр Оренбург шәһәрендә һәйкәл кору турында карар кабул иттеләр. Каһарман шагыйрьгә һәйкәл салу татар халкынның лаеклы өлеш һәм ядкарь булыр иде.

Бу эштә чыгымнарның күп өлешен шагыйрьнең якташлары үз өсләренә ала.

Һәйкәл коруга матди ярдәм итәргә теләгән ватандашлар һәм оешмалар акчаны «Туган тел» татар мәдәнияген яңарту Оренбург өлкә үзәгенә җибәрә алалар.

Адресы түбәндәгечә: р/с 000700304 МФО 284019 в Ленинском филиале ОрИндБанка г. Оренбурга, к/с № 800161113 с пометкой «ПАМЯТНИК ДЖАЛИЛЮ». Валютный счет 020070001. МФО 284019. К/с 800161113 в Ленинском филиале ОрИндБанка.

## ПЕН-ҮЗӘК ОЕШТЫ

19 апрельдә Татарстан Республикасының милли китапханәсендә Татар ПЕН-үзәген оештыру җыелышы булды.

1921 елда язучы Голсуорси оештырган халыкара язучылар оешмасының төп үзәге — ПЕН-клубы Лондонда урнашкан. Төрле илләрдәге язучыларны сәяси һәм матди яктан яклауны максат итеп куйган бу клуб ЮНЕСКО канаты астында эшләп килә. Узган ел бу клубка Рәсәй язучылары әгъза булып кергән иде. Быелның апрелендә исә Кыргызстан һәм Казахстан язучылары әгъза булып керде. Татар ПЕН-үзәге президенты итеп язучы һәм драматург Туфан Миңнуллин сайланды. Могтәбәр рәис итеп Миргазиян Юныс, вице-президентлар итеп Рәшит Вәлиев, Рафаэль Хәкимов, җаваплы сәркатип итеп Әхәт Мушинский сайландылар. Оештыру җыелышында шулай ук ПЕН-үзәкнең башкарма комитеты да сайлап куелды.

Җыелышта Татарстан Республикасы президенты М. Шәймиевнең яңа оешкан Татарстан әдипләренең ПЕН-үзәгенә юллаган телеграммасы укылды. Анда болай диелгән: «Республикабызда ЮНЕСКО канаты астындагы Бөтендөнья язучылар оешмасының состав өлеше сыйфатында ПЕН-үзәк оешу белән тәбриклим.

Үзәк Татарстанда иҗади процессны активлаштырыр һәм татар халкының мең еллык мәдәниятен дөньяга чыгаруда мөмкинлек тудырыр, дөнья халыкларының рухи хәзинәсен тагын да баетуга хезмәт итәр, дип өметләнәм. Сезнең белән хезмәттәшлеккә әзер торам.»

## ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ — ТӨРКИЯДӘ

Апрель аенда Төркиядә халыкара төрки яшьләр берлеге киңәшмәсе булып узды. Бу абруйлы киңәшмәдә Татарстаннан «Азатлык» яшьләр оешмасы җитәкчелегендәге делегация катнашты. Аларны Төркия җөмһүрияте парламенты рәисе Хисаметдин Җиндоруд кабул итте. Республикабыз вәкилләре программада булган чыгыш-кичәләрдә актив катнаштылар, шулай ук, Й. Акчура һәм Г. Исхакый каберләрен дә зыярәт кылдылар.

## ФОЛЬКЛОР ГАЛИМЕНӘ ХӨРМӘТ

Апрель аенда күренекле галим — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илбарис Надировка 70 яшь тулды. Шушы уңайдан 25 апрельдә Татарстан фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының киңәйтелгән гыйльми советы утырышы булып узды. Юбилярны фәнни оешма, иҗат берлекләре вәкилләре һәм хезмәттәшләре котладылар, галимгә иҗади уңышлар теләделәр.

## ТАТАР ҖЫРЫ-95

Апрель аенда традицион «Татар җыры» конкурсы тәмамланды. Бер атнага якын дәвам иткән әлеге бәйгедә 200 дән артык җырчы көч сынашты. Конкурс 22 апрельдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында җиңүчеләр һәм үткән еллардагы конкурсларның лауреатлары катнашында гала-концерт белән тәмамланды. «Татар җыры-95» халыкара конкурсында җиңеп чыктылар: I урында — профессиональ башкаручылар арасында — Резида Галимова (Түбән Кама), Җәлил Әбделманов (Уфа), үзешчән башкаручылардан — Хәйдәр Гыйльфанов (Екатеринбург) белән Зөлфия Алимбәкова (Уфа), ә II һәм III премия лауреатлары арасында җиңүчеләр булып Закир Шаһбанов (Казан), Фәния Халикова (Әлмәт), Резидә Афзалова (Бөгелмә), Зөһрә Смакова (Уфа), Фердинанд Фәттрахманов (Казан) һ. б. танылды.

# «ХАННЫҢ ХАЛЫККА АНТЫ»

Ыругдаш төрки кавемнәр тормышы сурәтләнгән бу киндернең уртасында тантаналы гүзәл ырым: бизәкле киез келәм өстендә акбүзат, аның өстендә чандыр гәүдәле, зариф сынлы, тәхеткә утырасы яшь хан. Ханның муенына аркан салынган, аның ике очын кабиләнең ышанычлы вәкилләре тотып тора. Булачак хөкемдар бөтен халык алдында — киләчәктә инсафлы илбашы булырга, үз халкының мәнфәгатен кайгыртып яшәргә, ил белән акыллы вә гадел идарә итәргә, миһербанлы-шәфкатьле булырга сүз биреп, шушы кайнап торган мәйдан уртасында аксакаллар, гаскәриләр, ир, хатын-кыз, яшь җилкенчәк алдында ант эчәргә тиеш...

Әгәр бу сүзләре хак булмаса, ул үзенең ил алдында биргән антын акламаса, начарлык-залимлек кылса,— яшь ханны борын-борыннан килгән, халык үзе тудырган гадел йола көтә: аны бүген зурлаган һәм өстенә җаваплы вазифа йөкләгән халык-ыругдашлары, шушы аркан белән ат өстеннән өстерәп төшергән кебек, тәхеттән төшерәчәкләр...

Бу кинаяле әсәрнең авторы — рәссам Канәфи Нәфыйков — гаҗәп тирән эчтәлекле, гыйбрәтле, шәрекъ сәнгате нигезләренә таянган, сынлы-рәсемле гүзәл кыйссариваять тудырган. Төрки-күчмә тормыш җиһазларын — җемелдәп торган ефәк ак чатырларны, эре-алсу җимешле алмагачларны, гөлле-чәчәкле тау-калкулыклар астындагы кеше тулы якты үзәнне, күчмә халыкларның кием-салымын биргәндә рәссам миниатюра сәнгатенә хас күптөслелекне һәм һәр төснең символик эчтәлеген файдалануны алга сөрә... Моңа ышану өчен дәүләт бөеклеген, халыкның мәдәни-сәнгать дәрәҗәсен, аның акыл-тәҗрибәсен, канун белән эш иткәнен аклау өчен үзәктәге манзара, кызыл-сары, алтын төсендәге киемнәр кигән яшь хан сурәте вә аңа зур өметләр баглаган һәм аны бу югарылыкка күтәргән «якты образлар» системасын барлау һәм, моңа капма-каршы буларак, кара киемнәр кигән, композиция эченә берән-сәрән сибелгән «скептикларның» шөбһәле йөзенә игътибар бирү дә җитә.

Бу әсәрнең остасы — нәкышьче, театр рәссамы Канәфи Афзалетдин улы Нәфыйков безнең сәнгатебездә тарихчы сәнгатькяр буларак аерым урын алып тора. Әле 1970 елларда, рәссамнәребез тукымаларында тарихи тема бик зәгыйфь хәлдә, бары тик совет чоры сәхифәләре формасында сурәтләнеп килгән чорда, Канәфи Болгар, Казан тарихы төпләренә төшеп, безгә кыйммәтле сәнгать хикмәтләрен алып чыкты; безнең тарихыбызны да зур вә эшлекле, мәдәни, каршылыклы һәм мәгънәле бер тәрәккыять мәрҗәне — цивилизация үзәге итеп сурәтләде.

Очсызлы сәясәткә сатылмыйча, дөресрәге, сәяси уеннан качып, тарих фәне һәм археология казанышларына нигезләнгән сәнгати эзләнүләре, ниһаять, Канәфи Нәфыйковны олы юлга алып чыкты. Йөздән артык әсәрне берләштергән «Канәфи Нәфыйковның тарихи әсәрләре» дигән мөстәкыйль-тематик күргәзмә моның ачык мисалы. «Ханның халыкка анты», «А. Невскийның Батый төрбәсенә килүе», «Болгар мунчасы», «Чуен кою», «Бачман», «Борынгы Казанда сабантуй», «Чичәннәр ярышы», «Сөембикәнең саубуллашуы», «Батырша» кебек күп фигуралы полотналары, «Алтынчәч» операсына, «Шүрәле» балетына ясаган эскизлары аша ул татар халкының тарихи һәм рухи үсешенең өзлексез һәм туктатып булмаслык күренеш идеясен чагылдырды. Ә композицион яктан камил, нечкә зәвыклы «Йосыф китабын уку», «Казан. Мәчет», «Триптих. Китап», «Мөхәммәдъяр» кебек әсәрләрендә, Акмулла, Утыз Имәни, Мәрҗани һ. б. мәгърифәтче язучыларның портретларында рәссам халыкның әхлакый сафлыгын һәм аның китапка булган чиксез мәхәббәтен гәүдәләндерде.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Канәфи Нәфыйковның «Ханның халыкка анты» дигән картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** фронтовик язучы Сафа Сабиров.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» — ЯКТЫРАК ЯНСЫН!

**Мөхтәрәм милләттәшләр!**

**Көн артыннан көн үтеп кенә тора. Әле кайчан гына без Сезгә «Казан утлары»на язылырга өндәп мөрәҗәгать иткән идек, хәзер исә 1995 елның икенче яртысы (июль, август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь айлары) өчен язылу бара.**

**Әйтергә кирәк, журналыбызга язылу бәһасе, башка басмалар белән чагыштырганда һәм, гомумән, базар мөнәсәбәте шартларында көнкүреш товарларының аеруча кыйммәт булуын да искә алсак, шактый арзан. Әйтик, элемтә бүлекчәләрендә әбунә тартмалары (абонаящиклары) булганнар өчен «Казан утлары»на язылу 11.316 сум, журналны турыдан-туры почтальоннар китергәндә исә 12.186 сумга төшә.**

**Кыскасы, Сезгә ничек уңайлырак, шул вариантны сайлагыз, кадерле дуслар!**

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов: 1

на 1995 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

---

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов | 1 |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1995 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

## ИҢ ЯХШЫ БҮЛӘК!..

«Казан утлары» — бәхетле язмышлы журнал.

Менә 70 елдан артык инде ул татар мәдәниятенең сүнмәс учагы — иң абруйлы айлык әдәби-нәфис һәм иҗтимагый сәяси журналы булып килә. Аның дуслары бихисап: чөнки «Казан утлары» әдәбият-сәнгатьне сөюче, милләтпәрвәр укучыларын беркайчан да алдамады, аларның өмет-ышанычларын һәрдаим аклап килде. (Җәяләр эчендә генә әйтеп китик, сугыш елларында хәтта Мәскәүдә чыга торган үзәк рус журналлары ябылып торган дәвердә дә «Казан утлары»ның даими чыгып килүе шушы үзара дуслыкның какшамас булуына ачык дәлил булып тора.) Ышанып әйтергә мөмкин, мәдәни учакка табынучы әдәбият сөюче дусларыбыз «Казан утлары»н бүген дә ярты юлда калдырып китмәсләр.

Индексыбыз — 73210.

Язылыгыз димибез, соңга кала күрмәгез, дибез.

«Казан утлары» журналы редакциясе.


## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ — МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Обл. тип., г. Кострома

# ЯҢА КИТАПЛАР

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН. **Казан ханнары.** Гыйльми хезмәткәр тупланмасы. Казан. Татар. кит. нәшр. 1995. 191 б. Тиражы — 10 000 данә.




Китапка үзенең йөзләгән хезмәтләре белән татар тарихы һәм мәдәниятендә тирән эз калдырган мәшһүр галим, дин әһеле, мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдиннең (1859—1936) Казан ханнары һәм аларның эшчәнлеге турындагы мәкаләләр тезмәсе тупланган. Укучыларга тулырак мәгълүмат бирү өчен төп текст төрле искәрмә-аңлатмалар, галимнең иҗатын яктырткан зур кереш мәкалә һәм ханлык башкаласы Казанның тарихи топографиясе турындагы язма белән баетылган.

Китапның төзүчесе, текстны бүгенге шрифтка күчереп-эшкәртүчесе, искәрмә-аңлатмалар һәм кереш мәкаләнең авторы — күренекле галим Равил Әмирхан.


Халкыбыз тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучылар бу китаптан, һичшиксез, бай мәгълүмат алачаклар.

ЯКУБ ЗӘНКИЕВ. **Иртеш таңнары.** Роман. Казан. Татар. кит. нәшр. 1994. 673 б. Тиражы — 16 000 данә.




Дөньяның төрле якларына чәчелгән татар халкы тарихы әлегә юньләп өйрәнелмәгән һәм әдәбиятта тиешенчә яктыртылмаган. Якуб Зәнкиевнең бу романында Себер татарларының тарихы гыйбрәтле язмышлар аша мавыктыргыч бәян ителә. Шунысын да искә төшерәбез: романның кыскартылган варианты үткән ел «Казан утлары» журналында дөнья күргән иде. Китапның ахырында авторның үзе турында да тулы мәгълүмат бирелгән. Китап «Мекаминефть» оешмасының матди ярдәме белән чыгарылган.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал [illegible]